# казан утлары

9
СЕНТЯБРЬ - 1973

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

9

СЕНТЯБРЬ
1973

## Бу санда

Ш. МАННУР Агымсуларга карап. Повесть . . 3
М. КӘРИМ. Көзге шигырьләр . . . . . . . . 71
Х. ТУФАН. Минутларның бөек чагы . . . . . . 80
А. ӘХМӘТ. Юксыну. Пьеса . . . . . . . . . 85
Р. ГАТАУЛЛИН. Лирик шигырьләр . . . . . . . . 98
Ш. МАННАПОВ. Сагындыра. Шигырьләр . . . 102

ОЧЕРКЛАР

КамАЗ елъязмасы . . . . . . . . . . . . . . 103
Р. БИКТАҺИРОВ. «Кубик»лар турында баллада . 107
Ф. НАСЫЙРОВ. Әйдәп баручы . . . . . . . . 117

СӘНГАТЬ

Й. ВӘЛИТОВА. Театрыбызның таң йолдызы . . 124

ИСТӘЛЕКЛӘР

Г. КАШШАФ. Революция солдаты . . . . . . . 130

Е. И. ПУГАЧЕВ ВОССТАНИЕСЕНЕҢ 200 ЕЛЛЫГЫНА

С. АЛИШЕВ, М. ГОСМАНОВ. Бөек крестьяннар сугышына 200 ел . . . . . . . . . . . . . 134
Документлар . . . . . . . . . . . . . . . 144

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Ф. МИҢНУЛЛИН. Прозаның гражданлык йөзе . 161

КИТАП КҮЗӘТҮ

М. РӘФЫЙКОВ. Шигърият үрләре . . . . . . . 180
М. МӨЛЕКОВ. Революция тарихына яңа сәхифә 183
Ә. БУЛАТОВ. Мишәрләр турында яңа хезмәт . . 184

Безнең календарь . . . . . . . . . . . . . 186

БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

Җ. Дәрзаманов. Яңа чана яңа шул . . . . . . . 187

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . . 189

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*
Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар. Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.

**Баш редактор: Гариф Ахунов.**

**Редколлегия: Хәй Вахит, Шәукәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова (җаваплы секретарь), Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина.*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева.*

Производствога бирелде 5/VI-1973 ел. Басарга кул куелды 31/VII-1973 ел. ПФ 07107.
Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 83246 экз.
Заказ Я-287. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советының нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре идарәсенең К. Якуб исемендәге матбугат комбинаты. Казан, Бауман урамы, 19. 1973 ел.

Шәйхи Маннур

# АГЫМСУЛАРГА КАРАП

Повесть

## Яфрак-яфрак кар ява иде

Озакламый Өскебашы дигән ерак авылдагы Майтүтәй килеп төште. Ул әнәйнең бертуган тутасы — хәл белергә килгән. Олы бер калач белән бер калай савыт бал, бер капламыш ак май алып килгән. Бу күчтәнәчләр белән чәй эчкәндә мин аларның тәмен бик тиз сизеп алдым. Табын җыелгач, бал белән майны өйалдына чыгардылар, калачны ашъяулыкка төреп киштәгә куйдылар. Әнәй белән Майтүтәй сөйләшеп утыра башлады, ә минем күзләр гел киштәдә...

— Пәрхулла кияүнең дә болай чыгып китүе бик үк әйбәт булмаган икән ләбаса,— диде кунак.

— Аның гаебе юк,— ди әнәй хәлсез генә сулап.— Үзем чыгардым, теш арана кыстырырга булмагач, нишлисең? Кыш уртасына да җитмәс дип уйлаштык... Өйалдында бер капчык арыш бар. Шунын белән кыш чыгасы... Чүмәлә хәтле солы кибәне. Чәчүгә җитәрме, белмим...

— Хәлең бик мөшкелләнеп киткән бит, шуңар әйтүем.

— Болайга ук әйләнер дип кем белгән соң...

— Уйлашырга кирәк: әллә кияүне чакыртып кайтарырга микән?..

— И тутәй,— диде әнәй.— Алар бит «Ерак күмергә» үк киттеләр. Ике-өч ай да тулмаган, кайтырлык акчасы да юктыр әле. Юллыгына да кияү тунын унбиш тәңкәгә заклат салды. Ул бурычын да җибәрә алганы юк. Кайта алыр микән шул, белмим...

Майтүтәй бездә озак торды. Әнәйне терелтер өчен әмбер тамыры, татлы тамыр, тәмле сабыр дигән дарулар да, гөмбә суы белән керән суы да эчереп карады. Әнәй мантымады. Һаман ябыга, саргая барды, ютәле өзлексезгә әйләнеп китте. Тора-бара ул бөтенләй хәлсезләнде...

Ә бер төнне таң алдыннан безне йокыдан уяттылар. Без өч бала өчебез дә байтактан бирле кече якта йоклый идек инде.

Дәвамы. Башы 8 санда.

— Торыгыз, балалар, тор...

Күзләрне ачып, урыннан баш калкытсак — өй эче тулы кеше: күрше җиңгиләр, әбиләр, әнәйнең килендәшләре...

— Әниегез вафат... — диде Гыйльмевафа әби кайгылы тавыш белән.

Түтәй сикереп торды да сандык өстенә ташланды, аның аша әнәй янына төште, битен ачып карады. Бик ябык, ап-ак чырайлы әнәй бер кыймылдаусыз ята иде.

— Әнәй, әнәй, әнәй! — диде ул ашыга-ашыга кабатлап.— Әнәй!..

Әнәй эндәшмәде. Түтәй аны йокыдан уятырга теләгәндәй селкетеп тә карады, ул уянмады. Шуннан соң түтәй аннан кире тайпылды да, сандык өстенә капланып, тәгәри-тәгәри елый башлады:

— Әнәй үлгән, әнәй үлгән!..

Мин бернәрсә дә аңламадым. «Вафат», «үлгән» дигән сүзләрнең чын мәгънәсен белми идем әле мин. Белмәсәм дә, түтәй кыланганны кыланырга тырыштым: сандык өстендә мин сыярлык урын калмаган иде, шуңар күрә идәнгә ятып, тәгәри-тәгәри еларга тотындым, тик күзләремнән яшь кенә чыкмады. Кешедән күрмәкче генә чынлап торып елап буламы соң?..

Безне юатып, бит-күзне юдылар да нәрсәдер тамакка бирделәр. Аннары күрше Ләүхия җиңги Шамилне төреп күтәрде дә мине житәкләп үзләренә алып чыгып китте. Түтәй өйдә калды. Ул бит олы кыз, кирәге булыр... Ә мин калырга курыктым. Җиңги безне Гыйльметтин белән калдырып, янадан кереп китте.

Күпмедер вакыттан соң тышка яктылык инде. Ләүхия җиңгиләрнең ян тәрәзәсеннән безнең ишегалды күренә башлады, пыялалары бер катлы гына булса да туңмаган, ике арадагы койма да биек түгел. Безнең баскыч төбендә кеше кайный, лапас белән абзар тирәсендә жигүле ике ат күзгә чалына. Хәзер күп кенә ир кешеләр капка алдына да җыела башлады. Безнең җил капканы ни өчендер киереп ачып куйдылар. Көн җылыдыр, ахры, җил дә юк бугай: салмак кына уйнаклап, яфрак-яфрак кар төшә...

Камалы яшел тун кигән, чалма чалган, кулына йомры башлы таяк тоткан хәзрәт тә безнең ишегалдына узды. Аның артыннан, озак та тормыйча, бер абзый мәчеттән җеназа кабыгы күтәреп килде. Аның агачларын ишегалды уртасына салдылар да кабыгын өйгә алып керделәр. Миңа ачык өйалды ишегеннән күп кенә кешеләр күренде: алар әнәйне кабык белән күтәреп чыгып, иплән кенә теге агачлар өстенә куйдылар. Безнең кызыллы-каралы бик матур палас бар иде, әтәй аны кытай жиреннән алып кайткан. Хатын-кызлар шуны чыгарып әнәй өстенә капладылар. Аннары әнәйнең туганнары Дәүабай белән Тәтәбай, әтәй туганнары Мөбаракша абый белән Җыянша абый, күршеләрдән Мактый бабай белән Әхсән абзый һәм тагын күп кенә кешеләр, әнәйне җилкәләренә күтәреп, капкадан алып чыга башладылар... Безнең турга бик күп кеше җыелды. Яше-карты, бала-чагасы: бар да шунда. Әнәйне юып, кәфенләп һәм башка хәстәрен күреп озатышкан хатын-кызлар да, капка төбенә чыгып, бер кырыйгарак бастылар. Шул ук мәшәкатьләрнең уртасында йөргән Ләүхия җиңги, инде бушанып булса кирәк, ишектән килеп керде. Без аңа борылдык.

— Әнә, әниегез китә инде, ыланнар, карап калыгыз,— диде ул, үзе дә түргә узып.

Без түр тәрәзәгә капландык.

— Әннәү, әннәү...— диде ике яше дә тулмаган Шамил бик мескен тавыш белән.— Әннәү, әннәү! — дип елап ук җибәрде ул аннары.

— Җылама, ылан,— дип юатты Ләүхия җиңги аны,— ул сиңа келиндер алып кайтыр...

— Тәлтилтә?.. — дип куйды Шамил.

Кумүчеләр, капкадан чыккач, сулга борылдылар. Кешеләр җилкәсендәге кабыкта яткан әнәй, инде бер сүз дә эндәшмичә, без утырган җиңгиләр турыннан узып китте. Нидер эшләргә теләгәндәй тиз генә бишмәт белән итекне элдем дә урамга йөгердем. Капка төбендә үк Түтәй туры килде, ул елый-елый шешенеп беткән иде.

— Әйдә, әйдә,— диде ул, мине җитәкләп.

Җитәкләшкән көйгә без җеназа артыннан йөгердек. «Әнәй, әнәй, тукта!» дип кычкырасы килә. Ә кумүчеләр һаман ераклаша бара. Алар инде югары очка менеп, басу капкасын уздылар да җеназа укырга туктадылар. Без барып та җиткән булыр идек, артыбыздан Нәфисәттәй килеп җитте. Нишләп монда соң ул? Тәкәнешкә кияүгә киткән иде бит? Әнәйне озатырга килде микәнни?..

— Әйдә, Хөршитбану, әйдә, Шәйхелислам, кайтыйк, гөлкәйләрем,— дип, безне җитәкләп алды ул.— Кыш бит, суык, туңарсыз... Кайтыйк... Әйдәгез, чәй эчәрбез бергәләп...

Ул миңа әнәй шикелле тоелды. Барлык яратуым белән аның итәгенә сарылдым. Кире борылдык, артыбызга карый-карый кайта башладык. Ә көн бер дә суык түгел иде. Кыш урталары булса да, җилсез, жылымса, болытлы көн. Кояш күренми. Шуңар микән, бөтен урам нинчектер безнең төсле үк боек шикелле. Салмак кына уйнаклап төшкән яфрак кар да бик ямаслы булып күренә... Ә түтәйнең күз яшьләре һаман коела иде. Артына борыла да:

— Әнәй, әнием! — дип тагын үксергә тотына.

Нәфисәттәйләрнең сөтле-шикәрле тәмле чәе дә юатмады аны...

Шул ук көнне бугай, ахры, безгә дә туган өйдән кузгалырга туры килде. Әнәйне күмеп кайткач, Югары Тәкәнеш абыйлар безне чаналарына төйи башладылар. Мактый бабай белән Мөбарәшка абый да үз атларында озатышырга бардылар. Бер чанага сарыклар белән бәрәннәрне төяп, күз-колак булып бару өчен түтәйне дә шунда урнаштырдылар. Икенче чанага олы сандыкны, түшәк-ястык, мендәрләрне салып бәйләделәр. Өченче чанага Шамилне тотып, Туганым абыстай белән Тәтәбай утырды. Дүртенче чанада Мактый бабай белән мин. Безнең янга тагын бик күп вак-төяк әйберләр төялгән.

Көн кичкә авыша башлаган, эз генә караңгы да төшеп килә шикелле. Чаналар шыгырдап кузгалды. Ишегалды буш калды. Өй дә буш калды... Әнәй дә чыгып китте, без дә чыгып киттек. Туган авыл артыбызда калды... Ә кар һаман туктамый. Күнелгә моң тутырып, салмак кына уйнаклап, яфрак-яфрак кар ява иде...

## «Тәк, дерәгә...»

Шулай итеп, без хәзер башка авылда. Монда безне икегә бүлделәр. Түтәй белән Шамил Тәтәбайларда (аның чын исеме Мөхәммәтҗан икән) торырга тиеш булды. Мин Дәүабайларда (чын исеме Миңлекәй) тора башладым. Бу йортта Гаяз исемле тагын бер ятим малай бар иде, әнәйнең Сәмига атлы сеңелесе булган — шуның малае икән. Димәк, ике йортка икешәр ятим.

Монда без чит авылда, кеше кулында булсак та, начар яшәмәдек. Безне кагып-сугып җәберләүче, тамак аралаучы булмады. Өс-башыбыз да ертык-тишек килеш кергә катып йөрмәде. Дәүабайларның йорты да, безнеке шикелле, ике катлы — асты таш, өсте агач. Өске өйләре дә эшләнгән: ишек-тәрәзә, идән-түшәм дигәндәй, бар да әзер. Тик сәке җәймәгән дә морҗа чыгармаган, шуның өчен кышын анда тормыйлар. Хәер, анда Латифәттәй тора, Дәүабайның әле кияүгә бармаган олы кызы. Ул түбән өйгә тамак туйдырырга гына төшеп менә. Бүтән ва-

кытын шул өске өйдә чигү-тегү, бияләй бәйләүдә уздыра, вак-төяк йорт эшенә катнашмый. Чибәр абыстай белән аралашмый, сөйләшми. Моның сәбәбен мин байтактан соң гына белдем. Дәүабай үзенең беренче җәмәгате үлгәч, Шәмик авылыннан шушы Чибәр абыстайга өйләнгән. Латифәттәй аны яратмаган: әтисенең инде чәч-сакаллары агарса да, шундый яшь хатынга өйләнүе өченме, әллә үги ананың бүтән сөйкемсез сөяге булганмы — нилектәндер аларның борчаклары пешмәгән. Чибәр абыстай да «ат хәтле» үги кызны өнәми иде.

Ә Чибәр абыстайның үз хәсрәте, үз моңы бар иде. Аның яратып чыккан ире булган. Тик ниндидер сәбәпләр аркасында аерылышканнар. Шуннан байтак вакытлар узгач, бу «ирдән кайткан кыз»ны шушы картка кияүгә биргәннәр. Инде Дәүабайдан ике баласы булса да, ул һаман беренче ирен оныта алмый, аны сагына иде. Йорт эшеннән бушанып, Дәүабай өйдә булмаганда каба төбенә утырса:

— Тал әйләнер, тал әйләнер,
Талларга җефәк бәйләнер шул,
Талларга җефәк бәйләнер.
Йөз илле сумлык атлар җигеп
Минем җаныем кайчан урам әйләнер,
Кайчан гына урам әйләнер...—

дип, бик матур, бик моңлы тавыш белән, бик озын көйгә сузып җырларга тотына. Аны тыңлап утыруы рәхәт тә була, күзгә яшь тә китерә. Күңеле дә каты түгел аның. Гаяз да, мин дә, аның өчен бөтенләй чит бала булсак та, ул безгә төксе сүз әйтми, урынсыз рәнҗетми, ялган-юма тел белән иркәләми дә. Безгә шунысы бик җиткән. Кушкан йомышын карусыз тыңлыйбыз.

Дәүабай озын буйлы, ап-ак чәч-сакаллы, күкрәк тавышы белән олыларча тыныч кына сөйләшә торган кеше. Аның бу тавышын мин бик яраттым, ничектер үз булып, якын булып ишетелә иде ул миңа. Бәлки, шул олылык сыйфатлары күп булгангадыр, без еш кына бабай дип эндәшә торган идек аңа. Ул күп вакыт ишегалды эшләре белән көнен уздыра. Бердәнбер олы малае Әхтәмҗан абый читтә булганлыктан, урман кисү, утын ташу, салам-печән китерү, тегермән тарту шикелле авыр эшләр бар да аның өстендә. Латифәттәй белән Чибәр абыстай арасындагы «сөзеш»кә дә катнашмый ул. Тегеләрнең телләре бик үткенәеп, эш әләк-чәләккә барып җиткәндә дә, «әйдә, җүләрләнешмәгез», дип кул гына селкә иде.

Гаяз да минем өчен начар малай булып чыкмады. Дөрес, аның бераз дуамалрак гадәте бар икән: кырт сөйләшә, гел юкка да шаулап киткән була. Мине «маймуч» итеп кенә каравы да бик сизелә: вак балык, янәсе. Хәер, шулай булмый хәле дә юк, ул инде Коръән күтәреп мәдрәсәгә йөри, миннән өч яшьләр чамасы олырак икән. Ә олы малайлар гел шулай бит — бәләкәйләргә күктән генә карыйлар, бик юаш дигәне дә борыныңа чиертеп китә. Шулай да без Гаяз белән тату яшәдек, сугыш-талашлар истә калмаган.

Тәтәбайлар күршедә генә — ике туган янәшә утырганнар. Мин көн саен диярлек Хөршит түтәй белән Шамил янына кереп чыгам. Тәтәбайлар бер катлы искерәк агач йортта торалар. Аларның кызлары күп: Зәйнәп, Гайзәбану, Тайба, Гарифәбану, шуның өстенә түтәй, шуның өстенә Шамил, шуның өстенә бәкәйләр белән бозау — өй эче тулы. Ничек сыя торганнардыр алар? Түтәй бер дә зарланмый болай. Киресенчә, бу өйдә кызларның шулай күп булуы аның өчен рәхәтрәк тә икән. Аларның үз сүзләре, үз серләре, үз уеннары бар, шау-гөж килеп яталар кече якта. Шамил дә, сәке йөзлеге буйлап, бик «җәһәт» йөри башлаган хәзер. Аның дуслары — бәкәйләр, күбрәк шулар арасында мәш килә. Өй уртасына асылган җүкә дуаннан бер-ике бөртек печән суырып ала да бәкәйләрне ашатып маташкан була.

Шулай да безнең аерым яшәү ничектер араларны суыта башлаган шикелле тоела. Әнә Шамил хәзер мине бар дип тә белми. Түтәйнең дә кызлар белән уйнаудан башы күтәрелми. Элек без, җиңнәр җиңгә ябышкандай, гел бергә йөри идек...

Озакламый безгә аш чыга, ипи чыга башлады. Белмим, казнадан булгандырмы, әллә берәр төрле «Ярдәм җәмгыяте»ннәнме. Ул шушы авылның Дияр абзыйлар йортында пешә, без аны Гаяз белән икәүләп барып алабыз. Бер савытта аш, бер савытта бутка алып кайтабыз. Кайсы көнне олы бер бөтен ипи дә күтәрәбез. Анысы атнага бер тапкыр бирелә. Ашның ите, тәме була идеме, хәтерләмим, әмма буткасы бик истә калган. Ул бик кызыктыргыч сап-сары төстә һәм бик тәмледер сыман тоелган кукуруз буткасы иде. Борчагыннан түгел, көрпә сыман итеп ярдырылган ярмасыннан пешерелгән бутка. Безнең як кешесе күргән-ишеткән аш булмагач, каян килгән, кем китергән,— анысын да белми идек. Шул аш белән бутканы, көн саен бер тапкыр сәке түренә утырып, Гаяз белән икәүләп ашыйбыз. Баштарак бик кызыктырган сары бутка тора-бара бик тиз туйдырып җибәрде безне, соңыннан инде күрәсе дә килми башлады. «Үрдәк мае»нда пешкән[1] борчак буткасы шикелле тамакка утыра иде ул. Моны «сиротски аш» дип йөрттеләр авылда. Безнең шикелле ятимнәргә, ялгыз карт-карчыкларга һәм ачыга торган фәкыйрьләргә чыга икән бу. Зурая төшкәч уйлавымча, бу инде «унберенче елгы ачлык» кышы булгандыр. Минем алты тутырып, җиде белән барган чак...

Гаяз мине мәдрәсәгә алып керде. Мулла йорты каршыда гына икән. Бер катлы кечерәк кенә агач мәдрәсә — ишегалдының бакчага башлаш почмагына салынган. Укучылар мыжгып тора. Монда да шул ук әлепи, иман шарты, ясин, әптияк кимерәләр икән. Малайлар мине ят мәчедәй итеп, кыргый күз белән чорнап алдылар. Берхәтле дәшми торганнан соң:

— Каян килгән бу корчаңгы песи баласы? — дип куйды берәве.

Җавап бирүче булмады. Ник дисәң, әле минем урамга да рәтләп чыккан юк иде, белмиләр, күрәсең.

— Әй, песи борын, кайсы авылныкы син? — дип сорады икенчесе. Бар да шаркылдап көлде: «Чыннап та, песи борын, валлаһи, песи борын!» диештеләр. Мондый мыскыллы сорауга җавап бирүне хурлык санап, башны түбән идем дә сабакны ятларга керештем. Тирәмнән һаман китмиләр. Араларыннан тагын берсе, янга ук иелеп, рәтләбрәк сораган булды:

— Әйт әле, парин, атың ничек синең? Шәкерт булып килдеңмени безнең мәдрәсәгә?

— Атым Шәйхелислам,— дидем теләр-теләмәс кенә.

— Шәйхыл икән, Шәйхыл! — дип гөжләштеләр тегеләр һаман китмичә. Ә бусы каршыма ук тезләнде:

— Җырактан килдеңме, парин, Кушторма башыннан түгелме?

Тагын ыржаеп көлешү.

— Җук, «Кайдырмый тау» астыннан килгән ул! — дип кычкырды тагын берсе.

Минем мәдрәсәгә килеп керү бу юньсез малайлар өчен гел бәйрәм булып китте. Ә мин, үземчә, изге ният белән сөенеп килгән идем: шәкерт булам, янәсе. Булырсың монда шәкерт! Бөтенләй күңел төште, монда бер дә башка авыл малайлары килеп укымый икән. Шуңар, ахры, урман киеге иттеләр мине.

— Бер дә Кайдырмый тау астыннан түгел, андый авылны ишеткәнем дә юк. Тулбайдан килдем мин,— дидем еларга житешеп.

[1] «Үрдәк мае» — су.

— Ә-ә, чумар буры икән бу, чумар буры! — дип кычкырышты теге башкисәр малайлар.— Чумар буры бу!..

Менәтерә, әле генә «песи борын» идем, хәзер «чумар буры»на әйләндем. Бер көн эчендә ике кушамат! Мәдрәсәнең болай каршылавы миңа бик авыр булды. Бөтенесе чит-ят дөнья, бөтенесе миңа дошман, бөтенесе мине тотып ашарга тора сыман тоелды. Таяныр кешем дә юк, бер ялгызым. Гаязга әйтсәм дә, белмим, яклармы ул мине? Кем мин аңа? Ул бит алай бик үлеп тормый минем өчен... Боегып почмакка постым. Шәкерт булу шулай кыен микәнни соң?.. «Чумар буры»ның нәрсә икәнен кич кайткач Гаяздан сөйләтеп белдем.— Кайсыдыр бер кышны безнең авыл саилчесе Югары Тәкәнештә соранып йөргәндә, кемнеңдер өйалдыннан чумарын урлап чыккан, имеш. Аны тотканнар, авылын әйттергәннәр. «Тулбайныкы» дигән, имеш. Шуннан бирле бу авыл безнең Тулбайларны «чумар буры» дип йөртә икән. Сәер инде мескен безнең авыл. Бер дә аның яхшы атын ишетеп булмый, гел яманатын гына чыгаралар. Үскәчрәк белдем, аның әле бурлык ягыннан тагын бер «даны» бар икән: Тулбайның ниндидер Сәйфеттин дигән кешесе Тавиле базарында чыбыркы урлап тотылган, имеш. Гади ат чыбыркысы. «Ник урладың, атың юк ич синең!» дигәннәр. «Чыбыркысы бик шәп. Аты булыр аның, ә мондый чыбыркыны каян табарсың?» дип әйткән ди бу.

Шуннан бөтен тирә-якка «чыбыркы...» дигән исем таралган. Соныннан Себердә, Донбасста йөргәндә дә күзне ачырмыйлар иде шуның белән...

Чит мәдрәсә тормышына иялэшү, чит малайлар белән аралашу бик кыен була икән ул. Дөрес, күбесенең исемен дә, кем малае икәнен дә, өйләренең кай тирәдә булуын да беләм мин хәзер, тик барыбер үз булып китә алмыйм, алар мине кырыйсытудан һаман туктамыйлар. Урамга чыксам — бәргәләп кайтаралар, чана шуарга төшсәм — юри карга батыралар, әллә ничә төрле капкынны корып кына торалар. Ә бер көнне мәдрәсәдә минем янга тып-тын гына Медерәй малае килеп утырды. Шундый юаш кына, шундый дусларча ягымлы итеп кенә елмая ул. Мин бөтенләй эреп киттем, үзем дә аңа елмая, дуслык белгертә башладым. «Кара әле, ни төрле әйбәт малай да бар икән монда!» дип сокланам. Күңелнең нәкъ шул нечкәргән чагында, нәкъ шул рәхәт һәм мөлдерәмә бәхетле минутында, һич тә сиздермәстән, минем ботны кинәт борып чеметте дә йөзендәге шул матур көлемсерәвен әз генә дә сүндермичә, яхшы-яман бер сүз әйтмичә китеп тә барды бу. Уйга килмәстәй мондый хәлдән бик ачы итеп чырыйлап, кычкырып елап җибәрдем. Аның шул хәтле юхаларча шома гына янга килеп, ышандырып алуы, мин аңа җанымны бирерлек булып торганда, шундый явызлык эшләве — бот авыртудан да каты әрнетте, йөрәкне яралагандай итте, бик тә кимсетте мине. Дөньяда мондый малайлар да була торгандыр дип белми идем әле мин. Ачык дошманга караганда, астыртын дошман, ай-яй, хәтәр була икән! Соңыннан да миңа мондый «дуслар» шактый очрады. Тик барыбер алдан белә алмадым, барыбер шулай көтмәгәндә чагып киттеләр...

Елыйм, җан-тән белән әрнеп, үкси-үкси, туктый алмый елыйм. Күрәсең, сабыр савытлары тәмам мөлдерәгән минем. Монда килгәннән бирле җыелган сагышлар, юксынулар, кимсенүләрнең ташып түгелер чагы җиткән. Яшь аралаш бөтен дөнья караңгы, бөтен нәрсә шыксыз, бар да усал, бар да җәберче булып күренә хәзер. Минем янга малайлар җыелды. Безгә сабак бирүче Нәкыйп хәзрәтнең Шәкүр исемле олы малае хәлфә булып калган иде — ул да килде.

— Кем тиде, ник тиде? — дип сорады ул.

— Әнә, Медерәй малае, тәк дерәгә килде дәген чеметте-е,— дидем мин, елаудан һаман туктый алмыйча тотлыга-тотлыга.

Бөтен мәдрәсә шаркылдап көләргә тотынды: «Тәк дерә!» — «Тәк дерәгә килде дәген чеметте!» дип такмаклый башлады алар. Мин тагын көлкегә калдым, тагын бер кушаматлы булдым. Ник дисәң, бу сүз нәкъ Тулбайча булып чыккан иде, ә мондагы малайлар «де» белән сөйләшмиләр, «дәген»не дә әйтмиләр бугай...

## Карлыгачым, кая очтың...

Бу мәдрәсәдә язга хәтле ничек укыганмын, нинди сабаклар өйрәнгәнмен — белмим. Минем үзәк өзгеч булып тоелган шушы вакыйгадан башка һичбер якты истәлек калмаган...

Кызлар бу авылда да мулла өенә йөриләр иде, хәер, кая йөрсеннәр инде алар, кызлар мәдрәсәсе кайда бар икән ул?.. Тәтәбайның ике олы кызы бик укымышлы, хәтта кыз башлары белән сәлам хаты да яза беләләр иде. Түтәй шуларга ияреп йөрдә сабакка быел. Ул да коръәнгә төште инде, тегеләрдән күрмәкче язу да яза башлаган. Кайбер читен сүзләрне ничек язарга икәнен миңа да өйрәткәли. Ә минем күңел үсми. Мәдрәсәгә дә этен-төртен генә йөрим, кызыгы юк, гел ялгыз сизәм үземне. Үзебезнең өйдән чыгып киткәннән бирле һаман боегып йөрсәм дә, элекке елаулар онытылып бара иде инде. Мәдрәсәдә әнә шул елавым беренче тапкыр булды. Анда да көлкегә генә калдым. Шуннан бирле күз яше күрсәтмим, кем ишетсен монда синең зарыңны, кем юатсын?.. Шундый чакларда үз анам булмавы һаман үзәкне өзә бара. Мин инде «үлү» дигән сүзне, әнәйнең кабат беркайчан да әйләнеп кайтмаячагын ачыграк төшенә башладым һәм аның каршында гаебем бар шикелле оялу көннәр буена тынгы бирми миңа хәзер...

Яз да бу Югары Тәкәнештә әллә нинди бик моңлы булып килә икән. Дәүабайларның капка төбендә биек карт каен бар, аның бер ботагында сыерчык оясы бар. Шул каен башына җыелган бу яз кошлары шундый матур итеп, шундый өздереп, әллә ничәмә төрле тавышлар чыгарып, хәтта ерак күк түбәсеннән узып бара торган кыр казлары кыйгаклашкандай итеп көн буена сайрашалар, мин көн буе шул каен төбеннән кермим. Шунда гына рәхәт миңа, күңел әллә нишли, күз төбенә кунган яшьләрне көчли-көчли эчкә куам, уйда онытылам. Шул бәләкәй генә сабый башның да уйга калыр көннәре булыр икән...

Аяк асты кипшереп, җир өсләре яшәргәч, шомыртлар чәчәк аткач, түтәй белән үзебезнең авылга кунакка киттек. Шамил бәләкәй, «Мин дә барам!» дип еласа да, өч яшьлек малайны алты чакрым җиргә күтәреп тә, җәяүләп тә алып барып булмый шул. Түбән Тәкәнештән узганда Нәфисәттәйләргә кердек, түтәй аларның йортын белә икән. Аның ире Зыяттин җизни дә бик ачык йөзле, бик ару кеше булып чыкты. Алар безне клиндер белән чәй эчертеп, кулыбызга да берәрне тоттырып, капка төпләреннән озатып калдылар.

— И гөлкәйләрем, кайтканда тагын керегез, җәме! — диде Нәфисәттәй.

Тәкәнешнең озын, тузанлы урамын җитәкләшеп узгач, түбән очтагы тыкрыктан уңга борылып, Тулбай юлына чыктык. Моны «Тәкәнеш үре» дип йөртәләр, күп булса — ярты чакрымдыр, без аны тиз менеп җиттек. Үрнең нәкъ түбәсендә, ямь-яшел чирәмле балчык өеме өстендә — «зимнәмир баганасы». Монда басу межалары башлана. Шунда килеп җитүгә безнең күзгә үзебезнең яклар ачылып китте: ин элек түбәнгә сузылган юл өстендәге зират күренде. Ул олы бер озынча агач бакчасы шикелле яшеллеккә күмелгән. Аннан ары — ике яктан килеп кушыла торган борма инешләре, яр буйларындагы тал-тирәкләре, яшел бо-

лыннары, калку җирдәге мәчет манарасы, сал‌ам түбәләре һәм аргы яктагы биек таулары белән Тулбай күренде. Туган авыл Тулбай! Киткәнебезгә ярты гына ел тулып узса да, без нихәтле сагынганбыз аны! Нинди икән хәзер аның урамнары!..

— Әнекәебез исән булса, әллә кайларга китеп тә йөрмәгән булыры-ек...— дип куйды Түтәй, нәкъ мин уйлаганча.

Багана төбендә әз генә утырдык та, җитәкләшеп, Тәкәнеш урен-нән төшә башладык. Күзләр тагын зиратка текәлде, күңел дә шунда иде. Түтәй үзенчә моңлы тавыш белән әкрен генә җырлап җибәрде:

— Карлыгачым, кая очтың,
Канатыңны талдырып шул,
Әнекәем, кая киттең
Безне җангыз калдырып?..

Мин дә кушылдым. Бу җыруны беләм, безнең аны инде югары Тәкәнештә дә җырлаганыбыз бар иде. Тагын бүтән җырулар да суз-дык. Зиратка килеп җиткәндә генә тукталдык. Аның янында инде җырларга ярамый, анда әнәй әйтә. Җырлап килгәнне яратмас. Әрвах-лар янында җырласаң — язык була дип тә әйтәләр.

Без әнәйгә дога кылмакчы булдык, ә каберен белми идек. Шуңа күрә зират киртәсе буеннан күзәтә килеп, артык әчкәредә булмаган яңарак бер кабергә тукталдык. Дәүабай да шулайрак өйрәтеп җи-бәргән иде, ул бит үзе күмешкән кеше. Шул кабер турына, киртә бу-ендагы яшел чирәмгә тезләндек тә, колһуалла белән аятелкөрси укып, бик ихлас күңелдән дога кылдык. «Газиз әнкәебез оҗмахның түрендә булсыные!» дип теләк теләдек.

Аннары, хәсрәтле генә кузгалып, бу тирәгә чәчелгән арпа-бодайлар арасыннан тар гына юл буйлап авылга юнәлдек. Без анда Мөбарәкша абыйларга барып төштек. Ул әтәйнең олы абыйсы. Бөтен туганнары арасында иң якын иткәне — шул. Мөбарәкша абый белән Олы җиңги-нең җиде баласы бар. Урам буена каратып салынган искерәк кенә бердәнбер өйнең эче, корт тулы умарта шикелле, гөжләп тора. Безнең анда барып керү берәүне дә тарсындырмады, «иш янына куш» кына булдык. Бәләкәйрәк кенә буйлы, чибәр генә йөзле Олы җиңги хәллә-ребезне сораштырды. Әнәй белән алар Пазый бабай йортында ун ел бергә килен хезмәте иткәннәр, бик тату яшәгәннәр, хәтта дус булган-нар. Әнәй авырткан чакларда да Олы җиңги гел килә иде безгә, прән-ник-җимеш шикелле күчтәнәчләр дә кыстырган була, әнәй белән озак-лап, тәмләп чәй эчәләр, сөйләшеп сүзләре бетми, кич кенә кайтып китә торган иде ул бездән. Менә хәзер дә үз балалары шикелле якын итеп каршылады ул безне, андагы тормышыбызны җентекләп сораш-тыра башлады. Аның барын да беләсе килә: өс-башыбыз умырылып йөрмиме, тамак аралау, кагу-сугу юкмы, Чибәр абыстай дигән җиң-гәбез ничегрәк, каты холыклы түгелме? Турыдан-туры туган булмагач, чит бала итеп карамыймы безне?.. Һәм тагын әлләниләр беләсе килә аның. Бездән зарлы сүз ишетмәсә дә, анда яшәвебезне бик үк хуплап бетерми.

— Әллә пәстәгә шулай җырак алып китәсе иттеләр. Шушында үзе-бездә дә сыярыегыз әле,— дип куя. Аннары түтәйне мактый башлый: — Бик үскәнең, Хөршитбану,— ди.— Гел әниең шикелле зифа буйлы, төскә-биткә дә аның күгүк чибәр булып киләсең,— ди. Бу сүзләрнең барысын да чынлап әйтә ул, рыядан гына сөйләшә белми, аның күңеле шундый кин, шундый әйбәт икәнен хәтта мин дә аңлыйм.

Без аларда бер атна кунак булдык. Олы җиңгинең безнең тирә яшьтәге балалары белән туйганчы уйнадык, бөтен болыннарны, чишмә башларын, инеш буйларын гиздек, күзләр күгәргәнче су керендек. Бүтән туган-тумача, Мактый бабай, күрше-күләннәр дә кунак итте

безнө. Барына да йөреп чыктык, шуннан соң гына Югары Тәкәнешкә кайтып киттек.

Аннары, берәр ай узгач микән, уракка төштеләр. Авылның кояш чыккан ягында биек тау, шул тау өстендә басу. Чибәр абыстай Гаяз белән мине шул басуга алып менде. Гаяз инде урак ура, ә мин тота да белмим әле, Чибәр абыстайның бәләкәй арбадагы баласын гына карыйм. Аяз көндәге эссе басуда ул бала киндер җәймә корылган кабык арба эчендә пешеп ята, гел еларга гына тора. Аны әрле-бирле тәгәрәтеп тирбәткәндә, арбасын тартып йөргәндә ялан тәпигә арыш камылы кадала, картаеп каткан кәҗә сакалы төпләре, билчән белән шайтан таяклары тубык-балтырларны тырный. Басуда бала карау бер дә рәхәт түгел икән. Шулай да ул баланың йоклап киткән чагы, я булмаса, әнисе имезгән чагы да була. Анда инде Гаяз да урагын сосланга кадый. Ул мине якындагы «утбал»ларга алып китә. Шул чокырлардан кайчандыр, әби патша заманасында диме шунда, бакыр чыгарганнар, имеш. Аның әйтүенчә, моннан хәзер дә әле чын бакыр ташы табып була икән. Күкле-яшелле тутык белән капланган вак ташлар арасыннан «чын бакыр» эзләргә тотынабыз. Ул ансат кына табылмый икән, вакыт та җитми кала. Гаязга урак урырга кушалар, ә миңа бала тирбәтергә кирәк була...

Икенче тапкыр эзләнүебездә, куе үлән каплаган «утбал» чокыры кырыеннан шундый ире булып, бүртеп пешкән жир җиләге килеп чыга — әйтерсең кып-кызыл кикрикле әтәч башы!

— Җиләк! Җиләк! — дип кычкыра Гаяз. Икебез дә чокырга ташланабыз. Мондый җиләкләр күбрәк очраса, бакыры табылмаса да сүзебез юк безнең.

Арыш урагы бетте, сабанга төшмәделәр әле — яшел ди. Мин дә басуда бала караудан котылып торам. Шул көннәрнең берендә авылга «сәмәхут» килде. Ул чакта велосипед дигән сүз булгандырмы, белмим. Бу сәмәхутка кем атланып килгәндер, анысына да ис китмәде, безнең күзләр машинаның үзендә иде. Бөтен җире көмештән койган шикелле ялк-йолк итеп тора! Тәгәрмәч чыбыкларына хәтле шундый. Чынлап та, көмештер ул! Атланып килгән кешесе туктап тормады, без уйнаган мәчет урамыннан узып кына китте. Бөтен малай аның артыннан чапты, берәү дә куып җитә алмады, ай-яй, кызу йөри икән! Ул чаттан борылып күздән югалды. Без сәмәхутны төштә күргәндәй генә сокланып һәм кешесенең ничек егылмавына гаҗәпләнеп калдык.

Сабан уратына төштеләр, мин тагын бәләкәй арба тирәсендә. Җәйнең калган ягы ничек узгандыр, бер кызыклы нәрсә дә хәтердә калмаган. Әтәй һаман кайтмый да катмый. Әллә ул әнәйнең үлгәнен, ә безнең башка авылда торганны ишетмәде микән? Аннан хат-хәбәр киләме, акча-фәлән җибәрәме — анысын да белмим, түтәйнең дә бу хакта бер сүз әйткәне юк...

## Үз куышың, үз тормышың...

Ә көз көне без үзебезнең авылга, шул әлеге Мөбәракша абыйлар йортына кайттык. Бу эш ничек эшләнгәндер, агай-энеләр үзара ничек сөйләшенгәндер, без бала-чага берни белмәдек. Югары Тәкәнешкә дә ияләнеп житкән идек инде, монда кайту да начар булмады. Бер өй эчендә безнең белән ун бала хәзер. Иң олы дигәннәре дә унбиш-уналты тирәсендә: шау-гөр килеп ятабыз. Без, малайлар, барыбыз бергә җыелып, өйалдындагы чоланда йоклыйбыз, кызлар өйнең кече ягына тезелешә. Бер сугышып-талашып, елашып йөргәнне хәтерләмим. Шулай

да кыш җитеп, барыбыз да өйгә кергәч, дөньялар тараебрак китте. Мич башына идәнгә дә тәгәри башладык, ә идәндә бәкәйләр белән бозауга да урын кирәк бит әле. Озакламый абыйның олы кызы Галияттәй белән Хөршит түтәй үзебезнең өйне җылытты. Таш стеналарын агартып, идәннәрен юып чыгардылар. Олы малай Хөснулла абый белән Мәхмүт абый утын китереп турап өйделәр, салам, печән китерделәр. Сарыкларны да абзарга кайтарып яптык. Безнең бер имана чәчелгән арыш җире Мөбарәкшә абыйда калган иде, сабанны да ул чәчеп, җыеп алган. Әтәй белән шулай килешкәннәрдер инде.

Монда күчкәч, дөньялар бөтенләй иркенәеп китте. Безгә иптәшкә Галияттәй белән Муллаәхмәт, я Мәхмүт килеп куна. Ә кайсы кичләрдә күрше Ләүхия җиңги кызы Мәлүфәттәй, каршы яктагы күршедән Минзифа белән Мәгъруфәттәй дә керә. Алар кич буе җырлый-җырлый орчык эрлиләр.

Төн урталары җиткәч, олы як белән кече якны тутырып йокларга ятабыз. Таңга хәтле әкият сөйләүләр китә:

— Барые ди, югые ди, ачие ди, тугые ди...

Күрше кызлары өчесе дә әкият сөйләүне бик ярата. «Бармак буе малай», «Кыл муен белән Курай бот», «Тугыз Тукылдык белән бер Мимылтык», «Таз малай белән корчаңгы тай», «Алты аяклы айгыр», тагын әллә нинди әкиятләрне тыңлаганда, эч катып көлә-көлә җаннар чыга. Әмма болар арасында иң остасы, иң тәмле итеп, гыйбрәтле итеп сөйләүчесе Мәгъруфәттәй иде. Ул ирдән кайткан хатын, Мактый бабайның олы малае Хәлиулла абыйга чыккан булган. Ә Хәлиулла абый озак та тормыйча читкә киткән дә никтер кайтмаган (моның сәбәбен Мәгъруфәттәйдән сорарга бер чакта да кыюлык җитмәде минем). Көтеп-көтеп тә күзгә-башка күренмәгәч, Мәгъруфәттәй үз өйләренә кайткан. (Алга сикереп булса да шуны әйтәсе килә: ул гомер буе ирсез хатын булып яшәде, авыл арасында бер генә яманаты да чыкмады. Телгә усалрак булса да, яхшы күңелле, ихтирамлы хатын булып гомер кичте.)

Мин шул Мәгъруфәттәйнең «җан Таһир белән җан Зөһрә» хикәятен бик матур, бик нечкә сүзләр белән бизәкләп сөйләвен тыңлаганда, без малайлар да эреп китәбез. «Үги кыз», «Сатылган кыз» әкиятләрен сөйли башласа, кызлар гел «балавыз сыгып» ята. Ә инде бер матур кызны урлап киткән җиде башлы дию пәрие көчлелеге белән бөтен диюләрне, хәтта гыйфрит җеннәрен дә җиңеп торса да, аның башын берәм-берәм кисеп төшерә торган көтүче Хәйдерүш әкиятен без кат-кат сөйләтә идек, тыңлаган саен сокланып туя алмыйбыз. Мәгъруфәттәйнең әкиятләре өч төн-өч көн сөйләсә дә бетә торган түгел, каян шул хәтле күп итеп өйрәнгәндер ул аларны! Шушы матур әкиятләре өчен мин аңа бик нык ияләшеп киттем, хәтта янына ук ятып тыңлый башладым. Ул мине кочаклап, аркамнан сөеп йоклата иде.

Шулай итеп, бу кыш безнең бик матур узды. Көндезләрен сабакка йөрим, безнең авылда хәзер мәдрәсә бар, аны кыш кергәндә генә салып өлгерттеләр, өйалдысы әле эшләнеп тә бетмәгән, урамнан кар ерып килгән килеш туп-туры мәдрәсә эченә керәсең. Без, малайлар, шунда укыйбыз. Башкалар кунып-төнеп тә яталар, мине түтәй җибәрми. Ул да укуын ташламады әле, элекке шикелле үк абыстай өенә йөри, Коръән укый, язуны да шатырдатып яза! Бөтен өй эше дә аның кулында. Әнәй шикелле карый ул безне.

Мин дә гел юкка чыккан малай түгел бугай, ахры: «Шәйхелислам Фәрхулла угылы Фазлытдинов» дип яза да беләм, укуны да су күк эчәргә исәп бар, өйдә түтәйгә дә булышам: чыра телә, бәкәйләргә печән алып керәм, көл түгәргә чыгам, утын кертеп бирәм — миннән дә күп эшләгән кеше юк! Аннары, кушкан чакта, түтәйнең башын да карыйм әле. Аның кара куе бөдрә чәчләрен бик яратам мин. Яулыгын

салып шул калын чәчләрен иңнәренә төшерсә, Мәгъруфәттәй экиятләрендәге патша кызларына охшап киткәндәй була. Ә ул тарап үрә алмыйча интегә шул чәчләрен:

— Тәрәшле тарагы кирәк моңар, шунсыз берни дә эшләп булмый,— ди.

Шамил дә бик әйбәт, бик акыллы малай булып үсеп килә, бер дә көйсезләнми, үзе урамга чыгып уйный ала хәзер. Без, «өч бәбкә», шулай кыш уздырып маташканда, язга табарак бугай, бик зур шатлыгыбыз булды: әтәйнең үзебезгә атап язган хаты белән бүләкләре килде. Дусай кешесе артыннан җибәргән, шул кеше үзе китереп китте. Башта әтәйнең хатын укыдык. Өчебезгә дә чук-чук сәламнәр язып, җәйгә таба үзем дә кайтмакчы булып торам, ходай кушса, дип язган иде ул. Аннары төргәкне сүтәргә тотындык. Күчтәнәчләре: чәй-шикәр белән кузаклы җимеш, өстәвенә бик матур калай савытта лампасый да бар. Бүләкләре: Шамил белән миңа күлмәк-ыштанлык, кара хәтфә түбәтәй: башка кигәч, текмә-тек сыланып кына тора, каян шул хәтле белеп алган! Ә түтәйгә шәмәхә атлас күлмәк җибәргән. Ул шундый матур: елык-елык уйнап, төсен үзгәртеп торуы белән күзләрнең явын ала! Әллә ничә бала итәкле, бала итәк саен кырыйларына яшькелт ука кәйтән тотылган, ә кәйтән өстенә көмештәй ялтырап торган вак кына балык тәңкәләре тезелгән. Җин очлары бөрмәле-каптырмалы, җилкә өсләрендә дә шундый ук кәйтәнле бала итәк. Барыннан да бигрәк, бу күлмәкнең тагын бер искиткеч яңалыгы бар: аның изүе артта!

— Әтекәйләрем, башым әйләнә! — дип кычкырды түтәй куанычыннан.

Бу атлас күлмәк үзе дә, тәңкәле-кәйтәнле кат-кат бала итәкләре дә, арттан каптырмалы якасы да — безнең төшкә дә кергән нәрсәләр түгел, авылда да юк!

Түтәй аны курка-курка гына киеп карады, якасын каптыра алмый җелегә кипте, аптырагач, миңа төймәләтте. Аннары көзгедән карады, ә көзге кисәге бәләкәй. Шуннан ул мине көзге итте: «Ылан, карале, ничегрәк?» — дип сорады.

— И түтәй,— дидем мин-көзге: — койган да куйган инде! Шул хәтле килешә, шундый матурайта сине, безнең авылда сиңа тиң бер кыз да юк хәзер. Белмим, башка авыллардан да табылыр микән әле!..

Бер дә арттырып әйтмим, мин нәкъ шундый озын сүзләр белән мактадым аны һәм чын күңелдән мактадым. Моңарчы иске-москы эчендә ничектер бер-беребезне күрми дә идек. Өскә-башка юньле кием эләккәч, без дә күзгә чалынырлык икәнбез ләбаса! Түтәй, билгеле, минем мактауга ышанмады: — Ә-ә-й, лыкылтык! — дип кул гына селтәде. Шуннан ул Мөбарәкша абыйларга чыгып йөгерде. Аларга хат укытып, күлмәк котлатып кайтты. Кайтышлый иптәш кызлары Мәсрүрә белән Мәлүфәгә дә кагылып, күлмәк күрсәткән. Олы җиңги аңа ярты каз биреп җибәргән, Шәмсиямалттәй бер бәләкәй таш савыт бал тоттырган, Ләүхия җиңги бер тәлинкә коймак күтәрткән. Кайту белән казны казанга тыкты. Кичкә таба түтәйнең шул иптәш кызлары, минем иптәш малайлар Һади белән Гыйльми керде, абыйның кызлары Галияттәй белән Шәмсенур килде. Безнең өй эче кеше белән тулды. Казан тулы аш пеште, каз ите белән кесәллек токмачы! Ул көнне көн буе, кич буе безнең өйдә бәйрәм булды.

Башта ук әйтергә онытканмын икән — хәзер әйтим: без үз өебезгә кайтып тора башлагач, Мактый бабай тагын безне кайгыртырга керешә. Йорттагы ир-ат эше гел аның кулында. Безнең көч җитми торган ботаклы утыннарны, элекке шикелле үк гых-гых итеп, ул ярып бирә, абзардагы тиресне бакчага чыгара. Бураннан соң күмелгән ишегалдын, капка төпләрен көрәргә Габдулла абыйны кертә, аның белән мин дә

кәрәгән булам. Каравыл чираты житкәндә, безнең өчен «дудур»[1] торырга Сибгат абыйны чыгара, чәчләрне гел үзе ала. Бүген дә ул безгә бүләкләр килүен ишеткәч, Шамил белән мине үзе алып чыгып китте.

— Әйдәгез әле, егетләр, чәчләрегезне кырып ташлыйк,— диде.— Мондый матур яңа түбәтәй белән иске чәч килешмәс.

Үзе ясаган киң чалгы пәкене яңавыч шикелле кытыршыланып беткән олы уч төбендә янап җибәргәндә саф корыч чыңы яңгырап чыга. Аннары су белән сабынлаган чәчне шытыр-шытыр китереп кыра башлый. Нәкъ лепкәгә житкәч, без бөгелеп төшәбез. Башның иң авырткан жире — шул.

— Әй, әй,— ди Мактый бабай,— нәрсә карыйсың аннан — сәке астыннан? Сак бул, борныңны каз чукып алмасын!

Елар хәлгә житсәң дә, көлеп җибәрәсең. Мин чыдагач, Шамил дә чыдарга тырыша.

— Бу баш түбәгез белән җәй буе ком сукаладыгыз мәллә? — ди бабай.— Тутагызга әйтегез, чыра пычагы белән кырып юсын башыгызны, шунсыз бетәрлек түгел.

Без тагын көлешәбез. Рәхәт шул бабай янында булу. Ул безнең муеннарга тулган чәчне тазартып, маңгай, колакларны сөрткәләде дә чыгарып җибәрде. Ә иртәгесен кичке якта, бик чибәр итеп, бик нык итеп ясаган чабата кертте тутәйгә. Яңа күлмәк белән кияргә инде ул!..

Узган гомер уза. Инде җәй башы да житеп килә. Әтәйне без күптәннән бирле сагынып көтәбез, кайтыр микән ул, «җәй башларына...» дигән сүзен онытмас микән?..

## Безнең әтәй кыз урлый

Онытмаган. Кайтты. Сөенечләр шул хәтле зур булса да, без тиз генә әтәйгә җан-тән белән ялганып китә алмадык. Ниндидер гаепле балалар сыман курка, тартына идек без аннан. Ә Шамилнең, аң керә башлагач, беренче тапкыр күрүе әле аны, чынлап торып таный да алмый. Бишектән үк керә башлый торган үзлек, якынлык тойгысы уянмаган, без әйткәнгә генә әтәй дип аңлый. Тутәй унөч яшь белән бара хәзер, олы кыз санала: ул да йомыкый, сөйләшә алмый әтәй белән рәхәтләнеп.

Ә сөйләшергә, үзләшергә бик кирәк, югыйсә. Әнәй юклыгы һаман саен ныграк сизелә барганлыктан, безнең дә сагыш савытлары бик тулган, аның да эче буш түгелдер. Кайтуының икенче көнендә үк җомгадан соң зиратка китте. Ул анда бик озак торып, салпы күңел, моңлы төс белән кайтып керде. Шунда безгә өчебезгә дә аңа килеп сыенырга, кочагына керергә, әнәй турында сөйләшергә, сагынуларыбызны әйтергә кирәк иде. Юк шул, булмады, беребезнең дә кыюлык житмәде. Ике арадагы күренми торган киртә шул көйгә кала бирде...

Аннары без аш уздырдык. Аны Олы җиңги белән Галияттәй дә әзерләште. Үзебезнең агай-эне килде. Күрше-күләннәрдән Мактый бабай, Әхсән абзый, Шәйдулла абзый керде. Югары Тәкәнештән Дәүабай белән Тәтәбайны да чакырып китердек. Безне караусыз-ярдәмсез калдырмаулары өчен әтәй аларның барысына да бик күп рәхмәтләр әйтте.

— Яхшылык утка янмас, суга батмас, аллаһы теләсә, мин дә онытмам бу изгелекләрегезне, — диде. Бу көн безнең өчен бик шәп бәйрәм

---

[1] Дудур — дозор дигән сүздән халыклашкан.

булды. Ә бәлеш төпләре, чәй токмачлары[1], тагын бүтән тәмле ашлар белән сыйлану өч-дүрт көнгә хәтле барды.

Берничә көннән соң әтәй йорт эшләрен карарга тотынды. Ничектер матча сыгыла башлаган икән безнең. Кече як кырыйгарак имән багана утыртып, ул аны терәтеп куйды. Аннары өй стеналарының инен, буен, биеклеген үлчәп алды. Ул таш стеналар җәен-кышын тирләп-суланып тора иде безнең. Агартсаң да икенче көнне ук буй-буй булып агып төшә. Каяндыр алып кайтып шомарткан такта белән шул стеналарны каплап чыкты. Хәзер безнең өй эче бөтенләй яңарып, яктырып китте. Моны ул әнәй исән чагында ук шулай эшләгән булса, нинди шәп буласы булган икән! Кышлый бәрәңге яткан сәке астындагы сайгакларның да кайбере череп төшкән иде, аларны да алыштырды. Шуннан соң капканы күтәртте, ул җиргә сөйрәлә башлаган иде, сыдырылып төшкән такта коймаларны да рәтләде. Түтәй белән миннән ишегалдын себертте. Ире мал-туар йөрмәгәнгә күрә, аны ямь-яшел йомшак чирәм баскан. Чүбе барлыгы күренми дә, себергәч ул да ямьләнеп китте, бөтен йорт-җиргә җан кергәндәй булды.

Бу эшләре беткәч, әтәй ике тырма ясады, түтәйгә дигәненә әллә нинди буяулы бизәкләр дә төшергән иде. Өй чормасыннан чүпрәккә төрелгән чалгы алып төшеп, аны да чүкеп, саплап куйды. Озакламый печән өсте житәчәге үзеннән-үзе билгеле иде.

Бар да шулай үз җае белән, әйбәт кенә барган чакта безнең колакка яңа сүзләр ишетелә башлады. Күрше-күләнгә керсәк тә, Мөбәракша абыйларга барсак та шуны кузгаталар.

— Бер әйбәт кенә яшь ана кирәк инде, ылан, сезгә,— ди Ләүхия җиңги.— Атагызны өйләндерегез, үзен дә, сезне дә карар кеше кирәк бит.

Олы җиңги дә шуны ук кабатлый.

— Әниегезнең гомере булмады инде мескенкәемнең,— ди.— Шундый да әйбәт, шундый да якын дустым иде — ун ел бергә килен хезмәте итеп, ичмаса, әз генә үпкәгә дә килешмәдек... Каян гына табарга соң сезгә шул үз анагыз шикелле алтын бер кешене!..

Бу яңа сүз, көтелмәгәнчәрәк булса да, безнең күңелдә дошманлык тудырмады. Түтәй белән без аны шулай кирәк дип кабул иттек. Өч яшьлек Шамил әле моны аңларлык түгел иде. Әтәйнең үзе белән дә олылар бу хакта, әлбәттә, сөйләшкәннәрдер. Аның шундый ният белән йөрүе озакламый миңа да мәгълүм булды.

Печән өләштеләр. Әтәй мин торганчы ук иртәнге чык белән печән чабарга китә. Төшке чәйдән соң печән кабартырга түтәйне дә алып бара. Шамил белән без каз көтәбез. Кичен болыннан кайтып, ашапэчкәч, әтәй өс-башын алыштыра да караңгы төшеп килгәндә тагын чыгып китә. Өченче тапкырында түтәйдән сорадым.

— Әтәй кая бара ул төнгә каршы?..

Түтәй моңа көлемсерәп җавап бирде:

— Яшь әнәй күзләп йөри ул безгә,— диде.

— Яшь әнәй?.. Кем соң ул?..

Түтәй болай дип аңлатты: арыякның югары очындагы түбән урамда торучы Гөлфаниттәйләргә Шәмәктән Шәмсебану атлы сеңелесе кунакка килгән. Кемнәрдер әтәйгә шул кызны димлиләр, имеш. Бик әйбәт, бик уңган кыз ди, эшкә дә бик тырыш, кул һөнәренә дә бик оста ди. Әтәй әнә шул кызны читтән генә булса да күрергә, холкын-фигылен белергә тырышып йөри икән. Билгеле, егет кеше булмагач, туптуры кызның үзен күреп сөйләшү мөмкин түгел инде аңа. Шуңа күрә, әдәм күзенә чалынудан бик сагаеп, су буе сукмакларыннан гына әйләнеп килеп, лапас почмагына посып кына, өйалды тактасы ярыгын-

[1] Чәй токмачы — кош теле.

нан күзәтә икән. Тегеләр өйалдына ут яндырып кичке чәй эчкәндә, кызның төс-битен, килеш-килбәтен күреп кала, имеш.

Түтәй боларны каян белеп бетергәндер,— әтәй үзе сөйләгәнме, Олы җиңги-фәлән тишкәнме,— мин нихәтле сорасам да, әйтмәде. «Анысы сиңа кирәк түгел», дип кенә куйды, кешегә әйтмәскә кушты. Шулай итеп, мин дә хәзер сер саклаучы булып киттем, Шамилгә дә әйтмәдем. Хәер, нәрсә аңлый соң әле ул! Ә үзем бу хәлләргә бик сәерсенеп йөри башладым.

Печәнне бетереп, арыш урагына төштеләр. Бер кичне әтәй кәефе бик кырылып, төсе-чырае бозылып кайтып керде. Ул өстенә читтән кайткан яңа киемнәрен кигән, башында яңа түбәтәй, аягында читек-кәвеш иде. Без инде Шамил белән болай да йокларга җыенып маташа идек, әтәйнең мондый чыраен күргәч, шып булып, тиз генә кече як сәкесенә үрмәләдек тә иске толып астына чумдык.

— Һи, алланың бар иткере, томаланган нәрсә... Шул аңгыра бәрән белән йөргәч ни...— дип сукранган тавышы ишетелде аның. Әллә түтәйне ачулана микән дип, колакларны торгыздым, күзләрне олы як яктысына суздым. Әтәй ян сәкегә утырган, түтәй аның читеген тарта. Аны тиргәми бугай, нәрсәдер үзалдына зарланган шикелле. Кайнаган самаварны да эчмәде, өстен чишенде дә түтәй салып биргән түшәккә менеп ятты. Утны сүндереп, түтәй дә безнең янга урнашты. Өй эче тынды. Байтактан соң түтәйгә пышылдадым.

— Әтәй нәрсәгә ачуланган ул?..

— Белмим шул...— диде.

Иртәгесен әтинең ачуы басылган иде. Шулай да ул элеккечә түгел, әллә ничегрәк шунда: кемнәндер оялган шикелләме, нәрсәдер үйланган шикелләме — башын түбән салып йөри. Ачылып сөйләшү юк, бик кирәк чакта бер-ике сүз. Шул гына.

Өч-дүрт көн шулай берни аңламый йөргәннән соң түтәйдән сорадым.

— Нишләп әтәйнең балтасы суга төшкән? Нигә шулай күңелсез икән ул?

Түтәй тагын беркөнгечә көлемсерәп куйды. Ул шулай көлемсерәсә — нәрсәдер белә дигән сүз. Миңа караганда дүрт-биш яшькә олы булганга микән, барын да миннән элек белеп өлгерә ул.

Өйдә кеше булмаса да, ярым пышылдап кына әйтә куйды:

— Кыз урларга барган безнең әтәй...

— Кыз урларга? Кит аннан!

— Барган шул!.. Урлап кына кайта алмаганнар...

Мин, күзләрне тасырайтып, аңа карап каттым. Ул озак назланмыйча сөйләп бирде.

Әтәй, шул Шәмсебану дигән Шәмәк кызын яшертен генә күзләп йөри торгач, ошатып куйган да өйләнмәкче булган. Яучы җибәрсә, бирмәсләр дип курыккан — кыз егерме икедә генә икән, әтәй аннан егерме яшькә зуррак. Олы кешеләрчә итеп үстергән кара мыегы аны тагы да өлкәнрәк итеп күрсәтә. Туйлап алуга расхут күп чыгар дип тә уйлаган булса кирәк. Шуңар күрә тота да урлый, имеш! Ә кызның алдан кылын тартып карау, шундый олы яшьтәге кешегә өч бала өстенә киләме-юкмы икәнен белү — уена да кермәде микәнни соң?..

Ярар, шул кичне бу Мөбарәкша абыйларның атын Мәхлис абыйларның тимерхутына җигә дә, янына Хөснулла абыйны утыртып, кеше күзенә чалынмас өчен ындыр артларыннан гына печәнлеккә башлап түбән басуга төшә. Бу юлдан кеше күп йөрми. Ә кунак кызының Гөлфаниттәй белән шушы түбән буйда урганнарын һәм шушы юлдан барып-кайтып йөргәннәрен алдан белеп куя. Менә алар кайтып та киләләр. Әтәй, Хөснулла абыйга атны борырга кушып, ялт кына сикереп төшә дә, кызны эләктереп, тарантаска таба өстери башлый. Ә Гөл-

фаниттәй, нишләргә белмичә: «Туктале, Пәрхулла кода, бу нишләвең була?» — дип, ике арага ташлана. Хөснулла абый мондый кызыктан авыз ерып көләргә тотына. Арбасын тиз генә бора алмый мыштырдаганда, дилбегәсе кулыннан төшә дә ат аягы астына керә. Инде әтәй кызны күтәреп килеп, тимерхутка салгач та шул дилбегә әбәгәрләнеп, тиз генә чабып китә алмыйлар — Гөлфаниттәй тәгәрмәч астына керә, ә кыз шул арада ничектер арбадан сикерә дә авылга таба йөгерә. Нишләргә? Менә әдәм көлкесе! Кырыктан узган кеше кыз артыннан юл буйлап ничек йөгерсен? Булмый, алай кыланса, бөтенләй әдәм хурына калачак. Арба астыннан чыгып өлгергән Гөлфаниттәй дә кунак кызы артыннан йөгерә. Ә болар, атларын гел кире якка чаптырып, караңгы төшкәч кенә әллә кайдагы әйләнеч юллардан авылга кайтып керәләр. Әтәй юл буе Хөснулла абыйны тиргәп кайта, ә тегесе шырык-шырык көлүдән туктамый. Шулай итеп, хәзергә безнең яшь әнәй булмый кала... Яхшыгамы бу, ямангамы?.. Без әле белмибез. Тик әтәйнең бу уңышсыз маҗарасыннан көлемсерәп кенә утырабыз. Сәер, бик сәер... Без бит әтәйне авылда бер акыллы кеше дип уйлый идек. Ә бу хәлдән соң аны акыллы дип әйтерләр микән? Бот чабып көлә башласалар, шуның белән күзеңне дә ачырмасалар — нишләрсең? Әле бит, әнә, безнең дә көләсе килә. Әллә кыз урлау дигән нәрсә акылсызлыкка саналмый микән ул? Ярый әле, беркемнең дә бу хакта биткә бәреп әйткәне юк. Күрәсең, бу кәмитнең уртасында булган кунак кызы да, Гөлфаниттәй дә эчтән тынганнардыр. Хөснулла абыйга да Олы җиңги беркемгә әйтмәскә кушкандыр. Юкса, аның ерык авызыннан бөтен авылга әллә кайчан таралган булыр иде инде. Түтәй мине дә «ишетсен колагың!..» дип кисәтеп куйды. Аллам сакласын, сөйлимме соң! Малайлар мине гел кимереп бетерәчәк бит аннары.

Шулай итеп, бу хәбәр, чынлап та, авылга таралмыйча калды. Без дә, ялгышып кына эшләгәндер ул моны, дигән уйга килдек. Шулай булмыйча ни, безнең әтәй бит ул? Нижитте кеше түгел!

## Алма битләр кала бит...

Көн саен таң тишегеннән мине дә, Шамилне дә уятып, әтәйләр уракка китә, без алар белән тамак туйдырып калабыз. Аннары мин Шамилне ияртәм дә Җамалый тау башына юнәләм. Тау астыннан ук инеш уза, басмадан чыккач та Шәмәк болыны башлана, нәкъ безнең авылга терәлеп тора диярлек, шул инеш кенә аера! Безнең аумак казлары шунда йөри, комлы балчыкка үскән чыршы үләнен үлеп яраталар. Шулай итеп, без башка авыл болынында каз көтәбез. Озак та барасы түгел, шул ук болынга Шәмәкнең басуы тоташып китә, анда сабан ашлыгы. Казлар шунда таба ычкыныр өчен атлыгып кына торалар. Безнең хәзер ала каз, тегесе шикелле үк барыбер зимагур, арканлап куйсаң да бер урында тормый. Ярый әле, мин аның тавышын бер чакрымнан ишетсәм дә танып алып, шунда йөгерәм.

Баштарак минем чыбыркы юк иде. Бөтен малайда бар, миндә юк. Нишләргә, юкә каян табарга? Шул тау астына бәләкәй күл ясап, Бәбекәй абзый мунчала салган икән, кичке караңгыда шуны төшерергә туры килде. Алып кайтып лапаска яшергән идем, әтәй барыбер күреп алган. Иртәгесен мин ишегалдына чыгуга, мунчаланы беләк юанлыгы итеп ишеп куйган.

— Каян алдың моны, каты борын? — ди.

Эндәшмим. Нәрсә дисең, мунчала юеш, каян икәне болай да күренеп тора, үзебезнең күл юк ич. Тиз генә шул беләк юанлыгы мунча-

ланы тотты да, икенче кулы белән мине эләктереп, арканы сыдырырга тотынды. Бер сукса — зәһәр суга иде ул.

— Бар, күземә күренмә, оятсыз, алган җиреңә илтеп ташла! — ди.— Әгәр моннан соң кеше әйберсенә тисәң, кулыңны чабам да өзәм!

Ничек котылганны хәзер хәтерләмим, тик шул мунчаланы сөйрәп, тавышсыз гына елый-елый, ишегалдыннан чыгып тайганым гына истә калган. Әле һаман мышкылдаудан туктый алмыйча, тау астына килеп төштем. Мунчаланы тиз генә күлгә ташларга да инеш арыягына сызарга исәп. Баксам: күлнең икенче кырыенда Бәбекәй абзый мунчала кабыгын әйләндереп ята. Кара чәчле, каратут чырайлы карт кеше иде ул, әйбәт кеше иде.

— Нихәл, агай-эне? — ди бу. Бер миңа карый, бер мунчалага карый. Мин дә бер аңа, бер мунчалага карыйм: кая гына яшерәсе соң?..

— Ару әле...— дим, пышылдагандай гына итеп.

— Шулаймы?.. Кире китерденме? — ди ул, минем эшне шундук аңлап.

Бу да кыйнар инде дип, котларым чыгып, тик катып торам.

— Әтәй кушты...— дим, яшькә мөлдерәп.

— Һемм, атаң әйбәт кеше икән... Бик кирәгиемени соң? — ди бу, бер дә исе китмәгәндәй тынып-тынып кына.

— Чыбыркым җугые...

— Һемм, шулаймыни... Чыбыркысыз булмый шул каз көткән җегеткә... Бар, алайса, агай-эне, иш чыбыркыңны... Җитмәсә, тагын килеп сора...

Авызны тубалдай ачып, тик торам: юри әйтә бу, алдалый дип уйлыйм.

— Бар инде, бар, йөгер! — ди Бәбекәй абзый. Һәм мин аңа авыз эчемнән генә рәхмәт пышылдап, басма аркылы теге якка сыздым. Кычкырып әйтү мөмкин түгел: тамак төбемә утырган оятым кайнар бәрәнге кебек пешереп тора иде. Казларны эзләп табып, яннарына утырдым да шундук чыбыркы ишәргә тотындым. Өч киндерәдән ишкән бик шәп юан чыбыркы булып чыкты ул. Куш бармак юанлыгы талны бөгеп сап куйдым, өстеннән нечкә киндерә белән көрмәп чыктым. Ә кайтышлый Мөбәракша абыйларга кереп, чыбыркыга куе дегет сыладым. Менә кайчаннан бирле әтәйдән яшереп кенә тотам мин аны. Болынны яңгыратып бер шартлатып җибәрсәң, күңелләр ирәеп китә. Озын чыбыркыңны җилкәңә салып йөрү үзе ни тора! Ала каз бик этләнеп чаба башласа, тәпи тирәсенә чыбыркы очы белән генә берәр чәлтерәтеп алу да бик файдалы, шундук акылга утыра.

Каз көтүнең чын тәмен быел гына белеп киләм әле мин — бик рәхәт икән ул. Гел-гел каз сагалап кына тормыйсың, алар үз җайларына йөри бирәләр, ә без әз генә көн эсселәнү белән су керергә тотынабыз. Басмадан сикереп чуму, ярдан ярга йөзеп чыгу, арканча өзү, башны суга тыгып йөзү, урысча йөзү, кырын ятып йөзү, бер кулны өскә чыгарып йөзү, аяк белән йөзү, тагын әллә нинди йөзүләр, әллә нинди чумулар, су чәчрәтешеп, кул белән «куласа» әйләндереп уйнаулар кичкә хәтле дә бетми. Яр буенда маймучлар күрсәк, шунда ук ыштан балакларын төйнәп, балык сөзәргә керешәбез. Су коена-коена дердер калтырап бетәбез, «каз тәне» чыга, төс-битләр күгәрә, күзләр тонтенләнә, ә күтәрелеп карасаң, бөтен дөнья күм-күмгәк булып күренә. Инде тешләр шак-шок килеп бер-беренә орына башлагач, ярга чыгып кнемнәргә ташланасың, кайсыдыр усалы ыштан бавыңны тартып бәйләп, өстенә кат-кат төкерә-төкерә чиләндереп бетереп киткән була. Яр буенда ыштансыз чүгәләгән килеш дер калтыраудан еларга житешеп, «каз боты кимерергә» туры килә,— чиләнгән ыштан бавын теш белән чишәсең.

Аннары болын буйлап йөгереш китә — кем баш килә? Сикереш китә—кем ераграк сикерә? Олырак малайлар, гел хәрәмдәләшеп, безнен ишене бер дә баш китертмиләр. Шуннан аунап-тәгәрәп, мәтәлчек атып уйныйбыз, баш аркылы сикереш башлана. Олы малайлар тагын хәрәмдәләшә: без сикергәндә генә башларын калкыталар да безне егып төшерәләр. Уен тагын бетә. Түбәтәй белән бал корты тотарга керешәбез, балын салдырып алабыз, янәсе. Ул «без-безз» килеп аякларындагы «ипиен» түбәтәйгә сылап калдыра да очып китә. Ашап карыйбыз — бер дә әллә ни тәмле түгел. Соңыннан гына белдем: аның балы эчендә була икән, ә бу сары нәрсәне чәчәкләрдән балавыз өчен жыя икән корт.

Ул да булмый, сазлыктагы вак таллыкка кереп китәбез дә бер кочак нечкә чыбык сындырып чыгабыз. Яфракларын сыдырып сөкә ураGбез. Өлгергән сөкәләрне, текә ярлы тирәнрәк жиргә кереп, суга батырабыз. Андый жирдә бәртәс була, шуны эләктерәсе килә. Балыкларга комачау итмәс өчен ул тирәдән читкә китеп, бүтән уен табабыз. Бер дә булмаса, солдатка китүче никрутлар булып, кочаклашып җырлый-җырлый, болын буйлап «урам» әйләнәбез:

И алма бит, алма бит,
Алма битләр кала бит,
Алма битләр калмас иде —
Патша солдат ала бит...

Арадан берәү «гармун» уйный: бармакларын түшендә биетә, үзе авызы белән гармун тавышы чыгарып, «бут-бут-бут» килә. Икенче кулы белән «гармун»ның күрүген сузып-сузып тарта, шул ук вакытта «быг-гыр», «быг-гыр» иттереп аның «бакасын» да кычкырткалап куя. Шулай җырлый-җырлый әйләнеп килеп, сөкәләрне карыйбыз — билгеле инде: сукыр балык та кермәгән була. Тагын җырлашып китәбез.

Никрут булып йөрү дә туйдыра безне. Шуннан берсе әйтеп куя:

— Киттекме, жегетләр, Кара чишмәгә?

— Дабай киттек!

— Дабай!..

Һәм без, ыштан балакларын тездән югары ук сызганып, болын сазлыгын турыдан гына кистерәбез дә, Ышыяның борма дугайларын әйләнә-әйләнә, ерак Кара чишмәгә барып чыгабыз. Шул ераклык аркасында бу тирәгә Шәмәк малайлары да, Кабык күпернен урыс малайлары да килеп җитә алмый. Дегетләнгән төсле кап-кара майлы балчык эченнән чыга бу чишмә. Суы боз күк. Тирә-ягы гел түмгәклек кенә. Ә түмгәк араларында нинди генә кошның оясы юк, нинди генә йомыркалар юк! Аяз күк төсле сыек-зәңгәр, кыяк суы йөгерткәндәй яшькелт-сары, көл суына мангандай көрән-соры, шикәр төсле ап-ак, каләмфер чәчәгедәй алсу-шәмәхә, малайлар битедәй тутлы кара, тагын әллә нинди, әллә нинди төсләр. Шуларның бик күбесенә вак кына, матур гына тимгел-чуар бизәкләр төшкән. Ә кайбер ояларда яна гына дөньяга сары борыннарын төртеп, нәни генә кошчыклар ята. Шул оялык арасына килеп керденме, баш түбәндә тәкәрлек әйләнә башлый. Аның тавышы шундый зарлы, шундый инәлгеч булып ишетелә, әйтерсең ул: «Зинһар таптый күрмәгез! Зинһар тия күрмәгез! Анда минем оям! Минем оям!» — дип кычкыра. Туйдырып бетерә ул. Тагын бүтән төрле бик күп кошлар да түмгәк төпләреннән пырлап өскә күтәрелә, без аларның исемнәрен дә белеп бетерә алмыйбыз. Монда хәтта «сәликъ-бәликъ та була. (Акчарлакны бездә шулай атыйлар.) Алар парлашып, инеш буйлап очып узалар. Без аларны күрү белән: «Сәликъ балык алалмый! Сәликъ балык алалмый!» — дип такмаклый-такмаклый үртәп калабыз. Алар да монда оялап бала чыгара микәнни? Безнең арадан берәү дә белүче юк.

Түмгәктән түмгәккә атлый-атлый, оя саен тукталып, андагы күкәйләрнең бигрәк тә матурларын уч төпләребезгә салып карый-карый сокланып туйгач, баш очындагы кошлар тавышыннан колак тона башлагач, без ул сазлыктан чыгып китәбез. Берәү дә бер генә ояга да зыян китерми. Кызгана идек без аларны. Су ярындагы таллык арасына килеп кергәч, яңа шатлык табыла безгә. Тал төбендәге озын үлән арасында, күләгәгә качып, юп-юан балтырган көпшәсе үсеп утыра: төптән үк өзеп әрчисең дә авызга кабасың, йоп-йомшак! Кетерт-кетерт килеп авызда эри дә бетә. Шул тирәдә үк бармак юанлыгы әнис күренә. Ул да картаймаган, тач бал булып эри авызда. Аннан килеп баллы какы, «дусай печәне» табабыз. Аларны күп итеп җыеп, юл буе чәйни-чәйни кире борылып кайтабыз. Авыз кырыйлары көн буе печән ашаган малныкы төсле ямь-яшел булып беткән була!..

Менә шул «дөнья кизү»дән әйләнеп кайтканда безнең казлардан җилләр искән була инде. Анда чабабыз, монда йөгерәбез — юк, яр буенда калган «вак балыклардан» сорашабыз.

— Без күрмәдек... Чәмәкләр алып киткәндер,— диләр.

— Соң, күрмәгәч, каян беләсез?

— Ник, әнә Сәкъби әйткәние...

Сәкъбине эзлибез, ул юк, өенә кайтып киткән, имеш. Артыннан йөгереп барсак, чыннан да шулай булып чыга. Өч оя казны Шәмәк пуләвәе алып киткән. Гел малайлар белән йөри торган Каимә исемле бер кара кыз бу юлы да безгә ияргән иде — шунын казы, аннары минеке белән Гыйльметтиннеке. Шамил дә шул кызлар белән уйнап, берни карамаган.

Кич белән, бөтен малайлардан артка калып, борынны җиргә төртеп кенә өйгә кайтабыз... Анда инде билгеле. Каян белгәннәр, кем әйткән? Хәер, андый яман хәбәр алтмыш аяклы була, имеш. Яман хәбәр — алдан чабар дип тә әйтәләр бит әле. Әтәй сыртны яра инде дип торсам, алай ук булмады тагы, теле белән генә пешекләде. Шамилгә җилянгыр бөтенләй тимәде. Аңа нәрсә, ул бит ияреп кенә йөри. Ә мин олы малай — каз башлыгы. Сыртның каезланмый калуына Ләүхия җиңги сәбәпче булмады микән, ул бездә утыра иде. Гыйльметтин дә борынын салындырып безгә анасын эзләп килеп керде.

— Әһә-ә, эләктегезме!—дип көлеп куйды җиңги.— Менә аягүрә йоклап йөрсәгез, шулай булыр...

Иртәгесен түтәй аркылы гына өч күкәй сорап алдым да Гыйльметтин белән Шәмәккә чаптык. Ул да ыштан бөрмәсенә өчне кыстырган. Пуләвәй абзыйдан ялынып сорап, алты йомырканы сузгач, абзар капкасы ачылмый калмады. Иң элек муенын өскә сузып, «ка-ка-ка!» дигән булып, безнең ала каз килеп чыкты. Әз генә ояла да белми, ичмаса. Әйтерсең: «Ха-ха-ха!» дип көлә. Әллә миннән, әллә пуләвәйдән көлә. Хәер, ник пуләвәйдән булсын, миннән көлә инде ул зимагур! Өч күкәй бит.

Аның артыннан тәүлек буе ач яткан бәбкәләр атлый. Алары инде юанаеп килә торган матур тавыш белән: «Без бит ялгыш кына эләктек, ачуланма инде...» дигән төсле юаш кына итеп миңа эндәшәләр, минем ачу да язылып китә. Алып кайтканда аларны куып маташу кирәкми— үзләре йөгерә-йөгерә кайталар. Ә без Гыйльметтин белән артларыннан чак өлгерәбез.

Мондый хәлдән соң мин аларны авылның бөтенләй икенче ягындагы Әчекүл болынында көтә башладым. Анда тагын шул ук бәла икән: Шыя арыягына чыккач та Дусай басуы башланып китә. Әллә ниткән безнең авыл: Дусай белән Шәмәк арасына кергән дә кысылган, тын алыр хәл дә юк...

# Яшь әнәй килде...



Сабан урагына төшкәндә тутәйнең күзләре бик каты авырта башлады. Ул баш күтәреп, көн яктысына да карый алмый: чәнчә, сызлый, ди. Иртәгесен эренгә ябышып каткан керфекләрен ача алмыйча җелеге кибә. Ә бөгелеп урак урганда бакыра башлады, алабута койрыклары бәрелүдән ике күзе дә кып-кызыл булып, бөтенләй кан сава башлады. Безнең кендек әбиебез Гыйльмевафаттәй өшкереп биргән дарулар да ярамады. Ә больнис алты чакрымдагы урыс авылында. Уттай эш өстендә кем барып йөрсен анда.

Әтәйнең шахта күзлеге булган икән. Аны кыл иләгенеке төсләрәк тимер челтәрдән ясаганнар; һәр күзе кап-кара түгәрәк булып, өскә бүлтәеп тора. Тутәй уракка шуны киеп йөри башлады. Бик күпләр сәерсенеп карап кала иде аның артыннан. Ә иртә-кичне «күкфараз» суы белән юа иде ул күзләрен. Аның әчеттерүенә чыдый алмыйча, урлекырлы сикергән чаклары күп булды аның.

Ничек кенә булмасын, сабан урагы да бетте, барлы-юклы киндер белән житен дә йолкынды, иген дә булганы белән ындырга керде, бәрәңге дә алынды. Шул көз көннәре килгәч, тутәйнең күзләре дә савыкты. Шул ук көздә әтәй әлеге теге Шәмәк кызы Шәмсебануга яучы җибәреп, туйлап өйләнде.

Ни булса булды, без хәзер яшь аналы булдык. Шул караңгы түбән өйгә аршин башлы чүпләм сөлгеләр, кижеле тастымаллар, чиккән кашагалар, яңа өлеңгеләр эленде. Әтәй ясаган яңа өстәлгә бик матур ашъяулык җәелде, идән-сәкеләр сап-сары итеп юылды. Хәер, аларын тутәй элек тә шулай әйбәт итеп юып чыгара иде, яшь әнәй тагын да шәбрәк итәргә тырышты, пычрак аяк белән идәнгә басу бетте, чабатаны ишек төбендә салып калдыра башладык, я булмаса, такталар өстеннән генә йөрибез. Өй эче, чынлап та, ямьләнеп, яктырып киткәндәй булды хәзер. Яшь ананы без ачык йөз белән каршыладык. Әнәй дип, елмаеп кына эндәшә торган булдык, Шамил хәтта бер тапкыр алдына да менеп утырган иде, тик әнәй кешее генә бик ул хәтле эреп төшмәде. Хәер, ул бит әле яңа кеше, ияләшеп тә җитмәгән, ятсына да торгандыр. Шуна күрә без аны сагызланып бик йөдәтмәскә булдык, Шамил дә кабат аның алдына менеп борчымады...

Тора-бара без, нечектер, үзебез дә сизмәстән, юашланып киттек. Нигәдер үзебезне һәр вакыт гаепле сыман итеп тоя башладык. Өй эче хәзер кискен рәвештә икегә бүленде. Олы якта — әтәй белән әнәй икесе, кече якта — без өчәү. Күнелләр дә, уйлар да, нишләптер, шулай бүленгән. Мондый араланыш бер дә рәхәт түгел икән. Ярый әле, кыш җитте. Кар төшү белән мәдрәсәгә киттем. Анда малайлар куныптөнеп яталар. Өе бер генә булып, бала-чагасы ишле кешегә бу мәдрәсә дигәнең бик уңайлы котылгыч урындыр, ахры. Шундый кеше малайлары бик күп куна монда. Мин дә, әтәйдән рөхсәт алып, шунда куна башладым һәм бик рәхәт булып китте. Мин инде әлтияк иҗеклим, язу-сызуны да шактый танып килəм, укуның кызыгын быел бигрәк тә таба башладым шикелле. Әбугалисинә турында да әтәйдәнме, кемнәндер ишеттем. Ул мәдрәсәгә килеп керер алдыннан аның көн дә утыра торган киезе астына шәкертләр бер табак кәгазь җәеп салганнар. Килеп утыргач, түшәмгә карап-карап торган да: «Әллә түшәм түбән төшкән, әллә идән күтәрелгән бүген», дигән, имеш. Аның шундый зирәк, шундый зиһенле булуына мин таң калдым. Үземнең дә шундый буласы килә башлады. Андый булу өчен бик нык уку кирәк икән шул. Ә безнең Гаяз хәзрәт рәтләп укытмый. Соң гына кереп, кичәге сабакларны аннан-моннан тыңлаттыра да, ашык-пошык кына яңа сабак биреп, тагын чыгып китә. Ә без ни теләсәк шуны эшләргә тотынабыз.

Берәүләр идәндәге ботакка кадак сугып тишек ясыйлар да шунда күкерт тутырып шартлаталар — зерә кызык! Икенче урында «андалай» салалар. Мөке Пәләхиенең Исрае бик шәп шәмәхә хәрендәш алып килгән. Ун малайдан берәр тиен җыеп, бәләкәй генә ун кәгазьне бөтереп, тегеләр күз алдында түбәтәйгә санап сала да шуны сикертә башлый. Акча түләгән малайлар түбәтәйдән шул «андалай» (лоторея)-ны бик житди кыяфәт белән берәм-берәм тартып алалар, сүтеп карыйлар — барысының да кәгазе буш. Иң ахырдан Исрай кәгазьне үзе тартып чыгара. Сүтәләр — кәгазь уртасында божра сурәте. Димәк, карандашны үзе отты! «Хәрәмдәләште!», «Алдалады, Мөке тәре!..», «Бармак арасына кысып калган ул аны!» дигән тавыш китә. Ә теге, чынлап та, шундыйрак мут малай. Шуның өстенә яше дә бар, буе да бар. Аларның ай-ваена төкереп тә бирми.

Бусы басылуга мич артындагы «әчелек» тирәсендә шау-шу китә. Барсак, Сабирҗан Мөбәрәгенең итегенә «олтан» салалар икән. Ул озын буйлы, юаш, тилемсәрәк малай, атасының олтанлы олы итеген киеп килгән. Шуның әле берсен, әле икенчесен, ике кунычыннан тотып, шап-шоп идәнгә сугалар. Теләгәнчә нык шапылдамаса, әчелектәге пычракка манчып сугалар. Шулай шапылдата торгач, итекнең олтаны кубып төшә. Менә шул «олтан салу» була инде. Калган малайлар итек, чабаталарын асларына яшереп утыра башлыйлар.

Төн буе да йокламыйбыз без. Кичтән мендәр белән сугышып, киезләрне яшерешеп ду килгәч, лампа мае бетә дә, стена буйлата тезелешеп ятабыз. Әкиятләрнең иң тузга язмаганнарын сөйләү китә. Кайбер малай үзеннән чыгарып маташкан була, икенчесе аны шунда ук бүлдереп, тагын да тозсызракны лыкылдарга керешә. Шул чакта берәр малайның йоклап киткәнен сизеп алсалар, күршеләре хәзер үк мичтән көл учлап киләләр дә тегенең ыштан бөрмәсенә сибәләр, шуның өстенә су җибәрәләр. Малай куркып уяна да үкереп елый башлый... Шулай этләшеп таң ата. Икенче көнне тагын шул ук...

Юк, болай булмый. Монда яту бик кызык сыман тоелса да, гыйлем алу мөмкин түгел. Белгәненне дә онытып бетерерсең — шул булыр. Моны әтәй дә сизеп йөри икән. Аның мине укытасы, тиз арада күп гыйлем алдырасы килә иде. Мәдрәсәдән кайткан саен бик җентекләп сабакны тыңлаттыра, язуны карый. Ә минем алга китеш әллә ни күренми...

Ул Гаяз хәзрәтне болай да яратмый иде. «Ялкау да ул, надан да ул» дигәнен әллә ничә тапкыр ишеткәнем бар. Мәчеттә мулланың үзенә дә әйтеп караган, имеш: «Тырыштырыбрак укыт, хәзрәт, балаларны», дигән. Аның сүзен берничә карт та җөпләгән, имеш. Тик файдасы гына булмады, шул ук хәл дәвам итте. Ә хәзрәт миңа рәтләп сабак та бирми башлады.

Шуннан соң мине әтәй мәдрәсәдән бөтенләй алды. Мин хәзер өйдә чабата ясарга утырдым. Ә чабата ясарга мине Мактый бабай белән Гаптулла абый өйрәтте. Мин аны тугыз юкадән дә ясый беләм. Минем чабатаны түтәй бик яратып кия. «Чибәр ясыйсың, ди, нык була», ди. Чабата ясау гына зур нәрсә түгел шул, өстәвенә тагы бик вак эш. Көн буена бер кием чабата белән утырырга кирәк.

Көтмәгәндә минем өчен тау хәтле куаныч туды. Инде бу кышта бөтенләй укымый калам дип торганда гына мине Шәмәккә җибәрделәр. Шәмәк мәдрәсәсендә укырга! Белмим, моңа әтәйнең үз башы җиттеме, әллә яшь әнәй киңәше белән эшләде микән? Карасана, ул өйрәткән булса, бик тә әйбәт бит әле бу: мине чит күрми дигән сүз! Үзе, мескен, китап танымаса да, хәтта үги малаеның укуын тели булып чыга. Күңеле яхшыда икән!..

Үги әнәйнең үги анасы Мәүлихә әбидә торып укый башладым. Шәмәкнең түбән урамында зур гына таш мәдрәсә бар икән. Ул икегә бүленгән: ишектән кергәч тә, беренче ягы суык, буш тора, эчкәре ягында без укыйбыз. Түбән Тәкәнештән килгән Афзал хәлфә укыта, әйбәт укыта, имеш. Башка авыллардан да шәкертләр бар, аларның бер унлабы шул ук мәдрәсәдә тора, шунда үзләре пешереп, үзләре ашап-эчеп, үзләре туеналар. Араларында егет булып килә торганнары да күренгәли.

Афзал хәлфә ике малае белән үзе дә шул мәдрәсәнең бер почмагындагы такта бүлмәдә яши. Авыл малайлары да сыйган хәтле шунда куныл-төнеп яталар. Урын тар «әлеп»[1] булып сузылып ятканда тына сыябыз. Монда малайлар мине «чит бүре» итеп каршыламады, бик тиз аралашып киттем. Хәер, монда тәртип тә шәп куелган иде шул: хәлфә абзыйның камчысы һәр вакыт янында була, үзе көн буена мәдрәсәдән өзелми, түшәмдә тал чыбыклары да бик матур тезелеп торалар. Шуның өстенә минем «терәк» тә бар: яшь әбинең Хәмидулла исемле олы малае шушында укый, Мөбәракша абыйның миннән биш яшькә олырак Мәхмүте дә монда йөри башлады. Иртән килеп, кич кайтып йөрсә дә, көн буе шушында була. Усал малайлардан бер дә куркасы юк.

Бу мәдрәсәдә мин әптиякне бетереп, коръәнгә төштем, аны ижекләп чәйнисе түгел, көйләп укыйсы. «Фәзаиле шөһүр»гә кердем. Теле бик авыр булса да, сукаларга тырышам. Тик бу китапның исеме генә нәрсә дигән сүздер, белмим. Сорасаң — наданлыгыннан көләчәкләр. Намаз ниргәләрен дә бик яхшылап өйрәндем. Көнәнә биш тапкыр намаз да калмый бит әле. Көндезге сабак беткәч, ашап-эчеп килгәннән соң, кичкесен өйрәнергә тотынабыз. «Күрми сабак» дип атала ул. Әптияктәге кыска сүрәләрне хәлфә абзый мәчеттән кайтканчы чайкала-чайкала такмаклап ятлыйбыз да аннары каршына тезләнеп тыңлатабыз. Белмәүче, буталып калучы малайларны аның камчысы өйрәтә. Бу да беткәч, язу-сызуга керешәбез. Мин дә, олы шәкертләрдән күрмәкче, «әвәл алдым» яза башладым.

«Әүвәл алдым түлки тириси бәһаси торадур ики сум да алтмыш тиен янә алдым сарык тириси илән кәҗә тириси бәһаси торадур бер сум да туксан үч тиен...» дип, үзең теләгәнчә күпмедер тезеп китәсең дә, ахырда килеп: «җәмгыси уладур екерми тукыз сум да житмеш тиен кемеш...» дигән нәтиҗә чыгарып куясың. Бу, үзенә күрә, бердәнбер дөньяви сабак. Монда исәп-хисапка сәләтең дә, җөмлә төзә белүең дә, дөресме-хатамы язуың да күренергә тиеш. Тыныш билгеләре дә булмады иске мәдрәсәдә: язмаңың башыннан ахырына хәтле бер ноктасыз, бер өтерсез тезеп бара идек....

Кич саен миң «әвәл алдым»ны ике бит тутырып язам да хәлфәгә китереп күрсәтәм. Ул күз йөгертеп кенә чыга да кире бирә, әйбәт булган, ди, шуның белән эш бетә — хаталарыңны күрсәтеп тору юк. Болардан тыш мин монда «түгәрәк ясин» язарга да өйрәндем. Ул чактагы бер табаклы кәгазьне (хәзерге дәфтәрнең дүрт бит) өчкә бөкләп, ике бармак иллелеге итеп кенә кыруыннан кисеп аласың да, шул тар гына дүрт почмаклы кәгазьгә ясин сүрәсен язасың. Вак кына хәрефләр белән буйдан-буйга әйләнеп язарга кирәк. Сүрә шунда сыеп бетәргә тиеш. Бу инде бер осталык булып санала. «Ул түгәрәк ясин да яза белә!» дип, гыйлем дәрәҗәңне шуның белән билгели башлыйлар. Язып бетергәч, аны бер дә сүтелми торган өч почмаклы бөти итеп төрәсең. Бу изге бөтине муенына тагыпмы, күлмәк инеченә тегепме йөрткән кешегә пәри-җен зәхмәте кагылмый, бүтән төрле хәвеф-хәтәрдән дә имин була. Балаларга күз тиюдән, корчаңгы йогудан да саклый.

---

[1] Әлеп — иске әлифбаның беренче хәрефе — туры бер сызык.

Анын хакы торадыр биш тиен. Тик алучысын гына каян табарга? Минем калайлы-тимерле бәләкәй яшел сандык төбендә инде биш бөти ята, әле берсен дә сата алган юк.

Шулай да үз хәлемнән зарланмыйм: монда килгәннән бирле ике кулга бер эш — уку. Ә укуның нинди авырлыгы бар? Юк. сөяк сынарлык, бил биртелерлек түгел. Атнага ике ипи ашыйм. Орлык ташы хәтле булмаса да, бик бәләкәйдән дә түгел. Берсен ашап бетергәнче икенчесе киштәдә катып бетә. Сохари шикелле кетердәтеп кимерәм.

Шәкерт нигә симерә?
Каткан ипи кимерә.
Каткан ипи ярар иде,
Ул да булмый тилмерә.—

дигән бәетне дә белеп алдым. Ләкин мин алай ачыкмыйм. Җомга саен өйгә кайтып килгәндә аш пешерерлек нәрсәләр дә җибәрәләр, кайчакта атнага бер чирек каз да эләгеп куя, чәй-шикәр дә кыстыргалыйлар. Хәтта биш тиен акчасын да кызганмый этәй: хәлфә абзыйга сәдака итеп бирергә куша.

Яшь әби — тол хатын. Анын ире күптән үлгән. Аннан калган ике кызын, ике малаен инде житлектереп килә. Мин бу бәләкәй иске өйдә бөтенләй чит малай булсам да, алар миңа кырын карамыйлар. Минем өчен шунысы бик житкән. Мин бит аларга беркем дә түгел.

Ә менә тутәй белән Шамилнең хәле шәптән түгел икән. Кайткан саен күңел боегып килә. Яшь әнәйдән бик зарлана тутәй: «Төксе, ди, каты телле»,— ди. «Ник суда шул хәтле озак тордың, аягың череп актымәллә?» дип әйтә ди. «Эш мәнесе белмисен, тавык мие эчкән нәстә», дип хурлый ди. Әз генә эштән арынсаң: «Ник терәлеп каттың теләүлек шикелле!» дип кычкыра ди. Ә Шамилгә бөтенләй көн юк икән. Ике бармак мөгезе белән маңгаена гына төртә, имеш. Ул малай гел почмакка сеңгән хәзер. Хәер, икесе дә кече як почмагына посканнар. Тутәй белән иркенләп сөйләшер урын да юк безнең. Ишегалдында утын яргандә, мал асты караганда гына күпме сөйләшеп була. Ярый әле, кышкы озын төн бар. Ятарга мөмкин булу белән әлеге иске җылы толып астына чумабыз. Аска иске бишмәт, баш астында өчебезгә ике мендәр, безгә бик житә. Бер-беребезгә сыенышып, өчебез дә кочаклашабыз. Еллар буе күрешмәгәндәй сагынышканбыз. Ничектер татлы да, әрнүле дә булган эссе тамчылар битләргә тия. Олы як белән безне зур сандык аера. Ул якта хәзер аулак чәе эчәләр, без толыпны баштанаяк бөркәнеп, әкрен генә пышылдаша башлыйбыз. Әнәйне сагыну сүзләре бетмәс-төкәнмәс татлы жырыбызга әйләнә безнең. Хәтта Шамил дә: «Әй, үзебезнең әнәй булса...» дип куя. Ул нәрсә белә инде? Әнәйдән калганда ике яшь тә тулмаган иде бит аңа! Күрәсең, анын да үзәге өзелә торгандыр. Шулай да ул озакка түзми, шушы рәхәт урталыкта изрәп йокыга китә. Ә без әле өченче этәчкә хәтле пышылдаудан туктамыйбыз. «Анын иң үзәккә үткәне шул,— ди тутәй,— печтек кенә бер нәрсә булса да, шуны тау хәтле итеп әтәйгә әләкли. Ә ул — безгә тотына. Гел ялган булса да авыз ачып бер җавап кайтарып булмый, куркам мин әтәйдән, барын да эчкә йотарга туры килә. Кыр казларын таный алам «кыйгак» дигән тавыштан. Эчләремә кату тулды яшьләй күргән сагыштан, дигән жыру да чыгардым инде, ылан. Эчемнән генә гел шуны жырлап йөрим...» ди.

Мин анын күңелен юатырдай бер сүз дә әйтә алмыйм. Хәер, безнең күңелләрдә дә, иртәгә туасы көндә дә бер якты юаныч күренми шул. Нәрсә әйтәсең? Без бит әле яшь ана белән тора гына башладык, алда ни булыр? Алда ниләр күрәсебез бар икән?..

# Төшемә дә кермәгән иде...



Җәй башында этәй тагын читкә чыкты. Бу юлы «Кәтернислау» ягына (хәзерге Донбасс). Этәй киткәч озак та тормыйча, яшь әнәйнең беренче баласы туды — ир малай. Ана Лотфулла дип исем куштык. Ул малай бишеккә ята башлагач та безнең кулга күчте. Көндез дә без карыйбыз, төнлә дә без тирбәтәбез. Бишек безнең аяк очында, ә тирбәтә торган бавы түтәй балтырында.

Эш өсте килеп житте. Әнәй белән түтәй уракка чыктылар. Лотфулланы карарга мин дә йөрим, Шамил каз карый. Лотфулла арбада йоклаган арада урак урырга өйрәнәм. Мин ашаганда кашыкны уң кул белән тотам, язуны да уң кул белән язарга өйрәнгән идем, ә менә урак ура башлагач, сулагай булып чыктым. Белмим, уракны кире ягы белән тотканга мы, арыш камылын кистерә алмыйча теңкә корый. Учма төбе чуалчыкланып бетә. Мин урып бәйләгән көлтә дә пәри курчагына охшый, аның төбен янадан тигезләп кисәргә туры килә. Шулай өченче көлтәне урып азаплана идем, уң кулның чәнти бармак өстен шытырдатып кисеп җибәрдем, тырнакны да урталай ярганмын, күшәрелеп кан китте. Ярый әле, түтәй туфрак сипте дә, ниндидер иске чүпрәк табып, бәйләп куйды. Кан тиз генә туктамады, уруның бөтенләй рәте бетте.

Әнәйгә шул житә калды:

— Ник бөкрәйгән көйгә йоклыйсың? Кызурак кыймылта, үләмәт! — диде ул тәмле теле белән. Аннары, үзалдына сөйләнгәндәй, тагын байтак сүзләр өстәде. Аның бу тиргәвеннән үземне гаепле санап, ялан тәпине камыл чәнчүенә, балтырны билчән чагуына да карамыйча, ашык-пошык урып кына ята идем, уч кырыен тагын уеп алдым. Ул хәзер бөтенләй алып биреп китте:

— Җебегән сыер б...! — дип кычкырды.— Булмастайны балга буясаң да эт яламас! — диде. Шушы әрәмтамак, әдәм имгәкләре белән чиләнеп ят инде! — дип зарланды. «Үксез бозау асрасаң...»ны да әйтте. Кичкә хәтле дулады ул. Шулай ачуы кабарганда аның битләре тимгелләнеп чыга иде.

Көн буе ура торгач, бил авыртуына чыдап булмый башлый. Берәр минутка гына тураеп, билне язып аласы килә. Сизеп торам, түтәйнең дә бик авырта биле. Мин әле бер хәл: бәхеткә, Лотфулла елый башласа, аны тирбәтеп киләм, ә түтәйнең көн буе баш калкытканы юк бит. Бик ялыккач, көлтәсен озаграк бәйли ул. Аннары, билен турайтып, ашыкмыйчарак кына көлтә бавы ясарга тотына. Әнәйнең уттай очлы күзләре моны шунда ук күреп ала һәм зәһәр уклары түтәй өстенә ява башлый.

— Ник шаңкаеп каттың, сайбата шикелле! Тавиле чиркәвенең машы түгелдерсең бит! Басудагы Түлбай кешесенә генә түгел, Кабык күпер маржаларына да күренә торгандыр синең ул шөкәтсез сының!..

Шундый канатлы сүзләр тагын санап бетергесез була әле. Ул чакта боларны ишетү бик авыр тоелса да, хәзер минем ана хәтта рәхмәт әйтәсем килә: чөнки бик күп мәкальләрне, бик үткен әйтемнәрне иң беренче тапкыр аның авызыннан ишеттем...

Шул урак өстендә сугыш чыкты. Безнең патша белән Герман патшасы сугыша башлаган. Көпә-көндез бөтен кеше басудан авылга агылды. Елаш та сыкташ китте.

Без дә соңга калып кына җир өстеннән чыктык. Болай вакытсыз кайтырга теләмәгән әнәй нидер мыгырданып та алды. Моның сәбәбе шул: безнең өйдән солдатка китәсе, озатып каласы кеше юк. Шулай да берүзе басу уртасында сураеп калырга йөрәге җитмәде аның, кеше сүзе бар бит...

Авыл өстендә зар гүелдәве, күз яше. Ләкин кеше хәсрәте безгә бөтен ачылыгы белән килеп җитми, күңелдә тик сугыштан куркыну гына бар. Әтәй безнең никрут булып каралганда ук буе җитмичә, «пу-чистый»[1] калган. «Бәләкәй Пәрхулла» дигән кушаматы да бар иң. Хәзер аның яше дә олы инде, андыйларны алмыйлар икән. Шул сәбәпле безгә бер куркыныч та юк. Иртәгесен яңадан басуда булдык, башкалар да күренгәли башлады.

Әлеге дә баягы бер имана җирнең эшен бетереп тә ташладык. Мин инде хәсрәт кенә. Ундүрт яше белән бара торган түтәйнең дә буыннары ныгып җитмәгән әле. Ә менә үги әнәй җен күк эшли безнең. Теләсә нинди эшкә шундый каты куллы, шундый җитез ул — аңа ни-җитте кеше тиңләшә торган түгел. Үзебезнекен бетергәч, кешегә урыштык. Шуның белән әнәй каты суканы сукалатты, көзге чәчүне чәчтерде.

Мөбаракша абыйның Мәхмүте күптән инде чүбек җыярга керешкән иде. Көзен мине дә әнәй шуңар ияртеп чыгарып җибәрде. «Безнең Җуныс абыйлар шуннан гына баеп киткән!» — диде. Капчык бәйләгән бәләкәй арба тартып, авылдан авылга йөрибез. Урамның бер ягыннан өй борынча кереп Мәхмүт бара, икенче ягыннан — мин.

— Чүбек бармы-ы?

— Иске бияләй, иске оекбаш та ярый-й! — дип кычкырабыз.

Булган кешеләрнең чүбеген иске яулыкка төйнәтеп, ыргак бизмән белән үлчибез дә капчыкларга аударабыз. Ике гөрәнкәсенә өч тиен акча түлибез. Кайчакларда дөңгечләп тутырган икешәр олы капчык чүбек җыеп кайтырга туры килә. Иртәгесен шул чүбекләрне Тәкәнешнең Миргазизгә менгерәбез. Ул кеше безнең бу тирәдә шактый зур сәүдәгәр. Аның комач кибете белән бергә, авыл кешесенә кирәкле бөтен товарлар бар. Тире-яры, сус-йон, иске-москы, чүпрәк-чапрак җыю белән дә шөгыльләнә, лапасында тау хәтле чүбек була. Без дә чүбекнең гөрәнкәсен өч тиеннән шунда китереп селкәбез капчыкларны. Күрдегезме, акча балалатабыз! Бер тиенгә — бер тиен балалый! Эшләр болай барса, тиздән үзебез дә бик баеп китеп, Миргазиздәй данлыклы сәүдәгәр булачагыбыз күңелне кытыклый башлый.

Без татар авылларында гына йөрибез. Ә чүбек дигәнең урыс авылында да тулып ята торгандыр бит, шуны ничек җыярга? Бер көнне Ишки ягыннан кайтканда Тауиле аркылы узарга туры килде. Бу — урыс авылы, волость конторы да шушында. Бик җыясы килә, ә икебезгә бер авыз урысча белмибез. Мәхмүт шулай да «Ухлупке жич?» дигән сүзне өйрәнеп алган икән, миңа да аңлатты. Киттек урамның ике ягыннан.

— Ухлупке жичме? — дип кычкырабыз.

Маржалар ишегалдына чыга да аптырап тора.

— Ухлупке, ухлупке! — дип кабатлыйбыз, капчыктагы чүбекне күрсәтеп.

Кайберләре төшенеп ала да булганын чыгарып бирә. Шулай ермачлый торгач, капчыкларны тәки тутырдык. Авылны чыгып килгәндә бер капка төбендә бик күп бала-чага шау-гөж уйнап утыра. Мәхмүт аларга каерылып карап узды да:

— Күр әле, бот буе гына маржа кызы өздереп урысча сөйләшә бит! — диде.— Ә без күсәк буе малайлар булып та бернәрсә белмибез!..

Мин дә бик гаҗәпләндем моңа. «Шулар шикелле белсәңие!» дип кызыктым, тик авылны чыккач кына искә төште дә:

— И җүләр инде без, име? — дип көлеп җибәрдем.— Соң маржа кызы урысча сөйләмичә, кемчә сөйләсен инде?..

---

[1] Бөтенләй котылган.

Мәхмүт, сискәнгәндәй башын борып, миңа карады, ләкин көлмәде. Ул бик олыларча күренергә ярата иде...

Бу йөрүләргә мин шактый нәләшә башлаган идем инде, тик кыш кергәч тукта́рга туры килде, кышкы суыкта авылдан авылга йөрергә өс-баш юк иде. Ә өйдә яту бик туйдыра икән. Әнәй кешенең татлы сүзләрен ишетмәс өчен гел күңелне биклап, гаепле кешедәй дәшмитынмый, уйнамый-көлми яшәргә кирәк. Сизеп торабыз: аның үзенә дә без «күз көеге», «җан көеге» генә. Бу сүзләрне ул безгә шактый еш кабатлый һәм мөмкин булса, бер көн эчендә безне төрле тарафка очырып та бетерер иде.

Шуны белгәнгә күрә, бик әйбәтләп кенә бер көнне мин аңардан быел да Шәмәккә укырга җибәрүен сорадым. Барыбер чүбеккә дә йөреп булмый, тик ятыла бит, дидем. Мәхмүт тә тагын йөри башлый икән, дип өстәдем. Башта тимгелләнеп битләре бүртенде, дуларга кереште, аннары Мәхмүтнең чынлап та укырга йөрүен Олы җингидән үзе белешкәч, җибәрәсе итте. Шулай итеп, мин тагын Шәмәктә, яшь әбиләрдә торып укый башладым. Дөресен әйткәндә, әнәйнең үги анасы үзенең үги кызына караганда яхшырак. Ул, ичмаса, ярату күрсәтмәсә дә, дошманлык күрсәтми, юк-барга бәйләнми.

Мин бу кышта да шул ук коръәнне сукаладым, олы калын китап «Кыйссасел әнбия»га кердем. Пәйгамбәрләр хикиятен уку бик күңелле булып китте. Шуның өстенә кызлар хаты язарга өйрәндем. Уртасына: «...И җанымның җаны оҗмах хуры дөнья нуры күзем карасы күңелем парасы» дигән тәмле сүзләрне бер ноктасыз язып тутыргач, кырыйларына кыйгачлап җыру тезәсең, белгәннәре җитмәсә, үзеңнән дә чыгаргалыйсың. Тик тагын бәла: хатның хакы биш тиен, әмма бер тиенгә дә алучы табылмый. Ник дисәң, авылда егетләр юк — бары да сугышта. «Шыбыр-шыбыр яңгыр ява өй түбәсе калайга. Без китәбез, кызлар кала борыны юеш малайга» дигән җыру да чыкты бит инде...

Быелгы укуның файдасы шул булды — өйдә ятарга туры килмәде. Түтәй белән Шамил татыганнар мине читләтеп узды. Яз килеп, көннәр җылыту белән сабакны ташладым да тагын чүбек җыярга чыгып киттем. Ә Мәхмүт вак сату алып җибәрде. Җыйнак кына кызыл сандыгына йөз төрле кыты-мыты тутыра да дөнья гизеп йөри. Мин дә кызыгып куям мона, тик булдырып булмас. Мәхмүт бит хәзер олы малай ул,— унбиш тутырган, ә миңа — ун гына әле. Аннары акчасы да песи төкерәге бит әле аның. Өч пот чүбек җыеп сатканда да өч тәңкә дә алтмыш тиен сума була, аның белән нәрсә кырасың, алган товарың сандык төбен капларга да җитмәс. Ә суманы шул өч тәңкәдән югары үстереп булмый, артканын әнәй йорт расхутына тота тора. Әтәй дә күбрәк итеп акча җибәрми, ичмаса.

Әтәй дигәннән, җир-су кипкәндә ул үзе кайтып төште. Эшләре уң булып бетмәде микән — акча белән кайтканлыгы сизелмәде, безгә бүләк-салак та юк иде, яшь әнәйгә бер күлмәк, шуның белән вәссәләм. Күрәсең, кулына мал төшмәсә дә, яшь әнәйне сагынып кайткандыр.

Ул минем чүбек җыеп йөрүгә каршы бер сүз дә әйтмәде. Алай гына да түгел, ун яшьлек олы малаеның инде «эшкә ярый» башлавына, җитмәсә тагын, «акча табарлык», «башлы» булуына сөенеп тә куйды бугай әле, миңа шулайрак сизелде. Чүбек ташый торган бәләкәй арбаның сынык тәртәсен төзәтеп, кырыйларына җиңел генә үрәчә куеп бирде. Бу мине тагын да канатландырып җибәрде. Көн-төн авылларда чабам, кайчакта өчәр капчык чүбек тартып кайтам. Шәмәк, Чәбия, Арбаш буйларында еш йөргәнгәме, мине анда хәзер шаярта да башладылар. Шул яклардан җыеп кайткан чүбекне бушатканда, капчык эченнән олы гына кирпеч кисәге килеп чыга, әллә өч кадак бар тагы! Ә кайчакта иске бишмәт җиңе, төбе ярты́лаш ашалып беткән тирән

резин галош сынары тыгып җибәрәләр. Моны инде, мөгаен, үсмер «чыпчыклар» маташтыра, «кызлар кызык итә», янәсе.

Анда йөргәндә тамак кайгысы да булмый, авыл саен ниндидер кардәш-ыру, ерак бер чыбык очы, я булмаса шунда кияүгә барган безнең авыл кызы табыла. Шундыйларга кереп, «исәнме, саумы, фәлән түтәй», дигән тәмле теленне кызганмасаң, алар үзләренчә кунак итеп чыгаралар, һич югында, бәрәңгесе белән ипие туйганчы ашарлык була.

Чүбек арбасы шулай шома гына тәгәрәгәндә, минем уема түгел, төшемә дә кермәгән бер яңалык килеп чыкты. Халык печәнгә төшәр алдыннан гына әтәй тагын читкә китәсе итте. Шул хәтле тиз! Шуның өстенә яшь бикәчне ташлап?.. Шуның өстенә борын төбендә җәйге эш! Шуның өстенә үзе белән мине дә читкә алып китә! «Тамагың узар, урысча өйрәнерсең», ди. Ул чакта мин боларның барын да төптән-җирдән аңлый белми идем әле. Минем башта: «Читкә китәм!» дигән куаныч кына чыңлап торды. Күрәсең, әтәйнең читкә бу хәтле еш йөрүе, теге чакта безнең әнәйне хаста килеш калдырып, хәтта хәзерге яшь бикәченнән дә аерылып, борын төбендәге эшне дә ташлап чыгып китүе — читне яратканнан гына булмагандыр. Күрәсең, мине нәртүе дә тиктомалдан гына килеп чыкмагандыр. Күрәсең, минем «акча балалату» да ул хәтле өмет бирерлек нәрсә булмагандыр. Күрәсең, олылар үзара барын да сөйләшенгәннәрдер. Күрәсең, дөнья шулай кушкандыр...

Озак җыенасы булмады. Ашъяулыкка өч кесәллек күмәче белән, каяндыр юнәтеп, бер-ике гөрәнкә сарык ите пешереп төйнәделәр дә капчыкка тыктылар, аннары чәй-шикәр, бер кат күлмәк-ыштан, аяк-чу, юл киезе белән күпчек, бишмәт... Кичке караңгыда Мәхмүт үзләренең атына Мөхлис абыйның тимерхутын җигеп килде. Түтәй белән Шамил, икесе ике кулдан җитәкләп, елый-елый озата чыкты. Без тарантастагы кабарынкы печән өстенә менеп утырдык, Мәхмүт «атбашы»на урнашты. Яшь әнәй, шыгырдатмаска тырышып кына, җил капканы ачты.

— Аллага тапшырдык,— диде әтәй.— Исән-аман торыгыз...

Чыгып киттек. Түтәй белән Шамил, һаман үкси-үкси, капка төбендә басып калды. Ә минем бер дә андый тойгы юк, бер дә еласы килми иде. Эч тулы шатлык кына: мин бит читкә китәм, читкә!..

## Шушы микәнни ул...

Бездән әллә кайдагы еракта Мамадыш дигән өяз каласы булуын ишеткәнем бар. Аның якын түгеллеге шуннан да билгеле: безнең авылның йон тетүче Низамый абзый, гомерендә бер тапкыр шул Мамадыш хәтле Мамадышка баргач, урамында адашып калган, «Тулбайга юл каян китә монда?» дип, тәрәзә саен сорап йөргән, имеш. Шулай адашып, әллә кайсы якка китеп барганда Низамый абзыйга күршенең Дусай кешеләре очраган, юл буе үрәчәләренә ябышып кайткан. «Яңа күпер» урамнан Тулбай күренгәч кенә: «Ник бу безнең авыл түгелме соң?» — дип куйган, имеш. Дөрес, моны көлеп сөйләгән булалар, ә шуларның үзләрен җибәрсән?.. Бер дә аннан артык була алмаслар иде әле!

Без барасы Сукулкы пристанена Мамадыш аркылы узасы икән, аннан ике тапкыр ераграк — алтмыш биш чакрымда ди ул. Анда барып җиткәнче күзләрен күгәрер әле. Хәер, баруы бик рәхәт иц. Мәхмүт атны юрттырганда тимерхут келтерәп кенә тәгәри бирә, аста йомшак печән, бер җиреңә көйсез түгел. Җәйге төн тып-тын, җил юк, җылы. Күк тулы йолдызлар. Әнә, ерактагы караңгы тау артыннан кып-кызыл

олы карбыз телеме төсле булып ай да калкып килә. Минем бер дә йокы килми. Башка сыймаслык төрле-төрле уйлар күктәге йолдыздай җемел-җемел килеп чуалышалар. Берсен уйлап бетермисең, икенчесе калкып чыга. Сукулкыга хәтле генә дә шундый ерак булгач, чит җире кайда икән? Ул инде ерак-ераклар арыгындагы ерактадыр. Исеме дә. «Ерак күмер» бит аның. Парахут белән, поезд белән бер атна барасы ди анда, бер атна...

Иртәгә авылда ничек булыр икән инде? Гыйльметтин белән Һадиулла урамга чыгалар, ә мин юк. Көндез дә юк, кич тә юк, иртәгесен дә юк! «Тагын чүбек җыярга чыгып киткәндер», дип уйлый Гыйльметтин. Ә мин һаман юк. Тутәйдән сорый. «Ник, белмәденмени, читкә китте бит ул», ди түтәй. Гыйльметтин шаккатып, авызын ачып тора. «Читкә?» ди аның шарадай булган күзләре. Бу бер яктан бик кызык инде, ә икенче яктан ничектер әйбәт түгел шикелле. Шундый ерак юлга, чит хәтле читкә, үзеңнен шул ике иптәш малаеңа да әйтми чыгып кит, имеш! «Тырбайчык!» диярләр, «астыртын ас икән!» дип сүгәрләр...

Хәер, мин бит бик әйтәсе идем, «читкә китәм!» дип, әз генә түш киереп тә аласы килгән иде, тик ышанмаслар дип курыктым. Чынлап та, безнең яшьтәге нинди малай читкә чыккан, кем малае, кайсы авылдан?.. Шулай булгач: «Мактанчык, мактанчык! Мактанчыкның арты ачык! Ә ялганы — бер капчык!» дип, «коры куык — шартлавык!» дип күзне дә ачырмаган булырлар иде. Ә көлкегә калсам, мин һәр вакыт җир тишегенә керерлек булам, мыскыл итүләрен дә бик авыр күтәрәм. Һадиулланың андыйга бер дә исе китми: шапылтаучының авызына берне кундыра да — китте барды тидия! Шундук шып булалар; артыннан куучы да юк, кусалар да тоттырмый, әллә кайларына кереп кача белә. Шулай да әйтәсе калган икән аларга. Белгән булсалар, озатып та калырлар иде әле, үпкәләмәсләр дә иде...

Без һаман барабыз да барабыз. Үзара сөйләшү дә юк, әтәй дә үз уендадыр инде,— минем шикелле. Тик Мәхмүт кенә ара-тирә атка дәшкәләп куя. Кайсыдыр бер авылдан әтәч тавышы ишетелде, нәкъ үзебезнең печәнлек түбәсендә яткандай булып китте. Ниндидер озын сөзәк үрдән төшә башладык, тимерхут тагын келтерәргә тотынды. Нинди рәхәт бу дөнья! Челтерәвек тарантаска утырып кына читкә китеп барасың!.. Әтәйгә, шүрләмәсәм, иртәгә үк әйтеп куям әле: читтән кайтканда да тимерхут ялласын, дугасында шөлдере дә булсын, басу капкасыннан кергәндә прәнник тә чәчсен. Шунда әллә мина да берәр уч сибәргә туры килмәсме? Әх, шәп булыр иде! Нигә булмасын? Шулай кайтабыз, алла теләсә! Минем башта менә дигән кырпу бүрек, өстә өр-яңа бишмәт белән бик шәп чалбар, аякта читек-кәвеш. Юк, кәвеш түгел, аны картлар кия, ә миндә көзгедәй уйнап торган ризинкә. Кырыеннан бик матур булып ал-кызылы да күренеп тора. Ә үзебез — пар ат җиккән, пар кыңгырау таккан шәп тимерхутта туп-туры кукраеп кына утырып, басу капкасыннан кайтып керәбез. Әтәй чәчә прәнник, мин чәчем чуклы канфит. Бөтен авыл малае җыелган! Кара, кара, инде олы малай булсалар да Гыйльми белән Һади да килгән! Без кайтасыны алдан ишеттеләр микәнни?.. Мин аларга калган канфитны кабы-ние белән ыргытам. Җиргә төшкәнче үк Һади тотып ала да читкә чаба. Гыйльми, ике сикерсә, аның җилкәсеннән каптырып ала инде, югыйсә, сикерми генә. Ул һаман мина таба караган килеш елмаеп тора...

Шушы матур хыяллар эчендә йөзә торгач, мин изрәп киткәнмен, Мамадышны да йоклап уздырганмын.

— Тор, улым, килеп җиттек,— дигән тавыш күзләрне ачтырды. Каршыда киң идел, өстендә кояш уйнап күзне чагылдыра, яңа йокыдан уянган килеш бигрәк тә рәтләп карап булмый. Мәхмүттән сорадым, моны «Кама иделе» дип йөртәләр икән. Без биек тау булып гөшкән текә яр кырыена килеп туктаганбыз. Төрле буяулы, төрле матур чел-

тәрле, кибетле йортлар да шул текә ярга сыенышкан, түбән як кырыйлары баганаларга утыртылган — казык белән терәткән шикелле булып тора. Шундагы бер марҗаттәй белән сөйләшкәч, бәләкәй генә лапас сымак җиренә Мәхмүт атын тугарды да арбага бәйләде. Ат печән кушн калды, без күтүмкәләрне кидек тә пристаньга ашыктык. Хәер, күтүмкә әтәйдә, минем кулда бәләкәй бер төенчек кенә, ә Мәхмүт гел буш.

Парахут сурәтен китапларда күргәнем бар иде инде, шуңар күрә, әз генә барганнан соң, яр буена төртеп: «Әнә парахут!» — дип кычкырдым.

— Пристань бит ул,— диде Мәхмүт эре генә.

Менәтерә, ул да гел парахут төсле икән! Янына килеп, такта күпердән пристань өстенә кергән генә идек, анда көтеп ятучы кешеләр: «Әнә парахут килә!» — дип, үзебезчә кычкырып җибәрделәр. Әтәй тиз генә билитка дип ташланды. Тик бу әле безгә түгел икән, Казан ягына китәсе ди.

Мин пристаньның теге кырыена ук барып, кешеләр караган якка төбәлдем. Су өстендә кап-кара төтенле ап-ак парахут күренде. Якынлаша төшкәч, бик матур, бик шәп тавыш белән кычкыртып җибәрде. Кызык: монда бөтенләй кермичә узып киткән шикелле, әллә кайлардан әйләнеп килеп туктый икән ул. Туктауга тагын бер кычкыртып алды. Аны тиз генә юан арканнар белән пристаньдагы чуен казыкларга чалып куйдылар. Чын тере парахут менә нинди була икән ул? Аста да, өстә дә гел тәрәзә. Өске кат кырыендагы сәндерәсенә (палуба икәнен соңыннан гына белдем) бик бәйрәмчә, бик шәһәрчә киенгән кешеләр чыкты. Шәһәрне күргәнем булмаса да, алар өстендәге киемнең авылча түгеллеге әллә каян күренеп тора. Шулай да аларга түгел, парахутның куласасына исем китте минем. Безнең тегермән куласасы моның янында уенчык кына икән! Шул ике яктагы ике зур куласасы белән Иделне лапыр-лопыр ярып, суларны гөбер-гөбер китереп, яңадан әйләнде дә китеп тә барды ул. Шундый кызу, шундый җиңел бара, әйтерсең су өстендә уйнаклап кына йөри. Ә үзенең артыннан, язгы ташудагы шикелле киртләч-киртләч булып, ике олы толым ишелеп-үрелеп кала. Эх, матур!..

Безнең парахут әле кечке якта гына буласы икән. «Кайтып, әлеге марҗаттәйдә чәй эчтек. Мәхмүт атны туйдырып, сулар эчертте дә тимерхутка җикте. Өйдәгеләргә сәлам тапшырырга кушып, без аны озатып калдык. Аның артыннан үзебез дә пристаньга атладык.

Көн буе каравыллаган парахут караңгы төшә башлагач кына килде. Бөтен җирендә балкып электр утлары яна. Кичкесен бигрәк тә матур икән ул! Кешеләр арасына төртелә-кысыла, сырлы баскычтан түбәнгә төштек тә эчкә кердек. Балык исе килгән юан-юан бүксәле мичкәләр, эченә кереп утырырлык биек-биек тау өемнәре, әллә нинди олы-олы чыбык чуманнар, мунчала көлтәләре, тагын әллә нәрсәләр арасыннан көчкә узып, үзебезгә дигән «читбирти класс»ка барып җиттек. Ул «читбирти...» дигән җире акка буяган ике катлы сәндерә икән. Өстәгесенең почмактагырак бер бүлемтегенә әйберләрне куйдык та аскы сәкегә утырдык. Парахут тыштан бик матур күренсә дә, эчкә кергәч алай ук түгел икән. Сукыр лампа төсле караңгы гына ут яна, сәндерәләргә генә түгел, шул теге мичкә, мунчала өсләренә хәтле кеше тулды, борылыр урын да калмады. Ничек кузгалып киткәнне дә күрә алмадым, куласалар гөбердәве генә безнең инде юлда икәнлекне аңлата. Әтәй кипәтүк алып килде (монда кайнар суны шулай диләр икән), чәй салды. Төн буе юлда, көн буе пристаньда уздыргангамы, мин бик талчыккан идем, рәтләп ашасы да килмәде, аннан-моннан гына капкаладым да сәндерәдәге капчык өстенә түндем...

Иртәгесен мин йокыны гел симерткәнче туйдыргач кына тордым, анда да әтәй уятты әле. Чәй эчкәннән соң, үзебезнең читбиртине «үзләштерә» башладым. Минем хәтле малайлар да бар, кызлар да күренә. Алар кая баралар икән? Тел төртергә чамалап карыйм да — урыс малайлары булып чыга. Бернәрсә белмиләр. «Куда пайжуш» дисәм, «чауа-чауа» дип торалар да «Камбарка» диләр. Ни дигән сүздер, һич аңлый торган түгел. Мина ул камфарка булып ишетелә, самавар камфаркасы искә килеп төшә дә көлеп куям. Шуны да рәтләп әйтә белмиләр дип уйлыйм эчтән. Шулай да шактый аралашып киттек. Йөри торгач, сап-сары буяулы, җиз тоткалы бик матур бер баскыч күрдек — ул өскә таба менеп китә.— Айда! — диде бер малай өскә күрсәтеп. Кара син аны, безнеңчә әйткән була бит, белә микәнни? Менә дә башлаган идек, «кудый!» дип кычкырды бер усал тавыш. Шундук шыбырдашып кире коелдык. Әтәй килеп җитте.

— Әллә кая чабып, күп күренеп йөрмә, урыныңа мен дә ят,— диде. Сәндерәгә менеп кунаклагач, баш очындагы бәләкәй тәрәзәдән карап бара башладым. Киң дә булса була икән бу идел. Аны йөзеп чыга алучы берәү дә юктыр. Әллә кайларга җәелеп аккан су да су. Безнең авыл уртасында ике су бергә кушыла, алар икесе иң шәп булып ташыган язда да бу хәтле киң җәелә алмыйлар. Ерак аргы якның сөзәк ярында агачлык күренә — бездәге шикелле таллыктыр инде ул...

Шул чагында безнең тирәдә нindидер ят тавышлар ишетелде. Кемдер билит дигән сүзне юан аваз белән ачулы итеп кабатлый. Баягы малайларның кайсыларыдыр, каядыр шым гына кача барганы күзгә чалынды. Нәрсә икән дип, башны аска сузарга гына уйлаган идем, аннан бик куркыныч бер баш күтәрелде. Ялтыравык кара күзрикле ак картуз кигән, маңгай уртасында озынча түгәрәк медале, җилкәләрендә урәтникнеке төсле пагуны бар. Аңар аксыл җефәктән үрелгән әллә нинди бау беркетелгән, өстендәге күк киемнең җиз төймәләре елкылдап тора. Күзләре шул төймәләрдән дә олырак булып акайган, мыегы шитыйна шикелле тырпайган — котлар да чыккыч. Яман да усал эт ырлагандай карлыккан тавыш белән нәрсәдер кычкырып җибәрде бу миңа. Куркудан капчыкка кереп китәрдәй йомарланып, түр почмакка сеңдем. Тагын әллә нәрсәләр җикеренде дә күренмәс булды. Аста әтәйне шундый ук әшәке тавыш белән сүгәргә тотынды ул баш.

— Баранчук кенә бит... сапсим малинки-н! — дип, мескен тавыш белән ялварганы ишетелде әтәйнең. Анннары аны каядыр алып киткәннәре күзгә чалынып калды. Мин бөтенләй коелып төштем: «И ходаем, кая алып киттеләр икән аны? Ни гаебе бар икән? Мин нишләрмен инде?.. Өтермәнгә утыртмасалар гына ярарые...» дип уйлыйм. Күзләрдән яшь шыбыр-шыбыр коела. Тавыш белән еларга куркам. «Бетте баш, бетте баш!.. Менә сиңа чит!..» Бүтән бернәрсә уйлый алмыйм, төшеп әтәй артыннан йөгермәкче булам.

Ярый әле, озак та тормыйча, әтәй үзе килеп җитте. Йөзенә ачу чыккан, күзләре очлайган. Юпь-юеш битләрем белән аңа сыендым.

— Әтәй! Әтекәем! Мин инде сине гел алып киттеләр дип, котларым очканые...

— Нәгаләт суккан җаннар! — дип сукранды ул.— Тоймыйчарак калдым аны. Шул билит бәласе инде... Тәки алдырдылар...

Ул көнне мин сәндерәдән бүтән төшмәдем. Икенче көнне бу явызларны тагын күрдем — алар икәү икән. Кешедән-кешегә тукталып, берсе шул әшәке тавыш белән билит сорый, икенчесе әллә ниткән тимер каптыргыч белән шул билитны пытырдатып, иясенә кире бирә. Бу юлы инде безгә кагылмыйча уздылар, шуннан соң гына эчкә җылы керде. Алар күздән югалгач, идәнгә төшеп, бик кирәкле җиремә барып килдем. Кечкенә малайларны да күз белән генә эзләп караган идем — берсе дә күренмәде, билитсыз булгач, төшереп калдырдылар микәнни соң?..

Тагын бер тәүлектән артык баргач, без дә төштек. Әллә ничәмә парахут туктаган әллә ничә пристаньның берсеннән үргә таба күтәрелеп, йомры таш җәйгән шәһәр урамына килеп чыктык. Андагы шикелле олы таш йортларны минем әле гомердә дә күргәнем юк иде. Әтәйдән сорадым, Пирме каласы диде. Шул хәтле йортлар, урамнар, тыкрыклар, жигүле атлар, җәяү йөрүчеләр күп — күз күреме җитә торган түгел. Ялгыз булсаң, шундук адашып каласың!..

Ничәдер урамны аркылы узып, чамасыз олы ак багзалга килеп кердек. Аның зур-зур тәрәзәләрен, кырыйларындагы һәм эчендәге таш баганаларын санап бетерә торган түгел. «Багзал» дигән сүзне ишеткәнем бар иде — шушындый була икән инде ул. Без аның эчендә озак тормадык. Бәләкәй генә бер ачык тәрәзәгә килеп, әтәй билит сорады, янчыгыннан акча чыгарып түләде, тәрәзәдән сузылган ике катырка кисәген шул ук янчыгына салып, эчке кесәсенә тыкты. Аннары багзалның пуез китә торган ягына чыктык, анда чыгу белән иң элек чуен юлга шаккатып карап калдым. Сәер. Бер дә мин уйлаганча түгел икән. «Чуен юл» дигәч, мин аны кара-каршы ике арба узарлык киң итеп тоташ чуен җәелгән, өсте күзге күк ялтырап торган шома юлдыр, машина шуннан челтерәп кенә йөреп торадыр дип күз алдына китерә идем, ә ул тар гына ике рельс икән.

Мин шулай аптырап торганда, нечкә генә тавыш белән кычкыртакычкырта, чуен машина үзе парларын бөркеп, каядыр узып китте. Айяй, зур була икән ул! Шул тар гына чуен тасма ничек күтәрә икән аны?..

Әллә нихәтле сораулар белән әтәйне йөдәтергә туры килде. Ачуланмады тагы. Әз генә көлемсерәде дә барын да әйтеп бирде. Әнә ничек икән! Рельсларны башта бик нык итеп бер-берсенә тоташтыргач, аннары тип-тигез итеп җәйгән шпалларга беркеткәч, бер урыны да кылжый-мылжый килми торган юл өстеннән әллә ничәмә вагон таккан паравызлар да келтерәп кенә йөрерлек була икән!..

Озакламый безгә дигән пуез килде. Артка ук йөгереп, бер яшел вагон баскычына туктадык. «Читбирти класс эздич?» — дип сорады әтәй. Юлчылар белән этешә-төртешә эчкә кердек, тиз генә урын алып та өлгердек. Мондагы «читбирти»нең сәндерәләре өч катлы икән, без уртадагысына эләктек. Ул тоташ сәкеле, ятарга иркен булып чыкты, егылып төшү куркынычы да юк.

Халык урнашып, байтак көттергәннән соң пуез «гөлдерт!» иттереп бер тарттырып куйды. Сөрлегеп китүче малайлар да булды. Икенче тарттыруында әкрен генә алга тәгәри башлады. Пирме каласыннан чыгып киттек... Түшкә ятып, тәрәзәдән карап барам. Машина кызурак киткән саен куе нарат урманы яшел ташкын булып безнең өскә ыргыла төсле, чыбыклы баганалар каяндыр чабып килә дә кинәт егылып китә, шырпы тартмасыдай гына булып юл буена кунаклаган бәләкәй сары өйләр ничектер янга борылып кала шикелле. Сәер икән бу чуен юлдан барулар...

Дүртме, бишме көн барсак та, телгә алырдай яңалык булмады. Ике билит алгач, качып-посып маташырга да туры килмәде. Тик тамак ягы гына кайтыланды. Өйдән алып чыккан ашъяулыктагы ипи катып-күгәреп бетте: яшькелт черек сипкән төс керде. Әле һаман бетмәгән ит тә әллә ничек йомшап, исләнеп китте, авызга алырлык тәме калмады. Әтәй нишләптер яңа ипи алып керми...

Бер көнне сәндерәдә эч чурлап ятканда, иң югары шүрлектә бер кыерчык ак ипи кисәге күзгә чалынды. Әтәй астагы кешеләр белән сөйләшеп утыра иде, берсе дә күрмәгән арада гына мин ул кыерчыкны үренеп алдым да урынга капланып чәйнәргә тотындым. Теш үтмәслек шатырдап каткан, үзе тач тоз булып чыкты ул. Бер дә безнең як калачы тәме килми... Кимереп-кимереп азапландым да кире урынына озат-

тым. Пычак белән эстен кырып, чәйгә жебетеп ашасаң, үзебезнен ипи лутчырак...

Шул урта сәндерәдә ятып бара торгач, күрше бүлемтектәге бер малай белән дуслашып киттем. Ул елмая, мин елмаям. Әй сөйләшәбез шунда икәү генә яткан килеш: ул урысча, мин татарча. Бар да аңлашыла тагы. Бер мәлне бу миңа нииндидер бәләкәй генә ясмак-йомры нәрсә сузды, үзе дә шундый ук берне авызына капты. Мин дә тешләп караган идем — бик тәмле булып чыкты бу. Бармак битләрен ялыйялый, башны селки-селки ашап бетердем. Рәхмәт әйтүем инде, янәсе. Минем генә бирер әйбер юк. Тагын берхәтле «сөйләшеп» уйнагач, теге кырыйдагы анасыннан сорап алды да янә бер түгәрәк телем сузды бу миңа. Монысы аксыл-кызгылт төстә, тәме дә бүтән, әзрәк шытырдап та куйган сыман. Шулай да ашамаслык түгел. Моңарчы күрмәгән яңа ризык бит, теге малай шикелле итеп чәйни-чәйни озатып җибәрдем. «Кусно, кусно?» — ди бу миңа. Ни дигән сүз икәнен белмим, белмәсәм дә «кусно-кусно» дип кабатлыйм. Шуннан соң ул миңа тагын калынрак бер телем сузды. Минем баш күккә тиде. Сәндерә кырыеннан аска сузылдым да: «Әтәй, карале, минем нәрсәкәем бар? Теге малай бирде...» дип мактанып та алдым. Мин әтәйгә шактый иялэшеп барам бугай хәзер, ничектер үзем дә сизмичә иркәләнә дә башладым төсле. Бу юлы да шул ук кыланыш белән әлеге күчтәнәчне аңа суздым. Кулына тотып каравы булды:

— Кит аннан! Авызыңа кабасы булма! Дуңгыз колбасасы бит бу! — дип атып та бәрде идәнгә. Бармакларын оек кунычына сөртеп куйды. Аптырадым да калдым. Кабасы түгел түгелен дә, бер телемен ашап бетергән идем шул инде... Вәт чучка малайны, дуңгыз белән сыйлаган икән мине!.. Билгеле, әтәйгә ләм-мим ычкындырмыйча, эчтә әллә нәрсәләр булачагын көтә башладым. Харам аш — карын ярып чыга, диләр иң. Көттем-көттем, ярып чыкмады тагы, узды шул көйгә...

Юлда без Кәтримбур, Чиләбе, Омски, Навай-Николайски дигән калаларны уздык. Вагоннан чыгып йөрмәгәч, мин аларны күрмәдем, әтәй әйткән буенча гына беләм... Әлеге дус малаем әнисе белән «Балутный» дигән бер стансада төшеп калды.

Ахыр килеп, көннәрдән бер көнне без дә «Әнжирски» дигән стансада пуездан төштек. Аннары җәяүләп киттек. Җәйге эсседә кап-кара тузанлы юлдан бара-бара оек-чабаталар күмер онына баткан төсле булды. Шулай унбиш чакрымнар (әтәй әйтүе буенча) барганнан соң, «Мөхлисун шахтысы» дигән җиргә килеп җиттек. Бу сүз миңа ничектер: «Мөхлисулла шахтысы» дигән күбрәк яңгырады. Авылда Мөхлис абый бар бит безнең. Янәсе, без шуның мондагы шахтысына киләбез, таныш җир шикелле тоела!..

«Шахты» дигәннәрен дә шунда ук күреп алдым. Берничә төштә тактадан дүрт почмаклы итеп ясап менгергән биек маш, өскә калкыган саен нечкәрә бара, әзрәк мәчет манарасына охшаган дип әйтергә дә була: югарыда тоташ ачык тәрәзәләре бар. Тик аннан, азан әйтеп торучы мәзин башы түгел, бик олы кара тимер куласалар күренә, алар гел әйләнеп тора. Шул машка тоташкан биек агач күперләр төрле якка сузылып китә. Алар өстеннән кешеләрнең бәләкәй вагон тәгәрәтеп барганнары күренә. Бер тишеккә килеп җиткәч дә вагоннарын аударып җибәрәләр. Аска «гөж-ж!» итеп кара күмер коела, эре кисәкләре әллә кайларга хәтле тәгәрәп китә. Шул күперләр астына чуен юл кергән, анда тимер әрҗәле зур-зур вагоннарга күмер төйиләр. Шуннан арырак киткәч, бик биек көлсу-соры балчык тавы күтәрелә, аны җир астыннан чыгарып өйгәннәр икән.

Без шулар тирәсеннән узып, уныньчы калуния дигән җирдәге җитмеш бишенче баракка килеп туктадык. Ул нарат бүрәнәдән шактый

озынга сузып салган бер катлы йорт. Катып беткән агач баскычтан менеп, эчкә уздык. Әтәй, сәлам биреп:

— Хисаметтиннар монда торамы?— дип сорады.

— А-а, Пәрхулла абзый икән, вәгаләйкем сәлам, исәнлек-саулыкмы? Монда тора, әнә теге почмакта алар,— дип тезеп китте бер яшьрәк кенә, юка гәүдәле кеше.

Без зур мич артындагы шул почмакка юнәлдек, анда такта бүлмә бар икән, ишеген ачып эчкә кердек. Өстәл артында кыска сары сакаллы, җиз мыеклы, калку таза гәүдәле бер кеше чәй эчеп утыра, хатыны өстәлнең икенче читендә бала имезә. Икесе белән дә күрешеп алдык. Болар безнең якташ кешеләр булып, Югары Тәкәнешнең Бәһлүл малае Хисаметтин, ә хатыны — Мәгъмүрәттәй икән. Үземнең әнәй ягыннан кардәш тиешле кешеләр дә икән әле. «И-и, Гайшәттәй малае Шәйхелислам шушымыни инде ул? Ничек үскән!..» дип, Мәгъмүрәттәй аркадан да шапылдатып алды, шундук рәхәт булып китте. Әйтерсең бөтенләй чит-ят җирдә түгел!..

Алар безне чәйгә утыртып, ил хәлләрен сораштыра башладылар. Үзләре унберенче ел ачлыгында Тәкәнештән китеп, төрле җирләрдә йөргәннән соң, монда килеп урнашканнар. Хисаметтин абзый кумер чаба, ә Мәгъмүрәттәй «халастуй» карый икән. Сүзләр сөйләшенеп беткәч, бүлмәдән чыгып, барак буена сузылып киткән озын сәкенең буш калган аргы башыннан урын алдык. Икенче кырыйдан да шундый ук озын сәке сузыла, анда да кешеләр ята. Ул кырыйны янәшә бүлмәдә торучы Хәҗвәли абзый дигән кешенең хатыны карый икән. Ике сәкедә алтмышлап кеше бардыр, шулар һәммәсе дә халастуйлар дип атала, буйдаклар булып чыга инде. Боларны мин әтәйдән сораштырып белдем.

Юлдан арып килгән килеш йокларга яттык, әмма төн буе күз йомылмады, кыскаяк сырып алды. Барак уртасында электр уты яна, шул ут яктысында да талыйлар, каһәр суккырлары, берсе-берсе бармак башы хәтле бар, әллә бәйләп симерткәннәр тагы. Монда аларны кибәк дип кенә йөртәләр, кандала дип әйтсәң, тагын да котырыныбрак кан талый башлыйлар, имеш. Шулар белән сугыша-сугыша уйланып ятам: «Чит дигән җирләре шушы була микәнни соң инде? Ә бит авылда чакта, юлда килгәндә дә, нинди кызыктыргыч матур булып, сөйләп бетергесез шәп җир булып күренгән иде ул. Хәер, мин әле нәрсә белдем дә нәрсә күрдем соң? Ашыгып борын салындырмаска кирәк, иртәгә әллә ни төрле хикмәтләр ачылыр әле, барын да карап, белеп, сокланып йөрермен, аннары бөтенесен тезеп-тезеп түтәйләргә хат язармын...»

## Яңа дусларым

Иртәгесен әтәй Хисаметтин абзыйга ияреп, эш белешергә киткән иде, кичкә хәтле йөреп тә керешә алмыйча кайтты. «Эштигер» дигән нәчәлник сөйләшергә дә теләми ди. Сугышка алынудан качып килүчеләр күп икән, шундыйлар майлап-җайлап урнашу аркасында кешене кая тыгар урын юк, имеш. Икенче, өченче баруында да буш кайтты. Шулай ун көнләп йөргәннән соң, Дусай Тәхәү дигән әртилшек белән көчкә управляюшигә кереп, «Мин иске забуйшек дип, моннан китконемә әле ике генә ел дип, зинһар, читкә какма дип, первай бух, ыфтаруйтый дип, вәзми пажалыста!..» дип, бүрек салып, баш иеп ялваргач кына алганнар.

Ул көннәрдә безнең тамак ягы да кысылып киткән иде: ипи дә чәй, ул да Хисаметтин абзый биреп торган акчага. Ә плитәдә кайнаган кәстрүлләрдән итле аш исе бөтен барак эченә җәелә, шундый тәмле

булып борын эчләрен кытыклый, теш төпләре, тел өсләре кычынып, авызга су тула. Үзендә булмаганда кеше ашы нигә шулай тәмле булып тоела торгандыр ул?..

Хәзер инде без дә рәтләнеп киләбез. Этәй көн саен кап-кара булып шахтыдан кайта, чоланга кертеп коптилкасын элә дә эш киемнәрен чишенеп, ишегалдында бик озаклап юына, мин аңа су сибеп торам. Күмер тузаны битләренә-муеннарына гына түгел, бөтен тәненә кап-кара булып утырган. Аны юып төшерер өчен әллә нихәтле гомер кирәк. Шулай да ярты гәүдәсе барыбер кап-кара килеш кала. Анысын инде атнага бер тапкыр сигезенчә шахты мунчасына баргач кына җебетеп була.

Озакламый этәй «абансы» да алды, бер потлы ак бәз капчык белән крупчатке оны да күтәреп кайтты. Мәгъмүрәттәй аннан мамык күпчектәй күпертеп ап-ак калач пешерде, шул ук камырдан вак кабартма да салып ашатты. Плитәдә безнең дә кәстрүл бар хәзер, эчендә тай ите кайный!

Урамга чыгып, малайлар белән дә аралаша башладым. Безгә орынып кына торган житмеш дүртенче баракта Җәгъфәр дигән малай тора икән. Ул мине күршеләрендәге «Якупка» белән таныштырды. Бу озын сары чәчле, сары кашлы, сары керфекле малай булып чыкты. Күзләре күк ташыяк төсле, борыны да бик шәп, төс-бите зерә ачулы карый, үзе бик этчәйни икән — сугыш чукмары ди. Аларга ияреп киткәч, Янка дигән поляк малаен да очраттык, монда андый халык та бар икән, минем ишеткәнем юк иде.

Аннары без, чуен юлын аркылы чыгып, вак куралык арасындагы сукмактан унсигезенче баракка төшеп киттек. Ул яшел үзәндәге сирәк карагайлар күләгәсендә утыра. Анда Һади, Шәмсемехәмәт, Фәтки дигән малайлар тора икән. Һадие безнең яктагы Алкин авылыннан, Шәмсемехәмәт — Казаклардан булып чыкты, гел үзебезнең авыллар белән очрашкан күк булдым. Фәтки генә Өфе ягыннан икән, Җәгъфәр белән якташлар. Без алар белән җыйнаулашып «Дәлни атбут» дигән жиргә киттек, анда жиләк бар, имеш. Үләннәре шытырдап кибеп беткән яланнан бер чакрым барганбыздыр, чокырлар-канаулар чыктык, ичмаса, бер тамчы жиләк тапмадык. Кайтканда бик эсселәгәч, су кирәсе килгән иде, малайлар минем ул сүздән кычкырып көлделәр генә. Үрдәк чумарлык су да юк икән монда! Әллә кайда «вадакачка» бар, имеш, баракларга суны шуннан «вадавызлар» ташый икән...

Һаман таныша барам чит дөньясы белән, белеш-танышлар да күбәя бара, урыс малайлары белән аралашырга да бик курыкмыйм хәзер. Хәтта, ду килеп тиргәшә-талаша, кузналы уйныйбыз. Оста бәрүчеләр өемне кырып кына сала, ә мин бөтенләй рәтләп бәрә белмим, битогым әллә кая читкә барып төшә. Безнең авылда мондый уен юк шул, күргән уен булмагач, осталык та житми. Минем кузнаны бик тиз отып бетерәләр, аның унысы бер тиен тора, ә минем акча юк. Бигрәк тә Вахрушев дигән олы малайга ачу килә. Ул гел хәрәмдәли. Мине генә түгел, бүтән бәләкәйрәк малайларны да алдап ота. Без җыйнаулап аның белән талаша башлыйбыз. Миңа ул «татарчонок!» дип кенә кычкыра, минем кырган баштан «гололобый!» дип көлә. Әй ачу килә дә соң. Үзләреннән ишеткән әшәке сүзләрнең барын да әйтеп бетерәм. Нәкъ үзләренчә бөтен «тәшдит»ләрен китереп әйтергә тырышам. Аннары килеп: «Атса ыскажу» дип тә куркытып куям, ыржаеп кешни генә теге...

Рус теленнән беренче сабакны шулай урамда ала башладым һәм озакламый әзме-күпме сукаларга да өйрәнеп киттем.

Бер көнне без, биш-алты малай, уйный-уйный, үзебезнең «дисәти колония»дән шактый читкә чыгып киткәнбез. Анда чыпчык кузгалагы табып, шуны чәйнәргә, кулга җыярга тотындык. Көтмәгәндә өскә таш ява башлады. Карыйбыз — кем атканы күренми, ә таш — агач склады

почмагыннан оча. Без дә шул якка атарга тотындык. Шуны гына көткән шикелле, склад почмагыннан унлап малай чыкты, тагын да ныграк яудыра башладылар. Поляк малае Янка: «Ребята, наших бьют!» — дип кычкырып җибәрде. Шул арада каяндыр Якуп күренде, килешли ук бөрмәсенә кыстырган күлмәк эченә таш җыя килә. Аның артыннан Вахрушев белән Фәтки, аннары Миткә белән Җәгъфәр йөгерә. Безнекеләргә дә гайрәт керде хәзер, таш тондыра-тондыра әллә ниләр кычкырып, алга ыргылалар. Якуп иң алдан бара, аның аткан ташлары теге малайларның я корсагына, я чәкәненә эләкмичә калмый. Иң арттан мин дә йөгерәм, мин дә аткан булам. Безнең як һаман күбәя, яңаданяңа малайлар өстәлә бара. Теге якның да көче артты хәзер. Безнең алга баруы тукталды, ике арада «позиция сугышы» китте. Таш ява, сүгенү сүзләре ява:

— Бей седьмовских!

— Колоти десятских! — Тагын әллә ниләр, әллә нидәр. Ике яктан да егермешәрләп малай, шулай бер-берсен куркытып, бер-беренең башына таш томырып, бер урында таптана...

Менә бер заманны Якупка алга сикереп чыкты да, маңгаена чуалып төшкән сары чәчләре арасыннан күк ташыяк төсле күзләрен акайтып, кул болгый-болгый:

— Ай-да, робята, в штыки! Урра! — дип кычкырып җибәрде. Үзе алга ташланды. Аның артыннан бөтен «гаскәр» ташкындай ургылып, тегеләр өстенә китте. Нихәтле нык торып, янап маташсалар да, тезләре сыеклана башлады: әкрен-әкрен чигә барып, баракларга җитәрәк бөтенләй чәчелеп беттеләр. Ә без «дошманны» җиденче шахтага хәтле куган җиңүчеләр булып, бер дә әкәмәт кукрайган кыяфәт белән үзебезнең унынчыга кайтып кердек. Якупның маңгай читендә мөгез бар, беләгендә кан табы күренә. Вахрушның тезенә таш эләккән — җиңелчә генә титаклап кайта. Нишлисең бит, андый гына була инде ул — батырлар ярасыз йөрмиме соң?

Бу — «десятскилар белән седьмойлар сугышы» дип атала икән, инде әллә кайчаннан бирле шулай бара, имеш. Әлегрәк хәтта олылар да катнашкалый торган булган. Ә нәрсә өчен? Ни бүлешәләр? — аңысын беркем дә белми...

Мин дә кеше рәтенә керә башладым бугай: малайлар да артык теңкәгә тими, урысчаны да көннән-көн арттырыбрак сукалый барам, кузнаны да әз-мәз белебрәк сугам хәзер — көн саен бер кесә оттырып кермим. Оттырсам да бик ис китми — алырга акча бар. Ник дисәң, миңа хәзер барактагы шахтерлар хат яздыра. Язган саен биш тиен бирәләр! Шул хәтле күп акча бит ул — минем инде этәй күптән түгел алган бәләкәй сандык төбендә бер тәңкәдән артык акчам бар! Кайтканчы күпме булыр икән ул, ә? Читтән кайтасы кеше бит мин!.. Хатны авылда чакта ук яза идем, бигрәк тә, сугыш башлангач, солдатка җиңгиләр өйләренә алып китеп, бөтен зар-интизарларын, сагыну тулы җырларын кәгазьгә тездерәләр дә, бәрәңге дучмагымы, бөккәнме, нарапыймы, күмәчме, бер дә булмаса арыш ипие беләнме чәй эчертеп, хәзинәләрендә булганы белән сыйлап та җибәрә иделәр. Кайберсе, «кул ялың булыр, ылан» дип, ике тиен акча да бирә. Ә монда — биш тиен! Бигрәк җәлләми бу шахтер акчаны. Әйтерсең күмер урынына көрәп кенә ала! Мин, югыйсә, бер дә нәфсемне сузмыйм. Үзләре этеп-төртеп бирәләр. Ул яхшылыклары өчен кат-кат рәхмәт әйтергә генә кала. Шуның аркасында әрбет чикләвеге кесәдән өзелми минем хәзер...

Җәйнең бик эссе көннәре башланды. Себер булып Себердә дә шундый эссе булыр икән! Бездәге урак өсте вакытларыдыр инде бу. Барактагы кыскаяк тагын да чамасыз котырып китте, һич чыдар әмәл калмады, кем кайда урын тапса, шунда йоклый. Без дә күршедәге стайка башына чыктык, бүтәннәр дә менде. Бер-ике төн генә кунган

идек, кибәк анда да көчеп өлгерде, тагын безне үрле-кырлы сикертә башлады.

Шул көннәрдә мин бик каты авырып киттем, дөньяның бер кызыгы калмады, урыннан кузгаласы да килми, тамактан аш та үтми. Әтәй минем өчен бик хафага төште, эштән кайту белән гел янымда утыра. Мәгъмүрәттәй дә кайгырта, төрле тәмле нәрсәләр пешереп, сәндерәгә менгерә. Ике-өч көннән соң бөтен тәнне кызгылт тимгел басты. Мәгъмүрәттәй моны күргәч: «Олан, кызамык чыккан сиңа!» — диде һәм әтәйгә кипкән чия табарга кушты, шул бик файдалы була, имеш. Әтәй ул чияне каяндыр икенче көнне генә табып кайтты. «Кыш уртасында кура җиләге» дигәндәй, Себер җирендә алма да, чия дә үсми икән бит. Күрәсең, аны әллә кайдагы җылы яклардан китерәләрдер инде... Шул чияне кайнатып, каты чәй белән бергә атна буена эчә торгач, файдасы булды тагы: әкренләп тамакка ашый башладым, аякка бастым, сәндерәдән дә төшкәләп йөрим инде. Әтәй дә сөенеп эндәште:

— Куркыта яздың бит, улым,— дигән булды ул һәм аркамнан сөеп куйды. Шунда белдем: әтәй яхшы кеше икән безнең — кайгырта да, ярата да белә икән!

Ә ул чакта балалар врачы дигән кеше булды микән? Никтер аның хакында Мәгъмүрәттәй дә, әтәй дә телгә алмады, әллә аны чакыртыр өчен бик күп акча кирәк иде микән?..

## Сәер өстенә сәер...

Себернең кыска җәе шулай узып та китте. Инде иртә белән урамга чыксаң, ап-ак кырау төшкән була, ялан тәпи туңа, өскә дә бишмәт киярга кирәк. Безнең янда гына уныччы шахтаның күмер эстакаты. Кытайлар шунда җәй буе кызыл вагоннарга күлмәксез-нисез күмер төяделәр. Хатын-кыз шикелле озын чәч йөртә икән алар, тик чәчләре баш түбәләрендә генә, толым итеп үрелгән дә шул түбәгә чорнап куелган. Ә баш артлары, маңгай өсләре чәч пәкесе белән ялт итеп кырылган. Алар көндезге ашларын шунда платформада гына ашыйлар иде. Зур кәстрүл әйләнәсенә биш-алты кеше тезелеп утырган, һәркайсының кулында ике озын чыра. Шул чыралар белән кәстрүлдән дөге эләктереп алалар да авызларына озаталар. Без, малайлар, читтән бик сәерсенеп карап торабыз. «Кашык алырга акчалары юк микәнни?» — дип уйлыйбыз. Икенче бер вакытны аларның шул ук чыралар белән кәстрүлдән озын-озын токмачлар чыгарып ашаганнарын күргәч, мин бөтенләй аптырап калдым. Ничек эләктереп чыгаралар? Ничек ул шуып төшеп китми?

— Макарон ашыйлар,— диде Якуп. Ул инде андый нәрсәләрне белә! Озакламый моны Мәгъмүрәттәйләр шкафында миңа да күрергә туры килде: нечкә курай шикелле эче куыш итеп катырган камыр икән ул. Ничек шулай куыш итеп ясыйлардыр: бер җирендә дә ялгаган, ябыштырган эзен күрмәссең. Болай гына баш җитәрлек түгел, берәр машина ясап чыгара торгандыр аны! Хәер, өйдән чыкканнан бирле андый хикмәтләрне әзме күрдем инде мин: пароход пар белән су өстеннән йөзеп бара, паровоз шул ук пар белән тар гына чуен юлы өстеннән тәгәрәп китә, шахта клите пар белән җир астына кешеләрне алып төшә, аннан күмер күтәреп чыгара, моның да берәр пар машинасы бардыр әле. Ә менә самаварга көпчәк куйсаң, тәгәрәп китәр иде микән? Аның да пары бик шәп бөркелеп чыга бит, кайчакта капкачын да күтәреп куя, дип уйланам. Шулай да күп еллар узганнан соң гына макаронның бик борынгы кытай ашы икәнен һәм алар моны үзләре уйлап

чыгарганын белдем. Уйлап табарга башлары җиткәч, ничек ашарга кирәклеген дә бик яхшы өйрәнгәндер инде алар...

Менә хәзер платформа өсләрендә шул кытайлар да күренми инде. Чуен юлның түбән ягындагы такта баракта торалар иде, ул барак хәзер буш, эче суык, без аның югары сәндерәсендә туңа-туңа кәрте сугабыз. Куллар, ялан аяклар күшегеп беткәч, өйләргә таралышабыз. Кая булды икән ул кытайлар: берәр җылы баракка күчтеләр микән, әллә илләренә үк кайтып киттеләр микән?..

Күчү дигәннән, андый хәл бездә дә булды бит әле. Озакламый кырпак кар төшкәч, безне дә 93 нче номерлы өр-яңа баракка күчерделәр. Баскыч сайгакларыннан алып бөтен идәннәре сап-сары итеп буялган, стеналары ап-ак известь белән агартылган. Кергәч тә уң кулда Хисаметтин абзыйлар бүлмәсе, сул якта зур плитә, аның артында тар озын чолан — шахтерка элә торган һәм юына торган җир. Уртадан узып олы якка чыгасың, каршы стенада ике киң тәрәзә, алар да ак буяулы. Уң якта да, сул якта да тоташ сәке, ул да ап-ак, ләкин буялмаган. Түрдә кырын сугылган такта — баш асты тәбәнәк булмасын, янәсе. Ике яктагы ике йөзлек буенда тәрәзәләргә яндаш ике аш өстәле, алар да сап-сары буяулы. Бөтен җир чиста, аяк-чуны ишек төбендә үк салып керәсе.

Без сул яктагы тәрәзә буе почмактан урын алдык. Менә монда инде кибәк таламаячак. Безнең авылдагы байлар өе шикелле бу! Алай гынамы соң? Күмерне китереп әрҗәгә аударалар, суны баскыч төбенә мичкә белән китерәләр, тик «патша җәяү йөри торган җире» генә тышта, буран уртасында...

Урамнан караганда бу барак та озын итеп салынган, тик ул кап-урталай икегә бүленә, аның икенче башына үзләрендәге буйдаклар белән Хәҗвәли абзыйлар урнашты, шулай итеп, без хәзер икегә аерылдык — бүлем саен утызлап кеше. Мондый әйбәт, яңа баракка күчү безгә шактый сәер тоелды. Ни дисәң дә, тегесе дә тормаслык түгел иде әле. Чынлап та, авылдан җыелган чабаталы татарны да әдәмгә санап, шундый яңа, әйбәт баракка күчерделәрме, әллә бу очраклы килеп чыккан бер хәл генәме? Баш ваттылар, төрлечә юрап карадылар һәм бик тә канәгатьләндерә торган әкияте дә табылды: «Шахта бае безнең татар кешесен бик ярата икән, «Алар төн-көн шахтадан чыкмый, бик күп күмер бирә, ә сугыш заманында күмер бик кирәк, шуңар күрә мин аларны әйбәт баракка күчерәм», дип әйткән, имеш. Дөрестер дә шул, аның фамилиясе дә безнеңчә бит — Мөхлисун...» дигән сүзләр китте. Ә язга таба күмер таулары иске платформага сыймый башлагач, безнең теге баракны сүтеп ташладылар да яңа, киң платформа кордылар...

Әмма ничек кенә булмасын, без кышка яңа, якты, җылы баракка күчеп калдык. Монда торуны чит рәхәте күрү дисәң дә ярый. Бу инде безнең өй шикелле җиргә баткан таш чокыр түгел...

Авылдан килгән чабата әллә кайчан тузган иде инде. Кар яугач, әтәй киез итек алып бирде. Ул, ниндидер сыек кына нәмәрсә тоелса да, тула оек белән киеп җибәргәч, ярыйсы булды тагы. Ә бишмәт әйбәт әле, ертык-тишеге артык күренми. Башка бозау колакчын да алып кайтты әтәй. Менә шуларны киеп, Мәгъмүрәттәй тегеп биргән бәз букчага Коръән белән кәгазь-карандаш салып, мәдрәсәгә укырга киттем. Себер хәтле ерак читкә килеп укучы шәкерт булам мин хәзер!

Мәдрәсә дигәннәре безнеке шикелле озынча бер баракның яртысы булып чыкты. Икенче яртысында Әхтәм мулла дигән хәзрәт бала-чагасы белән тора икән. Ишектән кереп өсне-аякны салу белән, мин монда безнең як мәдрәсәләрендә булмаган сәер яңалык күрдем: малайлар-кызлар бергә укыйлар икән, барысы да кара парта арасында утыралар. Түр стенада кара такта. Менә сиңа кирәк булса! Бу ничек мәдрәсә

булсын инде? Түгел икән шул, «мәктәп» дип атыйлар икән аны, сабакны да «дәрес» дип йөртәләр. Минем таныш малайлар — Фәтки, Һади, Җәгъфәр, Шәмсемехәмәт, Сәмиләр дә укырга килгәннәр. Якуп кына күренми — ул йөрмәскә булган, имеш, өстенә юк ди.

— Син кайсы сыйныфка килдең, Шәйхел? — дип сорады Җәгъфәр миннән. Аптырап калдым, «сыйныф» дигән сүзе нәрсә икән, ишеткән юк бит...

— Мин былтыр ук корьәнгә кергәнием инде,— дидем.

— Алайса, син өченчегә — безнең белән,— диде Сәми.— Давай, утыр, минем янда урын бар.

Гомеремдә беренче мәртәбә парта арасына кереп утырдым. Букчамдагы Корьәнне парта өстенә ачып салдым. Сәми белән бергә туры килү яхшы булды әле. Ул минем якташ малай, Югары Арбашныкы, шуның өстенә безнең әтәйләр күптәнге дуслар булып чыкты. Корбан бәйрәмендә без аларга кунакка да бардык. Алар монда әллә кайчаннан бирле торалар икән. Өй эчләре тулы бала-чага, барысы да кызлар. Бу — бердәнбер малай. Атлары да бар, атасы шуның белән баракларга су ташый икән. Сәми миңа караганда тәбәнәгрәк буйлы, бер яшькә бәләкәйрәк тә, ә үзе инде әнә корьәнгә төшкән! «Р» хәрефен сакаулабрак әйтсә дә, урысчаны бик чиста сөйләшә.

Рәтләбрәк карасаң, монда төрле яшьтәге, төрле сабактагы балалар бер тәртип белән утыра икән: иң алда, кара такта каршында ук — беренчеләр, алар артында — икенчеләр, ә без аларга каршы сул яктан утырганбыз, безнең уң якта ике партада дүрт олы кыз утыра — алар дүртенчеләр икән. Бүлмәсез-нисез бер өй эчендә дүрт сыйныф!

Түрдәге почмакта ике яктан чаршау белән әйләндерелгән кечкенә генә бүлмә сыман урын бар — анда хәлфә абзый тора икән. Мин шулай дигәч, малайлар көлде: «Ник хәлфә булсын ул, мөгаллим абый!» — диделәр. Озак та үтмәстән, менә шул кеше чаршау артыннан килеп чыкты. Бөтен бала «дөбер-р» килеп аягүрә басты. Сәми мине дә төртеп торгызды.

— Исәнме, балалар! — диде ул бер дә ачылмый гына.— Беренче дәрес көнегез мөбарәк булсын!

Аннары утырырга кушты. Без тагын дөбердәшеп утырдык. Гел сәер: парталы, кара такталы мәктәбе дә сәер, малайлар, кызлар бергә укуы да сәер, мөгаллим дә сәер, әйткән сүзләре дә сәер. Шундый озын, ыспай буйлы, артка тараган кара чәчле, баштанаяк шәһәрчә киенгән, хәтта күз камашырлык чиста ак күлмәгенең кайтарма якасы астыннан җемҗем кара ефәк таккан (галстук икән ул) — бай баласыдай бер егет, шундый олылаган кыяфәт белән без чүпле борыннарга: «Исәнме... мөбарәк булсын...» дип, баш иеп торсын, имеш! Моңарчы миңа «гыйлем үгрәткән остазларым» берьюлы күз алдыма килде. Иң алда Югары Тәкәнешнең Нәкыйп хәзрәт күренә. Майлагандай шома түгәрәк битле, кыска түгәрәк сакаллы, түгәрәк чалмалы, үсеп килә торган түгәрәк корсаклы ул. Әллә ничә кат миндәр өстенә түгәрәк булып утырган килеш, бездән кичке сабак тыңлаттыра.

— Әй, хәсис, тагын өйрәнмәдеңмени сабагыңны? — ди. Үзе кауры белән тешен казый, үзе көлемсерәгәндәй итеп кенә: «шул колһуаллаңы да белмәгәч!» дип, кыска түгәрәк бармак очлары белән генә маңгайга төртеп җибәрә.

Аның артында: майланып беткән җиләнле, кергә каткан чалмалы, кырышылган иске читекле, җилпер сакаллы карт Афзал хәлфә шулай ук миндәр өстендә утыра. Кулында озын юан чыбык аның.

— Ятыгыз өчегез дә, хинзир дуңгызлары! Сасыклар! — дип кычкыра ул. Гыйлыкай дигән малайның итегенә «олтан салышлы» уйнаганда үз генә якалашып киткән идек. Хәзер шуның рәхәтен татыйбыз.

Афзал хәлфәм артында, колга башына чалма киерткәндәй, нәзек озын буйлы, җилкә башына каккан тар тактадай җансыз озын куллы, нәзек озын муенлы, чүрәкә борынлы, салынкы озын мыеклы, озын нечкә сыйраклы, чалыш-чолыш аяклы кыяфәте белән үзебезнең авылның Гаяз хәзрәт басып тора. Ул беркемгә кизәнми. Гыйльметтин белән миңа салам көлтәләргә, абзарын әрчеп чыгарырга гына куша. Аннары чүнниктә утын вакларсыз, ди...

Юк, мин боларны бер дә көлеп, мыскыллап язмыйм. Малай күңелдә сеңеп калган сурәтләрен генә бирәм. Бу мөгаллим абый да, бәлкем, шулай күңелгә кайсыдыр ягы белән сеңеп калыр. Ә хәзергә ул сокландыргыч ягы белән генә күренә әле.

Башта дүртенчеләргә, аннан безгә коръән сүрәләре буенча дәрес бирде, шаулашмый гына укырга кушты. Кулындагы кенәгәсе буенча исем-фамилияләребезне барлап чыкты. Аннары, беренче-икенчеләр янына китеп, аларны да барлаганнан соң, тактада төрле хәрефләр күрсәтеп, китапларыннан укыткалап, кат-кат төшендерде дә дәфтәр бите тулганчы шул хәрефләрне язарга кушты. Беренче-икенчеләрнең парталарыни өчендер тәбәнәгрәк итеп ясалган иде, мөгаллим абый парта сыен аларның, баш очларына иелә-сыгыла, ничек язганнарын тикшереп йөрде. Билгеле, гел аны күзәтеп кенә утырмадым мин, бирелгән дәресне ике-өч кат укып чыктым, аннары яндагы малайлар белән чыш-пыш килеп, карандаш очлаган булып, пәкеләр күрсәтештек. Хәер, алар күрсәтеште инде, минеке юк иде. Сәминең әллә ничә балык сурәте төшерелгән калай саплы пәкесе бар икән, ул миңа шуның белән очлатты. Аларның карандашлары да алты кырлы, шәмәхәләре дә, ике башлылары да бар. Ә минем берәү генә, ул да йомры — ике тиенлек карандаш. Бакчи, шуңар да баш җитмәгән, нигә инде төрлесеннән алмаска? Югыйсә, сандык тулы акча ич минем! Ярар, иртәгә килгәч, күзләрен ут итәм әле мин аларның!

Мөгаллим абый безнең янга килде, бирелгән сүрәне тыңлатты. Мин дә шул ук дәресне шартлатып укып бирдем, кешенекеннән бер дә ким булмады, мөгаллим абый туктатмый тыңлады да: «ярый-й» дип кенә, кенәгәсенә билге төртте. Шул чакта дүртенче кызларыннан берсе почмактагы чаршау артыннан чыгып, кыңгыравык шылтыратты.

— Тәнәфес, тәнәфес! — дип бөтенесе шау-гөж килә башлады. Һәм урыныннан кузгалды. Бу да бик сәер — мәдрәсәдә күпме укып, бу сүзне ишеткәнем юк! Мөгаллим абый үз ягына кереп киткәч, бөтенебез дәррәү күтәрелеп тышка чыктык та ничәдер минут уйнап кердек. Монысы да сәер. Баш калкытмый сабак укып ятканда, ду кубып урамга чыгып кит, имеш! Кайсы мәдрәсәдә мондый хәлнең булганы бар?

Ярар, уйнап кердек, утырыштык, икенче дәрес башланды.

— Хәзер безгә имля була, имля! — дип пышылдашты малайлар. Каләм-караларын алып, дәфтәрләрен ачып салдылар. Тагын гаҗәп: нәрсә икән ул «имля»? Каян белә болар барысын да? Сәмидән сорадым.

— Ну, диктовка яздыру инде! — диде ул.

— Ә диктуфкы нәрсә?..

Ул миңа шактый озак карап торды... «Күрегез әле бу миңгерәүне» дип көлгән төсле иде аның күзләре.

— Әйтеп яздыру, алай булгач! — диде ул пышылдап кына.

Башкалар белән эшен бетергәч, укытучы безнең янга килде. Барыбызның да имля өчен аерым дәфтәр, кара-каләм барлыгын тикшергәч, ашыкмый, пычратмый гына уйлап язарга кушып, имлябызның исемен әйтте: «Тырыш шәкерт». Ул аны, партадан партага йөри-йөри, тагын бер тапкыр кабатлады. Аннары, юл башыннан язарга кушып, кулындагы китапның правилә[1] кыстырган җирен ачты да яңа сүзләр әйтте. Ул

[1] Правилә — линейка.

беренчеләрнең сабакларын күзәтеп, парта араларыннан әйләнеп килүгә, мин инде әллә кайчан язып та куйдым.

Инде ярты битне узып киткән идек. «Фәритнең китап һәм дәфтәрләре һәр вакыт тапсыз вә керсез булыр...» дигән сүзләрне язып бетергәндә, мөгаллим абый: «Я-ле, яңа шәкерт, синең хәлләр ничек икән?» дип, яныма ук килеп басты. Басты да, әчмуха минут уздымы-юкмы, минем партадагы бармакларга «шык!» итеп линейка кыры белән китереп тә сукты. Ручка кулдан сикереп, дәфтәр битен буяп, идәнгә барып төште.

— Бу нинди тәртә буе хәрефләр? — дип кычкырды ул кызып.— Мондый язу буламыни? Төш беренчегә! — Имән бармагы белән төртеп, түбәнге парталарга күрсәтте.

Минем, һичнидә аңламый башны түбән салып, мескен генә күчеп утырганны бөтен мәктәп карап торды. Ярый әле, көлүче булмады, нигәдер барысы да тып-тын. Бер ягымда нәкъ чыпчык күкәе төсле сипкелле, чи борынлы бер малай, икенче ягымда нәкъ тәкәрлекнеке шикелле нечкә, чиялак тавышлы бер кыз. Икесенә дә, күп дигәндә, җиде-сигез яшь булыр. Ә мин хәзер унбер тутырып килә торган олы малай, шул көзге чебешләр арасында оялмыйча утыр, имеш! Парта арасына рәтләп сыеп та булмый, аяклар әллә кая сузылып чыга...

Ул көнне мин тагын ниләр укылган, күпме утырылганны хәтерли алмадым. Бөкшәйгән баш белән, кеше ни кыланса, шуны кыланып, кыңгыравыктан соң малайлар киенә башлагач, мин дә киенеп урамга чыктым. Алар, йөгерешеп-уйнашып, берсен-берсе куа-куа чыр-чу килеп, таралышып беттеләр. Ә минем беркая чабасы да юк, аяклар атларатламас бара. Баракка кайтасы да килми, бу хәлне әтәйгә әйтәсе дә килми, куркам да... әллә нәрсәдән куркам...

Ә мәктәптә яңа сабак икәнен белгәч, яңа укытучыны күргәч, инде сөенгән идем. Бактың исә, дөнья кайда да бер төсле икән. «Кая барсаң да бер кояш» дигәннең хикмәте шундадыр инде. Кадим мәдрәсәдәге Нәкыйп хәзрәт кулында таяк булса, яңача укый торган җәдит мәктәбендәге мөгаллим абыйда — үткен кырлы озын правилә. Барыбер түгелмени?.. Бар микән бу дөньяда сукмый-кыйнамый гына укыта торган берәр мәктәп? Юктыр, бер дә тукмаусыз гына безне ничек тынлатмак кирәк?..

Сүлпән генә атлый бирәм. Маңгай эченә кургашын койган шикелле. Бигрәк тә көтмәгәндә китереп сукты бит — үчле малайлар күк... Бөтен кеше алдында өченчедән беренчегә куып төшерсен әле! Хурлыгыңнан җир тишегенә керерсең! Әллә бармыйм микән моннан ары? Валлаһи. Ну үкенерие үзе дә яңа хәлфә! Шундук көләсе килде: үкенә пычагым, күрмәгән ди ул синең күкләрне генә. Ике ятып бер төшенә дә кермәс. Аннары бит әле, бармый нишли аласың? Әтәйгә нәрсә дип җавап табасың?..

Хәер, төптән-җирдән уйласаң, монда мөгаллим абый гаепле дә түгел бугай. Ул бит минем иске мәдрәсәдә укыганлыкны белми, беренчедән үк җәдиттә укыган дип уйлый торгандыр. Алай дисән, мин дә гаепле түгел. Мине бит берәү дә язарга өйрәтмәде, мәдрәсәдәге бүтән малайлар ничек язса, мин дә шулардан күреп, аркылы-торкылы сызгалый башладым. Аннары әтәй хатларын күчереп, сугыштан килгән солдат хатларын укып өйрәндем. Ул чагындагы гарәп хәрефе белән «без» дип язганда, кырын бер сызык сызып, астына бер, өстенә бер төртсәң шул җитә иде. Ә мөгаллим абыйга һәрбер хәрефне китаптагыча төгәл итеп, матур итеп язу кирәк икән. Шулай рәтләп кенә аңлаткан булса, күңелдә бер үпкә дә туасы түгел бит, югыйсә...

Сынык күңел белән шулай уйланып кайта торгач, кыерсыну-җәберсенү дигән нәрсә суына төште. Әтәй үзе ишетеп тыкырдата башламаса, бу хакта ләм-мим авыз ачмаска булдым. Укуны ташлау дигән нәр-

сә барыбер мөмкин эш түгел. Песием генә булып баракка кайтып кердем. Кайтып керсәм, безнең сәке буенда Җыянша абый белән Хөснулла абый утыра. Шаклар да каттым! Алар да безнең янга килгәннәр. Минем бөтен хәсрәтләр бу сөенечтән шунда ук таралып бетте. Өсне салу белән йөгереп килеп, икесен дә кочаклап алдым. Дөресрәге, алар кочаклады мине. Туганнар бит: Җыянша абый әтәйнең энесе, Хөснулла абый әтәйнең абыйсының малае. Кич белән әтәй эштән кайткач, ил хәлләрен сөйләшә-сөйләшә, тамак туйдырдык. Без хәзер өстәлдә үзебез түгәрәк табын булып киттек. Сөйләүләренә караганда, өйдәгеләр, агайэне, кардәш-ыру бар да исәннәр икән. Кыр эшләре беткәч, Җыянша абый читкә чыгасы иткән, безнең күк ул да атсыз-тунсыз кеше бит. Ә уналты яшьлек «егет» — Хөснулла абый аңар ияреп килгән.

Мөбарәшкә абый Мамадыштан ары беркая да чыкмаган, ил-җир күрмәгән булуыннан зарлана иде, олы малаен «Ерак күмер» хәтле ерак җиргә чыгаруы да шуннан икән. Хөснулла абый үзе үк: «Әтәй мине доньяга күрергә җибәрде, Лаеш шулпасы эчеп кайтырга кушты», дип рәхәтләнеп көлеп утыра. Яратам шул Хөснулла абыйның эчендәге тышында булуын! Керсез күңелле егет ул! Моннан соң миңа бик рәхәт булачак инде, миннән алты гына яшькә олы бит — гел малай әле ул! Теге чакта әтәйгә кыз урлашканда авыз ерып калуы да шул малайлыгыннан булгандыр аның...

## Кыр казлары гаңгылдашкач...

Барактагы кешеләр белән дә мин хәзер шактый аралашып, үзләшеп киләм инде. Минем иң яраткан кешем — Төхфәт абый. «Төркәш Төхбәй» дип йөртәләр аны. Авыллары бездән җиде-сигез чакрымда гына — якташ булып чыга инде. Фамилиясе Туйчин. Бик кызык — гомердә мондый фамилияне ишеткәнем юк иде. Бик озак кыймый йөргәннән соң бер вакытны үзеннән сорадым: туйда туган икән ул. Читкә чыгып киткәч, фамилиясен дә шулай яздырып йөртә башлаган. Төхфәт абый ниндидер нечкә күңелле, моңлы-зарлы кеше булып күренә миңа. Буш вакыты булдымы, баскыч төбенә чыгып сап-сары буяулы өйалды башына утыра да бик матур яшел күркле тальянын сыздыра башлый. Юк, шәп уйнамый ул, гармун остасы түгел, гадәти генә уйный. Буын сырларына күмер валчыклары баткан каты бармаклары белән гармун телләренең нечкәрәк тавышлыларына басып, берәр моңлырак авыл көе сайлый да шуны хәсрәтле генә итеп сузарга тотына. Гармунның бер генә бакасына да кагылмый. Күрәсең, аларның юан гырылдык тавышы тупас тоела аңа. Тик уртадагы шундый ук нечкә авазлы, зарлы «сыбызгы»сын гына ара-тирә баскалап куя. Шулай уйный торгач, аның башы әкрен генә уң якка, гармун планкаларының дүрт сәдәфе өстенә иелеп төшә. Мондый чакта аның янына берәү дә килми, сүз катып борчымый, сөйләшмәячәген беләләр, күрәсең. Мин дә читтәге күмер әрҗәсе кырыена сөялеп, аңа күренми генә карап торам хәзер. Элегрәк ул гармун белән чыкса, артыннан ук ияреп, янына килеп утыра идем. Гармун телләренә төртелердәй үк итеп борынны сузам да, аның бармаклары ничек йөгергәнен, кайсы телләргә басып, кайсын калдырса, нинди тавышлар агылып чыгуын күзәтә идем. Ник дигәндә, үземнең дә бик гармунга өйрәнәсем һәм беркем дә көтмәгәндә үкертеп уйнап җибәрәсем килә иде. Минем малай күңелдәге иң татлы һәм иң бөек хыял иде бу! Ничектер бик тиз өйрәнермен, бик җиңел уйнап китәрмен шикелле тоела иде. Җитмәсә, әллә нинди шәп, кызыктыргыч күренешләр күз алдына килеп йөдәтә. Имештер, мин читтә бик тиз үсеп, авылга яшь егет булып кайтам да шул кичне үк урамга чыгып, үзем алып

кайткан шушындый ук яшел күрүкле шәп гармунны кулда биетеп кенә уйнап җибәрәм. Бөтен авыл егете шакката! Шуннан мине аулак өйгә алып китәләр. Анда да бер сайратып җибәрүгә бөтен кызлар һуштан яза!..

Менә шуның өчен дә мин Төхфәт абыйның бармакларына дүрт күз белән текәлеп янында утырам, аның бармакларыннан күчереп, үз бармакларымны да тез өстендә биеткәлим. Гармунын бер генә тапкыр кулыма тотып, бер генә тапкыр кычкыртып карыйсым килә. Көй дигәнең үзеннән-үзе минем бармаклардан да түгелеп китәр төсле. Сорамакчы булам, кыюлык җитми. Ә Төхфәт абый, янында мин барлыкны уйлап та карамыйча, күзләрен бөтенләй йомгандай итеп, һаман уйный да уйный. Аның үз уйлары, үз моңнары бар дөньясын басып алганлыгы әллә каян беленеп тора. Шулай озак моңайганнан соң, уянып киткәндәй күзләрен ача да башын калкыта. Башын калкыта да, үзе уйнаган көйгә кушылып, әкрен генә, басынкы гына тавыш белән моңлы итеп җырлап җибәрә:

> Безнең иләр кайда дибук
> Кыр казыннан сорадым шул,
> Кыр казыннан сорадым.
> Кыр казлары гангылдашкач,
> Бер утырып җыладым...
> И-и кыр казы,
> И-и кыр казы,
> Адаштыңмы дингез читендә?
> Адашкан ла кыр казы кук
> Яра башым йөрим чит илдә...

Бу аның бик яраткан җыры булса кирәк, минем инде аны Төхфәт абый авызыннан берничә кат ишеткәнем бар, кайчакта гармун уйнамаганда да җырлап җибәрә ул шуны. Аның баштагы өлешен безнең авылда да җырлыйлар, ә менә ахырын бер дә ишеткәнем юк иде. Аны-сын үзе чыгарды микән әллә? Хәер, булыр да, шундый моңлы кеше нигә чыгармасын?..

Шул матур җырын җырлап бетергәч, урыныннан кузгала ул:

— Бәрәч, син мондамыни әле, Шәйхели дус? — дип сорый аннары, бик гаҗәпләнгәндәй елмаеп.— Мин гүпчи күрмәдем дә бит сине! Онытылып кителгән, малай. Әйдә керик, эшкә барыр вакыт җиткән бит...— Ул шулай дип шахтерка чоланына кереп китә. Озак та үтми, иске-москы, кара-күмер киемнәр киенеп, кулына коптилка тотып, эшкә китеп бара. Мин аны баскыч төбеннән карап калам.

Ә минем гармунга өйрәнәсе килү тора-бара тәмам бер әче хәсрәткә әйләнде бит. Нишләргә соң, бармак очларына хәтле тиртә, әллә ничек кытыкланып, түзгесез кычынып йөрәккә төшә. Инде төшемдә дә гармун уйнаганымны күрә башладым. Нишләргә соң? Әтәйдән гармун сорау турында башка да китерә алмыйм: акча каян табар? Тапса да алмас, ул андый кеше түгел, уен-муенны бар дип тә белми. Аннары бит әле аны оялмыйча ничек авыз ачып сорыйсың? Минме соң ул андый кеше, куркам ич мин аннан...

Ә бер көнне иртә белән мин үзебезнең шул буйдаклар ягында берүзем калганмын. Йокыдан уянуга — бүлмәдә беркем юк. Әтәй бу атнада беренче сменага йөри, тагын унлап кеше — шулай, алар алтыдан ук чыгып китәләр. Ә калганнар кая китеп беткән соң? Мәгъмүрәттәйләр ягында да тавыш-тын ишетелми. Бит-күзне юу, тамакка кабуны да онытып, бүлмә ишегеннән яптым да Төхфәт абыйлар ята торган каршы як сәке астына кереп киттем. Әллә кайчан беләм: ул гармунын иске брезент кисәгенә төреп, шунда аскы стена буена тыгып куя. Гармунны тиз генә алып сүттем дә, элмәкләрен ычкындырып, шул ук йөзлек буена утырып «уйный» башладым. Бармакларны чын гармунчыларча биетеп

йөрткән булам. Тик пычагым да чыкмый: әле кәҗә бәтие елый, әле бәләкәй генә чучка малае чикылдый. Баш, Төхфәт абыйныкы шикелле, әллә кайчан планка төймәләре өстенә төшкән. Инде ул төймәләр битне сытып кергәндәй авырттыра башлады, күзләр гармун телләренә ябышып каткан, бармаклар һаман эштә. Гармун кычкыра да кычкыра, ә көй дигәнең чыкмый да чыкмый. Исе дә килми, ичмаса! Гармун уйнау — бәрәңге ашау гына түгел икән! Әйтәм җирле аны төннәр буе мунчада, я булмаса сәндерә башында өйрәнәләр, дип көлке итеп сөйләгән булалар, көлке булса да дөрестер, ахры, ул. Әмма күңел болай гына барыбер суынмый әле. «Бер уйнауда гына кем өйрәнгән? Менә үземнеке булса, әллә кайчан гөрләтеп уйнар идем инде» дип юатам үземне һәм тагын ярсып-ярсып кычкырта бирәм...

Берни ишетмәдем, берни сизмәдем, берни күрмәдем, әллә куктән төште, әллә җир астыннан килеп чыкты:

— Кем кушты сиңа гармунга кагылырга, малай актыгы! — дип кычкырып җибәрде Төхфәт абый. Һәм гармунын кулдан йолкып та алды.

Мин аны сменададыр дип уйлаган идем, ә ул бөтенләй эш киеменнән түгел, ничек кенә кайтып керде соң ул? Ник кенә чыгып киткән, ичмаса, өйдән?..

Билгеле — тел юк, тел йотылган минем, баш иелгән, гәүдә бөкрәйгән, куллар салынган, тик торам муены борылган айбагыр шикелле. Ярый әле, озак допросламады, гармунны тартып алуга җилкә тамырына берне тамызды да:

— Ычкын, бәләкәй зимагур! — дип кычкырган булды. Аннары үзе, өстен дә салмыйча, сәкегә йөзтүбән сузылды, гармун да, хәсрәтле тавыш чыгарып, аның уң ягына ауды. Төхфәт абый әз генә «кәкмеш» иде бугай, ахры. Моны сизеп алу белән шундук өйдән чыгып тайдым. Оятымнан нишләргә белмичә, аның күзенә әләкмәскә тырышып йөрдем, әтәйгә әйтер дип котларым чыкты. Менә шуның өчен дә мин гармун уйнаганны читтән генә күзәтәм хәзер. Юк, Төхфәт абыйга үпкәләмәдем, ул бит бер дә явыз түгел, эчкерле-астыртын да түгел, бaрактагы бер кеше белән дә тавышланганы юк, хәтта «чыгымчылап» киткән чагында да һичкемгә бәйләнми...

Ә чыгымчылап китүен үзе дә сизми кала бугай ул. Шул «кәкмеш» булып кайтудан соң берничә көн узуга Төхфәт абый бөтенләй чыгырыннан чыгып куйды. Кыш булса да изүләрен чишеп, җирәнчә төстәге борындык бүреген шәп егетләрчә генә кыңгыр салган килеш ишекне киереп ачып җибәрде дә:

Һай, нужалар, нужалар,
Безнең баштан узалар.
Нужа күрмәгән егетләр
Карт ишәктән хужалар,—

дип җырлый-җырлый, дөнья күчереп кайтып керде. Без чәй эчә идек, өстәл катына ук килде:

— Исәнме, Пәрхулла абзый! — дип кычкырып җибәрде бу. Аның болай ук кыланганын бер дә күргәнем юк иде әле минем.

— Исәнен исән дә... авызыннан шайтан ние исе килә икән,— диде әтәй.— Чүмечләп чөмердеңме, әллә чиләкләп кенәме?..

Бу аның исереп, шау кубарып кайткан кешеләргә әйтә торган текә сүзе иде. Төхфәт абыйга да бик әче тоелды бугай ул, каршы берни дә эндәшмичә, үз почмагына барып ауды. Әмма бер башлагач, ул шулай айдан артык булганып йөрде. Онытканда бер эшкә төшеп менә дә тагын кәефләнергә тотына. Сәке астыннан чыгарып гармун кычкырткан була, тик уйнавының рәте китте, үтмәс пычак белән тавык суйган тавышлар чыгара башлады. Шуннан соң ул: «Һәй, анасын эт еккыры»,— дип, гармунын түргә ташлый да тагын күңел ачарга чыгып югала.

Бер көнне аны эштән борып кайтардылар, эчеп килгәнгә микән, әллә расчетка ук эләкте микән. Бер дә исе китмәде, өс-башын алыштырып чыгып китте дә бүтән бараклардагы дус-ишен ияртеп кайтты. Ике як кесәсендә ике «кәжүнни савыт» моның, эшнәләрендә дә бер-икене тоттырган. Өстәл сырып эчү башланды.

Безнең баракта Арбаш Мәүлә дигән кеше бар иде. Төхфәт абый белән күрше авылныкы гына, ул гел аның табыны уртасында була. Мәүлә агай аракы дигәндә җанын бирердәй кылана, аванс-получка көннәрендә кем табынында шешә күренсә, шунда сыланып, «чокыр төбе» генә булса да яламыйча калмый. Бик ата зимагур булып күренергә дә ярата, усаллыгы да шактый зур. Эт күнеле бер сөяк дигәндәй, юктан җәнҗал чыгармасын өчен генә табынга кыстыралар аны, болай бер дә өнәмиләр. Ник дигәндә, «Мәүлә абзагыз кешедән эчәргә ярата да, кесәдән эчәргә яратмый» диләр аның хакында. Ә Төхфәт абыйны ул аерым бер комагайлык белән имә. Өстәлдә аракы бетсә, хәзер Төхфәт абыйдан акча таптыра да үзе йөгереп алып кайта. Бу юлы да ул «баш» иде.

— Уйлама да, Төхбәй дус, ыраччут дип өркеткән булсалар да, үзләре килеп чакырачаклар сине! Күмернең мондый да кирәк чагында забуйшекне көндез чыра яндырып эзлиләр, башың гына исән булсын! — дип, аның кайгысын «юдылар». Аннары баракны яшелле-күкле тавышлар белән тутырып, әле татарча, әле урысча җыру яңгырый башлады.

Күп чакта Солтан абый башлап җибәрә җырны. Калку буйлы, озынча матур йөзле, кара бөдрә чәчле, җем-җем янып торган үткен күзле бу егетне табынга үзе чакырып утырта кеше. Ул Чыршы арты дигән авылныкы, бездән биш кенә чакрымдагы якташ. Аны да яратам мин. Елмаеп кына эндәшә ул кешегә. Табыннарда утыргаласа да, ямьсез кыланмый, ә тавышы бик матур яңгырый аның — гел җырлатып кына торырлык. Ун елдан бирле кайтканы юк икән. Нинди язмышлар, нинди серләр шулай читтә йөртәдер ул тәүфыйклы егетне. Бу хакта беркем дә сөйләгәне юк. Табын утырган чакта гел бер җырдан башлый ул:

Зимагур булды башым,
Кайталмам, кара кашым.
Көтмә мине, түкмә яшең,
Чык кияүгә, җанашым...

Җырга башкалар да кушылып җибәрде. Аның артыннан бик шәп сары бөтеркә мыеклы, майлап тараган саргылт чәчле, читчә тегелгән кара постау тужуркалы, ялтыравык каты күныч күн итекле Яшка-Ясәви дигән зимагур тотынды. Ул кеше бүтән барактан, сөйләшкәндә гел урысча гына сукалаган була, ә сүзләрне ватып-җимереп әйтүен хәтта мин дә сизеп торам. Андый кешене «тугызлык ваклый» диләр бездә. Карлыккан тавыш белән җырлап җибәрүе дә шулай килеп чыкты:

Лүбелү, лүбелү, милаша,
Лүбелү, уважжлю.
Чирез тибә, милаша,
Ташкин уежжаю...

Бик кыланчыкланып маташса да, күтәреп алып кушылучы булмады.

«Берегез дә минем хәтле булдыра алмый!» дигәндәй, ялт кына Мәүлә калкынып, ике кулын ике ягындагы кешенең җилкәсенә салды һәм яман да әче нечкә тавыш белән тамак төбен ертырдай чәрелдәп җибәрде:

Абзый, атың кайда-ле,
Болындамы, бәйдәме?
Аяк тибеп, җырлап эчү —
Зимагурның бәйрәме!

Чух-мух, ни дэй бух,
Закускыга калбаса.
Безнең моннан кайтасы юк,
Әтәй килеп алмаса!

Бар да беравыздан кабатлап алдылар:

— Э-эх, безнең моннан кайтасы юк,
Әтәй килеп алмаса-а...

Шуның артыннан ук кычкырып көлеш китте.
— Беткән башлар! — дип куйды берсе.
— Юк, егетләр! — диде Солтан абый,— мин өметне өзмим әле, аяктагы буразна балчыгы барыбер үзенә тартачак. Сал тагын берне, озатып бирәм!
Чокырлар күтәрелгәч, без каз көткәндә җырлаган җыруны әйтеп бирде ул:

Агыйделгә яр якын,
Яр якынга су салкын.
Алтын-көмеш чыккан җирдән
Туган-ускән ил якын.
Һәй-й, сумса, сумса, сумса,
Кайтырбыз, бирган булса!

«Сумса»ны тагын шау-гөж килеп кабатладылар. Көндез үк башланган бу типтерү кичен эштән кайткан шахтерларга тамак туйдыру өчен өстәл кирәк була башлагач кына таралды. Ә кайчакта өстәлдән сәкегә күчеп тә дәвам итә ул. Тик безнең әтәй кайтып керсә генә кинәт шым булып, берәм-берәм барактан сызалар. Аннан куркалар икән. Үзе дә, ахры, усал бугай ул. Кырыс тавыш белән бер генә сүз әйтә, әгәр инде берәр исерек каршы тел кайтара башласа, якасыннан эләктереп бусага төбенә хәтле китерә дә (ә теге муены буылудан гыж-гыж килә) ишектән «озатып» җибәрә, егетең баскычтан ничек төшеп киткәнен сизми дә кала.
Төхфәт абый ул чакта шулай күңел ача торгач, рәешкә генә кия торган яңа «парочкы»сын, бөтен өс киемнәрен, күлмәк-ыштанын дигәндәй, сатып бетерде. Эшкә йөри торган күн итеге әйбәт кенә, нык кына иде, ул да ычкынды. Тора-бара гармунын да «кияүгә» бирде. Ахыр килеп, җыен иске-москыдан йөри башлады, барактагылардан «бер чокырлык кына» теләнүчән булып китте. Дуслары да әллә кая эреп бетте. Хәтта бер сәкедә ята торган Мәүлә дусы да аны хәзер белми дә, танымый да иде. Ялынып бер сүз эндәшсә, эт итеп сүгеп җибәрә, артыннан мыскыллап кала. Тик аңа Мәгъмүрәттәй генә бик зур булышлык күрсәтте. Аларда да шул ук шахтер чуены, югыйсә. Җитмәсә, бер эшчегә, бала караучы кыз белән, дүрт тамак. Шулай да Мәгъмүрәттәй аңа, ни пешерсә — шуннан өлеш чыгармый калмады. Кайчакта холостойлардан калган аш булса да, әгәр тегеләр үзләре ашамаса, Төхфәт абыйны үз якларына чыгарып тамак ялгата, өстендәге иске-москысын юып, ямап бирә иде. Бер кичне мин аларга тоз сорап кергән идем, Төхфәт абый өстәлгә терсәкләре белән таянып башын кыңгыр төшергән дә елап утыра; алдында — аштан бушаган тәлинкә белән кашык.
— Их, Мәгъмүрәттәй! — ди бу, миңа таба күз дә төшермичә.— Туган анам син минем, туган анам!.. Без дә болай йөрериекмени-и, канат яшьтән каерылмаса-а!.. Рәхмәт сиңа, түтекәем, җаным-тәнем белән әйтәм...
Тавышына, сөйләвенә караганда, әз генә «кәкмеш» иде ул. Мин әкрен генә үз йомышымны әйттем дә шундук чыгып китү өчен ишек бавына тотындым. Төхфәт абый башын калкытты:
— Ә-ә, синмени әле бу, Шәйхел дус! — диде. Аннары бөтенләй турайды да: — Әйт әле, ылан, синең үз анаңмы? — дип сорады.

Мин кызмача абыйга ничек җавап бирергә белмичә торганда, Мәгъмүрәттәй тоз китереп тоттырды. Авыз эченнән генә «әйе» дидем дә чыгып киттем.

Мәгъмүрәттәй аны озак вакытлар күз читеннән ычкындырмады. Әкрен, йомшак тавышы белән үгетләгән чакларын да ишеткәләдем. «Болай йөрмә, Төхфәт, әрәтләнә. Менә эшкә башлап, өс-башларынны хәстәрләп җибәрсәң, өйләндерәбез үзенне. Үзем бик әйбәт кыз табып бирәм, менә дигән җегет бит син!..» дигән шикеллерәк сүзләр белән юмалый иде бит аны.

«Яхшылык җиргә екмас» диләр бугай. Мәгъмүрәттәйнең аңа күрсәткән мәрхәмәте дә, яхшы ният белән юмалавы да бу сынык канатлы егеткә күңел даруы була килде, ахры. «Бичула» йөрүләре әкренләп күренмәс булды. Хисаметтин абзый булышлыгы белән өстәге откаткага гына булса да керешкәч, кеше арасына табынга утырып ашый да башлады, тора-бара элекке шикелле юаш холыклы, кече күңелле әйбәт егеткә әйләнеп китте Төхфәт абый. Озакламый яңа күлмәк-ыштан да күренде, ә получкадан соң яшел вельветтән генә булса да өстенә яңа костюм да юнәтеп җибәрде. Тагын берәр ай узгач, әнә шул яшел күркәле, нәкъ элеккесе төсле гармун да алып кайтты ул бер көнне. Белмим, шулай туры килде микән, әллә яшел күркләне юри сайлап алды микән.

Бер баракта бергә яшәгәч, кемнең кем икәне барыбер беленми калмый инде. Миңа да Төхфәт абыйның үткәннәре хакында ишетергә туры килде. Туйда аны тапкан анасы, шуннан кайтышлый нык кына суык тидергән дә, бик каты чирләп, өч ел буена кара ютәл белән җаны суырылгач, гүр иясе булган. Атасы яшь хатын алган. Үги аналарның йөздән туксан тугызы шикелле, ул да «мәрхәмәтле» булган, имеш: бәләкәй Төхфәтне кыш уртасында ялан аяк, ялан өс урамга куып чыгарулар да, ачулы йодрыкның каты мөгезе белән баш түбәсен дыкылдатып торулар да, тамагына бирми тилмертүләр дә гадәти нәрсәгә әверелеп киткән. Атасы әкияттәгечә күзле сукырга әйләнгән, имеш. Төхфәтнең ике олы тутасын, унҗидегә җитәр-җитмәс үк, бер-бер артлы кияүгә очырган үги ана. «ипи чертеп ятмасыннар!» дигән. Төхфәт унбиш яшендә туган йортыннан чыгып киткән. Пирмегә хәтле җәяү атлаган ул. Су өстеннән пароход бара, ә су ярыннан пароходка карап бу бара, имеш. Шулай көчкә-начылый Кизеле шахтасына килеп егылган, шуннан бирле Урал-Себер рудникларының, алтын прискаларының кайсында гына бәхет сынап йөрмәгән, тик авылына бер генә тапкыр да кайтып күренмәгән. Ә үзенең туган җирләрен өзелеп сагынуы, һаман да бик газиз итеп күңел түрендә саклавы әллә каян ук сизелеп тора аның.

Бу хәлләрне белгәч, Төхфәт абый миңа үз туганым шикелле якын булып китте. «Үз ананмы?» дип сорады да бик ачык аңлашылды. Моңаеп гармун уйнавы да, кыр казларын җырлавы да шуның билгеседер. Сагышлы йөрәге ярсуына чыдый алмыйча «чыгымчылап» китүе дә һич гаҗәп түгел иде хәзер.

Минем бала күңел кинәт куырылып, без яга торган ташкүмер шлагыдай катып киткән кук булды. Бөтен үги бала бердәй үк бәхетсездер, кешене җәберли торган барлык дошманнар — үги ана төсле шәфкатьсездер тоела башлады. «Мин дә кайтмыйм!..» дигән уйга килдем. Шунда ук олаеп киткәндәй булдым, әйтерсең иртәгә үк шахтага төшәчәкмен!

Палучка көннәре килеп җитсә, авылга хат яздыру китә иде. Бөтен өй эченә, кардәш-ыруларга, күрше-күләнгә, мәчет картларына һәм хәлэхвәл сораганнарга чуктыйн-чук сәламнәр тездергәннән соң, үзенең исән-аман эшләп ятуын хәбәр итеп: «Бу палучкада эшләремез таманчарак булу сәбәпле, ушбу хатым белән фәләнчә сум гына акча салам, аз булса да күп итеп алгайсызлар», дип яздыралар иде. «Алдагы ай-

ларда ходай насыйп итеп, кәсепләремез уң булса, күбрәк җибәрергә тырышырмын. Югары оч Мифтах абзый белән сөйләшеп китткән идем, язгысын биясе исән-сау котылса, колынын безгә бирмәкче булган иде, җибәреләсе акчаны шул колын өчен саклабрак торсагыз бик яхшы булыр иде», дип юатып та куялар.

Мондый чакта Төхфәт абый стенага карап үз почмагында ята. Аның беркайчан да беркемгә дә хат яздырганы юк. «Хат чире» чыккан көннәрдә ул бигрәк тә боегып, моңсуланып китә. Мәүлә булып Мәүлә дә хат яздыра бит өенә. Акча салмаса да яздыра. Хатыны бар, малае бар икән, шуларны алдалый: «Киләсе айда күп итеп салырмын»,— дигән сусыз мунчала белән аркаларын ышкый.

Ә Төхфәт абый, япа-ялгызы баскыч төбендә утырып, гармунын суза да суза, ә күңеле,— читтән үк күреп торам,— сыза да сыза... Этәй дә аны җәлли бугай. Бер кичне үзебезнең өстәл янына чакырып сөйләште. Алдына чәй ясап куйды. Мәгъмүрәттәй ат маенда чыжылдатып кына кабартма пешереп керткән иде,— шуны куйды, шикәр белән лампасый куйды, шуннан үгетләү сүзләре теркәп алып китте:

— Атаң бар бит, Төхфәтулла, ул инде картайгандыр, ярдәмгә мохтаҗдыр... Ата хакы — алла хакы, диррие безнең Шәһи әби. Шулай булгач, гел онытып бетермәскә кирәгие син аны. Бер-ике авыз җылы сүз яздырып, биш-ун сум акча да салып җибәрсәң, башы күккә тиярие. Анда синең әле кыз туганнарың да бар түгелме соң?..

Мондамы, авылдамы ишеткәнем бар: безнең этәй зимагурны үгетләп игә китерүнең «догасын» белә, имеш. Хәтта унбишәр ел койрык чәнчеп йөргән якташларын да шулай игә кертеп, үзе белән бергә ил җиренә алып кайткалаган, диләр. Бу юлы да ул шундый ният белән керешкән иде микән, белмим, әмма Төхфәт абыйга теше бик үтеп житмәде аның:

— Их, Пәрхулла абзый-й,— диде ул, тирән сулап.— Хат салыр кешем юк шул минем! Анда мине берәү дә көтми, берәү дә сагынмый, берәүгә дә минем кирәгем дә юк анда... Ата хакы дисең син. Бик кадерле сүз. Әмма нишләмәк кирәк: «Анаң үги булса, атаң урыс була», дигән сүз дә бар бит әле. Хәер, урыс әле ул — кеше, аның белән бер баракта тып-тыныч яшәп була, бер табактан ашап була, бер забуйда күмер чабып була, ә минем әти белән бер өйдә яшәү мөмкин булмады, үз баласын үзе куып чыгарды. Оят булса да әйтим: дуңгызга әйләнде ул, үги ананың ата дуңгызына! Ул ни мыркылдаса, бу да шуны мыркылдап, өйдән чыгып качарга мәҗбүр итте. Күрше авылда бер җәй көтү көттем, янымa килү түгел, кеше аркылы да бер җылы сүз әйтеп җибәрмәде. Шуннан соң инде читкә олактым... «Биш-ун сум» акча салу да пүчтәк. Зимагур Төхбәй ун тәңкә акча җибәргән дип, бот чабып көләчәкләр генә. Күңелемдә үч төбедәй генә җылы булса, йөз тәңкәсен дә табарыем. Юк, Пәрхулла абзый, булмый, үгетләмә, әрәм итмә яхшы сүзеңне. Йөрәгем боз булып каткан, аны эретә торган утлар юк. Рәхмәт әйбәт сүзеңә, рәхмәт тәмле чәеңә...»

Этәй, нишләптер, бер сүз дә эндәшмәде һәм ничектер уйга баткан шикелле булды. Төхфәт абый әкрен генә кузгалып китте. Нишләп этәй үгетләүдән кисәк туктап калды соң? Әллә үз башыннан үткәннәре исенә төште микән? Аны да яшь ана кулында үскән диләр бит... Тик бу хакта минем берни дә сораганым юк, куркам да, оялам да. Ә үзе сөйләми инде ул...

Төхфәт абый күптән инде минем белән сөйләшкәләп йөри башлады. «Син үпкәләмә, агай-эне», дип бер вакытны баштан да сыйпады, үз иткәне әллә каян күренеп тора иде. Алай гынамы соң, бер көнне гармунын миңа үзе китереп тоттырды ул.

— Мә, алып кал, мин эшкә китәм, туйганчы уйна да сәке астына тыгып куй,— диде.

Ә мин алмадым. «Рәхмәт, Төхфәт абый, уйнасым килми», дип кире бирдем. Юк, үпкәләп түгел, ачуым килеп. Гармунга ачуым килде минем. Нихәтле теләп, нихәтле кайнар дәртләр белән ашкынып та, шул түземсезлек аркасында хәтта рөхсәтсез тотынырга мәҗбүр булып та, бер көй дә чыгармаганы өчен, тиз генә уйналып китмәгәне өчен ачуым килде. Мин гаепле түгел, гармун гаепле иде. Муен тамырына төшкәнгә өчен дә ул гаепле иде. Бөтен ашкынуларым, бөтен матур хыялларым көлке булып калганы өчен дә ул гаепле иде. Шуңа ачуым килде. Шуңа алмадым. Читтән тыңлап торуы әйбәтрәк...

## Кем иде соң ул?..

Төхфәт абыйлар ягындагы сәкенең икенче кырыенда, шулай ук стена буенда ятучы Гайнеттин абый бар. Ул да бик әйбәт. Бараккагы бөтен кешегә ачык йөз, тәмле тел белән эндәшә, берәүнең дә йомышын кире какмый, «Гайнеттин дус, әдрис кенә язып бирче» дип, бөтенесе аңа килә. Ник дисәң, ул бөтен баракта бердәнбер әдрис яза белүче, алай гынамы соң, теләсә нинди урысча китапны шартлатып укый алучы кеше. Ул әле без бу баракка күчкәч кенә монда күренә башлады, элек бүтән жирдә торган булса кирәк. Үзе Өфе ягыныкы булса да, якташы Хәжвәли абзыйларга түгел, никтер безнең якка урнашты. Хәер, я анда урын булмагандыр инде, я ничектер...

Калку буйлы, төзек гәүдәле, кара житү чәчле, сирәк кенә, сай гына шадра сибелгән мөлаем йөзле, аксыл чырайлы егет иде ул. Шахтада эшләсә дә, үзен бик чиста йөртә, аның колак артларында, тырнак асларында калган күмер карасын күрмәссең, күлмәк якасы да ап-ак, аның өстеннән кигән яшькелт-кара костюмы да бик пөхтә,— хәер, бөтен өс-башы коеп куйгандай килешле һәм ыктымат аның. Гайнеттин абыйга мин бигрәк тә сокланып карыйм: урысчаны су күк эчә, әллә нинди калын китаплар алып кайтып укый, ничек әләктерде икән шул хәтле гыйлемлекне! Ә мин урысчаның бер хәрефен дә яза белмим, ичмаса.

Гайнеттин абый «гүләнҗе» табыннарына катышырга яратмый иде, шулай да аны көчләп булса да утырталар, ә ул хәйләкәр: я бер уенкөлке сүз белән тегеләрне мавыктыра да, я бер тәжел йомыш тапкан була да араларыннан чыгып сыза. Аңа үпкәләмиләр, тик Мәүлә генә аны яратмый.

— Ник утырсын ул безнең ише кара мужик белән,— ди.— Ул бит димназиядә укыган. Берәр бай баласыдыр әле...

— Димназия түгел, гимназия! — дип төзәтә теге сары бөтеркә мыек Яшка-Ясәви.— Эх, бар иде жегет чак — желек чак! Үзем дә кайчандыр бер гимназистканы апнимал и патсалавал! Канешно, янакка берне чалтыратты анысы, но чүтеки авызы татлы иде!..

Бар да аннан көләләр, ә Гайнеттин абыйның табын ташлап китүе шуның белән онытыла. Ул гимназиянең нәрсә икәнен мин белмим, беренче ишетәм, әтәйдән сорап караган идем, ул да бик ачык әйтеп бетермәде: студиннар укый торган жир дип кенә куйды. Ә студиннар кем, алар кайда була? Ул хәтлесен үк төпченергә минем йөрәк житми. Бишектән үк ата кулына, аның сулышына ияләнмәгәнгәдер инде ул...

Гайнеттин абый кыш буе дип әйтерлек шулай безнең арада яшәде. Төхфәт абый чыгымчылап терелгәннән соң, аның белән дуслашып алды. Серләре бик килешкәндәй гел бергә йөрүчән һәм эшкә дә бергә төшүчән булып китте алар.

Кышкы озын кичләрдә сугыш турында бәхәс чыга иде. Хәер, бәхәс тә түгел инде ул, «кем җиңә?» хакында сөйләшеп утыру гына. Билгеле,

баракта гәзит алдыручы юк, шулай да фронтта ни хәлләр барлыгы монда да килеп керә. Аны шахтерлар эштән ишетеп кайталар.

— Һаман «нашы бирут» та «нашы бирут» дип кычкыралар,— дә берсе.— Ә патшаның вәйскесе һаман артка чигенә дә артка тәгәри.

— Бирут, пычагым!— дип, икенчесе аны куәтләп җибәрә.— Үзе һаман солдат җыя, үзе күпме каланы мимечкә бирде инде!..

— Ник бирмәсен, патшабикә мимеч кызы ди бит безнең...

Бу әңгәмәгә безнең әтәй дә катышкалый. Ул үзе солдат хезмәтеннән ерак торса да, сугыш хәлләре белән бик кызыксына, ничектер шуны төпченә белә. «Дибетсут читбирти» елда японнарның Пыртатурны ничек ватып-җимереп, безнең корабларны ничек батырып, безнең патшаны ничек җиңүе турында да, нәкъ үзе шунда булган кешедәй ышандыргыч итеп сөйләргә ярата ул. Бүген дә шулай сизелде.

— Әле бер көнне теге карт табилшек Петр Яклич белән кайттык,— дип башлады.— Позициядә эшләр ничегрәк, мин әйтәм, нашы бирутмы, немес бирутмы? — дим.

— Наши берут...— ди бу, сүлпән генә итеп.

— Бирутын бирут, мин әйтәм, зачем назад бигут? дим. Теге эндәшми. Сам пасматри, мин әйтәм: ничәмә кала китте хәзер? Мин белгәннәре генә — Кауна, Вильнә, Ревель, Лудзы, ә чичас Варшау! Кайчан кайтарып алабыз инде без боларны?.. Теге ни әйтергә дә белми, үзе елмаймакчы була, үзенең ачуы килә. «Па-ашул, татарин!» ди.

Бараңтагылар кычкырып көлә, мин дә әтәйнең шулай курыкмый сөйләшүенә куанып утырам.

Монарчы үз почмагында тып-тын гына ниндидер урысча китап укып яткан Гайнеттин абый да сүзгә катнаша:

— Әйе шул, «наша берет»ны кычкыручылар шактый безнең илдә, һәм бер урыстан гына түгел, безнең мөселман гәзитләре дә шулай дип кычкыра. Ләкин кычкырып кына ни файда соң? Корал юк бит бездә. Хәзер яңа алынган солдатларны агач мылтык белән өйрәтәләр, агач патрон аттыралар. Позициядә винтовка җитми, пушка юк. Безнең патшалык хәерче бит ул. Шунлыктан генераллар солдатны сарык көтүедәй өереп сугышка кертәләр, алдагылары кораллы, арттагылары буш куллы. Алдагылар үлгәч, аларның коралын алып сугышырга тиешләр. Ә немеснең корал күп, әнә хәзер газ белән дә тончыктыра башлаган. Шулай булгач, Кайзер җиңми хәле юк. Только ул җәнгәннән Россия халкына нинди җиңеллек килер икән? Безнең патша җиңсә дә шулай ук. Патшалар сугышудан ил кешесенә нинди игелек килгәне бар? Менә сугышны тизрәк бетерергә иде аны. Урыс солдаты белән герман солдатының нәрсә бүлешәсе бар? Ә күпме ятим балалар, тол хатыннар, караучысыз карт-корылар кала?..

Әле генә шау-гөж килеп утырган кешеләр тынлыкка чума. Аның белән кайберәүләр бәхәсләшергә теләп карый:

— Без нәрсә, кара халык — кара сарык. Барыбыз да патша кешеләре, ул ни куша — шуны эшлибез. Бик бетерәсие дә, безнең кодрәттә түгел шул.

— Бөтен бәлә дә шунда инде,— ди Гайнеттин абый.— Кодрәт юк дип уйлауда. Ә бәлки бардыр ул?.. Без менә күмер чыгаручылар, ә күмерсез сугышып буламы? Ә башка күпме заводларда, күпме фабрикаларда сугыш өчен эшләүче тагын күпме эшче халык бар? Алар да тынсамы?..

Аның мондый сүзләреннән соң баш кашучылар күбәя. Үле тынлыктан котылыр өчен берәм-берәм теге-бу йомыш белән тая башлыйлар. Калганнары да аңа сәерсенеп һәм сагаеп карый, күңелләренә шом сала төсле ул. Аның сүзләре минем малай башны да уйландыра. Аңлап бетермәвем тагы да мавыктыра төшә. Әллә нинди мәгънәләр бардыр кебек ул сүзләрдә. Гайнеттин абый үзе дә әллә нинди яшерен серләр

белә торган бик укымышлы кешедер төсле тоела. Шундый көлеп тора торган итеп яза бит ул әдрисләрне дә! Әй бер сөйләшиең үзе белән, мина да ул ачсын иде шул куркыныч та, мавыктыргыч та булып тоелган серләрен!..

Алай булмады шул... Инде яз башы иде, көяшлы көннәрдә әз-мәз тамчы да тама башлаган чак иде, мин Мәгъмүрәттәйгә күмер кертеп йөргәндә, баракка стражник килеп керде. Башында папаха сыман очлы бүрек, өстендә кара шинель, биләндә кылыч. Калын каш астыннан карый торган күзләре уттай янып тора. Стражникны болай якыннан беренче күрүем булгангамы, аның бөтен кыяфәте бик куркыныч төсле тоелды миңа, сөйләшүе дә шул ук тойгыны көчәйтә генә бирде. Шак-шок басып Мәгъмүрәттәйләр бүлмәсенә керде дә, сумкасыннан ниндидер кәгазь чыгарып:

— Гай... Гай... Гайсаров у тебя живет? — диде ул төксе тавыш белән Хисаметтин абзыйга.

Хисаметтин абзый сменадан соң ял итеп ята иде, ашыкмый гына кузгалып, ялан тәпи идәнгә басты һәм сабыр гына тавыш белән җавап бирде:

— У нас был...

— Был! — дип кычкырды стражник. Шунда минем малай башка сәер бер уй килде: «Бу шакмак күзнең исеме «куркытучы» дигән сүз булып чыга түгелме соң? Әллә шунар күрә болай әшәке кычкыра микән ул?..»

Ә Хисаметтин абзый, бер дә исе китмәгәндәй, һаман шулай сабыр гына җавап бирде:

— На работу пашол, шахту. Здвух...

Ул һәр вакыт шулай ашыкмый сөйләшүчән кеше иде, әмма стражник алдында да үзен шулай тыныч тоткач, мин ана сокланып калдым, «батыр икән бу!» дип уйлый башладым.

— Смотри, гололобый, башкой отвечаешь! — диде стражник, күзләрен тагын да акайтыбрак.— Вечером штоб на месте был!..— Аннары кырт борылды да дагалы итекләре белән шак-шок атлап чыгып китте. Бу хәлне олы як бүлмәдәгеләр сизми дә калды. Ә мин «кемне эзли соң бу?» дип аптырагач, Мәгъмүрәттәйдән сорадым.

— Шаулый күрмә, ылан,— диде ул пышылдап,— Гайнеттин абыеңны сорый...

Мин тагын да аптырабрак калдым. Бердән, аның фамилиясе Гайсаров икәнен бөтенләй белми идем. Кара син аны, нинди фамилия бит! Гомердә ишеткәнем юк иде. Икенчедән, ни өчен стражник эзли икән аны? Әллә берәр гаебе бар микән? Әллә берәр законсыз эштә катышкан микән, начар юлда йөри микән? Хәер, алай дисәң, гимназиядә укыган кеше ди бит. Ничек кенә баш ватсаң да очына чыга торган түгел. Серле кеше ул: үзе дә серле, сүзе дә серле, фамилиясе дә серле! Һәм минем өчен шул серле килеш юкка да чыкты ул.

Бер көн юк, ике көн, өч көн юк! Мин һаман берни белми йөрим. Төхфәт абыйдан сорыйм — баш кына селкә. Аптырагач, әтәйдән сорыйм. Ул да белми, никтер бу хакта сөйләшергә теләмәгән төсле тоела. Гел пошаманга төштем, нигәли аны теге стражник төнлә мин йоклагач алып китте икән?. Ахырда, бик йөдәтә торгач, сер итеп кенә Мәгъмүрәттәй аңлатты:

— Эзләмә инде син аны, ылан,— диде,— кеше барында ул хакта сүз дә кузгатма...

Аның сөйләвеннән мин шуны төшендем: Хисаметтин абзый, төнге сменага алданрак барып, Гайнеттин абыйны күргән дә өйдәге хәлне әйтеп биргән. Гайнеттин абый баракка кайтып күренмәгән, тик төн уртасы җиткәч кенә бер кеше сак кына Мәгъмүрәттәйләрнең тәрәзәсен чиертеп Туйчинны сораган. Төхфәт абый үз дусының бәләкәй чемода-

нын тып-тын гына бараклан алып чыккан да теге кешегә биреп җибәргән. Шуның белән вәссәләм. Дөрес, Мәүлә генә салмыш баштан бер сөйләнеп алды:

— Гайнинең шикле икәне кыланмышыннан ук күренеп торадырые! Җуләр, берәр укымышлы разбунниктер ул!..

Тик аның сүзенә катышучы да, җөпләүче дә булмады...

## «Почмак фирештәсе»

Безнең баракта тагын бер сәер кеше — Җиһангир абый бар иде әле. Сәер дип, әллә ни сәерлеге дә юк инде аның, шулай да бик үзенчәлекле егет. Ин әлек: ул берәү белән дә аралашмый, якташлары Бәләбәйләр белән дә якынлыгы күренми, табында да берүзе ашый, эшкә дә берүзе чыгып китә, анда-монда барса да гел берүзе. Икенчедән, ул вак тәмәкече. Урыны безнең як сәкенең мич буе почмагында. Эштән кайтып ашый-эчә дә, авызына насбай салып, шул почмагына барып каплана. Шул йөзтүбән сузылган килеш, баш асты тактасы артына черт-черт төкереп тик ята бирә. Аның баш очындагы стена бүрәнәсе дә, такта кырыйлары да сап-сары булып беткән. Юк, чиста сары түгел, яшькелтпычрак сары! Мәгъмүрәттәй тактаны кырып юып, бүрәнәне известь белән агартып та карый, Җиһангир абыйга әйткәләгән чагы да була, тик ул барыбер үзенекен итә.

— И Мәгъмүрәттәй, ачуланма инде,— ди,— төн уртасында кая куз-галып йөрмәк кирәк? — ди. Ике көннән аның баш очы тагын сыек гәрчис сиптергән төсле була. Шул насбай дигәннәрен бер дә ирен астыннан төшерми ул. Усалраклар: «Әй, вак тәмәкече, кая, бер сыйла әле!» дип кычкырган була аңа. Үзе бер дә ачуланмый тагы.

Өченчедән, башы таз аның. Хәер, кутыры хәзер беткән инде, ул урыннарга чәч үсмәгән, шәп-шәрә, шуның аркасында бөтен башы ала-тилә булып тора, күрер күзгә бик иләмсез тоела. Дүртенчедән, шадра әле ул, тирән кара шадра. Әйтерсең кара буяулы борчак белән аттырганнар битенә, һәм шул буяу бер дә юмаслык булып, чокыр төбенә сеңеп калган! Бишенчедән, әйтеп кеше ышанмас, болары гына әз булган шикелле, бер колагы куш яфраклы иде әле аның. Икенче яфрагы, юрамалый ябыштырып куйган сыман, аска таба сузылып үскән. «Бияләй колак» дип тә көләләр аннан. Бирсә дә ходай бирер икән бәндәсенә шул хәтле бәхетсезлекне! Шуларның берсенә дә карамастан, шәкерт булган әле ул. «Картайганчы мәдрәсәдә яткан шәкерт» дип сөйлиләр аны. Ә мәдрәсәдәге вак шайтаннар арасында ничек түзде икән ул бичаракаем. Шул бәхетсез кыяфәте өчен күпме мыскыл, күпме җәберләр күтәрде икән? Бәлкем, шуңа күрә дә Җиһангир абый әнә шундый сүз сөймәс, аралашмас булып, «почмак фирештәсе»нә әйләнеп киткәндер. Керпедәй шулай йомылып яшәсә дә, кешеләрне яратмавы яки дошман күрүе сизелми, һәр вакыт йомшак җаваплы, йомыш тыңлаучан кеше ул. Шәкерт дисәләр дә, китап-коръән тотканы, намаз-нияз белән маташканы булмады. Эчүнең дә рәтен белми иде. Сыйлап бирсәләр дә, «кых-кох» тончыгып, күзләреннән яшьләр агызып, көлкегә калып бетә. Олылар аңа кызганып карый: «Бу мескен, сугыш булмаса, монда килеп йөрмәсие инде, берәр авылда мәзин-фәлән булып ятырые шунда...» — дип куялар үзе ишетмәгәндә. Белмим, шуннан куркып килде микән, әллә укып-укып та рәт күренмәстәй булгач, нужа җитәкләп китерде микән?.. Мин дә аны эчтән кызганып йөрсәм дә, янына килеп сөйләшергә кыймый идем, шул малай чакның кыюсызлыгы белән гамьсезлеге аркасында бараклагы күпме кешеләрнең, хәтта әтәйнең дә, тормыштаниләр күргәнен, аларның эчке серләрен белми калганмын. Ә бу

анлаешсыз дөньяда әйләнә-тирәнне белү өчен генә булса да «ничек?», «нишләтеп?», «нигә?» дигән сүзләр белән олыларның колак итен ешрак чәйнәү бик тә кирәк эш икән!..

Мин белгән Җиһангир абый әнә шулай үзенчә бер дөнья белән генә яши иде. Ә язгылыкта мин аның яңа бер искиткеч сыйфатын күреп шаккаттым. Ишегалдында гөрләвек ачып маташа идем. Көтмәгәндә генә Хәҗвәли абзый, шарт итеп ишек ачып, үз якларыннан килеп чыкты да бик каты ярсыган тавыш белән тиргәнә-тиргәнә безнең баскычка йөгерә башлады. Ул шактый исерек, алпан-тилпән килеп атлый, ә кулында олы пычак, сугым пычагы! Ул аны болгаганда, яшен уйнагандай, кояшта чагылып китә. Безнең баскычка килеп менүгә: «Суям мин ул Хисамбыйны! Аннары бөтен барагын суям!» дип кычкырды бу. Нишләгән ул Хәҗвәли абзый? Нәрсә өчен шушы хәтле котырынды икән? Әйбәт кенә кеше бит ул, югыйсә, бер дә мондый гадәтен күргәнем юк иде.

— Чык, Хисамбый! — дип, тагын бер кычкырып җибәрде ул. Ишектән, бик гаҗәпләнгән кыяфәт белән, ялан өс кенә килеш Җиһангир абый килеп чыкты да:

— Хәҗвәли абзый, нишләвең бу? Кирәкмәс, ярамый,— дип, аның юлына аркылы төште.

— Кит, якташ, кысылма, суям! — дип, аңа кизәнә башлады теге. Шунда Җиһангир абый аны ике кулы белән уратып алып, кире борырга теләде. Ишектән Хисаметтин абзый килеп чыкты, аны күрүгә Хәҗвәли абзый кинәт ычкынды да котыргандай ыргылып, күршесе өстенә кизәнде. Озын пычак кояшта тагын бер уйнап китте һәм очы белән Хисаметтин абзыйның күкрәгенә төшә башлады. Шул авык эчендә Җиһангир абый кулын өскә сузды, исереккнең беләзегеннән тиз генә эләктереп алмакчы булды, ләкин коточкыч хәл килеп чыкты: тегенең кирелгән кулындагы үткен сугым пычагы Җиһангир абыйның нәкъ уч төбенә йөзе белән туры килеп, аркылыга ярып та чыгарды. Шыбырдап кып-кызыл кан китте. Инде баракның ике башыннан да шактый җыелган халык ай-вай килде. Хәтта этәй дә чыккан икән.

— Тоз китерегез, тоз! — дип кычкыргач кына күреп алдым мин аны. Төхфәт абый күз ачып йомганчы өйдән тоз капчыгы күтәреп чыкты, кайсыдыр Җиһангир абыйның учын җәеп торды. Яраны күргәч, тагы аһ-уһ килделәр:

— Ай алла, гел сөягенә хәтле кисеп кергән бит уч төбен.

— Эшкә ничек йөрер инде ул?..

Төхфәт абый шул тирән яра өстенә учлап-учлап тоз тутырды. Баштарак, салган бере кып-кызыл булып эри барды, кан һаман көчәрелеп ага торды, ә Төхфәт абый өстәгән өстенә өсти бирде. Ахыр килеп, кан сирәк тамчы булып кына сарка башлады. Уч төбенә чүмәләдәй итеп өелгән тозның өске катлавы кызармый иде инде. Ярасына тоз тутырганда Җиһангир абый читкә борылып торды. Йөзенә чыккан аркылы-торкылы тирән җыерчыклар аны бөтенләй танымаслык карт итеп күрсәтә, йөрәгенә төшкән авыртудан никадәр газаплануын шуннан аңларга була иде. Шулай да ул эһ дигән тавыш та чыгармады. «Ярага тоз салма әле» дигән сүзнең чын мәгънәсен, чын ярага чын тоз тутырганны үз күзләрем белән күргәннән соң гына чынлап торып аңлый башладым мин.

Яраны бәйләү өчен чүпрәк кирәк иде. Алдан ук күреп торды микән, моны шундук Хәҗвәли абзый хатыны Һаҗәрәттәй чыгарып бирде — ап-ак итеп юылган иске мендәр тышы сыман әйбер. Һаҗәрәттәй дүрт почмаклап бәйләгән яулыгын шактый ук алга тартып, ярты йөзенә хәтле күләгә төшергән. Шулай да аның елый-елый кызарып беткән күзләрен һәм күгәреп чыккан каш читен күрергә була иде.

Бу хәлләргә төкереп тә бирмәгән Хәҗвәли абзый әле һаман болганып-кычкырынып маташса да, инде аның кулындагы пычакны алганнар һәм үзен өенә кертергә тырышалар иде, ләкин ул алардан ычкынды да яңадан ажгырып килеп безнең баскычка ябырылды. Өйалды башында баядан бирле сүзсез торган әтәй аның юлына каршы төште, шулай ук бер сүзсез-нисез чалт-чолт яңаклый башлады тегене. Бик ачуы кайнап, кыжрап торган күрәсең: унлы-суллы яңаклады. Баштарак карышып маташкан Хәҗвәли абзый түбәнге баскычка чүмәште, яңакларын ышкый-ышкый:

— Пәрхулла абзый, җаныкаем, бетте, зинһар тимә,— дип ялынырга тотынды. Бер ачуы чыкса, тиз генә туктый алмый икән әтәй, ул аны әле тагын яңаклады.

— Хәйван! Шайтан сидеге эчеп котырган башың белән нишләттең син кешене!— дип, баскычтан ук төртеп төшерде. Хәҗвәли абзый, дүрт аяклап дигәндәй, үз баскычларына таба китеп барды. Һаҗәрәттәй белән буйдаклар аны култыклап баракка алып кереп киттеләр.

«Ир-егетнең эчендә игез арыслан булыр» дип әйткәләргә ярата безнең әтәй. Белмим, халык сүземе, үзе чыгарганмы. Үзлегеннән өстәштерә торган гадәте дә бар аның. Әйтик, «чиләгенә күрә капкачы» дигән сүзне болайга әйләндерә ул: «Чиләгенә күрә капкач, сөенеп ал эзләп тапкач!», «Кешедә кешенең эше юк — Пәрхиттәйнең теше юк», (ул безнең күрше карчыгы), «Куянда колак озын, сыерда койрык озын — аннан кемгә ни файда?». Аның мондый әйтемнәре нихәтле мәгънәледер, белмим, әмма ир-егет хакында әйткәне Җиһангир абыйга бик туры килә шикелле. Кулына пычак күтәргән юләр баш исереккә каршы аның шулай батырларча ташланып, башкаларны бәладән саклап калуы һәм тирән ярасына тоз тутырганда үзен шундый егетләрчә тотуы ис-акыл китәрлек сокландырды мине. Гомергә онытылмаслык хөрмәт уятты. «Менә батыр нинди була икән ул!» дип йөри башладым.

Җиһангир абый ай буе җәфаланды ул кулы белән. Бер-ике көннән башланган чамасыз каты сызлавына чыдар әмәл тапмыйча, идәндә төн буена ишекле-түрле йөри иде. Шулай да ни көндез, ни төнлә булсын, бер генә рәт ыңгырашканы да ишетелмәде. Беренче тапкыр чүпрәген чишеп, тозын кыптарып караганда, аны ярасы сап-сары булып үлекләгән, ә бөтен уч төбе кызарып, шешенкерәп киткән иде. Больниска барырга киңәш бирделәр: «Заражин булыр да, кулыңны кисүләре бар»,— диделәр.

Больницадан аның үлекләрен әрчеп юып, бөтен җәрәхәтен йодага манчып, ап-ак марля белән кат-кат бәйләп кайтардылар. Шуннан соң Җиһангир абый тынычлабрак йоклый башлады. Ай тулганда ярасы кипшенеп житте, ул хәзер бәйләвен үзе чишеп йода сөртә иде инде. Аның уч төбе тирән булып аркылыга уелып калды, пычак кискән эзгә ит үсмәде, шулай да кулы хәзер кәйлә сабы тотарлык хәлгә килгән иде инде. Яралануы үз гаебеннән булмаса да, шуның аркасында ай буена эшли алмавына да карамастан, аңа бер тиен дә акча чыкмады. Эштә-забойда чакта булмаган, имеш. Дистәләп кеше гуаһ булып барса да, файдасы тимәде. «Баракта була торган шахтер сугышы», дип кенә әйткәннәр, имеш. «Эштән чыгармыйбыз, шул житкән, эшли бирсен», дигәннәр. Шуның белән вәссәләм. Җиһангир абый бу вакыт эчендә актык тиеннәре белән тамак ялгап килде. Безнең аш өстәле бергә бит, күреп торам: ипи дә чәй, ипи дә чәй! Белмим, Хәҗвәли абзый, өенә эндәшепме, бүтән җаен китерепме дәгәндәй, якташы каршында үзенең шундый зур гаебе барлыгын таныганмы, бәхиллеген сораганмы-юкмы, әмма безнең якта күренмәде, бер генә тапкыр да баракка кереп Җиһангир абзыйның хәлен сораганы булмады. Мин моны малай баш белән һич аңлый алмый идем: нәрсә, гаебен танырга куркамы? Безнең әтәйгә күренәсе килмиме? Әллә якташын кешегә дә санамыймы? Бу-

лыр да. Мескен таз шәкертне, куш колаклы кара шадраны кем соң санга суксын!.. Хәер, уйласа Хәҗвәли агай гына шулай уйлагандыр, ә безнең яктагылар аны ташламады, хәлләреннән килгәнчә булыша тордылар. Җиһангир абыйның дәрәҗәсе барыбыз каршында да нык үсеп китте.

## Риян белән Сәриян

Риян агай белән Сәриян агай да сәер кешеләр. Боларның да туган җирләре Өфе ягында. Ул тирәләрдә бездә ишетелмәгән шундый сәер исемнәр күп бугай, ахры. Алар икесе бертуган, икесе дә бакыр чәчле, куе сакал-мыек җиткереп йөри торган кеше. Бит-кулларындагы кызгылт-тут сипкелләренең дә бик куе булуын күргәч, аларны баштанаяк бакырдан койган дип уйлый башлыйсың. Бу агайлар, үз әйтмешләре буенча, унберенче ел ачлыгында тулы бер ишалон булып монда килгәннәр дә Себер карурманы тайга эченә кереп утырганнар. Авыллары моннан утыз биш кенә чакрымда икән, Куербак дип атаганнар. Гомердә ишеткәнем булмаган сәер сүз. Мәгънәсе нәрсә икәнен белмим. Шулай да **«куе урман эче»** дигәнне аңлата шикелле.

Моннан унике чакрымда тагын бер татар авылы бар диләр. Анысын Тепларечка дип, урысча гына атап йөртәләр. Анда гел ат караклары җыелган, имеш. Кызык итеп мәзәк тә чыгарганнар:

Таратайка белән күмер ташучы Ханнан агай бердәнбер малае Мәннәнне шул авылдан өйләндергән, имеш. Ике-өч атна торгач та кыз ата-аналарын сагына башлый. Нишләмәк кирәк, яшь кәләшне елатырга ярамый. Китә бердәнбер Мәннән атасының бердәнбер эш атын җигеп, яшь кәләшне утыртып, бабаларына кунакка. Барып керә Мәннән кичке якта «келлиң-келлиң» шөлдер белән генә Тепларечкага. «Исәнме дә саумы! Хуш килдегез! Әйдүк, түрдән, балакайлар!..» Шулай әйбәт каршылый әби белән бабай. Ярар, ипи дә тоз — якты йөз дигәндәй, төче коймак ясап кына чәй эчертәләр дә кунакларга, түр сәкегә түшәк-ястык җәяләр. Үзләре өйалды чоланында яталар. Иртә торуларына кияү белән кызга бар да әзер: мунча да ягылган, ап-ак бодай коймагы да пешкән, мичкә бәлеш тә тыгылган, казан тулы ит белән аш та кайный, табынга кәҗүнни «акбаш» та килеп утырган. Әй китә сыйлау, әй китә кыстау! Бабасы бигрәк тә юмарт була бердәнбер Мәннәннең, һәм аны бик ярата да, ахры: эчерә дә эчерә, сыйлый да сыйлый: «Аша, кияү, аша, минә монысын гына, минә тегесен генә! Үз итең шикелле итеп, тартынмый аша!» Калҗа өстенә калҗа белән кызыктырып кыстый кияүне. Җаннары эреп китә инде бердәнбер Мәннәннең. Атна буе кунак була кияү белән кыз.

Шулай да Мәннәннең аңгы-миңге башына бер иртәне уй төшә: «Кайтырга кирәктер бит... Әтәйнең бердәнбер атын җигеп киттем, эшсез ятадыр, ачулана торгандыр...» Бабасы бер дә җибәрәсе килмәсә дә, көчкә ризалатып, ат җигәргә чыга Мәннән. Арбасын бора да, лапас баганасыннан йөгәнен алып, абзар капкасын ача. Анда ат түгел, тавык та юк! Йөгереп өйгә керә Мәннән. «Ат болында мәллә, бабай?» дип сорый «Юк, болында түгел, күптән синең карыныңда», ди бабасы бер дә исе китми генә. Бердәнбер Мәннән дулый башлый, «әтәйнең бердәнбер аты бит ул!» ди. «Әйттем ич мин сиңа ди бабасы: үз атың ите шикелле итеп аша! дидем. Белеп ашадың, кияү!..» ди.

Ихтимал, моны усал телләр генә шулай күперткәннәрдер, ихтимал, анда ат карагы шушы Мәннәнчең «юмарт» бабасы гына булгандыр, ә бөтен көтүне буярга шул бер сыер җитмимени? Безнең Тулбайлар да

өй борынча чыбыркы буры түгел, әмма яманат сыларга бирәү табылган!..

Ә Куербаклар турында андый сүз ишетелми. Аларны әдәм кермәслек тайга төпләп, басу ачып, иген чәчеп яши, дип сөйлиләр. Кырмы кытлыгы булмагач, мал-туарны күп асрап, бодай ипие генә ашап торалар, имеш. Черкигә генә чыдарлык түгел ди. Шул черкине бетермәкче булып, җәен-җәйли урман яндыралар, имеш. Монысына ышанасы килми, ничек инде шул хәтле утын байлыгын әрәм итсеннәр?..

Шундый әйбәт тормыштан Риян белән Сәриян агайның шахтага килеп керешүе миңа бик сәер тоелды. Алар бит инде бер кат читкә китеп урнашканнар, читтәге кеше дә читкә чыга микәнни? Безнең якның читкә йөрүе бер дә гаҗәп түгел: икмәге житми, утыны булмый, ат-туны юк, якында гына эшләр иде — рәтле эш табылмый. Ә боларга?..

Аннары шунысы да гаҗәп: бу ике туган бик кысан тора, икмәкне арыш сеенкесеннән генә пешертәләр, ат итенең иң очсызлысын гына алалар. Өстәлдәге ашларында чыпчык күзедәй өре дә күренми. Әллә кайчан күгәреп беткән трити сурт такта чәйне, әчмухәләп кенә алып, сары су итеп кенә эчәләр...

Сары су дигәннән... бер көнне бик сәер бер хәл булып алды бәракта. Якшәмбегә каршы ике смена куып, кичен эштән кайткач, бу ике туган аннан-моннан гына юынып табынга утырган чакта Сәриян агай түбәтәен тапмый аптырады. Риян агайныкы түрдәге кадак чөйдә эленеп тора, ул аны үрелеп алды да башына киде, ә Сәриян агайныкы юк. Кеше алыр дип тә әйтерлек түгел, каешланып беткән бәләкәй генә иске түбәтәй иде ул. Хуҗасының баш очына менеп, тәлпәеп кенә утыргач, бик кәмит итеп күрсәтә ул аны. Менә шул каеш кәпәч юкка чыккан. Дөнья бетереп эзли башлады Сәриян агай, беркаян таба алмады. Табынга түбәтәйсез утырырга кыенсынып, бик озак башын кашып торды. «Әйдә, утыр инде, ачка үләм бит, берәр жирдән килеп чыгар әле яткандә», диде Рияны. Сәриян агай бәлки үз гомерендә беренче рәттер, ялан баш көйгә ашарга утырды. Башта алар икесенә бер кәстрүл аш сыпырдылар, чап-чоп ит чәйнәделәр, сөяк кимерделәр. Аннары инде теге як плитәдә шау кайнап утырган олы буксәле яшел чәйникләрен алып кереп, чәй шопырдатырга тотындылар.

— Кара, ничек каты пешкән бүген чәй! — дип куйды Сәриян агай.

— Учлабрак тондыргансыңдыр,— диде Рияны.

— Ю-ук,— дип суызды тегесе,— шул, көндәгечә инде... Тулке бу юлы озаграк кайнады ул, табынга утырганчы нихәтле гомер узды бит...

Теш белән тел арасына кыстырылган лампасый аркылы уздырып кына чөмерә торгач, ул олы буксәле чәйникне дә эчеп бетерделәр. Актык чынаякны сыгып ясаганда чәйникнең жепле капкачы бер якка асылынып төште, шул чакта чәйник авызыннан ниндидер кара-көрән нәрсә яртылаш килеп чыкты.

— Пәрәмәч,— дип куйды Риян агай,— нәстә бу?

Сәриян агай да ул нәрсәгә озак карап торганнан соң гына телгә килде:

— Түбәтәй бу...— Кулына алып карады.— Минеке...— диде аннары, кара коелып.— Чукынмышлар, мыскыл итәләр! — дип өстәде.

Бу хәлне күреп алган халык эчләре катып көлә башлады.

— Менә сиңа «каты чәй!» — дип пырхылдады кайсыдыр.

Тик Солтан абый гына мич буенда йокламышка салынып ята иде... Шулдыр, аның шундый ширлекле гадәтләре булгалый...

Шулай да мондый әкәмәтләргә генә исләре китми бу агайларның. Бөтен кешедән күбрәк эшлиләр, сигез сәгать забой чабып кайталар да сигез сәгатьтән соң тагын шахтага чабалар. Бу бит тәүлегенә уналты сәгать була түгелме соң? Айга утыз сигез-кырыгар «үпрәжке» куалар. Аванс-получкалары да бөтен кешенекеннән күбрәк була. Күзләренә бә-

реп үк әйтмәсәләр дә, «шахты корты» дигән кушамат та тактылар инде үзләренә. Тәннәре кап-кара, муеннары чуп-чуен, хәтта күзләренә дә, сөрмә тарткан шикелле, күмер утырган. Нигә бу хәтле казганалар икән?..

Бәлки йорт-җир, мал-туарлары житеш түгелдер? Себергә килеп төпләнә башлауларына кайчан гына ич әле. Ләкин хат яздыруларыннан күренүенчә, андый ертык-тишек барлыгы да сизелми. Өй эченә бер сәлам, кардәш-ыруга бер сәлам әйткәннән соң, «чуар байталны ач тотмагыз, төнгелеккә каен сарайга ябып бикләгез. Ала сыер бозауламадымы әле, сарыклар бәрәнни башладымы? Мал-туарга курмыны Нигъмәтулла ташып бирсен, бурычы өчен чутларсыз. Кызыл тана шулай кысыр калды микән инде, буазлыгы беленмиме? Үгез бозауны, икмәк каптырып, язга таба суйсагыз, күрше Назаровка базарына чыгарсагыз яхшы булыр иде. Үзебез исән-сау булсак, язгы кырлар ачылуга таба кайтырбыз инде...» дигән сыманрак сүзләр яздыралар иде миннән.

Бу агайларның төп нияте тора-бара гына мәгълүм булды. Бер кичне, олы кеше итептер инде, безнең әтәй белән сөйләшеп утырдылар: икесенең дә алты почмаклы нарат буралары бар икән. Җәйгә чыккач шул бураларны янәшә күтәреп калай белән ябылган шатрун түбәле итеп, сигез тәрәзә, өч ишек тишеп, идән-сәкесен, түшәм-матчасын, Себер «чалдуыннары»ныкы шикелле сап-сарыга буятып, пәтистинни йорт житкереп кермәкчеләр икән. Менә шуңа кирәкле калай-кадак, буяу-пыяла, тагын күп кенә бүтән тимер-томыр, вак-төяк нәрсәләрне каян юнәтү — ерак булса да шахта жиреннән китерү очсызгарак төшмәсме дип киңәш кылыштылар.

— Туган җирләрне ташлап, шушы хәтле ерак якларга, урман-агач уртасына килеп утыргач инде, авылдагы тавык кетәгән онытырлык итеп, әдәмчәрәк яшәп карасы киләдерие бер,— дип куйды Риян агай.

Аларның бу ниятен безнең әтәй бик хуп күрде. Шулай итеп, бу агайларның көн-төн казганулары комсызлыктан, «акча корты» булудан гына түгел, үзләренчә изге теләк белән икән. Безнең дә бит югары өй эшләнмәгән, инде мин белә-белгәннән бирле «күзсез» бура булып тора, хәтта идәне дә юк. Инде безнең ул йортны салып керүебезгә ун елдан артык гомер узган, шуннан бирле әтәй ничәмә тапкыр читтә йөреп кайткан, ә куыш һаман шул көйгә тора. Шундый базга кайтып керү аңа бер дә рәхәт түгелдер, югыйсә. Бик сәер бу. Шул өйне эшләтеп керерлек тә акча төшми микәнни соң аның кулына?.. Әллә ул кайсын алдан булдырырга белмичә аптырый микән? Югары өй генә түгел, ат та юк, сыер да юк бит әле безнең. Абзар-лапас торыклары да берике генә. Яшь әнәй килгәч, арыяк Зайнетдин абзый хатынынннан асрамага бер бозау алдык, менә шул без кайтуга үсеп торса, сыерлы булабыз инде, алла бирса!

Дөнья шул бу. Син болай итәм дисең, ул тегеләй бора. Әнә Риян агайларның да ниятләре челпәрәмә килде. Шул хәтле күкрәк көче түгеп җыйган акчалары урланган булып чыкты. Шахтер үзенең эшләп тапкан акчасын кайда һәм ничек саклаганын мин һич тә белми идем, әтәйнең кайда куеп тотуын да күргәнем юк.

Баракта утызлап ата баласы, утызы утыз холыклы. Берәүнең эчендәге тышында: ачык йөзле, чиста куллы. Андыйлар синең шырпыңа да тиячәк түгел. Икенче берәүнен күңеле тимерле-йозаклы сандык шикелле. Аның эчендә ниләр ятканын кем белә? Өченче берәү — үзе тыйнак, сүзе — коймак, ә кулы йөри кесәләрең буйлап. Бу сүзләрне мин әтәйдән ишетеп әйтәм, акча югалган көнне шулай сөйләнеп утырды ул. Ә Риян агайлар акчалары югалуын көндезге сәгать икедә генә белделәр. Аларның кат-кат тимерләп бетергән, олы чуен йозак белән бик сикритле бикләнә торган такта сандыклары бар иде. Йөзлек аягының эчке ягына тимер бөҗра кагып, сандыкны чылбыр белән шунда

беркеткәннәр иде, күтәреп чыгып китмәсеннәр, янәсе. Акча шунда булган. Эшкә төшәр алдыннан, акчаны үзләре белән алып китәргә дип, сандыкны ачсалар — эчендә җилләр уйный! Риян агай сандык каршына чүгәләгән килеш кинәт кычкырып җибәрде:

— Ай алла-ходаем, хәрәпләр генә булдык! — дип, шап итеп идәнгә утырды да җан ачысы белән кычкырып җибәрде: — Урлаганнар, урлаганнар!..

Сәриян агай, йөгереп килеп, сандык эчендәге вак-төяк нәрсәләрне чөерә башлады, кабаланудан кулы да калтырый, үзе дә калтырый... Шашкандай атылып сәке астына кереп китте, аның бөтен почмакларын әйләнеп, тузанга, пәрәвез оясына батып чыкты.

— Юк бит, юк бит, юк бит! — дип, нindидер суык тавыш белән кырт-кырт һаман бер сүзне кабатлады ул. Купкан күзләре белән бөтен почмакларны, шүрлекләрне, хәтта бүрәнә ярыкларын капшагандай, бар бүлмәне айкап чыкты.

— Юк бит, юк бит, юк бит, абый! — дип тагын бер кабатлап алды. Өйдә булганнар алар тирәсенә җыелды, бар да аптыраган хәлдә сүзсез иделәр. Ниһаять, «кем булыр?» — дигән сорау ишетелде. Җавап бирүче булмады.

— Ә Мәүлә кайда соң? — диде кайсыдыр.

— Мәүлә?..— дип ялт күтәрелде Риян агай идәннән.

Мәүлә алардан ике кеше аркылы гына ята иде. Урыны да җыелмаган: каешланып беткән бәләкәй күпчеге белән таланып беткән иске киезе түргә таба кайтарып кына куелган. Югары шүрлектәге вак-төяге арасыннан бер күлмәк җиңе асылынып тора.

— Мәүлә... эштә булырга кирәк,— диде аптыраган Сәриян агай.— Иртәнге алтыдан киткәндер ул.

— Алтыдан булса, инде кайтырга тиеш. Әнә Төхфәй әллә кайчан юынып ята бит...

Төхфәт абыйдан сорадылар.

— Юк, чаваты күрмәдем мин аны,— диде ул.— Киткәндә дә унимание бирмәдем — безнең борчаклар пешми бит хәзер.

Әтәй дә кайтып керде эштән, ул да күрмәгән. Бу хәлне ишеткәч, бик гаҗәпкә калды:

— Нишләп анда куясы иттегез соң? Нишләп бер дә искәрмәдегез? — дип төпченергә тотынды.

— И-и, Пәрхулла абзый-й,— дип сузды Риян агай гаҗиз тавыш белән,— акчаны табуы мең бәлә булса, саклавы ике мең бәлә икән мондый җирдә... Мәгъмүрәгә куеп тормакчыек. «Югала-нитә калса, нәрсәм белән түләрмен?» дип алмады. Шуннан соң, аптыраган үрдәк... дигәндәй, без ул кәгазьләрне янчыгы белән чолгауга урап шахтыга алып төшәбез, өйдә чакта эчке яктан ыштан бөрмәсенә бәйләп йөртәбез, төнгә — әнә шул сандыкка тыгадырыек... Әдәм көлкесе, валлаһи... Мәңге сөйләмәсием... хәзер барыбер инде...

Моны ишеткәч, байтагысы көлешеп алды.

— Көлмәгез, чукынчыклар! Бактың исә, үзегез дә шулай йөртәсездер әле,— диде Риян агай җәберсенеп. Аннары теге сүзен дәвам итте.— Күрәсең, алдан ук күзәтә килеп, сигездән сигезгә йөргәнгә безнең каты йоклаганны белеп, ачкыч яратып эшләнгән инде бу эш...

Кешеләр таралышты. Барак тына төште. Риян агайлар бу көнне гомерләрендә беренче мәртәбә эшкә бармый калдылар. Ә Мәүләне күпме көтсәләр дә кайтмады, күренмәде, ишеткән-белгән кешеләр дә булмады. Полициягә әйтеп эзләтергә кирәк диючеләр дә булган иде, Риян агай кул гына селекте:

— Яландагы җилне кем тоткан? Мәүлә урлаганын кем күргән? Маңгаена язылмаган бит,— диде ул.— Белешкәләдем инде: ике көн алдан раччут алып, пашпыртын кесәсенә салып куйган, кулы череп аккыры!...

Нихәтле генә гарьлек булмасын, мин тагын мәктәпкә киттем. Беренчедә Коръәннең кирәге юк, шулай да аны букчадан калдырмадым — әтәй сизмәсен. Тагын шул маймычлар арасына кереп утырдым. Мөгаллим абый иң элек безгә дәрес бирде. Хәрефләрне тактада күрсәтеп, аңлатып, укытып карады да бер бит тулганчы шуларны тактадагыча итеп язарга кушты. Ә минем кулга «Мөгаллиме әүвәл» дигән китап биреп, беренче битен ачтырды да: «ата, ана, арба, чана, ат» дигән аерым дәрес бирде. Шуларны миңа матурлап, китаптагыча итеп, бер дә пычратмыйча ике бит тутырып язарга кушты. Бу миңа тагын сәер тоелды. Мәдрәсә ишеген ачып кергәннән бирле мин «әбҗәд һәүвәз» дип, «кәлимәтен тайбатын» дип, «ясин вәл коръәнелхәким» дип, «әлхәмде лилляһи раббиль галәмин» дип гел үзем белмәгән телдә укып килгән идем. Ниләр сөйләде икән ул сүзләр? Ә монда, ана сөте белән үк ачыла башлаган җип-җиңел үз телеңдә: «ата, ана, арба, чана, ат» дип, күз алдында теп-тере булып торган нәрсәләр турында укып маташ. Шул — сабак була, имеш! Бер уйласаң, гел көлке иң! Ә икенче бер уйласаң — ник сабак булмасын? Анда бит шундый якын, шундый газиз кешеләр, шундый таныш нәрсәләр турында әйтелә. Юк, әйбәт дәрес икән бу. Нәрсә чәйнәгәнеңне белеп чәйнисең.

Үземчә шундый «акыллы» фикергә килдем дә, бик тырышып, тәбәнәк парта өстенә ята төшеп дигәндәй, язарга тотындым. Мөгаллим абый килеп-килеп күз төшергәләсә дә, «тегеләй ит, болай ит» дип, ләммим бер сүз әйтмәде. Эштә гаеп күренмәгәч, күңел гел үсеп китә икән. Ике бит белән генә калмадым, кыңгыравык булганчы өч бит яздым мин ул сүзләрне. Язган саен хәрефләр шомарак төшкән сыман күренә башлады.

Икенче сәгатьтә хисап дигән дәрес керде. Башта иллегә, йөзгә хәтле санату булды. Анысы чүп кенә, меңнунга хәтле дә саный алам! Ә менә икегә икене сыйфыр белән язып кушу минем өчен тагын яңалык булды. Кара әле, аның да үз билгесе, үз тәртибе бар икән! Бигрәк тә 11 гә 13 не кушканда, бармак белән санап утырасы түгел.

Шулай итеп, мин инде беренче сыйныфка төшүемә бик үк үкенми дә башладым хәзер. Өйрәнәсе нәрсәләр монда да бар икән ләбаса! Ай тулганда «Мөгаллиме әүвәл»не хәреф-би-хәреф укып чыгып, кушылган шигырьләрне ятлап, язуны да рәтләп өлгердем. Элекке аркылы-торкылы таяклар үземә дә көлке тоела хәзер. Хәтта хатларны да бик яңача язып, үземнең абразауный (әтәй сүзе) икәнлекне күрсәтергә тырышам. Ил җирендә мин язган хатны укыган кешеләр шаккатсын!

Тырышып маташуны мөгаллим абый да сизеп алды шикелле. Аның линикәсе минем кулга бүтән бер тапкыр да төшмәде. Алай гына да түгел, ул миңа йомшаграк тел белән эндәшә, дәресләрне күбрәк итеп бирә, күбрәк сорый, эшләремә дүрт тә биш куя башлады хәзер. Минем дә күңел язылып китте, элекке үпкәләрне онытып, ярата башладым үзен, исем-фамилиясен дә бик ошаттым: Хөсәен Абушаев икән. Фамилиясе бигрәк тә шәп, минеке шикелле, теләсә кемдә була торган Фазлытдинов түгел.

Озакламый ул мине икенчеләр янына утыртып, кулыма «Мөгаллиме ссани» дигән китап тоттырды. Бу — гарәп сүзләрен ничек укырга өйрәтә торган китап иде. Аны да бишлегә укыдым, тик мәгънәсен генә белмәдем. Ул китапның «дәббәрә, кәссәрә» дигән бары тик ике сүзе генә хәтердә калган. Уйлап карасаң, гарәпчә китапларның шулай мәгънәсен белмичә укып йөреп, күпме сәгатьләр, көннәр, айлар, еллар җилгә очкан. Без надан калмыйча, кем калсын соң?..

Шул икенчедә чакта минем өчен тагын бер бик зур яңалык булып алды. Белмим, берәр бәйрәм уңае беләнме, әллә болай гынамы, мөгаллим абый безнең беренче-икенчеләрне шигырь әйтергә өйрәтте. Башта ул шигырьне берничә дәрестә безгә әйтеп яздырды, аннары күрми өйрәнеп килергә кушты. Ятлап килгәч, такта янына чыгарып тездә, үзе өйрәткән көйне үзе башлап җибәрде. Без яшелле-күкле тавышлар белән аңа кушылдык:

И туган тел, и матур тел,
Әткәм-әнкәмнең теле...

Бөтен мәктәп яңгырап китте. Өченчеләр белән дүртенчеләр дә парта арасына басып безгә кушылды, тагын да шәбрәк яңгырата башладык. Шәмәк мәдрәсәсендә минем малайларга кушылып әлвидаг әйткәнем бар, гарәфә кичтә малайлар белән мәчет манарасына менеп салават әйткән бар, гаеткә барганда әтәйгә, күрше-күләнгә кушылып тәкъбир әйткән бар, түтәй белән бергә кушылып «Мөхәммәдия» китабыннан мөнәҗәт әйткән бар, әмма шигырь әйткәнем юк, монда килеп кергәнче шигырь дигән сүз булуын ишеткәнем дә юк һәм дөньяда без әйткән шикелле шундый матур шигырь барлыгын да белгәнем юк иде...

Икенчедә дә озак тоткарланмадым. Инде кыш урталары узуга, мин янадан өченчегә менеп, Сәми янында буш торган үз урыныма утырган идем. Тиле тигәнә буе сикерер дигәндәй, үзалдыма сөенеп-куанып йөри башладым. Укыган саен укыйсы килә, дөньяның әллә нинди мин белмәгән тагын бик күп матур яклары ачылып китәр төсле тоела...

Шул көннәрдә безнең баракка, минем яшәр Мехәмәй атлы малаен ияртеп, аксак Гыйлаж абзый килеп чыкты. Аның элек тә бер-ике булганы бар иде. Ул үзе Түбән Тәкәнешнеке, әтәйнең дус кешесе, кайчандыр шахтада басылудан шулай аксак булып калган. Хәзер Томскидан китереп, китаплар сатып йөри. Аның аркасына күтәреп йөри торган фанер әрҗәсе бөтен «Мөхлисун» өчен бердәнбер китап кибете иде бугай, бүтән урында татар китаплары сатылуын белмим. Үткән килүендә әтәй аннан коръән тәфсире алып калган иде, миңа бик үк аңлашылып бетми торган һәм укырга кызыгы булмаган калын китап. Мин ул чакта Гыйлаж абзыйның әрҗәсендә тагын нинди китаплар булуы белән кызыксынмаган да идем, ә бу юлы «әрҗә кибет»кә иң элек мин ташландым. Ул миңа төрле догалыклар белән бергә «Җырлар әхтәрисе», «Менә сиңа шәп җырлар», «Сугыш бәете», «Канау буе», «Суга баткан кыз» дигән китаплар күрсәтте. Боларның хаклары ике-өч тиеннән артмаганга күрә, барысын сыпырдым да алдым. (Бакыр биш тиеннәр әзмени минем!) Бу аңа бик ошап китте бугай, «Көйле иман» белән «Бәдевам»ны да кыстырырга чамалый башлады. Ә минем аларны ничәмә кат укыганым бар инде, хәтта байтак урыннарын күңелдән беләм,— алмадым. Шуннан соң ул әрҗәдәге китапларны үзем сайлап алырга юл куйды. Актара торгач, кыры белән әрҗә читенә кысылган юкарак бер китап тартып чыгардым. «Балалар күнеле» дигән. Исеме матур булгач, аны да алдым. Мин ул көннәрдә гел шулай кызыклы, матур китаплар җыярга дип уйлап куйган идем инде. Бу шул ниятнең башлангычы иде.

Алдан җыру китаплары белән сугыш бәетен укып чыккач, «Канау буе»на тотындым. Ул бәләкәй генә, юка гына китап миңа бик кызык булып тоелды.

Канау буеннан кайта,
Сәкегә менеп ята,
Хатыны чәй кайната,
Чәй эчәргә тидия,—

дигән юлларын такмаклап йөри башладым. Вәсим Солтанов дигән кеше язган икән аны. Иң ахырдан теге китапка керештем. Менәтерә

кирәк булса! Бу китапта әлеге без өйрәнгән «И туган тел, и матур тел»не басканнар. Бүтән шигырьләре дә үзеннән-үзе укылып бара. Ә инде «Кәҗә белән сарык хикәясе» көлә-көлә эчең катарлык!

Кәҗә әйтә: «микикики, микикики,
Капчыктагы бүре башы бит уники! —

дигән юллары тагын минем көндәлек такмакка әйләнеп китте. Кара әле син аны, кәҗә шундый тапкыр булып, бүре хәтле бүре алдында шундый батыр булып кылансын да аны качыра алсын, имеш! Менә сиңа «рыйстан кәҗә!» Китапның тышында Габдулла Тукаев дигән сүз бар, Казанда басылган!..

...Ә язга борылган көннәрнең берендә мөгаллим абый безгә кич белән җыелырга кушты, «Тукай кичәсе» ясыйбыз диде. Дүртенчедәге олы кызлар белән безнең өченче малайлары алдан моңа әзерләнеп йөрделәр. Авылдан килгән юашлык аркасында мин катнашмадым. Башта укытучыбыз сөйләде. Аның сүзләреннән мин шуны аңладым: Габдулла Тукаев ил халкының йөрәк моңнарын, кайгы-хәсрәтләрен шигырь сүзе белән әйтеп бирүче бик зур, бик әйбәт кеше булган икән. Ул балаларны да бик яраткан, безнең өчен дә укып туйгысыз шигырьләр язган. Шундый ялкынлы шигырьләр язучы кешене шагыйрь дип атыйлар икән. Шагыйрь! Бу сүзне дә шушы яшемә житеп, беренче тапкыр ишетәм. Кызыклы сүз, кытыклы сүз, эченә әллә нинди серле мәгънәләр җыйган сүз булып ишетелә!.. Тукаев әнә шул яшерен серләргә, йөрәкләр-күңелләр ачкычына ия булганга күрә мәңге онытылмас җәүһәрләр калдырган икән. Татар халкының күзләрен ачкан ул, аны алга, мәгърифәткә өндәгән, якты дөньяга чакырган. Бүген аның вафатына өч ел тулган икән инде. «Бу кайгылы матәм көне безнең күңелләрне һаман яралап тора. Халык аны онытмый һәм онытмаячак!» дигән сүзләр әйтте мөгаллим абый.

Әнә нинди кеше булган икән Тукай! Аннары Габдулланың бала чакта нинди авырлыклар кичергәнен сөйләп күрсәтте. Карасана, ул да ятим булган икән ләбаса! Шул ятимнәр турында, үги аналар, кеше кулында йөрүләр турында ишеттем исә, елыйсым килә башлый, монда да көчкә тыелып утырдым. Габдулла абый да, Төхфәт абый да һәм мин үзем дә, өчәүләшеп, бергә газап чиккәнбез шикелле тоела. Юләр мин!..

...Инде гөрләвекләр дә чынлап ага хәзер. Авылда боз калкып, су ташыр чаклар житеп килә торгандыр, әллә кайчан сыерчыклар да килгәндер. Ә монда һаман күренмиләр әле. Хәер, ул бәләкәй кошлар Себер хәтле ерак җиргә килеп тә житә алмыйлар булыр, никтер бер түбәдә дә ояларын күрмим.

Безнең укуларның да актык көннәре килеп житте, имтиханнар тапшырдык. Бу да минем өчен яңалык: биш-алты кыш мәдрәсәгә йөреп, имтихан биргәнем һәм ул сүзне ишеткәнем юк иде, билге куюлар барлыгын да, «шәһадәтнамә» алуларны да белми идем. Ә минем кулда хәзер зәңгәр хәрефләр белән басылган шәһадәтнамә! Мактанып әйтә алам: кыш буе укыган дәресләрем буенча гел бишле! дияр идем... ике дүртлем бар. Өчлем берәү дә юк! Ә инде иң астагы юлда «әхлякъ гүзәл» дип язылган. Монысын аңлап бетермәдем. Кулыма ат тоттыргандай олы куаныч белән баракка кайтып кердем дә шәһадәтнамәне әтәйгә күрсәттем, әлеге ике сүзнең нәрсә икәнен сорарга да курыкмадым. Ул билгеләрне күзәтеп чыкты да әз генә көлемсерәп куйды:

— «Үзен әйбәт тота» дигән сүздер инде,— дип баштан сыйпап алды.

Бу минем иң бәхетле көнем иде. Юк, бу «яңа уку» дигәннәре гел начар түгел икән: маңгай күзең белән бергә күңел күзеңне дә ача, тырышлыгыңны һәм сәләтеңне билгеләр белән ачыклап, алга таба дәртләндерә икән. Алай гына да түгел, мөгаллим абыйның имля, инша

дәресләрендә дөрес язарга өйрәтүе, ә сабакташ малайларның минем сөйләшүдән гел көлеп торулары авылдан килгән телемне шактый шомартып җибәрде. Алар: «чабата тел», «каеш кәпәч» дип мыскыллый торгач, минем «кыдыл бодау, дагын-дәген, дырыем-дерием, этәй-энәй» дип сөйләшүләрне тәки ташларга мәҗбүр иттеләр. Мин хәзер «әти, әни» дип китапча әйтергә, Михельсон дияргә һәм бүтән сүзләрне дә бозмый сукаларга тырыша башладым. Елдан артык йөреп, авылга «чит теле» алып кайткач, бик сәерсенгәндәй булдылар. «Карале, Шәйхелислам ылан, син хәзер китапча гына сүләшә башлаганың икән!» диделәр...

## Яңа бәхет, кайда син?

Мин шулай укуларым белән, яз матурлыгы белән мавыгып һични уйламый йөргәндә, әти (мин хәзер әтәй дип язмыйм инде) көн саен өйдә күренә башлады. Беренче көнне — сменалары алышынган чактыр дип уйладым, икенче көнне — төнгә төшә торгандыр, дидем. Өченче көнне мәктәптән кайтып керсәм — бу тагын өйдә. Ниндидер бер тәбәнәк бүкән өстенә утырган да йөзлек буенда итек төзәтә. Дүртенче көнне дә шул ук урында, шул ук эш белән утыра. Үзе күңелсез, төсе якты түгел. Шунда гына башка уй төште: әллә бер-бер хәл булды микән? Булгандыр шул, булмаса — шундый боек чырай белән өйдә утырыр идемени?..

Үзеннән сорарга кыймаганлыктан, мин бөтенләй пошына ук башладым. И ходаем,ниләр генә булды икән? Әле бит тормышлар үтә чыккан әйбәт кенә бара иде, дүртебез бер почмакта чөкердәшеп, үзебезгә бер бәләкәй Тулбай булып ята идек. Тамак та тук, өс тә ялангач түгел, укуларым да начар бармый, күңел дә көр иде. Җыянша абый белән Хөснулла абый да, әллә кайчан эшкә керешеп, ярыйсы гына тимтенеп яткан булалар иде. Дөрес, эш хаклары бик әллә ни түгел бугай. Җыянша абый өстәге откаткада гына эшли: шахтадан чыккан вагоннарны эстакад буенча тәгәрәтеп, күмерен шул күпер астына, порода булса — отвалга илтеп аудара. Хөснулла абый, әйтүе буенча, шахтада «чана» тарта. Чана дигәне — астын табанга охшатыбрак калайлап ясаган такта әрҗә икән. Забойчылар ятып чапкан тәбәнәк, тар «мич»тәге күмерне шул чанага тутыра да, җилкәсенә ләмкә киеп, үрмәли-үрмәли тартып чыгара. Коногоннар (аста ат белән бәләкәй вагон тарттыручылар) юлы өстенә китереп бушаткач, чанасын өстерәп, тагын кереп китә икән. Хөснулла абый күмер тузанына батып, дию парисдәй кап-кара булып кайтса да, ап-ак тигез тешләрен елтыратып, һаман көлә дә көлә генә. Ә Җыянша абый: «Эшләгән — тамакка гына җитеп бара»,— дип зарлангалый. Ул семьялы кеше шул...

Ничек кенә булмасын, минем өчен дөнья ал да гөл иде. Көтмәгәндә әтинең эшләре көйсезләнеп китү генә күңелсезлек тудырды. Дусай Тәхәү аны теге вакытта үз әртиленә керткән иде бит. Менә шул әртилшек боларның март получкасыннан байтак кына акчаларын басып калган. «Зарабутны яхшы төшә торган забойда эшләткән өчен дисәтникне сыйладым, чабылган күмер күләмен безнең файдага перлимайт иткән өчен эштигерне сыйладым, бүләк тә төртергә туры килде», дип аңлатмакчы булган. Әти моңа каршы төшкән. «Мөхлисунда беренче тапкыр эшләвем түгел, үземнең дә әртилшек булганым бар, бер дә безнен забуй бүтәннәрнекеннән җүнлерәк дип әйтерлеге юк, зарабутны да артык төшмәгән, бүтәннәрнеке шикелле үк тәңкә дә егерме тиен!» дигән. Сүз әрләшү-талашуга барып җиткән. «Юк, бу гаделсезлеккә мин риза түгел, син безнең эшләгәнне талап калмакчы буласың! Конторга

керәм, яңадан чутлатам!»— дигән эти. Әйтүен әйткән дә бит... калган иптәшләре авызларына су кабып, тик торганнар. Күп чакта шулай бит ул: актык ыштанын салдыра башлаганчы түзә кеше...

Бу талаштан соң ике смена эшләп кайткач, өенчесенә барса, этине эштән борып кайтаралар. Әртилшек Тәхәү абый инде расчет бирдереп куйган була. Менә шул борылып кайткан кичне табын янында этинең Жыянша абыйга сөйләп утыруыннан ишеттем мин бу хәлләрне. Миңа хәзер дөньялар бер дә ал да гөл булмаганы аңлашылды. Алгысы көндә нишләрбез, ике тамак бит әле без. Әтигә эш табылырмы?..

Табылмады шул, бүтән бер җиргә дә керешә алмады, айга якын шул йөзлек буенда утырды. Аның бәләкәй күн капчыкта үзе белән йөртә торган коралллары һәм башка кирәк-яраклары бар иде. Менә шуларны сәкегә җәеп сала да, тәбәнәк бүкәндә чүмәшеп, тук-тук чүкеч суга ул хәзер. Кемнең эш итегеме, бүтән аяк киемеме тузган, барын да ямап, «яңартып» бирә. Эшен яраталар тагы үзенең: «Нык итеп, ыктымат итеп эшлисен, Пәрхулла абзый», дип мактап та куйган булалар. Барак буш калган чакларда көйләп тә алгалый ул:

> Утырдым уйламага,
> Уйладым җырламага,
> Һичберәү дә килүче юк
> Хәлемне сорамага...

Шуннан тагын байтак вакытка тынлык урнаша. Җеп сумалалап, очына шитина куеп, итек укчәсенең бүселгән җиренә тар гына ямау сала. Белмим, төрлесен уйлап утыра торгач, кәефе уйнаклабрак китәме, ишеткән саен миңа сәер тоелган һәм әз генә елмайта да торган икенче бер җыруны башлый ул:

> Гыйнвар, февраль, март, апрель —
> Акча бетергән айлар.
> Бу ни гаҗәп, бу ни хикмәт,
> Фарсит итә бу байлар...

Бу җырлар миңа этине тагын да якынайтып җибәрә һәм моңарчы мин белмәгән яңа бер ягын ачып бирә төсле иде: аның күңелендә моң да, шаянлык та бар икән! Ә инде аның мине иң сөендергән эше —уку бетереп чыккан көннәремдә булды: ул миңа читек тегеп куйган булып чыкты! Кайчан, ничек теккән, минем аяк үлчәвен ничек алган — бернәрсә белмичә калдым. Иске булса да, ял-яңа диярлек елкылдап торган күннән, тезне капларлык озын кунычлы, әйбәт шыгырдавык олтанлы читекне аягыма киеп җибәргәч, үземне танымый башлагандай булдым. Безнең авылда мулла Нурулласыннан башка бер малайның да читек кигәне юк! Бу бит кая китә, беләсезме?.. Өстәвенә, шул әйбәт читек белән кияргә, көзгедәй уйнап торган төсле, бик ачык алсу-кызыл эчле, бәләкәй генә, матур гына резин кәлүш тә алып бирде бит әле эти миңа. Монысына минем биш тиеннәр дә кереп китте. Барыбер сөенечнең чиге юк иде. Боларны мин гомердә беренче мәртәбә киям бит әле. Эх, шул читек өстеннән төшереп кияргә чалбар да булса, аннары гел егетләрчә китәр иде эшләр? Юк шул, хәзергә анысы тәтемәде әле, авылдан килгән алача ыштан белән генә чикләнергә туры килде. Хәер, читекнең кунычы озын, эченә тыгып кигәч, бишмәт итәге астыннан күренми бит ул ыштан!..

Читнең түренә хәтле килеп, итек төзәтүчелек белән генә көн күреп булмавын мин дә аңлый идем инде хәзер. Ике тамакны ничек туйдырсын да өйгә нәрсә җибәрсен?.. Көннәрнең берендә эти юлга җыена башлады. Жыянша абый да, эшнең барыбер рәте юк дип, безнең белән китәргә булды. Хәснулла абыйга, патша сугышка алмасын өчен, хәзергә шушында калып, тыныч кына эшләргә киңәш бирделәр. Әгәр инде яхшы эшкә туры килсәләр, аны да чакыртасы булдылар.

Безнең күршедә генә Гыймран абзый ята иде. Ул этинең чит җирләрдә бергә йөргән күптәнге белеш-танышы, Югары Тәкәнешнеке икән. Бу баракка ул кыш башында Амур ягыннан кайтып керде. Эти аңа Гыймран абзый дип эндәшә, ә миңа ул хәтта бабай булып күренә. Җирән чәчле, шундый ук сакал-мыеклы, тәбәнәк буйлы, юка гәүдәле, йөргәндә ничектер пырҗинага баскан төсле дерт-дерт сикереп атлый торган кеше ул. Олы маңгае тирән сырлар белән уелып, битләрендә дә җыерчык шактый күп булганга шулай карт күренәдер инде.

Малай чакта колакта җил уйный: олылар сөйләшкәне берсенә чалынса, икенчесеннән чыгып китә. Шулай да бер кичне аның эти белән сөйләшеп утырган кайбер сүзләре хәтердә эленеп калган. Инде өч баласы үсеп килгәндә, җәмәгате белән ни өчендер килешә алмыйча, шактый каты үпкәләшеп, читкә чыгып киткән бу. Шуннан бирле уникe ел буена хат-хәбәрсез йөри икән. Ә өйдә ике малае егет булып житкән, имеш, хәзер. Эти аны һаман кайтырга үгетли. «Теге вакытта да күпме әйттем мин сиңа, сүзне тыңламадың, кире беткән,— ди.— Давай көзгә хәтле басылып кына эшлик тә бергә кайтып китик, җәмәгатең янына үзем илтеп куярмын, килештермичә китмәм»,— ди. Гыймран абзый кул гына селти: «Йо-ок, кайтмыйм, барыбер кабул да итмәс... Кайтмыйм — и баста!» — дип, тәмәке пыскытырга тотына.

Ә безнең этинең зимагур үгетләп кайтару — үзенә күрә бер өянәге дисәң дә ярый. Шундыйларның берсе, безнең авылның Мөти Әтәй Галимулласы дигәне, ишегалларына кайтып җиткәч, өйгә кермичә, бакча якларыннан чыгып качкан, имеш. Монысын көлеп сөйлиләр инде.

Гыймран абзыйның да кул селтәвен күргәч, «кайтмас бу, кайтса да качар», дип уйлаган идем. Ә менә без юлга җыена башлагач, Гыймран абзый эти каршына үзе килеп басты да:

— Мине дә иярт...— диде әкрен һәм дәртсез тавыш белән генә.

Эти аңа тиз генә ачылып китмәде. Хәер, без бит әле илгә кайтмыйбыз, эш эзләп кенә китәбез... Шуны аңлатырга теләпме, әллә сер бирәсе килмәдеме:

— Үз җаеңа кара, Гыймран абзый,— дип кенә куйды.

Шулай итеп, без, инде гөрләвекләр узып, җир кипшерә башлаганда, яңа урынга, яңа бәхет эзләргә чыгып киттек. Бараккагы абзыйлар, Мәгъмүрәттәйләр безне озатып калдылар. Ә Җиһангир абый инде кутумкаларны кия башлаганда гына каяндыр кайтып керде дә, этине кешесез почмаккарак алып китеп, аңа ун тәңкәлек кызыл кәгазь сузды. Эти бик аптырап калды, «Нәрсә бу?» дигән шикелле гаҗәпләнеп, аңа карады.

— Ал әле, Фәрхулла абзый, кирәк булыр. Сез бит икәү, үзең ай буе эшсез булдың...— диде ул, ярым пышылдагандай тавыш белән сүзләрен ашыкмый гына тезеп.

— Юк, Җиһангир энем, юк, рәхмәт яхшы сүзеңә,— дип, эти аның сузылган кулын йомшак кына кире какты. Җиһангир абый барыбер тыңламады. «Мин бит чын ихлас күңелдән!» дип ялваргандай, әлеге кәгазьне этинең түш кесәсенә кыстырды. Эти бер сүз әйтә алмады, аның күз төпләрендә яшь бөртеге җемелдәде. Ул Җиһангир абыйны кысып кочаклады да бараклан җәһәт кенә чыгып китте. Без аның артыннан атладык...

Калды, бар да калды, Төхфәт абый да, миңа күпме тәрбия күрсәткән Мәгъмүрәттәй дә калды, хәсрәтле Риян абзый белән Сәриян абзый да калды, мине гел көлдерә торган Хөснулла абый да калды, урамда күзнә уйнаган, «мат»тан башлап урысча сабак биргән дус малайлар да калды, мине таш атып сугышырга өйрәткән Якуп та калды, мине «каеш кәпәч»лектән чыгарган мәктәп дусларым да калды, анам сөте белән бишектән үк керә башлаган үз телемдә беренче тапкыр «арба, чана» дип дәрес биргән, «И туган тел» дигән шигыре белән мәшһүр

шагыйрь Габдулла Тукае да булган дөньяны эз генә булса да ачып күрсәткән, минем малай күңелдә беренче уяну чаткылары чәчкән мөгаллим абый Хөсәен Абушаев та калды, бар да калды...

Ә менә Җиһангир абый, миннән берәр генә адым алдан барган күк, гел күз алдымда килде. Нинди асыл кеше икән ул!.. Теге вакытта үзе пычак астына кереп, башкаларны фаҗигадән коткаруына әллә ни гомер сокланып йөргән идем. Ә хәзер — без чыгып киткәндә?.. Хәтта мин дә белеп торам: актык тиенен суза ич ул. Ник дисән, ай буе эшли алмый ятты, яралы чагы өчен бер тиен акча чыкмады. Әле яңарак кына эшкә тотынгач алган барлы-юклы авансысыдыр инде ул аның. Үзенең актык ун тәңкәсен айнык баштан кешегә чыгарып бирүчене көндез чыра яндырып эзләсәң дә табу мөмкин түгел иде ул заманда. Моны тырбайчык бер купис малае эшләсә, гаҗәп тә тоелмас иде. Үсеп буйга житкәч кенә төшендем: хикмәт акчада гына түгел, хикмәт — кешенең күңеле нинди булуда икән.

Без кичке караңгыда поездга утырып, мин өске сәндерәдә йокыга эри башлагач кына ул миннән аерылып калды. Хуш, Җиһангир абый, хуш! Син миңа киләчәк тормышым өчен бик олы, бик матур сабак биреп җибәрдең. Хуш, Җиһангир абый!..

## Карурман төбе

Иртәгесен бик соң йокыдан торып, тәрәзәгә күз салгач кына сорау килде башка.

— Кая барабыз соң без?

— Ил ягына таба кайтабыз,— диде Җыянша абый. Мин уянганда ул инде тәрәзәдән карап бара иде.

Ил ягына?

Сөенергәме, көенергәме?

Ел да тулмаган... Читкә чыгып, озаграк та йөрмәгәч... Минем өскәбашка да юк ич әле... Хәер, читек белән резинкә бар, чалбарда гына тора эш!..

Өч тәүлектән соң микән, Кәтримбур каласына житеп, поездан төштек. Ике катлы таш вокзалда икенче бер поездны көтеп алып, тагын кайсыдыр якка утырып киттек. Шулай күпмедер барганнан соң урман арасындагы бер стансага килеп чыктык. Иң элек күзгә ташланганы шул булды: станса бинасының бүрәнәләре тоташ яшелгә буялган, ә түбә кыегы астына гарәп хәрефләре белән «Билимбай» дип татарча да язылган. Себер уртасына хәтле барып-кайтып, татарча исеме дә язылган бер генә станса да күрмәгән идем...

Вагоннан төшкәч, әйберләрне күтәрдек тә гади бер юл буйлап урман эченә кереп киттек. Гыймран абзый белән эти алдан атлый, Җыянша абый белән мин — алар артыннан. Шактый барганнан соң озын, иске бер барак янына килеп җиттек. Ул яртылаш җиргә казып салынган, тәрәзәләре дә җиргә батып тора. Тирә-ягы гел урман да урман. Моны әдәмчә итеп салырга агач булмады микәнни соң? Баракның ишеге кырыеннан гына диярлек казылган тирән чокыр сузылып китә, салына башлаган шпаллар да күренә. Аңлашылды: монда чуен юл салалар икән, без шушында эшләргә килгәнбез, күрәсең. Әтинең яраткан сүзе: ни хода язгандыр? Ә минем монда килеп туктауга бер дә күңел үсмәде. Иң элек барагы ошамады: җиргә баткан сукыр тәрәзәләр, эченә төшү өчен балчык баскыч, нәкъ безнең өйдәге шикелле! Тәбәнәк кенә түбәдән тырпаеп торган һәм корымга баткан кыйшык-мыйшык моржалары да бигрәк шыксыз иде. Туксан өченче барактан соң андый чокырга барып керәсе килми шул!

Нишлисең: «Без барасы җирләргә салмаганнар ташпулат...». Кердек, түр сәкенең сул кырыеннан урын алдык. Уң кырыенда үзенең карты белән бер әби карчык утыра. Сөйләшеп киттек, олылар эш хәлләрен сораштырдылар. Монда Кәтримбурдан Казанга барасы чуен юлының иң озын тунеле казыла икән, кеше күп кирәк ди, имеш. Әтиләр шунда керешергә ниятләделәр. Әби карчык безгә дә аш пешерергә булды, ул буйдаклар карый икән. Баракта без кергәндә үк якты түгел иде, ә бераздан бөтенләй авыл мунчасыдай караңгыланып китте. Әби карчык лампа яндырды, электры да юк, ичмаса! Капчыктагы кыты-мыты белән чәй эчтек тә йокларга яттык. Былтыр Себердәге шикелле монда да кандала белән сугышып төн чыгарга туры килде...

Бәхеткә каршы, без монда озакка төпләнеп кала алмадык. Атна-ун көн чамасы эшләгәч тә, әтиләр моннан китәргә булдылар. Ни өчен?.. Хәер, сәбәбен төшенергә була инде: эш хакы әйбәт булса, тунельгә түгел, җәһәннәм тишегенә кереп эшләргә дә әзер бит кеше. Кәрәк-кәйлә белән балчык актарып кына нәрсә тапсын ул!.. «Гомер уздыру, чабата туздыру» — шул гына.

Нужа капчыкларын яңадан асып, Билимбайга чыктык, яңадан поездга утырып, кайсыдыр якка юнәлдек. Күпмедер барганнан соң Багрово (әллә Боброво иде микән) стансасына килеп төштек. Аннары карурман эченнән сузылган олы юлга чыгып, җәяү атладык. Юл туптуры, урталыгына әз-мәз таш түшәлгән, кырыйлары канаулы, юан-юан карт каеннар тезелеп киткән. Вак кына, сыек кына яшел яфрак чыгарып киләләр. Алар артын ике яктан да чын кара урман каплый, аның аркылы кояш бик әз үтеп кергәнгәме, аяк асты һаман пычрак әле. Без шул юлдан җитмеш чакрым бардык. Беренче көнне мин олылардан калышмыйча диярлек атлаган идем, икенче көнне бөтенләй бара алмас булдым. Капчыгым да авыр түгел; эчендә бишмәт белән күлмәкыштан да китап-дәфтәрләр генә, бүтән җирем дә авыртмый, тик ике аякның баш бармагына чыдар хәл юк — икесе дә төртә, үтереп сызлый. Тора-бара артка кала башладым, әти ачулана:

— Аягыңа таш бәйләмәгәнсеңдер бит! — ди. Ә минем еласы килә. Гарьлек тә, сызлау да үзәккә төшә. Һаман ныграк артка кала бирәм, алар мине көтеп ала, аяклы каза, ди торганнардыр инде.

Ниләр генә кылыйм соң? Әллә читек бәләкәй тегелде микән, әллә резин кәлүш кыса микән? Инде бүтән әмәл калмагач:

— Минем аяк кыса, бара алмыйм...— дип, канау кырыена чүмәштем дә бүселеп елап ук җибәрдем. Олылар да утырды.

— Нияmәрсә соң, пычагым булганмыни? — дип, эти читекләрне салырга кушты. Алардан котылгач, җаннарым рәхәтләнеп китте. Моңарчы эти миңа ялан аяк барырга кушмаган иде, ә хәзер Гыймран абзый да бу хәлгә кушылып:

— Барсын соң ялан аяк! Бу бит Сибирский тракт, кемнәр генә моннан ялан аяк узмаган? — дип, әллә көлеп, әллә чынлап әйткәч, риза булды. Читек-кәлүшне капчыкка тыгып, аркага астык та яңадан китеп бардык. Әле кибеп тә җитмәгән юеш салкынча җир өстеннән ялан тәпи баруы шундый җиңел, шундый рәхәт иде, мин йөгерә-йөгерә дигәндәй атлый башладым.

Җитмеш чакрымны ике тәүлектә узып, өченче көнне бер бәләкәй генә өйгә килеп кердек... Ничек килеп чыктык соң без бу җәһәннәм тишегенә? Кем акылы, кем өйрәтүе белән? Хәер, каян беләсең олыларныкын. Бала-чагага әйтеп торамыни алар. Себердән килгәндә дә, сорап-эзләп тормыйча, туп-туры тунель казыла торган җиргә килеп кerделәр бит. Инде анда эшләре уңмагач, тагын туп-туры монда килеп чыктылар. Күрәсең, ниндидер бер акыллы баш өйрәтеп җибәргән инде. Ай-яй, бу акча дигән нәрсә авыр табыла икән. Күпме юллар гиз, күпме газаплар чик!..

Без килеп кергән йорт ярлы бер авыл өе хәтле генә. Ул мина бер дә ошамады. Өч ягында өч бәләкәй генә тәрәзәсе бар, ә түрдәге стена «күзсез». Ишектән керүгә ике яклап тоташ сәке сузыла, уртада калган буш арада буралап балчык тутырган мич казнасы. Аның өстендә иске чуен мич тора, шуннан болай табарак эпен-төпен генә ясалган иске бер өстәл,— башка һичнәрсә күренми. Сәке өсләре гел тузан. Ишектән кергәч тә сул як стена буеннан урын алдык, аның тәрәзәсе дә бар, яктырак...

Җеп өзәр хәлләр дә калмыйча килеп кергәннән соң тамакка нәрсә һәм ничек әзерләп ашаганбыздыр, белмим, тик эти урын-җирне таратуга стена буена тәгәрәп китүемне генә хәтерлим. Иртәгесен торып тышка чыккач, ишек каршында гына озын бер бура барлыгын күрдем, кичә ул никтер күзгә чалынмаган иде. Түбәсе ябылып бетмәгән, ишек-тәрәзәләр куелмаган. Эченә кердем: идәне-түшәме дә бар, моржасы гына юк. «Әһә, бу эшләнеп беткәч, безне шунда күчерәләр икән!» дип уйладым — эчкә җылы кереп куйды. Әтиләр эш белешергә киттеләр, бик иярмәкче идем дә, әйбер сакларга өйдә калдырдылар.

Озак йөрмәделәр тагы. Управляющига барып, эшкә керешеп кайткаңнар, монда тимер рудасы чыгаралар икән, авансы да яздырып алган булсалар кирәк, тел төпләреннән шул сизелде. Алар ничек урнашу, ничек ашау-эчү ягын әмәлләү турында уйлаша калды, ә мин урамга, дөнья күрергә чыгып киттем.

Менә сиңа «урам»! Өй янына чыккач та, шул бурадан бүтән һичбер йорт, каралты-кура күренми. Әйләнәдә сирәк-мирәк озын чыршы, нарат, каен һәм вак агачлы урман аланы. Өйнең арткы ягыннан арба юлы сузылып бара-бара да урманга кереп китә. Ә юлның теге читендә киртәләгән печәнлек күренә. Ул инде бу тирәдәге берәр байның заимкасыдыр[1]. Беркайда бер әдәми зат күренми. Шулай шаккатып йөри торгач, яр кырыена салынган бер бина эченә килеп кердем. Уртасында киң итеп буралап казылган кое бар. Матчадагы чыгырдан төшкән юан аркан ыргагына олы гына агач бадья эленеп тора. Аңладым: монда яңа шахта сугалар икән. Ә кайда соң моның кешеләре? Нигә эш туктаган?

Бу корылмадан чыккач, шактый түбән якта тагын бер иске генә озынча йорт күреп, ул тирәдә дә һичбер җан иясе очратмыйча, кире әйләнеп өйгә кайттым. Шушыны рудник диләр, имеш? Ташландык бер чокыр ич бу! Монда нишләр безнекеләр — белмим. Мөгаен, озакка чыдамаслар, тагын чыгып китәрбез...

Олылар барын да сорашып-белешеп кайткан булсалар кирәк: моннан алты чакрымда Атиг дигән авыл бар икән, иң якын дигән авыл. Безгә бөтен нәрсәне шуннан ташырга туры киләчәк, имеш. Монда кибет тә, хәтта мунча да юк икән. Әдәм көлкесе, менә сиңа — чит! Шулай да безнекеләр зарланмый әле, тып-тын шул авылга җыеналар. Иртәгесен дүртебез дә шунда чыгып киттек. Өйне кантурдан алган олы йозак белән бикләп, мине дә үзләре белән алдылар.

Авыл урамы буйлап сораштыра торгач, бер өйгә фатир кердек. Хуҗабыз озын буйлы, соры чәч, соры мыеклы, ир уртасын узып бара торган бер кеше булып чыкты. Исемен Ларион диде. Гыйммран абзый урысчаны су күк эчә иде, безнең кайдан килү, ни йомыш белән йөрүне сөйләп бирде. Аңлавымча, безнең мәшәкатьләр шактый гына икән: он табып икмәк пешертергә, ит юнәтергә, чәй-шикәр, сабын-тоз шикелле нәрсәләр алырга, һәр вакыт килеп алу өчен яхшы сөт табарга, кер юдырырга, мунча керергә һәм тагын әллә ниләр.

Ларион дәдәй этиләрне кибеткә алып китте. Аның хатыны Марфа түткәй, кәрләрне сорап алып, уарга әзерләнә башлады. Олы малае Петькага су ташырга кушты. Аңа ияреп мин дә чыктым, суларын ише-

[1] Заимка — биләп алган җир.

галдындагы коедан гына аласы икән. Ике чиләк белән тотынгач, бу эшне бик тиз төгәлләдек. Петька миңа караганда берәр яшькә олырак, гәүдәгә дә калку, итләч малай, атасы төсле сорыга төргән, миннән көчлерәк сыман да күренә. Ул мине урамга алып чыгып китте, зур бер күл читенә килдек, ул аны «пруд» диде. Аның теге кырыенда кызыл кирпечтән салган озын торбалы завод күренә. Анда хәзер сугыш өчен чәнечкеле тимер чыбык ясыйлар, имеш...

Кара, мин урысчаны диһи[1] төшенәм икән хәзер, бер сүзен дә аңламыйча аптырап калмадым. Үзем дә сорауларны яудырып кына торам, шулай да үзем сөйләшкәндә «вак» җитеп бетми әле, еш төртеләм, кул бармаклары уйный башлый, «ык-мык» белән «как сказайт»,— иң күп кабатланган сүз булып чыга.

Без байтак йөргәнбез, ахры. Марфаттәй (үземчә шулай дип атадым) инде керләр элеп йөри, этиләр бер колын алып суйганнар, келәт артында аны тунап бетереп яталар. Аннары, итен чапкалап, бер агач кисмәккә тутырдылар да хуҗаның лапас түрендәге кар базына төшерделәр. Азык-төлек тә табылган, кичке караңгы төшкәндә Марфаттәй ипи изә калды, без аларның бакча ягындагы мунчасына киттек. Себердән чыкканнан бирле мунча кергән юк иде, бик рәхәтләнеп чабынып-юынып чыктык. Кайда ятканны да белмичә, төн буе изрәп йоклаганмын. Иртәгесен эти уяткач, күзне ача алмый тас булдым — әле генә яткан идек түгелме соң?

Марфаттәй безгә дигән ипиләрне мичтән чыгарып, сәкедәге ак җәймәгә тезеп куйган, керләрне төреп тәрәзә төбенә өйгән иде инде. Куе сөт белән, яңа пешкән җылы күмәч белән бик шәпләп чәй эчтек тә кайтырга җыендык. Бөтен азык-төлекне өч капчыкка тутырып, олылар күтәрде. Юылган керләрне төйнәп минем аркага астылар. Чуенда кызарганчы кайнатылган каймаклы сөтне олы агач тәпәнгә салып кулга тоттырдылар. Шулай төянеп өйгә кайтылдек. Әйбәт кеше булып чыкты хуҗаларыбыз, ничек хәстәрләп җибәрделәр. Алга таба да Марфаттәй безгә икмәк пешерергә, сөт бирергә, атнада бер мунча кертергә, керләрне юарга булып калды. Шуннан башлап алар безнең якын белешкә әйләнде.

Кайтып кергәч, әйберләрне урнаштыру, бу ташландык алачыкны тәртипкә китерү, урын-җир кору, кичкә аш пешерү белән көн узды. Шулай итеп, безнең бу карурман төбендәге сәер тормыш башланып китте.

## Әби патша заманасыннан

Хәзер мин кайбер нәрсәләрне белдем инде: бу урын «Листьянка» дип аталган казна руднигы булачак икән. Беренче шахта әле сугыла гына башлаган. Авыл кешеләре сабанга кайтып киткәч, ул да туктап тора. Безнекеләр, управляющий күрсәткән иске шурфларның берсен тазартып эшкә тотындылар. Һәр көнне иртүк килеп, авылның буралы коесы төсле шурф почмагына сугылган тар гына такта баскычтан аска төшәләр дә руда арасындагы балчыкны, комташларын кәйлә-көрәк белән актарып, шурф төбенә китереп өяләр. Аннары Гыймран абзый белән Җыянша абый өскә чыга, стан чылбырына беркетелгән агач бадьяны төпкә төшерә, ә тегеннән эти бадьяны тутырып сигнал бирә — породаны өскә күтәрәләр. Шулай итеп, забой «запал»га әзерләнгәч, моннан динамит шашкасы төшерелә. Аны эти руда арасына үзләре ясаган «оя»ларга кыстыра да, шнурын суза килеп, шурф төбендәге бадьяга утыра. Аннары «әҗәл»нең койрык очына ут төртә һәм шундук:

— Күтәр! — дип кычкырып җибәрә.

[1] Диһи — шактый, ярыйсы ук.

Күптән әзер булып торган Гыймран абзый белән Җыянша абый станның тимер сапларын җан-фәрманга әйләндерә башлый, хәтта муен тамырлары бүртеп чыга. Әти шурф авызына менеп җиткәндә астан «доңк-доңк!» килеп шартлаган саңгырау тавыш ишетелә. Дүртебез дә (беренче көннәрне мин дә шунда бутала идем) аска карыйбыз. Анда шурф төбен аксыл-зәңгәр төтен сарып ала.

— Хәере белән...— ди әти.

Гадәт буенча кәйлә-көрәкләрен агач астына сонгалап, төшке ашка кайталар. Баштарак ашны Җыянша абый пешерә иде. Миңа да эш җитәрлек: утын әзерлим, якындагы урман елгасыннан су алып кайтам, бәрәңге әрчим. Ә тора-бара аш пешерү гел минем өскә күчте, мин ул ашка тәмам «остарып» җиттем. Мактанып куясы килә: җәй буе пешергән ашымның бер гаебен дә тапмыйча, янган-көйгәннәрен әйтмичә, бик яратып ашадылар.

Дүрт карынга бер су чиләге ашны төягәннән соң олылар сәкегә тәгәри, мин өстәлне җыеп, кашык-аякны чиләккә тутырам да юарга китәм. Иске отвал чокырына бәләкәй генә күл чыккан. Астан чыкканмы, язгы кар суымы — үзе суык кына. Яр читендә әз генә комлыгы да бар, майлы-корымлы нәрсәләрне ышкып юарга бик җайлы. Төшке кояш та нәкъ каршыда гына, комны да кыздырган. Савытларны чыбык-чабык өстенә тезеп салам да бер ялгызым комга тәгәрим. Бу төш нәрсәсе беләндер безнең инеш буйларын хәтерләтә, авылны сагынып куям. Сагындыра торган тагын бер нәрсә бар: көненә ике тапкыр түбән як нарат урманы эченнән поезд кычкыртып уза. Чуен юл моннан бишалты чакрымда булса да, аның, бик якыннан гына ишетелгәндәй, шундый моңлы итеп, суза-суза кычкыртып узуы йөрәккә төшә, күңелне әллә кайларга җилкендерә, шул поездларның берсенә утырып кайтып китәсе килә башлый...

Ярар, мин дә эш кешесе бит әле, комнан сикереп торам да, табак-савытларны җыеп, өйгә кайтам. Җыянша абый чәй кайнатып маташа инде. Чәйдән соң алар тагын эшкә китәләр. Чынаякларны җыйгач, мин дә барам. Шурф төбендәге зәңгәр сөрем инде өскә суырылып беткән була, аттырылган руданы бадьяга төяп өскә күтәрәләр, аннары порода чыгару башлана. Бу эшләр беткәч, астагы кеше креп (ныгытма) баганаларын кабат тикшереп чыга, аттырганда какшаганнарын ныгытып куя, кирәк урыннарга яңа стойкалар утырта. Аннары өстәге эшләргә тотыналар: астан күтәрелгән руданы ике кеше носилка белән читкә ташый, өченчесе аны кирпеч шикелле дүрт почмаклап өеп тора. Смена буе чыгарылган породаны да читкә көрәп ташлыйлар, креп агачы да юнып куярга кирәк була. Монда сәгать юк, вакытны кояшка карап кына билгелиләр. Көн саен иртүк китәләр, кичке кояш сүрелә башлагач кайталар, нәкъ авылдагыча.

Белмим, аларның көндәлек эшен кем үлчәп, кем кабул итә булгандыр. Әртилшек, дисәтник-фәлән юк, управляющий үзе дә әллә нигә бер генә күренә. Ул калку гәүдәле, салам эшләпәле, коңгырт мыеклы кеше, күзлек кигәнгәме — бик җитди һәм карт чырайлырак булып тоелса да, шурф янына килгән чакта этиләр белән гел елмаеп кына сөйләшә, кәеф-хәтерләрен сораштырган була, ә кулында үлчәү таягы, я булмаса тасма сузылып чыга торган түгәрәк нәмәрсәкәе дә булмый. Бәлкем, ул күзе белән генә үлчәп китә торган булгандыр? Һәрхәлдә, безнекеләрне рәнҗетмәгән булса кирәк, берсенең дә ул кешедән зарланганы ишетелми. Эш турыннан гаделсезлек сизелсә, иң элек безнең әти күтәрә алмый. Хак төшмәсә, бүтән чакта гел мыштым йөрергә яраткан Җыянша абый: «Тамактан артмый»,— ди башлый. Ә Гыймран абзый — ошамаса, бүген үк кубып чыгып китә торган кеше.

Юк, дөньяны байтак ураган бу өч татарга шушы кыргый урман төбе килеште, ахрысы. Кузгалу турында ләм-мим ишетелми. Инде өйләргә хат язып, хат та алыштык, әти белән Җыянша абый азмы-күп-

ме акча да җибәрде бугай. Хәтта Гыймран абзый да өенә хат салды. Әйтәсе сүзләрен бик уйлап-җайлап кына тезеп, эти язып бирде аңа хатны. Үзенә дә хат килде. Олы малае үз кулы белән язган, бик сөенгәннәр: «Бик сагынабыз, әнкәй дә бик сагына, барыбыз да исән, малтуар да юк түгел, колын үстереп, атлы да булдык»,— дигәннәр. Үзен, бик ныклап, кайтырга чакырганнар. Аның бу хатын башта эти укып бирде. Гыймран абзый атна буе уйланып йөрде. Сөенүен сиздермәскә теләп, исе китмәгәндәй генә кыланса да, җирән керфекләре артындагы соры күзләрендә очкын яна башлавын барыбер яшерә алмый иде. Атна-ун көннән соң бу хатны ул миңа тагын бер кат укытты, өйдә ничкитер икебез генә идек. Башын иеп, хат беткәнче тыңлап утырды-утырды да:

— Малай үскән икән, ә?.. Ат та бар дип мактанган бит...— дип куйды, әз генә елмаенкырап. Шуннан соң аның бөтен хәрәкәтендә ниндидер терелек, җирән чыраенда каяндыр күңел түреннән сибелгән яктылык бар сыман тоела башлады.

Инде агачларга чын яшел төс керде, ә шомырт ап-ак булып чәчәк атты. Әй, күп икән монда шомырт! Тегендә дә ап-ак өем, монда да ап-ак өем! Йөгереп килэм дә туйганчы исним, борынны чәчәкләр арасына төртеп, яшь ботакларны кочаклап торам, исертеп җибәргәндәй була. Безнең урамда Шәйдулла абзыйлар белән Гарифулла абзыйларда гына бар иде ул шомырт. Аны да читтән, киртә аркылы гына карап узасың. Ә монда кочагың каерылганчы җый, башың әйләнгәнче иснә!

Шомырт чәчәкләре шулай ике көн бик матур торды, ә инде өченче көн иртәсендә шул ап-ак чәчәкләр өстенә буранлый-буранлый ап-ак кар яуды. Бөтен яшел яфраклар, чәчәкләр, үләннәр өстенә үле кәфен сарылгандай булды, кычкырып елыйсы килде.

Суык яңгырлар тиз генә туктамады, көннәр бер ачылып-бер йомылып, һаман сибәле торды, аяк асты лыжырдагач, ялан тәпи йөреп булмый башлады. Ә минем читек-кәлүшне рәешкә саклыйсым килә. Бигрәк тә, резинкәнең көзгедәй йөзен тоныкландырасы, астындагы матур сырын бетерәсе килми. Аякчу мәсьәләсе этиләр өчен дә кыенлашып китте — Себердән чыккан күн итекләре бүселә башлады, тәзәтү артыннан йөрсәләр — эшләре каласы...

Бер көнне эштән соң алар урманга кереп, юкә курысы төшереп килделәр, бер дә ботаксыз бик шома, яшь юкә алып кайтканнар. Тотындык чабата ясарга! Башта үзләренә калып юндылар, кибеп беткән кәкре имән ботагыннан шөшле ясадылар, аннары эти миңа да калып юнып бирде. Алдагы көн якшәмбе иде бугай, иртәдән кичкә хәтле дүртәүләп шул эш белән маталандык. Әйтерсең чабатачылар артеле. Кая барсаң — кара сакалың дигәндәй, чабата да безнең арттан калмый.

Мин чабата ясауны күптән үк өйрәнгән идем инде. Яшь әни килгәч, аңа да, Хөршит түтәйгә дә тугыздан ясап киерткәнем бар хәтта! Тар гына итеп теләнгән тугыз мижан[1] юкәнең шома ягын гына өскә китереп, йөзен чибәр итеп, борынын туп-туры матур куеп чабата кайтару, артык тирән дә, сай да итмичә, кырый юкәләрен тигез генә бора бару, колаксаларын таманча гына кую, астын тезгәндә чүп-мыек калдырмыйча тезү, калыптан төшергәч уенчык итеп уйнарлык матур чабата ясау — шактый кыен эш. Моңа сәләт кирәк, осталык кирәк — тугыздан ясалган чабатаны кызлар, яшь киленнәр генә киясе бит аны! Әйе, чабатачы булырга шактый сәләт биргән бугай миңа ходай! Безнең авылда гомер буе чабата ясап көн күргән Нәзир абзый бар, үзе дә әйбәт кеше, чабатасы да бик сөйкемле һәм бик нык була. Әгәр чабатачы булып китсәм, минем аннан да уздырырга исәп бар әле!..

*Дәвамы бар.*

---

[1] Мижан — сынмый торган, йомшак.

Мостай Кәрим,
*Башкортстанның халык шагыйре*

## КӨЗГЕ ШИГЫРЬЛӘР

●

*Чыңгыз Айтматовка*

Гомерем минем сәер уен булды,
Серле бер жирәбә — тотыштан.
Алмаш-тилмәш килде так белән җөп,
Отылулар белән отышлар.

Югалтулар аңдып торды һәрчак
Урау юллардагы табышны.
Мәхәббәт тә ялгыз йөрмәс булды,
Гел ияртеп алды сагышны.

Инсафланып беттем дигәч кенә,
Янә килеп шайтан котыртты.
Мактау күргән саен, гамем артып,
Отры мине хурлык куркытты.

Минем йөрәк аша үтә, ахры,
Көннәр белән төннәр ызаны.
Шатлыгым еш бәхет чигенә җитте,
Тик ул чикне әле узмады.

Гомерем минем хәтәр уен булды,
Серле бер жирәбә — тотыштан.
Алмаш-тилмәш килде так белән җөп,
Отылулар белән отышлар.

...Уңышларым егет итте мине,
Басынкы ир итте табышлар,
Әмма мине шагыйрь ясадылар
Югалтулар белән сагышлар.

●

Бу юлы син диңгез буйлап килдең,
Комлы буш яр иде алдыңда.
Шул ярга син аяк баскан саен
Ком әйләнә барды алтынга.

Акчарлаклар күксел канатларын
Алтын томаннарга мандылар.
Син учыңа кабырчыклар алдың,
Алар энҗе булып яндылар.

Син иелеп сөйдең бик сак кына
Дулкыннарның тузгак ялларын.
Кагылуың булды, бар дәрьяны
Офыккача алтын ялмады.

Хәтта кояш ул көн күктә түгел,
Алтын бизәк иде — түшеңдә.
Дөньяны мин шундый күрдем бер кат
Әллә өндә, әллә төшемдә.

Киткәндә син урман аша киттең,
Алтын сукмак — синең эз иде.
Агачларда алтын моңсулыгы —
Әйе, монысы инде көз иде.

●

Язгы гөрләвекләр гөрләп аккан
Иләс бер чак иде,
Җиһан аяз, яшь гомерем минем
Әле бик саф иде.

Сиңа килдем әйтермен дип зур сүз —
Сихри сөю сүзен.
Авыз ачкач эндәшәлми калдым —
Ничек кенә түздем?

«Гөрләвекләр гөрли»,— дигән булдым,
Имеш, салдым хәбәр.
Кычкырып бер сәер көлдең дә син,
Кинәт тындым мәгәр...

Җимеш пешкән иде, ботакларын
Җиргә иеп-иеп.
Дөнья күргән, җөй-яралар йөрткән
Инде мин ир-егет

Сиңа килдем әйтермен дип зур сүз —
Яңа язмыш сүзен.
Әйтми калдым шул чак, янә түздем.
Нигә генә түздем!..

«Кызарып җимеш пеште,— дидем бары,—
Яфрак арасында».
Өмет катыш җиңел сагыш иде
Синең карашыңда...

Күзгә кырау җәйне өтеп алды.
Яфрак ява бурап.
Шушы мизгел минем гомерне дә
Үтмәгәндер урап.

Сиңа килдем әйтермен дип бер сүз —
Үкенечем сүзен.
Ярый аны тешем белән кыстым,
Ярый әле түздем.

Пышылдадым бары: «Агачларда
Ап-ак бәсләр, әнә».
Баксам, синең ике битең буйлап
Ап-ак яшьләр ага...

●

Кичтән давыл купты. Ярга сугылып,
Төне буе диңгез үкседе.
Бөек дәрья! Әллә синең дә, дим,
Гамьсез, шат көннәрең үттеме?

Өзгәләнмә, диңгез, гомерең чиксез.
Син бит, юләр, шундый яшь әле,
Ә мин исә мәңгелекнең бары
Бер дулкыны булып яшимен.

Шулай да мин тыныч. Борчылырга
Бәлки юктыр инде сәбәп тә...
Ни гаҗәп бу? Кинәт җан тетрәтеп,
Гарасатлы, шомлы сәгатьтә
Илаһи моң килде... Курай моңы
Давыл түбәләрен артылды.
Нур сеңгесе булып төнне тишеп,
Ефәк тасма булып тартылды.

Курай үкси, курай мактау җырлый:
«О, Уралым минем, Уралым!..»
Шушы минутта мин ярсу атта
Ун гасырга кайтып урадым.

Тамырларым буйлап моңнар акты,
Моңнар ташты, моңнар яндылар.
...Җиргә сеңеп, берчак мин тынармын,
Диңгез шаулар. Моңнар яңгырар.

Әй, сөеклем!
Шул чак баш очыма
Кара мәрмәр куйма. Сораем:

Яз җиткәч тә яп-яшь курай утырт,
Көмеш чуклы Урал кураен.
Көзгә кадәр үсәр, моңнар җыяр.
Бер таң аны шундый уйнатыр:
Каберемнән сикереп чыгармын да
Мин китәрмен галәм буйлатып.
Миллиард йолдызларның арасыннан
Син кабызган утны танырмын,
Ишегеңне килеп кагырмын...

...Диңгез үкси. Өзгәләнмә, дәрья!
Синең белән без бит яшь әле.
Дулкынланып гомер раслыйсың син,
Ә мин исә монда яшимен.

●

Ялтырап тормыймын. Дөнья
Таушалтты, шомартмады.
Шәүләм озыная. Әмма
Рухымда шом артмады.

Элеккечә балкый гүя
Хыялымчың таңнары.
(Тик ешрак кабатлана
Хәтерләү акшамнары...)

— Хәерле юл! — димен җилгә,
Һаман да беркатлымын.
Тауга менсәм — канатлымын,
Сыбай күрсәм — атлымын.

Күктә бер кошчык сайраса,
Бар җиһан хәйран димен,
Җирдә бер кеше елмайса,
Җир йөзе бәйрәм димен.

...Хәвеф юкта хәвефләнәм,
Чик юк җирдә — чикләнәм.
Күз яшьләренә ышанам,
Ә антлардан шикләнәм.

— Кордаш!— димен кояшка мин;
Бигрәк тә беркатлымын,
Һаман сакаллы сабыймын,
Һаман шул бер затлымын.

Моннан соң да, исән булсам,
Утырмас инде акыл.
Һич вакытта белә алмам
Әйберләрнең «үз хакын».

## Салаватның Ануга әйткәне

Очраштык без нигә синең белән,
Нигә үтә соң?
И син, гомер, нигә бергә түгел,
Арабыздан гына үтәсең?

Аерылышканбыздыр бәлки иртә,
Бәлки үтә иртә...
Орлык койган мәлдә кайчак гөлгә
Җил кагылып үтә.

Парлап төшкән ике орлыкның берсен
Алып китә алыс [1].
Җил —узгынчы. Нәрсә аңа сөю,
Нәрсә аңа сагыш.
Ярый әле, сине ташламаган
Үтә еракка.
Чал башымны иеп, рәхмәт әйтәм
Җилгә, туфракка.

## Чигү чигә кызлар

Кич утырып кызлар чигү чигә,
Чиккәннәре, беләм, бирнәлек —
Апаемны былтыр сораттылар,
«Әле яшьрәк шул», дип бирмәдек.

Чана юлы төшкәч (вәт күр дә тор),
Янә килер эрсез яучылар,
Телләреннән баллар тамар,—
Имеш:
«Сездә аккош, бездә аучы бар...»

Кич утырып кызлар чигү чигә,
Бизәкләргә ялгап бизәкне,
Бизәкләре ефәк җырдай агыла,
Тик җырлары өзә үзәкне.

«Күпер асты күк томан,
Күпсенмәгез, күп тормам,
Айлар торсам, еллар тормам,
Сагынырсыз, мин булмам...»

Мин бәләкәч, бик бәләкәч әле,
Тар сәндерә — барлык җиһаным.
Шул җиһанда бу кич япа-ялгыз
Йомма яшем түгеп еладым.

---

[1] Алыс — ерак.

Мин еладым:
Менә килерләр дә
Кыңгыраулар таккан атларда
Берәм-берәм алып элдерерләр
Җиде кызны җиде якларга.

Мин еладым:
Бу кич кабатланмас,
Кире кайтмас инде бу моңнар...

Кызлар җырлый.
Күбәләкнең нигә
Яшь түккәнен белми былбыллар.

Кичләр кабатланмый. Моңнар кайта,
Урап кайта икән бер талай [1].
Күпме үрләр үткәч, шул җыр тагы
Йөрәгемне телде урталай:

«Күпер асты күк томан,
Күпсенмәгез, күп тормам.
Күп торсам да, мәңге тормам,
Сагынырсыз, мин булмам...»

Мин хәзер зур. Хәзер бик зур инде.
Бәтен дөнья — минем биләмем.
Бер кичәнең түгел, бер гомернең
Ике килмәүләрен беләмен.

Шуңа күрә үксеп кенә түгел,
Үкереп еласаң да җирлек бар.
Еламыймын. Чөнки сабырлык бар,
Сабырлыкка тиңдәш ирлек бар.

Еламыймын. Фани дөнья аяз.
Чыклар яна яшел үләндә.
Таң нурына кунып, яз тургае
Тәүге җырын җырлый түбәмдә.

●

Җиңүләрем, уңышларым булды,
Бүләк алдым, хөрмәт татыдым:
Менмәсәм дә, сыйпаганым булды
Алтын ялын шәһрәт атының.

Тик тырыштым эреп төшмәскә мин
Килеп китәр шатлык каршында.
Чөнки бәхет була тик иртәгә,
Тылсымлы ил — диңгез арты да.

Ләкин булды бер чак бәхетемнән
Түбәләрем күккә тигәне.
Ул көн миңа: «Иң бәхетле кеше
Җирдә мин ул!»— диде сөйгәнем.

---

[1] Бер талай — бер мизгел.

●

Онык — яшь арыслан. Бар куәте
Тимер тырнагында.
Атасы — йөк аты. Бар мөлкәте
Алтын тоягында.

Карт атасы — керпе. Аның инде
Хәле аянычлы:
Тырпаерга торган энәләре —
Барлык таянычы.

●

Акыллыга серем чиштем —
Үзе теләп
Улы итте;

Бер ахмакка серем чиштем —
Теләмәстән
Колы итте.

Табигатьтә шундый мизгел бар:
Җил тынгач та, яфрак тирбәлә,
Кояш бата таулар артына,
Нуры бүленеп кала түбәдә.

Табигатьнең шундый мизгелен
Күрсә иде минем елларым:
Мин киткәндә, берәр гасырга
Бүленеп калса иде ерларым.

●

Мин киткәндә: «Ятим калдырма!»— дип,
Шигырьләрем арттан иярер.
Балаларым! Сезнең тугрылыкка
Хәзердән үк башым иямен.

...Сабый чагым. Атын җигеп, әти
Чыгар гына хәл юк курадан [1],
Йөк артыннан тыр-тыр иярәм дә:
«Мине ал!»— дип дөнья кубарам.

Бераз баргач, атын туктата да
Мине утырта әти алдына,
Әмма басу капкасына җиткәч,
Арбасыннан төшереп калдыра.

---

[1] Кура — ихата.

Шигырьләрем,
Сезне алырмын «имән көймәмә» мин,
Соңгы җилләр өргәч җилкәнгә.
Тик барыбер төшереп калдырырмын
Зират капкасына җиткәндә.

Сез гөнаһсыз. Мин бит беләм сезне.
Сез төштегез миңа күкләрдән;
Бар языкны үз өстемә алам,
Бар җәзасын үзем күтәрәм.

## Бүләкләр

Ундүрт яшьтә башкорт кызы
Качып кына яулык чигә; —
Тәү бүләк бу һәр кич саен
Бик зарыгып көтүчегә.

Үнсигездә әсирләнеп
Мәхәббәтнең гамәленә,
Бар булмышын, рәхәтләнеп,
Бүләк итә хәләленә.

Шуннан алып күкрәгендә
Йөрәтә ул илнең котын,
Бүләк итә туфрагына
Яңа кеше, яңа токым...

Ә алтмышка җиткәч инде
Җыя башлый үлемтеген,
Ләкин аны борчылдырган
Һич кенә дә үлем түгел.

(Ни юк аның сандыгында?!—
Яулыклары, сөлгеләре,
Хушбуйлары, сабыннары,
Хәтта вак-вак көзгеләре...)

«Өлешсезләр калмасын»,— ди,
Шушы аның бар хәстәре.
Төн йокламый барлап чыга
Кордашларын, кардәшләрен.

Ул соң изге бурычларын
Бетмәгәнме инде түләп?
Юк, барыбер калганнарга
Биреп китә соңгы бүләк,
Калганнарга соңгы бүләк...

— Талпынасың, ашкынасың,
Күзләреңдә нур гына;
Әй, яшь егет, йөрәгеңнән
Нинди шатлык ургыла?

— Янып-шашып, янып-шашып
Булдым гашыйк!..

— Чал чигәле узаман [1] ир,
Нигә авыр канатың,
Нинди хәсрәт төште сиңа,
Нинди моңсу карашың?

— Янып-шашып, янып-шашып
Булдым гашыйк...

## Сагыну

Ак томанлы Акманайны,
Ак каенлы Чагылымны
Бу юлысы бигрәк тә,
Бигрәк тә сагынылды.

...Җилләр монда ят көйләрне
Уйнаса да төн кылында,
Туган өннәр җитә миңа
Барыбер үз дулкынымда.

Мин аларны чүпләп алам
Меңәр аваз арасыннан.
Бер карашны аерамын
Йөзәр мең күз карашыннан.

Акманаем, сине онытмам,
Килер тәмуг җәзалары —
Минем өчен корып калыр
Дөньяның бар дәрьялары.

Чагыл тавы, әгәр сине
Төшермәсәм исләремә,
Җир шарының бар таулары
Ишелерләр өсләремә.

Инәм теле — иман телем,
Әгәр сине сагынмасам,
Көн дә сиңа табынмасам,
Телләремнән язар идем.

Таллин, 1970.

---

[1] Узаман — хөрмәт казанган кеше.

## Кошлар очырам

Вак мәшәкать, ыгы-зыгы тәмам,
Бар эшемнең чыктым очына.
Шуңа күрә бүген таңнан алып
Күкрәгемнән кошлар очырам.

Аклык, пакьлек өчен көрәшчеләр!
Тәү бүләгем сезгә, карагыз:
Канатларын горур кага-кага,
Күтәрелде күккә каракош.

Юлдагылар! Сезгә җибәрәмен
Җил-давыллар үтәр торнаны.
Чирләләрем, кәккүк очырам сезгә —
Озак-озак чакыра торганын.

Чыгып очты ярсу бер сандугач,
Гашыйкларым, сезнең өлешкә.
Көткәннәргә — ак күгәрчен килер,
Яңа өмет естәп өметкә.

Хыялыйлар, чая һәм юашлар!
Һәммәгезгә тияр кошым бар,
Гамьсезләргә генә һич нәрсә юк —
Әйдә, алар кошсыз торсыннар.

Ыгы-зыгы, вак мәшәкать тәмам,
Бар эшемнең чыктым очына.
Шуңа күрә һәр көн таңнан алып
Күкрәгемнән кошлар очырам.

# МИНУТЛАРНЫҢ БӨЕК ЧАГЫ

Әдәбиятка килгән көнемнән бирле генә дә ярты гасыр вакыт үткән булуы, шул гомер агышында, әдәбияттан аерылган елларда да, шигырьдән аерылмау, поэзиядәге вакыйгалар, проблемалар турында уйланмаган көнең булмау — сыналган, аксиома хәленә килгән карашлар, фикерләр тудырды инде: һәр шигырь, кемнеке генә булса да, ул, беренче очрашуда ук, үзенең авторы турында, аның сәләтенең, талантының күләме турында ачык итеп әйтә ала, хәбәр бирә ала һәм бу беренче хәбәр авторның алдагы иҗади эшендә тулысынча раслана.

Бүген миңа хәтер Мостай шигыре белән беренче тапкыр очрашуымны һәм шуңа аналогия рәвешендә, аңа кадәрге иҗатлар белән тәү тапкыр танышуларны да искә төшерә.

Тукай. Ул мине,— ә мин яшь идем, яшел идем, күрәсең,— кинәт түгел, акрынлап биләде. Тукай абый да, Н. Думави абый да, М. Гафури абый да бертигез әйбәт кебек иделәр әле. Тукай вафат булгач, «Җан азыклары» җыентыгына очрагач кына, сискәнеп, уянып киткәндәй булдым. Ул һаман үсә, бөекләнә барды һәм әле дә ачыла, яктыра бара ул минем күңелдә.

Ш. Бабич. Аның шигырьләре мине кинәт, өермә күк бөтереп алды, тылсымлы шигырьләр шагыйре икәненә ышандырды.

Аннан соң (1921 елда) үзенең «Война и мир»е, «Облака в штанах»ы белән давыллланып, хисләрне аягүрә бастырып Маяковский килеп керде йөрәккә.

Такташ. Аның шигырьләре белән беренче мәртәбә 1923 елда Уралда очраштым. Бөтен барлыгымны биләп алды. Берничә көн йоклатмады, көннәрне төннәргә ялгатты. Татар теле шигырьгә менә нинди могҗизалар бирә ала икән дигән иман тудырды.

А. Твардовскийның «Страна Муравия»се белән танышкан елларда Сибгат Хәкимнең беренче адымнары татар теле шигырендә яңа «Җан азыклары» туачагын хәбәр итте.

Шигырьләр шул рәвешчә авторлары турында әйтә тордылар.

Кырыгынчы еллар ахырлары иде. Редакциядә Башкортстаннан килгән газета-журналларны күздән кичерә идем. Бер шигырьгә очрадым. Гаҗәпләнеп уйга калдым. Җибәрми мине бу шигырь. Кат-кат укыта. Укыган саен эчтәлеге киңәя, тирәнәя бара. Күгәрчен генә, сандугач кына түгел бу шагыйрь, ә шигъри лачыннар, бөркетләр токымыннан, чынлап та, Урал тауларыннан күтәрелә, күрәсең, дигән хис тудыра. Баштагы әдәби адымнарында ук, битараф хәлдә генә, урталыкта гына яшәргә дә риза була торган егет түгел икәне ачыктан-ачык сизелеп тора. Теленең, сүзнең ямен, тәмен нечкә рәвештә сиземләве, мәгънәне соклангыч ягымлы итеп әйтә белүе, сурәтләүләренең табигыйлеге, фикерләренең тапкыр юмор белән сипләнеп, әдәпле, олы җанлы тәнкыйть аша әйтелеше — гадәти шагыйрь генә түгел икәнен раслый. Авторы — Мостай Кәрим. Бу исемне ишеткәнем бар иде, ләкин аның шигырен беренче мәртәбә укуым иде әле бу.

Аны башыннан сыйпыйсы, дәвам ит әйдә шулай, синнән чын шагыйрь чыгачак дип хат язасы килде. Ләкин ул хат язылмый калды.

Унбиш еллап вакыт үтеп китте. Бу егетнең дөньяда бармы-юкмы икәнен белми яшәдем.

1955 елда, Себернең бер авылында, «Комсомольская правда» газетасы саннарын караштырып утырганда, Башкортстан турында шигъри тел белән язылган бер мәкаләгә һәм русчага тәрҗемә ителгән шигырьләргә очрадым. Авторы миңа таныш исем — Мостай Кәрим иде. Димәк, ул исән-сау икән дигән фикергә килдем.

Мостайның үзе белән беренче мәртәбә 1956 елның августында Казан вокзалында очраштым. Каршылаучы замандашларым арасында миңа таныш булмаган бер егет бар иде. Ул — Башкортстандагы дусларымның сәламнәрен алып килгән Мостай Кәрим булып чыкты.

Мостай Кәрим безнең заманның күренекле шагыйре, язучысы, драматургы гына түгел, кеше буларак та соклангыч шәхес ул. Өлкән, күркәм, ягымлы гадилек — аның табигый халәтедер, күрәсең. Беренче кат очрашканнан бирле, икәүдән-икәү генә серләшеп, киңәшеп утырулардан тыш, әдәби җыелышларда, съездларда, юбилейларда һәм тантаналы табыннардагы күрешүләрдә байтак сынадым инде аны: ул һәр вакытта, һәр очракта сокландыра һәм гаҗәпләндерә. Каударлану, каушау кебек вак сыйфатлар аңар бөтенләй ят нәрсә. Чәчләренә чал кергәнче үк инде ул өлкән аксакалларда гына очрый торган акыллы, ягымлы, зирәк этиканың бер үзаман егете иде. Нинди дә булса мәсьәлә буенча кузгалган берәр бәхәс киеренкеләнгәч, («минутларның кызганлыгы дәрләр чиккә җиткән мәлдә») тыныч кына, сабыр гына хәлдә ул җитди, акыллы сүз әйтеп куя һәм киеренкелекне нормаль хәлгә юнәлдерә. Мостай тормышта сабыр, тыйнак. Әмма иҗатта, шигырьдә аның эчке рухи темпераменты кайнар.

Миң штабка кергәнем бар
Бойга приказ көткән мәлдә,
Минутларның кызганлыгы
Дәрләр чиккә җиткән мәлдә.

...Эчтә давыл, эчтә ялкын,
Тыштан шундый тынычсың син,
Корып куйган граната син,
Суырып алган кылычсың син.

Әй, гомерне гомер иткән
Минутларның бөек чагы!

**Йөз тапкырга артык янып**
**Кичердем мин сезне тагы...**

(*«Кремльгә кергәндә»*[1].)

Әгәр дә шигъри хисләр, шигъри фикерләр эчке дулкынлануның, мәхәббәт һәм нәфрәтнең, җанның-канның кайнап торган металл сыман югары температурада чагында әйтелгән-язылган икән, аның теле дә, сүзләренең табылышы һәм аларның ни рәвештә тезелеше дә шул югары дәрәҗәдә күтәрелгән халәткә, «минутларның бөек чагына» лаек булып туа.

Бу урында Җәлилне дә искә алмый үтеп булмый. Әгәр дә шагыйрь үлем камерасы тәрәзәсеннән Германия яшьләре мәйданнарына:

**— Арагызда кем бар Цеткин улы! —**
**Тельман егетләре кайсыгыз!!**
**... Капкаларны безнең ачыгыз! —**

дип аваз салган икән, бу очракта инде бу әйтелештәге сүзләрнең, инверсияләрнең кагыйдәләргә буйсындырылмый әйтелүләре дөресме соң, болай ярыймы соң дип бәхәсләшү — чын шигырьнең тышкы ягында «капка кагып» йөрү генә булыр иде. Югары әдәби телнең табышларын, ачышларын чын шагыйрьләр, әдипләр тудыралар аны.

Салкын җан белән генә, «язар» өчен генә язылган, ритм-рифмасы белән генә шигырьгә охшатылган «шигырь»ләр биреп ятуны исә гафу итә алмый аны поэзия.

Мостай Кәримнең эстетик кичерешләре коммунизм төзү чорларының алдынгы сафында баручылар этикасы белән сугарылган. Аның йөрәге аша үткән кичерешләр шәхси лирика гына түгел:

**...Йөрәгемдә — мең ел тоткынлыкны**
**Үтеп чыккан өмет җырлары.**

(*«Россиянмыч»*.)

Зур шагыйрь, узаман шагыйрь йөрәге үзенең Башкортстаны юксылларының ун гасырлык коллыктан Октябрь революциясе мәйданнарына, социаль азатлыкка чыгуларына, күп милләтле җирдәшләренең яңа язмышка ирешүләренә битараф булып кала алмый, билгеле. Дөньяга лирик аваз сала ул:

**Биш гомерең миңа кирәк түгел,**
**Бер язмышым шуңа торырлык.**

Шагыйрь — гомер буе янып яшәүче, тынгысыз фидакарь йөрәк ул:

**«Яшисе бар, сакла үзеңне»,— дисең,**
**Теләкләрең, әйе, хак сымак.**
**Ләкин мин бит бөтен гомерем буе**
**Бәйгеләрдә чапкан ат сымак.**
**Дөнья бездән генә калмаган ул,**
**Бер чак килер үлем — ят кунак.**
**Аусам иде шул чак,**
**бәйгеләрдә**
**Йөрәге ярылып үлгән ат сымак.**

(*«Яшисе бар...»*)

Шигырь — тирәннән дулкынлануның, әйтми калырга мөмкин булмаган хисләр-фикерләрнең сурәтләнеп әйтелеше ул. Дулкынлану, әйтми калу мөмкин булмау халәте — илһамлануга, иҗади кичерешкә әверелә һәм бу хәл хисләр-фикерләрне шигъри телгә, сурәтле, нәфис, соклангыч телгә күчерә. Чын шигырь, җанлы шигырь шулай, тирәнтен дулкынланудан башлана.

Мостай Кәримнең тирәнтен дулкынлануларының, рухи нурлануларының асыл чыганагы, чишмәсе кайдан соң? «Шул туфракта туып-үсү — үзе бер бәхет инде» диген

---

[1] М. Кәрим. Еллар авазы. Шигырьләр һәм поэмалар. Уфа. 1973. Өзекләр агла таба да шушы басмадан китерелә (автор).

хиснең туган җире-иле кайдан соң? Без аны шигырьләре аша, гүя ап-якыннан, ап-ачык күрә алабыз: «Бөтенесе ямьле анда, җанлы анда»:

Ө мөештә үткән яуда
Җиңеп кайткан кылыч тора,
Бер ул гына кыны эчендә
Тыныч тора.

(*«Бөтенесе дә ямьле монда».*)

Бу — аның туган Башкортстаны, бу — аның шигъри чыганагы.

Мостайның сурәтләүләре гади генә булып тоелган хисләргә дә әйтерсең канатлар куя:

Һавалар зәп-зәңгәр монда,
Һавалар шундый биек!
Шул күк астында олатай
Яшәгән башын иеп.
Ә бит башың иелмәсә,
Һавалар шундый биек...

(*«Туфрагым, һавам, суларым».*)

Әйтелеше гап-гади кебек, ә тәэсир итә алуы гаҗәп тирән һәм киң: әгәр дә кеше, әйтик, аның олы атае, түшәме тәп-тәбәнәк өйдә яшәмәгән булса, әгәр дә башны идергән социаль сәбәпләр, михнәтләр булмаса, карасана, һавалар нинди биек, нинди иркен бит!

Һәр чын шагыйрь — тылсымлы шәхес ул. Гади бер таш кисәген алтынга әверелдергән сыман, гадәти сүзләрне шигырьгә, шигъри күренешләргә әверелдереп, укучыга бүләк биргәндәй, аның хисләрен учына китереп сала ул. Менә Мостай су дигән төшенчәне, гүя Җирнең миллиард еллык тарихын уч төбенә куеп күрсәтә:

Сулар тонык, татлы монда,
Сулар тау ярып чыга,
Мәңгегә сүнгән ташларның
Салкынын алып чыга.

(*«Туфрагым, һавам, суларым».*)

Мостай Кәримнең шигъри тел чаралары гаять бай, аның поэтик телен өйрәнүчеләр бик тә мөһим ачышлар һәм табышларга очрарлар.

* * *

Көндез кояшка, ә төннәрен йолдызларга карап юл бара шагыйрь. Ләкин көннәр бозык, йончулы заманнарда кояшны болыт каплап китә, төнге томаннарда йолдызлар да томалана бит. Андый чакта нишләргә? Моны чын шагыйрьләрчә итеп Мостай гына әйтә алды:

Аязда да, йончу көннәрдә дә
Гомер юлы дигән араны
Узган чакта,
Йолдызлардай күреп,
Мин күзләргә карап барамын.
Кешеләрнең шат, өметле, моңсу
Күзләренә карап барамын,—
Юлларымда адашмас өчен,
Җырларымда алдашмас өчен.

(*«Аякларым юлда, күңелем җырда».*)

Мостай Кәрим төрки телләр поэзиясендә генә түгел, Советлар иле поэзиясенең Александр Твардовский, Ярослав Смеляков, Леонид Мартыновлар сафындагы иң күренекле шагыйрьләребезнең берсе ул. Аның иҗаты асылда без яшәгән заманның, безнең чорларның шигъри елъязмасы булып тора.

Без, аның олы һәм яшь замандашлары, Башкортстанда булган чакларыбызда күрдек һәм күрәбез: Башкортстан үзенең сөекле шагыйрен, туган иленең шат, өметле, моңлы-аһәңле авазын башка халыкларга ишеттерә алган Мостаен өзелеп ярата, аның барлыгына чын күңелдән сөенә. Аның туган республикасы йөзендә: «Минеке бу, минем үз улым бу!» дигән елмаю нуры балкый. Шуңа күрә ул аны олылап «Башкортстанның халык шагыйре» дигән зур исем бирде, аның кая гына бәрса да йөрәге туган җиренә турылыклы икәнен белеп бирде:

Җилләр монда ят көйләрне
Уйнаса да төн кылында,
Туган еннәр җитә миңа
Барыбер үз дулкынымда.
Мин аларны чүпләп алам
Меңәр аваз арасыннан,
Бер карашны әерамын
Йөзәр мең күз карашыннан.
Әнкәм теле — иман телем,
Әгәр сине сагынмасам,
Көн дә синә табынмасам,
Телләремнән язар идем.

(*«Сагыну».*)

Мостай Кәрим гомере буе язганнарын анага һәм туган җиргә мактау җыры дип атады. Аның бу җырын туган җире Башкортстан гына түгел, башка халыкларның да ишетүен теләде. Аның җырын ишеттеләр. Аның җыры башка халыклар өчен дә тере тамчы да, сүнмәс чаткы да булганга күрә, үз республикасы олылап биргән Салават премиясеннән тыш, аңа РСФСРның һәм СССРның дәүләт премияләре бирелде.

Без, Татарстан шагыйрьләре һәм әдипләре, Мостай Кәримне хөкүмәтебезнең югары бүләкләре белән котлап, аның һәр вакыт авангардта булачагына ышанып калабыз. Аның шигырь белән әйткән сүзе бар, әйткән сүзеннән беркайчан да чигенми торган егетлеге бар:

Җирдә төтен, җирдә ялкын
Чакларда,
Мылтык алып без тезелдек
Сафларга.
— Рядовой Кәрим, өч адым
Алга чык,
Авангардта барачаксың
Юл ачып.
Шулай диде миңа ул көн
Командир.
Шулай диде партия һәм
Туган җир.
...И партиям, синең тере
Тамчың мин,
Җил-давылда сүнми торган
Чаткың мин.
Йөрәгемдә чакыруың:
«Алга чык!
Бар һәр вакыт авангардта
Юл ачып».

(*«Партиянең рядовое».*)

ХӘСӘН ТУФАН.

Абдулла Әхмәт

# ЮКСЫНУ

## ПЬЕСА ӨЧ КҮРЕНЕШТӘ

КАТНАШАЛАР:

Кәримә —
Рәшидә —
Нәсимә —
Нәфисә — } солдат хатыннары.
Кыз бала.
Нургали — яралы солдат.
Флюра — Рәшидәнең кызы, укытучы.
Ринат — Рәшидәнең улы, бораулаучы ярдәмчесе.
Айрат — оператор егет.
Әхмәтшин — Рәшидәнең ире белән бергә сугышта булган кеше.
Сәрсенбай —
Саша — } яралы кызылармеецлар.
Таня — медсестра.
Хәсән —
Броня —
Вероника — } Литва мәктәбе укучылары.

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Рәшидәләр өе. Гади, ләкин пөхтә итеп җыештырылган бүлмә. Бер як стенада радиорепродуктор. Икенче стенада Садри белән Рәшидәнең бергә төшкән фоторәсеме. Ирләре фронтта булган хатыннар кич утырырга җыелганнар. Кайберсе бияләй, кайберләре оекбаш бәйли. Пәрдә ачылыр алдыннан моңлы гына, сузып кына музыка «Юксыну»[1] көен уйный, аңа хатыннар кушыла. Җырны Нәфисә башлап җибәрә.

Күз карашым нигә уйчанлавды‘,
Син беләсең микән, юк микән?
Син киләсе юлдан күзем алмый,
Сине көтәм, иркәм, кич-иртән.

Пәрдә ачыла. Җыр тагын бер тапкыр кабатлана.

Пауза.

Кәримә. Белсәң иде, ул исән микән, исән булса, безне исенә төшерә микән? Юктыр. Исән булса, бер елга якын хат язмый тора алмас иде!

Нәсимә. Исәндер. Син юкка өметсезләнмә, күрше. Өметсез шайтан, ди.

Рәшидә. Гитлер мәртәтнең башына җитсәләр, әйләнеп тә кайтырлар әле. Исән булсыннар!

---

[1] Сибгат Хәким сүзләре, Шакир Мәҗитов музыкасы.

Нэфисэ. Тиздэн ул гыйфритнең башына житэлэр ди инде.

Кэримэ. Шулай гына була күрсен.

Рэшидэ. Бу арада каты сугышлар булды, дип яза безнеке.

Нэфисэ (көрсенеп). Булыр инде, сугыш булгач...

Нэсимэ. Нэфисэ, Илдарыңнан хат-фэлэн бармы?

Нэфисэ. Медсанбатта ятам дип, бер хат килгэн иде.

Кэримэ. Алай булгач, кайтып житүе дэ бар икэн.

Нэсимэ. Безнеке тупчы иде бит. Туп кебек бер тэгэрэп кайтып керсэ, э?

Рэшидэ. Безнең Садри разведкада бит. Бик хэтэр, ди, анда.

Нэфисэ. Безнең Илдар мэргэн мылтыгы белэн 30 дан артык килмешэкне дөмектергэн анда. Шуның өчен үзенэ «Слава» ордены биргэннэр, ди.

Нэсимэ. Мэргэн мылтыгы? Анысы нинди мылтык тагы?

Рэшидэ. Күзгеле мылтык. Ерактагы дошманны якынайтып, солдатның күз алдына китереп күрсэтэ, ди.

Радиоалгычтан Левитанның мэһабэт тавышы ишетелэ. Барысы да тыңлыйлар, репродукторга таба борылалар.

Левитан. Дала фронты гаскэрлэре, һөжүмне уңышлы җәелдереп, Ворскла елгасын кичтелэр һэм өч көн дэвам иткэн каты сугышлардан соң, бүген, 23 сентябрьдэ, немецларның сул ярдагы Украинада куэтле оборона узелы булган — Украина өлкэ үзэген — **Полтава** шэһэрен алдылар.

Нэфисэ. Эйбэт эшлэгэннэр! Полтава шэһэрен алдык дигэнме?

Рэшидэ. Жир дип килгэннэр иде, җир астыннан урын алганнар, кабахэтлэр!

Кэримэ. Сугышларда корбан булган батырларга дан! Э безнеке нишлэп йөри икэн? Исэн микэн, юк микэн?

Нэсимэ. Без монда жылыда. Атыш та юк. Анда ранен булып, бер йотым суга тилмереп ятучылар да бардыр инде.

Кэримэ. И, эйтмэ дэ инде, күрше. Я, Нэфисэ, башла инде!

Рэшидэ. Минем Нэфисэнеке күк тавышым булса...

Нэфисэ җыр башлый, башкалар кушылалар.

Яратам мин, эйтмим генэ аны,
Син йөрэкне күреп белмисең.
Кошлар кайта безгэ, син һаман юк,
Син һаман юк, никтер килмисең.

Нэфисэ (*Кэримэнең бияләен алып карый*). Эй, матур да итеп бэйлисең инде!

Кэримэ. Минем бияләйне кигэн сугышчының кулы туңарлык булмасын! Йоным да бетэ инде. Военкоматтан барып аласым бар.

Рэшидэ. Мин башта фронтовикларга бэйлим. Югыйсэ, минем Ринатка да оекбаш бик кирэк.

Нэсимэ. Фронттагыларга булсын дибез шул... (*Авызын ачып исни, йокымсырый.*)

Рэшидэ. Безнең Садри үзенең бер хатында, башына капчык кигезеп, бер фашист часовоен алып кайттык, дип язган иде.

Кэримэ. Гитлер дигэн мэлгуньнең башына кайчан капчык кигерерлэр икэн?

Нэсимэ, оекбаш һэм энэлэрен тоткан килеш, йоклап китэ.

Рэшидэ. Карагыз инде бу мескенне! Утырган жиреннэн йоклап киткэн бит.

Нэфисэ. Йокларсың да. Безгэ дэ авырга туры килэ шул. Эле кичэ генэ Сэфэргали утыннан кайтып килэ иде. Зу-ур киез итек сөйрэгэн, көчкэ атлап бара, мескен!

Кәримә *(акрын гына Нәсимәнең җиңеннән тарта)*. Нәсимә күрше, кайтып йокла булмаса. Аргансыңдыр.

Нәсимә *(күзләрен уып)*. Әй, күзләрем эленеп киткән икән. Кичә фермадан бик соң кайттык шул...

Ишектән бер кыз атылып-бәрелеп килеп керә. Ул ашыгып, кычкырып сөйләшә.

Кыз. Кәримә апа, Кәримә апа дим, сөенче, әле генә кайтты.

Кәримә *(урыныннан сикереп тора)*. Кем кайтты, кем?

Кыз. Ни инде, Нургали абый кайтты. Баскыч башында утыра. Мин башта танымый да торам. Яхшылап карасам, Нургали абый икән! Култык таякларын янына сөяп куйган. Үзем күрдем менә. Ул әйтә: «Безнең каралтылар кая китте?» — ди. Ә мин әйтәм: «Фашистлар яндырдылар»,— дим. Шулай дидем.

Нәсимә. Синнән булыр.

Барысы да китәргә җыеналар.

Кәримә. И җаныкаем, көтелмәгәндә генә нинди зур шатлык! Өем дә бикле ие, кайтыйм, кайтыйм. *(Кызны кочаклый, кат-кат үбә.)* Сөенчегәме, сөенчеме? *(Муенсасын тотып карый, бармагындагы йөзеген кармалый. Шуннан тиз генә муенсасын салып, кызга суза.)* Менә сиңа, туем бүләге ие. *(Кыз алырга да, алмаска да белми. Кәримә атылып-бәрелеп чыгып барганда, Нургалигә очрый. Нургали култык таякларына таянып, чак кына атлап килеп керә. Сакал-мыек баскан,ябыккан. Кәримә бик аз гына карап тора да шатлыгыннан кычкырып җибәрә).* Бәй, Нургали бит бу!

Нургали. Мин бу, Кәримә җаныем!

Кәримә Нургалигә ташлана, кочаклашалар. Нургалинең култык таяклары идәнгә төшеп китә. Аларны шундук алып бирәләр. Барысы да Нургалине әйләндереп алалар, утырталар.

Кәримә. Ходаем, сине дә күрәселәрем бар икән!

Нургали. Исәнмесез, күршеләр! *(Каранып, елмаеп.)* Фронттагыларга бияләй бәйлисезме?

Рәшидә. Без исәннәр әле, Нургали. Үзеңнең хәлләр ничек?

Нургали *(таякларына күрсәтеп)*. Менә, исәнлек шул инде безнең.

Нәфисә. Ярый инде үзең исән-сау кайткач.

Рәшидә. Нургали, син бит безнең Садри белән бергә киткән идең.

Нургали. Әйе, бергә киткән идек...

Кәримә. Я, ярый, ярый, иртәгә сөйләшербез. Бүген кайтыйк, карткаем!

Нәсимә. Әйе, бүген үзләре сөйләшеп туйсыннар әле.

Кәримә Нургалине алып чыга башлый.

Нургали. Ярый, күршеләр, без кайтыйк әле, иртәгә сөйләшербез...

Кәримә белән Нургали чыгып китәләр. Хатын-кызлар карап калалар.

Нәсимә. Менә син, ә? Юньләп сөйләшергә дә ирек бирмәде.

Нәфисә. Иа бәхетле дә инде бу Кәримә! Әле генә, бер ел буе хат килгәне юк, дип кайгырып утыра иде бит.

Чыгып китәргә торганда, радиоалгычтан мәһабәт тавыш ишетелә. Левитан сөйли башлый. Барысы да радиоалгычка таба борылалар.

Левитан. Верховный башкомандующий приказы...

Ут сүнә.

Хәрби госпиталь палатасы. Өч-дүрт койка. Анда яралы солдатлар ята. Сашаның башы бәйләнгән, күзләрге генә күренеп тора. Сәрсенбайның сул кулы бәйләнгән. Әхмәтшинның аягы яралы. Култык таяклары койкасына сөяләп куелган. Тәрәзә төпләрендә гөлләр. Тумбочка өсләрендә «телләрен» салындырып дару шешәләре һәм китаплар тора. Палатага язгы кояш нурлары төшкән. Пәрдә ачылганда Әхмәтшин тәрәзәгә карап ята. Саша китап укый. Сәрсенбай түшәмгә карап уйлап ята.

Әхмәтшин *(үз-үзенә сөйләнә)*. Яз! Гөрләвекләр ага. Их, хәзер өйдә булса иден! Булса иден дә бер читтән генә карап торса иден. Карчык ни эшләп йөри икән? Ул инде, мескенкәем, хәзер балаларга ашарга әзерләп йөри торгандыр. Аш дип инде. *(Тирән сулап куя.)* Үзе ябыккандыр. *(Тумбочкадан бер рәсем ала.)* Я, исәнлекме, карчыгым! Бер үзенә дүрт-биш вак-төяк бит. Алай да акыллылар шул алар. Зурысы бик булыша дип язган иде анасы. Ә кечкенәсе үзе ясаган көймәсен агызып уйный торгандыр. Их, җанкисәкләрем! *(Көйләп куя.)*

...Күз керфекләрем талганчы
карыйсым калган икән...

Сәрсенбай *(сөйләнә)*. Сугыс бетә дип сөйлиләр. Беткәч, кайту менән мәктәпкә балаларым җанына барам. Минем кырык балам бар иде, гой. Аннары өйләнеп җибәрәм. Ой, айналаем! *(Күзләрен йомып куя.)*

Әхмәтшин. Син әле күзле-башлы түгелмени?

Сәрсенбай. Басым да жок, күзем дә жок. Колагын тесләгән аялым бар иде барын!

Әхмәтшин. Булгач соң.

Сәрсенбай *(тирән сулап)*. Баска адәмгә кияүгә чыгып куймаган булса. Хат алганым жок.

Әхмәтшин. Сәрсенбай жолдас, Саша энекәш, сезгә күрсәтәм дип йөргән бер нәрсәм бар минем.

Сәрсенбай. Нимәнә бар?

Саша. Мин тыңлыйм. *(Китабын куя.)*

Әхмәтшин. Сезгә, дуслар, хәзер бер хикмәт күрсәтәм. *(Тумбочкадан ала башлый.)*

Сәрсенбай. Уйбай, нимәнә, күрсәтсәч.

Әхмәтшин. Сезгә мин бер танк күрсәтәм, та-нк.

Саша. О, танк!

Күрше бүлмәдән ике кулы, бер күзе бәйләнгән олы яшьтәге яралы солдат чыга да ишеккә сөяләп тыңлый башлый.

Әхмәтшин. Менә ул! *(Бәләкәй танкны өскә күтәреп күрсәтә.)* Белсәгез иде бу танкны, ул бик күп фашист мәлгуньнәрне таптагандыр, изгән-сыткандыр. Кабыргасына нәрсә дип язган бит әле.

Сәрсенбай. Мәган бирсәч, үзем укыйм. *(Сәрсенбай ала, укый.)* Немец илбасарларына үлем! Мынау, барып торган танк, гой!

Әхмәтшин. Олы малаем Рифгат ясаган аны. Эшләмәгән эше юк аның. Оста куллы малай ул! Нәрсәгә генә тотынса да, кулы ябышып тора. Үземә охшаган!

Сәрсенбай. Алма агашыннан жырак төсмәйде, диде, гой, халык.

Саша Сәрсенбайдан танкны ала, башын селкеп куя.

Саша. Молодец!

Әхмәтшин. Менә монысын са-мо-лет диләр. Аны кечесе эшләп җибәргән. «Әти, фашистларны шушы самолет белән куып җит, барысын да атып ек», дип тә язып куйганнар үзләре. *(Самолетны очырган*

кебек итә.) Врр... вррр кучтәнәчләрне яудыра инде бу! Дөп-дөп. *(Самолетны Сәрсенбайга бирә.)*

Сәрсенбай. Уйбай, «ЯК» дип язып та куйган, гой. Канатларында жондыз жанып торат! *(Самолетны Сашага бирә.)*

Әхмәтшин. Мең бәла белән саклап калдым бит мин аларны. Хәзер инде алып кайтып, мәктәп музеена бирәм.

Саша. Мәктәп музеена?

Әхмәтшин. Андый музей хәзергә юк әле. Мин кайткач, оештырабыз аны. Ватан сугышы музее. Бу сугышны берәүнең дә онытырга хакы юк. Менә, минем бәләкәйләрнең хатлары да бар.

Саша. Хат?

Сәрсенбай. Уйбай, укысач, гвардия өлкән сержант.

Әхмәтшин *(укый)*. «Сөекле әтием! Мин сиңа бүләк итеп танк жибәрәм. Ул советский танк, яшелгә буялган. Әти, безгә синең яныңнан бер сержант килде. Энем сиңа самолет эшләде. Ул кызылга буялган. Әти, кучтәнәчләреңне алдык. Рәхмәт, бик тәмле булды. Шикәрне әни бүлеп бирде. Миңа дүрт ярым шакмак тиде».

Сәрсенбай. Уйбай, кант жибәргән иденме?

Әхмәтшин. Әйе, бер көнлек шикәр иде ул. Безнең якка кайтучы кеше булгач, блиндаждагы иптәшләр чәйне бер көн шикәрсез эчәргә булдылар. Ә шикәрләрен минем балаларга кучтәнәч итеп жибәрделәр.

Саша. Һәркемнән утыз бишәр грамм... солдат шикәре! Шәп кучтәнәч!

Әхмәтшин *(укый)*. «Синнән килгән кучтәнәчтә бик кызыклы боткалар бар иде. Кәгазен жыеп куйдым, кайткач карарсың әле. Энемнең самолеты бомба ыргыта торган. Әти, сиңа әни пәрәмәч жибәрде. Минем танк «КВ» дигәне. Язуын да үзем яздым. Пәрәмәчләрне әни безгә дә бирде. Энемнең самолеты пикировать итә торган. Әти, мин өченче класска күчәм инде. Әти, безнең Әлфия хәзер рәсемнәр ясый белә. Сиңа да жибәрде. Әти, безнең песи алты бәби тапты. Барысы да сукырлар, бер нәрсә дә күрмиләр. Әти, безгә хат яз. Әти, без хәзер тагын бер самолет ясыйбыз. Анысы дүрт моторлы була. Әти, миңа карандаш жибәр. Әти, бик аз гына кәгазь дә жибәрсәң, әйбәт булыр иде.

*Улың Рифгат».*

Барысы да жанланып куялар. Ишек янында сөялеп торган сугышчы, бәйләгән кулы белән күзен сөртә-сөртә, бүлмәсенә кереп китә.

Сәрсенбай. Айналаен, кәгазь жибәр, дигән, гой.

Әхмәтшин. Гитлер башкисәрләре безнең балаларыбызның балалыкларын алдылар. Шуның өчен алмый калмаслар.

Сәрсенбай. Уйбай, үчне алып жатамыз, гой, инде.

Кулына градусниклар, дарулар тоткан медсестра керә.

Таня. Я, иптәшләр, хәлләрегез ничек? *(Градусникларны авыруларга бирә.)*

Саша. Яңадан фронтка китәрлек, Танечка.

Сәрсенбай. Минем кулым автоматны тотарлык, гой.

Таня. Ашыкмагыз, иптәшләр! *(Әхмәтшинга кашыкка салып дару бирә.)* Яле, гвардеец, даруны эчеп жибәр.

Әхмәтшин. Рәхмәт, Танечка. Сезнең кебек матур кызлар кулыннан эчкәч, шифасы тими калмас.

Таня *(градусникларны ала, карый, язып куя. Әхмәтшинга карап.)* Сезнең 38° гә төшкән. Операцияне әйбәт уздырдыгыз. Ярый, аягым жиңел булсын.

Чыгып китә.

Саша. Рәхмәт, Танечка, рәхмәт.

Әхмәтшин. Исән-сау әйләнеп кайтырга насыйп итсен. Тиздән Гитлерга капут була икән дип ишеттем.

Сәрсенбай. Шулай булсын.

Литва пионерлары белән Таня керә.

Хәсән. Исәнмесез, лабос ритос, солдат абыйлар!

Таня. Иптәшләр, менә Шәүләй мәктәбе укучылары сезнең хәлегезне белергә килгәннәр.

Сәрсенбай. Хуш киләсез, балалар!

Саша. Әйдәгез, узыгыз.

Таня бүлмәнең ишеген ачып куя. Аннан баягы солдат күренә.

Әхмәтшин. Мин, балалар, бераз сезнеңчә — литвача сөйләшә дә беләм. Атью, атью.

Броня *(бик матур чәчәкләр букеты һәм оекбашларны Әхмәтшинга бирә)*. Мәгез, абый, сезгә бу!

Әхмәтшин. Атью, рәхмәт, мин башка сүзләрне не супранто, белмим. Чәчәкләр! Бусы — оекбашлары. *(Берсен тотып.)* Ә монысы... Минем бер генә аягым...

Башка балалар Сәрсенбайга, Сашага, сүзсез солдатка чәчәк букетлары, оекбашлар, яулыклар, кисетлар бирәләр.

Сәрсенбай. Рәкъмәт. *(Кисетны карый.)* Уйбай, челем салырга нәгыз үзе, гой.

Саша. Спасибо. *(Яулыктагы язуны укып.)* Оho, «Гитлер — капут», дип язылган икән.

Әхмәтшин янына Хәсән килә.

Хәсән *(тартынып кына)*. Абый, сезнең аягыгыз яралымы? Бик авыртамы?

Әхмәтшин. Әйе, берсе авырткалый, ә бер аякны калдырдым, бик үк зарарлы түгел, улым. Сез мәктәп балаларымы?

Хәсән. Без, абый, Шәүләй мәктәбеннән. Минем әнием генә бар. Разия исемле.

Сәрсенбай. Әкаң кайда, карагым?

Хәсән *(күңелсезләнеп)*. Немецлар алып китте. Өебезне яндырдылар. Әтиемнең кайда икәнен дә белмибез. Фамилиябез Юныс Полтаржитский.

Әхмәтшин. Сез Литва татарларымы?

Хәсән. Юк, без, абый, мөселманнар. Бездә иске китаплар бар. Тик мин укый белмим аларны.

Әхмәтшин. Син безнеңчә, мөселманча, сөйләшә беләсең ич.

Хәсән. Аз гына беләм. Әни күп белә.

Әхмәтшин. Без, Хәсән, тиздән фашистларның оясына керәбез. Әтиеңне дә коткарырбыз.

Хәсән *(башын иеп куя)*. Атью, атью, рәхмәт.

Таня. Иптәшләр, хәзер Шәүләй мәктәбе балалары кечкенә генә концерт бирәчәкләр.

Яралы солдатлар кул чабалар.

Хәзер алтынчы класс укучысы Хәсән Полтаржитский шигырь сөйли.

Хәсән, кулларын бутый-бутый, ашыкмыйча гына Г. Тукайның «Туган тел» шигырен сөйли. Барысы да кул чабалар.

**Әхмәтшин.** Молодец, егет! Тукай шигырен каян беләсен син, ә?
**Хәсән.** Әнием өйрәтте. Бездә Тукайның китабы бар.
**Таня.** Пионерка Броня скрипкада уйный. Көйне үзе чыгарган. Сугышта үлгән әтисе турында.

Броня уйный. Көчле кул чабулар.

**Саша.** Инде бу кызның чираты.
**Әхмәтшин.** Исемең ничек синең?
**Вероника.** Вероника. Мин ни эшлим икән соң? Мин не супранто, белмим бит.
**Таня.** Я инде, солдат абыйларың янына килгәч...
**Хәсән.** Бии беләсең ич, Вероника.

Броня скрипкада бию көе уйнап куя. Вероника бик матур итеп бии. Барысы да кул чабалар.

**Әхмәтшин.** Танечка, сез гармун тапмакчы идегез. Бәләкәй куnaклар безнең һөнәрне дә күреп китсеннәр. Һөнәрле үлмәс, һөнәрсез көн күрмәс, ди торган иде безнең әти мәрхүм.

**Таня** күрше бүлмәдән гармун алып керә, Әхмәтшинга бирә. Ул гармунны бернчә тапкыр кычкыртып куя.

**Әхмәтшин.** Күптән кулга алганым юк иде. *(«Землянкада»*[1] *көен уйнап җибәрә. Бер тапкыр уйнагач, барлык яралылар, балалар да кушылалар.)*

Кысан мичтә дәртле ялкын дөрли,
Яшькә охшый сагызы утынның.
Землянкада миңа гармун жырлый,
Яктылыгын күзең утының.

Жырла, гармун, бәхет чакыр янга
Һәм үч итеп жырла буранга.
Мин өшемәм салкын землянкада —
Мәхәббәтең кайнар булганга.

**Сәрсенбай.** Уйбай, жахсы уйныйсың, гой! Жанга рәхәт булып китте...
**Таня.** Ярый, рәхмәт, иптәшләр. Абыйларыгыз да арганнардыр.
**Вероника.** Рәхмәт, абыйлар. Без сезгә отряд советыннан билгеләндек. Килербез әле.
**Броня.** Судево, судево, хушыгыз! *(Башын иеп куя.)*

**Хәсән** тартынып кына Әхмәтшин янына килә.

**Хәсән.** Абый, хушыгыз, атью, атью. Тизрәк терелегез!
**Әхмәтшин.** Рәхмәт сезгә, пионер иптәшләр!
**Сәрсенбай** *(кулын болгап)*. Килеңдәр, балалар, килеңдәр.

Балалар һәм Таня чыгып китәләр. Ишеккә сөялгән сугышчы, бәйләнгән кулы белән сыңар күзен сөртә-сөртә, бүлмәгә кереп китә. Әхмәтшин гармунга башын куеп, башка яралылар кул болгап, балаларны озатып калалар. Пауза. Берәздан ишек ачыла. Аннан носилкага салынган яралыны күтәреп, санитарлар керә. Яралы солдатны икенче бүлмәгә алып кереп китәләр. Солдатлар аларны сүзсез генә карап калалар. Әхмәтшин акрын гына урыныннан тора. Култык таякларын ала да яралыны алып кергән бүлмәгә таба бара башлый, туктый.

**Әхмәтшин.** Кемне алып килделәр? Безнең частьтан түгелме икән?
**Саша.** Да, авыр яралы күренә.
**Сәрсенбай.** Уйбай, кодай сакласын!

---

[1] А. Сурков шигыре. З. Нури тәрҗемәсе.

Таня керә. Яраланы алып керүгән бүлмәгә үтә башлый.

Әхмәтшин. Танечка, белешегез әле, зинһар, кайсы частьтан икән ул?

Таня. Неман елгасы ярыннан, ди. Аңын югалткан. Каты яралы. Самолет белән Москвага озатабыз үзен.

Әхмәтшин. Танечка, фамилиясен белмәдегезме?

Таня. Белмәдем шул. *(Кереп китә.)*

Әхмәтшин. Неман елгасыннан? Елганы кичкәндә яраланган инде! Ай-һай, каты бара иде шул анда сугышлар!

Бик аз гына тора да, ашыгып, яралыны алып кергән бүлмәгә кереп китә.

Пәрдә

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Беренче пәрдәдәге бүлмә. Авылча җыйнак, пөхтә итеп җыештырылган. Бер якта радиоалгыч, тегү машинасы. Түрдә Садри белән Рәшидәнең бергә төшкән зур фоторәсеме. Алар яшьләр, матурлар. Стенада борынгы сәгать. Китап шкафы. Бер якта Садри Әхмеровка багышланган фотокүргәзмә. Өстәл өстендә, чәйниген кырын салып, ак самавар утыра. Өстәлгә шакмаклы кызыл ашъяулык җәелгән. Аның өстенә ак май, сап-сары бал, шикәр, май күмәчләре, пәрәмәчләр куелган.

Пауза.

Рәшидә өстәлгә башын куеп йокымсырап утыра. Бераздан башын күтәрә, каранә, чәчләрен төзәтә.

Рәшидә. Һаман да кайтмаган. Нишләп кайтмый икән инде. Бик озак көттем бит. *(Күзләрен уып.)* Ай, һаман да йокымнан, татлы төшләремнән аерыла алмыйм икән. Нишләп ул алай? Ни өчен мин аны һаман оныта алмыйм икән? Мена аның үлеме турында кайгы хәбәре килгәнгә дә әллә ни гомер үтте инде! Ә мин аны һаман да исемнән чыгара алмыйм. Исән булса, бүген аңа илле яшь тулган булыр иде. *(Чәйникне алып, самаварны өрә, ул җанланып китә. Торып күргәзмә янына бара, карый.)* Әй, гомер дигәнең су кебек агып кына тора. Чәчләремә дә кырау төшә башлады! Мена безнең яңа гына танышкан чаклар. Рәшидә туташ белән Садри әфәнде! Ә хәзер... балаларымның балалары бар! Рәшидә әби! Дәү әни диләр миңа хәзер, дәү әни!.. *(Яңадан өстәл янына килеп утыра. Башын ике кулы өстенә куя, күзләрен йома. Пауза.)*

Иртәгә иртүк торасым, сөтбикәләрем янына барасым бар бит әле минем... *(Йокымсырый.)*

Пауза.

Акрын гына тәрәзә чиртәләр. Бераздан тагын чиртәләр. Рәшидә башын күтәрә, карана, төзәтенә.

Төшемдәме, өнемдәме ишетелде! Ул да шулай, тәрәзәне акрын гына чиртә торган иде. Бу да Садриның чиртүе! *(Тәрәзә янына бара.)* Кем бар анда? Әллә инде... ул кайтты? Кем бар анда?

Пауза.

Әхмәтшин. Мин бу. Әхмәтшин. Ачыгыз әле.

Рәшидә. Хәзер, хәзер... Әхмәт-шин!..

Чыга. Бераздан Әхмәтшин белән керәләр. Әхмәтшин толып кигән. Бер кулына кечкенә чемодан тоткан, таякка таянган.

Әхмәтшин. Мин дөрес керәмдер бит? Бу Садри Әхмеровлар өеме?

Рәшидә. Әйе, әйдәгез, түрдән узыгыз. Сез аны каян... беләсез? Әллә?.. Я, чишенегез әле.

Әхмәтшин чишенә. Толыбын, бүреген сала. Рәшидә аларны элеп куя.

Әхмәтшин. Садри — минем фронт иптәшем. Без аның белән сугыш юлларын бергә үттек.

Рәшидә (*күзен сөртеп*). Бергә!..

Әхмәтшин. Әйе, бергә. (*Күргәзмәгә якын бара.*) Садри Әхмеров турында күргәзмә. (*Халыкка карап.*) Димәк, ул исән!

Рәшидә (*күргәзмәгә күрсәтеп*). Менә, Садри Әхмеровка бүген илле яшь тулган булыр иде.

Әхмәтшин. Тулган булыр иде? Ә ул?..

Рәшидә. Ә ул... әйләнеп кайтмады!.. (*Яшьләрен сөртеп.*) Аның туган көнен без үзе булмаса да үткәрергә булдык. Әйдәгез, утырыгыз әле.

Әхмәтшин (*утыра*). Рәхмәт. Алай. Үзе булмаса да... (*Халыкка карап.*) Димәк, минем Әхмеровны актык күрүем медсанбатта булган икән! Ә бу күргәзмә?

Рәшидә. Улларым, кызларым оештырганнар. Үзем дә эштән кайткач кына күрдем әле.

Әхмәтшин (*күргәзмәне карый*). Монсы әйбәт булган. Миндә дә бер рәсем бар. Бер уңышлы операциядән соң, фронт газетасыннан килеп төшергәннәр иде. (*Чемоданыннан газета алып килә.*) Менә, «Алга, дошман өстенә» дигән газета. Беренче Балтик буе фронты газетасы.

Рәшидә (*газетаны ала*). Ай, безнең Садриебыз турында язганнармы?!

Әхмәтшин. Таныгансыздыр. Бу уртадагысы — безнең разведка командиры Садри Әхмеров.

Рәшидә (*яшенә тыгыла*). Кара, кара, минем командирымны! Мыек үстереп җибәргән. Монысы сез икән.

Әхмәтшин. Бу газетаны да күргәзмәгә куйыйк. (*Газетаны күргәзмәгә куя.*) Газета да Әхмеров турында сөйли бит!

Рәшидә. Рәхмәт инде. Ә үзегезгә?

Әхмәтшин. Үземдә бар ул газета. Балаларыгыз эштәме?

Рәшидә. Улым эштә иде, хәзер кайтыр. Ул буровойда эшли. Флюра дигән кызым шушы авыл мәктәбендә укыта. Әтисе мәктәп директоры иде, хәзер кызым укытучы. Шуларны көтеп утыра идем. Берсе Әлмәттә эшли. Сез тәрәзәне нәкъ Садри кебек итеп кактыгыз. Мин әллә нишләп... киттем.

Әхмәтшин. Мин аны-моны уйлап тормадым шул.

Рәшидә. Садри мәктәптән соң гына кайта торган иде. Акрын гына... шыгырдап кына капка ачыла, шуннан соң... акрын гына тәрәзә чиртә торган иде. Ә мин... аның аяк атлауларыннан таный идем. Шушылай самаварым җырлап утыра, ә мин, көтеп-көтеп, йокыга тала торган идем. Сез килгәндә дә тәрәзә чиртүгә уянып киттем. Бик арылган иде шул. Әйдәгез, өстәл янына рәхим итегез әле.

Өстәл янына килеп утыралар.

Карагыз әле, Садри белән соңгы тапкыр очрашуыгыз кайчанрак булды соң?

Әхмәтшин. Яз көне иде. Мин Литвада, Шәүләй дигән шәһәрдә яраланып санбатта ята идем. Шунда калдырдым мин бер аякны! Шулай бервакыт санитарлар бер авыр яралыны китерделәр. Неман елга-

сы буеннан дигәч, минем йөрәгем жуу итеп китте. Ни өчендер, Әхмеров исемә килеп төште. Аның белән Неман елгасы буендагы сугышта бергә булган идек.

Р ә ш и д ә. Кеше күңеле сизә инде ул. *(Яшьләрен сөртеп куя.)*

Ә х м ә т ш и н. Мин яралыны алып кергән бүлмәгә шундук кергән идем дә... ләкин...

Р ә ш и д ә. Нәрсә, ләкин?..

Ә х м ә т ш и н. Ләкин аның күзләре йомык, аңын югалткан иде. Мине бик тиз чыгардылар. Мин аның белән бергә сугыштым, мин аның якташы, мин аның якын иптәше, дип тә карадым... Шуннан соң мин күрә алмадым дустымны. Аны самолет белән Мәскәүгә жибәргәннәр. Катлаулы операция кирәк булган.

Р ә ш и д ә. Безгә дә шул... үлем хәбәре... Мәскәүдән килде... *(Күз яшьләрен сөртә.)*

Ишектән Р и н а т кайтып керә. Ул буровой эшчеләре киеменнән

Р и н а т. Исәнмесез, абый!

Ә х м ә т ш и н. Бик исән әле.

Ринат кул биреп күрешә.

Р ә ш и д ә. Менә, Садриның олы малае Ринат була инде бу. Бурильщик ярдәмчесе.

Ә х м ә т ш и н. Оһо, нефтьче! *(Тора, Ринат янына бара.)* Кара, кара, атасы хәтле ике бар бит! Нәкъ Садри инде, койган да куйган.

Р ә ш и д ә. Хәзерге яшьләр шул.

Р и н а т. Мин, абый, киемнәремне алмаштырып чыгыйм әле. *(Икенче бүлмәгә чыгып китә.)*

Ә х м ә т ш и н. Бу хәтле атасына охшар икән! Акыллы зәңгәр күзләр!

Р ә ш и д ә. Алма агачыннан ерак төшми инде анысы. Ягез, ашап эчегез әле.

Ә х м ә т ш и н. Карагыз әле. Монда бер нәрсә житми бит әле.

Р ә ш и д ә. Ә! Нәрсә житми? *(Карана.)*

Ә х м ә т ш и н. Солдатча әйтсәк, мин Садри белән бер котелоктан ашап йөргән кеше. Шулай булгач, гвардия лейтенанты Садри Әхмеровның да монда урыны булырга тиеш. *(Тора да янындагы буш урындыкны рәтләп куя.)* Менә биредә лейтенант Әхмеров утыра дип уйлыйк. Безнең Уралда шундый бер йола бар. Мәрхүмне искә алганда, аңа да урын калдыралар, аңа да ашарга, эчәргә куялар.

Р ә ш и д ә. Ул утыра, ул... Һәйбәт гадәт!

Р и н а т бәйрәмчә киенеп чыга.

Ә х м ә т ш и н. Менә, егет тә чыкты! Исемең ничек әле синең?

Р и н а т. Ринат.

Ә х м ә т ш и н. Менә шулай, Ринат энем. Әтиеңә дигән урынга чәй ясап куй әле. Куе итеп яса. Хәтерегездәме, Садри мәрхүм чәйне бик куе итеп эчә торган иде.

Р и н а т. Анысына хәтле беләсезмени?

Ә х м ә т ш и н. Без кайвакыт өйдәге хәлләр турында да сөйләшә торган идек.

Р ә ш и д ә *(чәй ясый, чынаякны Садри утырырга тиешле булган урынга куя. Янына ике-өч пәрәмәч тә куя).* Мескенем минем, пәрәмәчләрне бик ярата торган иде.

Ә х м ә т ш и н. Әйе, әйе, без окопта сезнең пәрәмәчләрне бик тәмләп ашадык.

Р ә ш и д ә. Сез?

Ә х м ә т ш и н. Әйе. Сез жибәргән пәрәмәчләрне.

Р ә ш и д ә. И минем Садрием, Садрием!

Р и н а т икенче бүлмәдән бер шешә кызыл аракы алып чыга. Рюмкаларга сала. Башлап әтисенә дигән урынга куя.

Ә х м ә т ш и н *(тора, рюмкасын күтәрә)*. Ерак сугыш елларында ятып калган иптәшләребезне искә алыйк.

Эчәләр.

Р и н а т. Абый...

Ә х м ә т ш и н. Абый? Юк, бабай инде мин.

Р и н а т. Абый, сезнең исемегез ничек әле? Анпары званиегезне дә беләсе килә. Балаларыгыз да бардыр инде.

Ә х м ә т ш и н. О, балаларым ярты дюжина. Ә званием, Садри дус әйтмешли, өлкәнейши сержант идем. Гатаулла Әхмәтшин булам мин.

Р и н а т. Сез, Гатаулла абый, әти белән булган берәр сугыш вакыйгасы турында сөйләсәгез, ә?

Ә х м ә т ш и н. Була ул. Мәрхүм Садри Әхмеров шушы авыл мәктәбендә директор булган бит. Хәзерге буын без үткән авыр елларны, илебезне фашизм афәтеннән саклап калган батырлар юлын белергә, онытмаска тиеш. Әйе, безгә бик күп корбан бирергә туры килде. Ржев дигән шәһәр тирәсендә зур сугышлар булды. Фашистлар анда жир астына миномет заводы салганнар. Ржев тирәсе сазлык, машиналар йөри алмый. Безгә патроннарны җилкәбездә ташырга туры килде анда.

Рәшидә шкаф тартмасыннан Әхмеровның орденнарын, медальләрен алып килә. Әхмәтшинга бирә.

Р ә ш и д ә. Үзе үлгәч, мәрхүмнең орденнары кайтты, үзе генә кайта алмады.

Р и н а т. Сәгате дә *(кулындагы сәгатен күрсәтә)*. Тарагына хәтле кайтты инде! Әтинең төсе итеп тотам мин аларны.

Ә х м ә т ш и н. О, моңысы «Ватан сугышы» ордены! Аны бер катлаулы операция өчен биргәннәр иде. Шул турыда сөйлимме әллә?

Р ә ш и д ә. Армаган булсагыз, сөйләгез әле, зинһар!

Р и н а т. Без төне буе тыңларга да риза. *(Блокнотын ала.)*

Ә х м ә т ш и н. Алай булгач, мин сезгә дошман «телен» — фашист алып кайту турында сөйлим әле.

Р ә ш и д ә. Безнең әтиебез дә анда катнаштымы?

Ә х м ә т ш и н. Әйе, Садри Әхмеров безнең командир иде. Нинди генә командир иде әле! Бер әйттеме — бетте. Яхшы ата кебек.

Р и н а т. Шулай, без дошманның «телен» тотарга киттек, ди.

Ә х м ә т ш и н. Сез түгел, без киттек, ди. *(Көлеп куя. Кулларын бутый-бутый, мимика белән сөйли.)* Ржев тирәсендә булды бу. Без олы юл буенда ятабыз. Тынлык. Ара-тирә кәкүк кычкырып куя. Бер куян, сикерә-сикерә, юлны аркылы узып китте. Без тын да алмыйча ятабыз. Ә фашист мәлгунь күренми дә күренми. Бервакыт ерактан машина тавышы ишетелде. Без сагайдык. Ул арада бер танкетканың килгәне күренде. Якынлаша бу. Якынлашкан саен, андагы кешеләр дә ачыграк күренә башлады. Танкетка өстендә ап-ак калфак кигән, ап-ак халатлы чүмәләдәй бер фриц кукраеп утыра. Үзе кып-кызыл, ярсаң ике фашист чыгарлык. Повар икән бу. Җилкәсендә моның автоматы да бар. Мәлгуньнең күзләре мелт-мелт итә. Йокымсырап утыра икән фашист! Шул вакыт Садри минем җиңемнән тартты. Бу йокысы килгән фрицны йоклатырсың инде дигән мәгънәне аңлатып, ишарә ясады. Мин танкетка өстендә утырган поварны сөйрәп төшерергә әзерләнеп торам. Танкетка килеп җитте. Без аны аз гына алга җибәрдек. Аннан кинәт кенә бердәм ыргылдык.

Р и н а т. Шунда автоматы белән атып җибәрсә...

Ә х м ә т ш и н. Андый чакта разведчик халкы яшен тизлегендә хәрәкәт итә. Мин теге мәлгуньне тартып төшердем. Төшердем дә автомат

түтәсе белән бик яхшылап берне кундырдым. Бик каты сугарга да ярамый.

Ринат. Нигә ярамый? Мин булсам...

Әхмәтшин. Каты суккач, җаны җәһәннәмгә китә ич аның. Ә безгә бит «тел» кирәк. Фриц теле! Поварның теле күп нәрсә сөйли торган тел бит ул! Аннары мин Садриның хәлен белергә дип барсам... ни күрим. Теге Сергеев дигән егетнең белгеннән кан ага. Каһәр суккан танкист аңа атып өлгергән булган. Танкистны шундук теге дөньяга... Аның кирәге юк иде безгә. Шуннан соң танкетканы ачып җибәрсәк... борынга ис килеп бәрелде — фу!..

Ринат. Нәрсә, әллә газмы?

Әхмәтшин *(елмаеп)*. Юк, зур-зур термослар. Борщ алып баралар икән болар. Алгы кырыйга, үз фрицларына. Без фашист солдатларыңа дигән борщны түгәбез дә...

Ринат. Их, әрәм иткәнсез икән!

Әхмәтшин. Шуннан поварым исемә төшеп, аның янына барсам, ни күрим. Ул мәлгунь аңына килеп, торган да урманга тая башлаган. Бу ачык авызлыгым өчен Әхмеровтан эләкте миңа. Мин тегене куып җиттем дә тагын да бер *(йодрыгын күрсәтә)* порция бирдем, аннары капчыкка салдым. Түгелмәсен-чәчелмәсен дип, капчыкның авызын һәйбәтләп бәйләп тә куйдым.

Ринат. Әтиләр, әтиләр нишлиләр иде?

Әхмәтшин. Алар танкистның коралын, документларын алганнар. Шуннан соң — тиз генә кайту юлына, урманга.

Ринат. Аш пешерүчене күтәрепме, сәйрәпме?

Әхмәтшин. Садридан, әфисәрдән, күтәртеп булмый ич инде. Шуннан соң ни эшләп күтәреп йөрим әле мин моны дип, капчыктан селкетеп төшердем дә: «Форвартс марш, үз аягың белән тәпи-тәпи атла» дидем *(бармаклары белән йөргәнне күрсәтә)*. Авызына юлдан табылган бер иске чүпрәк тутырдым да, әйдәме-әйдә... Фриц мәлгунь юл буенча иске чүпрәкне рәхәтләнеп суырып кайтты. *(Көләләр.)*

Ринат. Бик үк рәхәт булмагандыр әле.

Әхмәтшин. Алып кайтып штабка тапшырдык үзен.

Ринат. Сөйләттеләрме соң үзен?

Әхмәтшин. Штабта андыйларны сайрата торган кешеләр бар бездә. Барысын да әйткән.

Рәшидә. Әйткән икән тагы.

Әхмәтшин. Сезгә килеп чыгуның да сәбәбе шул иде: кайсыбыз исән калса, шул — семьяның хәлен белергә килә. Әхмеров белән шул турыда сүз куешкан идек. Ә мин... сөекле командирымны, бәлки, күрермен дә дип...

Рәшидә. Ярый инде, сүзегезне үтәгәнсез. Рәхмәт сезгә.

Ринат. Гатаулла абый, эти белән булган берәр операция турында мәктәп балаларына да сөйләсәгез, әйбәт булыр иде. Булачак солдатлар үсә бит анда.

Әхмәтшин. Була ул. Разведчикларның батырлыгы санап бетергесез ул. Аннары башка бер уй килде: сезнең мәктәпкә Әхмеров мәктәбе дигән исем бирергә кирәк.

Рәшидә. Анысы бик тә яхшы булыр. Ерак юлны якын итеп, Урал хәтле Уралдан килүегезгә зур рәхмәт инде.

Әхмәтшин. Әйткән сүз — аткан ук, ди торган иде безнең эти мәрхүм. *(Комод өстендәге гармунны күреп.)* Оһо, егет, синең гармуның да бар икән. Әтиең мәрхүм гармун уйнаганны бик ярата торган иде. Гармун тавышы минем авылымны искә төшерә, авылым исемә төшсә, өем исемә төшә, ди торган иде дустым. (Торып гармунны ала, *Ринатка бирә.)*

Р и н а т. Мин шул, абый, яңа гына өйрәнә башладым. Бәлки үзегез уйнарсыз.

Р ә ш и д ә. Сезнең күзегез юкка гына гармунга төшмәгәндер әле.

Ә х м ә т ш и н *(гармунны ала, кычкырткалый)*. Музыканы яратам. Музыка — җырның канаты, дилэр бит. Безнең землянкада бер сугышчының гармуны бар иде. Разведкадан кайткач, без шулай уйнап ала идек. Билгеле, «Моя любимая»ны да сыздыра торган идек. *(Җырлап куя.)*

В кармане маленьком моем
Есть карточка твоя.
Так, значит, мы всегда вдвоем,
Моя любимая.

Аннары гармунны миңа бирәләр, ә мин... «Юксыну»ны уйнамый калмый идем. Җырсыз дөнья тар, җырла, җыр белән сугышка кер, ди бит халык.

Р ә ш и д ә. Радиодан информбюро хәбәрләрен тапшыра башласалар, без нинди генә хәбәрләр бирерләр икән дип, репродуктор янына җыела торган идек. «Юксыну»ны җырлап юана идек.

Р и н а т. Бигрәк тә өмдә, фронтка бияләй бәйләгәндә...

Р ә ш и д ә. Күрәсен күрми гүргә кереп булмый, дигәннәр борынгылар! Күрдек инде!..

Р и н а т. Я, абый, уйнагыз әле шул «Юксыну»ны.

Әхмәтшин бик бирелеп, онытылып, «Юксыну»ны уйный. Башта бер кат үзе генә уйнап чыга. Аннары Рәшидә кушылып җырлый.

Күз карашым нинди уйчанланды,
Син беләсең микән, юк микән?
Син киләсе юлдан күзем алмый,
Сине көтәм, иркәм, кич-иртән.

Р ә ш и д ә *(тирән сулап)*. Әйе, мин дә сине, син кайтасы юлдан күзем алмый, көткән идем, көткән идем, иркәм...

Пауза.

Ф л ю р а белән А й р а т кайтып керәләр. Кулларында букетлар. Икесе дә шатлар, кычкырып сөйләшәләр.

Ф л ю р а. Әни, без кайттык.

А й р а т. Исәнмесез, Рәшидә апа!

Р ә ш и д ә. Исәнбез әле. Менә әтиеңнәр белән бергә фронтта булган Гатаулла Әхмәтшин абыегыз. *(Флюрага күрсәтеп.)* Садри Әхмеровның кызы — Флюра, аның булачак кияве — оператор... Айрат Сафин.

А й р а т. Рәшидә апа, без инде... *(Флюрага карый да оялып башын түбән ия.)*

Ф л ю р а. Әйе, без инде, языдышып кайттык, әни. Сөйләшкән идек бит. *(Килеп әнисен үбә, Айрат аптырый.)*

Р ә ш и д ә. Ярый, хәер-фатиха сезгә, балалар!

Ә х м ә т ш и н. Оһо, әти мәрхүм әйтмешли, күзле-башлы булгансыз икән.

Флюра белән Айрат елмаешып, башларын иеп куялар. Әхмәтшин кулына гармун ала, «Юксыну»ны уйнап җибәрә, барысы да кушылалар.

Бакчаларда шомырт чәчәкләре
Җәй буена сине көттеләр.
Син кайтмадың, инде көзге җилләр
Яфракларын җиргә сиптеләр...

Пәрдә

## Рәдиф Гатауллин

# ЛИРИК ШИГЫРЬЛӘР

### Дусларча бер киңәш

Дөнья бу, бел: картайса да, бер-бер
хәлгә тарыса да,
син кизәнмә ялгыш — мәгърур җанлы
мәҗрух арысланга!
Мәсәлдәге мәхлук ишәк кебек,
килеп тибә күрмә;
арысланга хас зур, горур хискә
саксыз тия күрмә!
Аңла: рухы белән җиңәр сине,
җаны шул ук, көчле...
Ваклыклардан өстен гәрчә һәрчак
арысланнар үче.
Яшьме, картмы — шул ук гали исеме,
ул — арыслан затлы.
Табылырмы арыслан белән тик
бер алышкан атлы?
...Мәңге бу адымнан саклана күр,
мәңге асылын аңла:
— Үлгән бу! — дип якын килмә... йоклап
яткан арысланга!

●

Көзге утлар кабынып ялмадылар
агачларны тагы...
Офыкларга кабыныр төсле яна
чаган яфраклары.

Нигә алдың яфрак кочак тотырып,
бүген бетәр төсле?! —
Мин курыктым: баскан урыныбыз
янып китәр төсле.

Сүндерергә иде ул утларны,
сүндерергә... күзне!
...Нигә әле язлар түгел, көзләр
якынайтты безне?

Көз утлары сүрелер, яфрак koяр
бу агачлар тагы...
Мәңгелекме бәхет?
Ә бит кулда
бары яфрак янды.
Көзнең ялкыннары...

## Шигырьләремә тәнкыйтьтән соң юату сүзе

Сезнең өчен әрни җаным,
сезнең өчен, йомшакларым!
Ап-акларым, елакларым,
юашларым, тыйнакларым,
барыгыз да бердәй якын,
тигез сызлар бармакларым,
күз нурымдай балаларым!
Аермый һичберегезне,
иркәлимче үзегезне!

Я, килегез, юаныгыз,
кочагымда ял алыгыз.
Аннан юлга кузгалырбыз
алга таба карап тагын,
онытмыйча көрәш барын,
безгә дигән Кояш барын.

Я, әйдәгез, балаларым,
ап-акларым, йомшакларым,
усал гына юашларым!

## Пушкин бәйрәмендә

Шагыйрь күңеледәй якты бер көн,
якты июнь көне.
Шигъри бәйрәм... алып килде бәхетем
бу җирләргә мине.

Даһи сөйгән, даһи баскан җирләр —
елга, урман, таулар...
(Черкиләре хәтта шигъри кебек!
Мәтәшагыйрьләрне тешли кебек...
усал икән алар.)

Усадьбадан усадьбага чабам,
(Онегиндай — атта.)
Керн йөргән аллеядә туктап,
няня торган чатта.

Йортта монда алла — шагыйрь:
әнә
Байрон портреты.
...Кабинетта ак каминның
мәңге
янар кебек уты.
Капкаларын ачып
иләһи йорт
гел дусларын көтә.
Еллар килер, чорлар —
Пущин кебек
буранлы һәр кичтә.
Ә бүген — җәй. Пушкин җырларыдай
якты июнь көне.
Алып килде бәхетем, очраштырды
Муза белән мине!

## Юлда

Кайтырга да тизрәк җан атарга
Кадерле Казанда!
Вакыт үтә. Күргәннәреңне син
тик өлгер язарга:

Син Литвада. Неман ярларында,
Вильнюс урамында;
Латвиядә — Рига, Сигулдада,
Балтик буйларында.

Син — Псковта, Пушкин эзләреннән
алып бара юлың.
Шагыйрь ишеген шакый
изге йортта
калтыранган кулың.
Син Мәскәүдә, Уфа, Пермьнәрдә,
я Төмәндә кинәт.
Астраханьда, Ташкент-Гөлстанда,—
җыр юлында, димәк.
Син — Чаллыда, син КамАЗда
бер көн,
бөек заманыңда
тойсын җаның яхшысын да, үзе
кусын яманын да;
Кушылырга шушы заманыңа,—
язарга, язарга!
Юллар бик күп, вакыт аз тик,
үтә
яндырып һаман да.
...Кайтырга да тизрәк, җан атарга
кадерле Казанда!

•

Бүген әллә нәрсә булды миңа!
Кичә башка идем:
Сиңа багышлаган җыр көченнән
күккә аша идем!

Бәйрәмнәрдә бергә булдык,
күрдек
күпме кыен бәйге...
Җиңеп үттем. Бүген атым тора
аранында, бәйле;

Бүген... ни бу? Каләм төшә кулдан,
шуны иелеп алыр
көчем дә юк! Хыял үзе никтер
таш шикелле, авыр.

Эшем бармый алга,
җырлар — үле,
минсез уза бәйге.
...Тау күтәрер көчем!
тик барысы
Синең сүзгә бәйле.
Күңел бүген бәйле!

Шамил Маннапов

## Сагындыра

Бала чакта әни тәрәзәдән
Дәшә иде:
— Бәбкәм, кайт инде.
Уен кызык,
Юк, кайтасы килми,
Дәшсә дә ул ничә кат мине.
Инде хәзер үз вакытында кайтам,
Сагындыра әни кайтмыйча.
Мине эзли чыгып киткәндер дә
Йөридер күк һаман тапмыйча.

●

Әллә нинди генә читтә сулар:
Күпме эчмә, һич басылмый сусын.
Һич басылмый йөрәгемнең уты,
Яндыралар мине уй-кайгулар.
Искә төшә, челтер-челтер агып,
Туган авыл башындагы чишмә.
Шуның суын тик бер йотым эчсәм,
Басылыр сыман барлык сусауларым...

Үлмәм кебек, калырмын күк исән,
Җан газабы белән ятканда да,
Авызыма кашык су салсалар
Туган авылымның чишмәсеннән.

●

«Улыгыз бар»,—
Дидең, сестра.
Әйттең моны бик гадәти.
Синең өчен гадәти сүз
Әти итте мине, әти!..

Әйтерсең лә үтеп киткән
Сабый чагым кире кайтты.
Елауларым, көлүләрем,
Гомерләрем — бар да артты.

# КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

**МАЙ-ИЮНЬ, 1972 ел.**

Узган көздә удар төзелешкә ВЛКСМ Үзәк Комитетының «Дружба» махсус отряды килде. Ундүрт союздаш, өч автономияле республика, унике өлкә вәкилләреннән җыйналган, барлыгы 500 кешелек бу отряд, Чаллыга килеп төшү белән үк эшкә кереште.

Отряд члennарының ничек килеп урнашуларын, аларның тормышын һәм хезмәтен «Советская молодежь» (Литва) газетасының махсус хәбәрчесе «Этиләр Магниткаңы төзеде, ә без КамАЗ»ны дигән очеркта сурәтли.

«Москабель» заводында КамАЗ заказлары аерым контроль астында тотыла. Икенче ел инде завод төзелешне үзенең продукциясе белән тәэмин итә. Заводта эшләнгән кабельләр аша КамАЗ станокларына, автомат линияләренә, эретү мичләренә һәм прессларына электр энергиясе барачак. Быел, ел башыннан ук, Мәскәү заводы КамАЗ адресына продукцияне графиктан элегрәк җибәрә.

ТАСС.

«Строительная газета»ның Беренче май санында комсомол-яшьләр бригадасы җитәкчесе, ВЛКСМ Үзәк Комитетының Үзәк ревизия комиссиясе члены Вазих Мавликовның мәкаләсе басылып чыккан.

Партия съезды алдыннан коллектив КПССның XXIV съезды исемендәге бригадасы дигән мактаулы исемгә лаек булды. Күптән түгел генә Чаллыга шатлыклы хәбәр килде: Мавликов бригадасы Энергетика һәм электрофикация министрлыгы буенча бөтен Союз социалистик ярышында җиңеп чыккан.

Атаклы бригадир төзелеш, үзенең иптәшләре турында яза. «Безнең бригада Чаллыда инде өченче мәртәбә Май бәйрәмен каршылый. Бу чор эчендә Кама буендагы тын шәһәрчек танымаслык булып үзгәрде. Без үзебез дә инде башка: олыгайдык, үзебезнең сәләтебезгә, көчебезгә ышаныч артты. Коммунистлар партиясенең һәр заданиесен үтәргә әзер торабыз»,— дип тәмамлый Вазих Мавликов үзенең мәкаләсен.

ТАСС хәбәрчесе түбәндәгеләрне хәбәр итә: Киров исемендәге Ленинград күтәрү-транспорт җиһазлары заводы Чаллы порты өчен 80 тонна йөк күтәрә ала торган гигант порт краннары ясауны үз өстенә алды. Бу краннар судноlardан КамАЗ өчен килгән уникаль җиһазларны бушатачак. Срогыннан ай ярымга элек, Беренче май бәйрәменә завод конструкторлары кранның чертежларын тәмамладылар.

Чаллының спорт тормышы, төзүчеләр теле белән әйтсәк, «Нуль циклы»ннан башланды, дип яза «Советский спорт» хәбәрчесе (1 май) үзенең «Гигантның корыч мускуллары» дигән репортажында. Төзүчеләр арасында спорт-масса эшләренең җәелүенә,— ди ул,— көрәш буенча РСФСР чемпионы В. Журавлев, авыр атлетика буенча Татарстан чемпионы Ф. Мөхәммәтдинов, тренерлар В. Логиновских, Н. Рыбина һ. б. лар кебек Казанның тәҗрибәле мастерлары зур ярдәм күрсәтә.

Спорт тормышы торган саен җанлана бара. Ә аның үсеш перспективалары гаҗәеп зур. Чөнки Чаллыда физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен бөтен шартлар тудырылачак. Мәсәлән, 20 мең кеше сыйдырышлы стадион, спорт сарае, җиңел атлетика манежы, спортның һәр төре буенча махсус заллар. Шәһәрдә ике йөзү бассейны, чаңгы базалары, спорт кирәк-яраклары биреп тору өчен про-

кат пунктлар, күтәрелү җайланмалары белән кече һәм зур трамплин, биатлон өчен трасса һәм башка спорт объектлары, корылмалары булдырылачак.

«Теплоэлектропроект» институтының Киев бүлеге коллективы КамАЗны һәм Яңа шәһәрне җылылык белән тәэмин итү эшләрен проектлаштыруны вакытыннан элек тәмамлады,— дип яза ТАСС хәбәрчесе.— Вакытны янга калдыруга болай ирешелде: институтта проектлаштыруның өч стадиясе — гомуми схема төзү, техник проект һәм каралама чертежлар эше берьюлы алып барылды.

«Социалистик индустрия» газетасы 11 майда КПССның Татарстан өлкә һәм Чаллы шәһәр комитетларының партия активы җыелышларыннан отчет биргән. Камадагы төзелеш,— диелә отчетта,— безнең экономиканың, совет кешеләре энтузиазмысының зур мөмкинлекләрен ышанычлы итеп демонстрацияли. Шулай да актив җыелышында сүз ирешелгәннәр турында гына түгел, күбрәк файдаланылмаган резервлар турында барды. Җыелышның карарына коммунистлар, производство алдынгылары чыгышларында әйтелгән конкрет тәкъдимнәр кертелде.

ТАСС хәбәрчесе Чаллыга Серго Орджоникидзе исемендәге заводтан «Минск-32» электрон-хисаплау машинасы җибәрелүе турында яза. «Камгэсэнергострой» идарәсендә бу машинаны монтажлау эше башланды.

КамАЗ төзелешендә төзү индустриясенең иң яңа ысулларын куллану турында 12 майда чыккан санында «Правда Севера» газетасы яза. Газета шуңа басым ясый: совет халкы ярты гасыр дәвамында төзү эшләренең киң колачы белән әллә ничә тапкыр инде дөньяны шаккатырды! Әмма эш анда түгел, эш шунда: СССРда барган һәр төзелеш элеккеге төзелешләрнең дәвамы һәм киләчәк төзелешләрнең нигезе. Һәр төзелеш — яңа инженерлык һәм оештыру эшләренең яңа чишелеше, ул Совет дәүләтенең аерым бер этапта экономик һәм иҗтимагый-социаль үсешен чагылдыра.

ТАСС хәбәрчесе яза: КамАЗ автотрассаларында төзелешнең беренче көннәреннән башлап Минск автозаводы эшләп чыгарган машиналар йөри. 1972 елның беренче кварталында төзелеш адресына МАЗ-503 һәм МАЗ-504 маркалы 110 машина җибәрелде. Заказ вакытыннан элек башкарылды.

«Төзүчеләр көнкүрешенә — югары культура» дигән баш астында «Строительная газета» 21 майда чыккан санында Чаллыдагы һәм төзелеш мәйданнарындагы ашханәләр турында яза.

Таганрог шәһәрендәге «Красный котельщик» заводы КамАЗ өчен бик күп җиһазлар җитештерә. 1972 елның беренче яртысында завод төзелешкә 11 мазут җылыткыч җайланма һәм югары сыйфатлы фильтрлар җибәрде. Срогыннан бер айга элегрәк КамАЗ заказы буенча сәгатенә 420 тонна пар чыгара торган куәтле казан эшләнде. Бу турыда ТАСС хәбәрчесе яза.

«На стройках России» журналының 5 санында КамАЗ тирәсендәге объектларның архитектура законнары ягыннан урнаштырылу тәртибе турында мәкалә басылган. Алар корпусларның зур масштаблы булулары һәм шул ук вакытта күп планлы композицияләре белән аерылып торалар. Проектчылар эре җәмәгать комплексларын төзүдәге күләм һәм пространство принцибын хәзерге заманча итеп эшләгәннәр.

ТАСС хәбәрчесе яза: КамАЗ нярчене — Красноярск автомобиль һәм трактор прицеплары заводы туган көнне Себер төзүчеләре тантаналы итеп билгеләп үттеләр. Чуен кою цехының нигезенә беренче кубометр салу хокукына Г. Коваленко җитәкчелегендәге комсомол-яшьләр бригадасы лаек булды.

Бу завод елга йөз мең прицеп эшләп чыгарачак. Ә аның күбесе КамАЗ чыгарган автомашиналар өчен файдаланылачак. Завод янында 50 мең кешелек яңа шәһәр салына.

«Строительная газета». 26 май. «Күп катлы Чаллы» дигән мәкаләдә торак йортлар салу темплары турында язылган.

Торак йортлар салуның Чаллы базасында иң мөһиме: елга 240 мең кв. м. торак мәйданы бирә торган яңа комбинат. Комбинат «83» серияле йортлар җитеш-

тера. Э бу серия буенча илдә төзү эшләре 1975—1980 елларда массовый төстә башкарылачак.

Бу серия архитектура, конструкция-технология чишелеше ягыннан хәзерге заманның иң прогрессив үрнәкләреннән санала. Мәкаләдә Мәскәү төзүчеләренең агым методы белән эшләүләре дә сурәтләнә.

ТАСС хәбәрчесе яза: Запорожье, Днепропетровск һәм Донецк заводлары 1972 елда КамАЗ төзелеше мәйданнарындагы монтаж эшләре өчен 22 мең тоннадан артык металл конструкцияләр җитештерде. Урында монтаж эшләрен башкару өчен «Криворожстальконструкция» тресты составында 138 номерлы махсус идарә оештырылды.

Калуга өлкәсенең комсомол газетасы — «Молодой ленинец» үзенең 27 майда чыккан санында якташлары, бөтен Союз комсомол удар төзелешендә эшләүче Галина Кабанова турында очерк бастырып чыгарган. Тормыш юлы аның катлаулы, әмма аның уйлары тормышка, гүзәллеккә олы хис белән сугарылган.

«Водный транспорт» газетасы 1 июньдә чыккан санында елга эшчеләренең Кама буенда төзелә торган автогигант заказларын вакытында үтәү өчен тырышулары турында сөйли. Юбилей елы навигациясе башка елларга караганда шактый оешканрак төстә башланган. Әмма шулай да бу өлкәдә елгачылар алдында зур бурычлар тора әле.

«Строительная газета»ның 2 июньдә чыккан санында Кама автомобиль заводының төп объектлары нигезен яңача салу турында мәкалә басылып чыкты. Зур диаметрда бораулаган җиргә тимер-бетон субайлар кою электәге багана субайлар кагу ысулына караганда җир эшләрен 10 миллион кубометрга киметә, төзелеш эшләрен ике-өч тапкырга арттыра.

«Вечерняя Уфа» газетасы үзенең 2 июньдә чыккан санында АПН хәбәрчесе В. Сухачевскийның «КамАЗ-72»: темп плюс темп» дигән мәкаләсен бастырып чыгарган.

ТАСС хәбәрчесе яза: КамАЗдан килгән 500 дән артык кеше Горький автомобиль заводында слесарь-ремонтчы, наладчик, кран белән идарә итүче һөнәрләрен үзләштерде. Горький шәһәре предприятиеләрендә Кама автомобиль заводында эшләячәк егетләр һәм кызлар егерме төрле һөнәргә өйрәнәләр. Биредә инженер-техник хезмәткәрләр дә белемнәрен күтәрә. Бер елга меңнән артык белгеч үзләренең һөнәрләрен камилләштерә.

«Социалистическая индустрия» газетасының (9 июнь) беренче битендә «Бүгенге КамАЗ» дигән баш астында Чаллыдан бернигә хәбәр басылып чыккан. «РИЗ өстендә кояш» дип исемләнгән репортажда автогигантның беренче эшко башлаячак ремонт-инструменталь заводындагы хезмәт күтәренкелеге сурәтләнә.

СССР төзелүгә 50 ел тулу уңае белән алынган социалистик йөкләмәләрне балта осталары, пыяла куючылар бригадасы ничек үтәвен комсомол комитеты секретаре Л. Бородай тасвирлый.

З. Юнусов җитәкчелегендәге коммунистик хезмәт бригадасы коллективы, ит комбинаты төзелешендә эшләп, зур уңышларга иреште. Бригада бетон кою буенча бер сменада сигез норма үтәде. Бу турыда Гидроспецстройның СМУ-34 идарәсендә өлкән инженер булып эшләүче О. Афонников яза.

Газетаның бу санында шулай ук төзелеш көндәлеге, алдынгы монтажчы Василий Шленский рәсеме, коллективларда «Социалистик ярышны оештыруны яхшырту турында» КПСС Үзәк Комитеты карарларын тормышка ашыру мәсьәләләре буенча үткәрелгән партия җыелышлары турында информацияләр бирелгән.

«Вечерний Ленинград» газетасы 10 июньдә «Советлар иле буйлап» дигән баш астында бишьеллыкның удар төзелешеннән материал бастырып чыгарган.

14 июньдә «Литературная газета»да язучы Георгий Бакланов КамАЗга сәяхәте вакытында алган тәэсирләре белән уртаклаша.

Узган көз һәм кыш көннәрендә,— ди автор,— КамАЗ төзүчеләр өчен шартлар бик кыен булды. Әмма КамАЗ төзүчеләренең характеры бу шартларда ныгыды гына.

Очеркта автор коллективның шул авыр шартларда тууын, аның ныгуын сурәтли.

«...Безнең илебездә беренче тапкыр 1200 миллиметр диаметрлы буровойларга бетон субайлар коюны балчык эремәсе кулланып эшләү башланды».

«Двигательләр заводы объектларында конвейер ысулы белән стена-түшәмнәрне шомарту җайланмасы сафка басты... Мондый конвейерлар башка завод корпусларында да кулланылачак».

«КамАЗның ремонт-инструменталь заводы 1972 елда сафка басачак комплекс... Объектта В. Эльблаус һәм Л. Рыбаков җитәкчелегендәге бетончылар бригадалары югары хезмәт үрнәкләре күрсәтәләр» — болар «Строительная газета»ның 18 июньдә чыккан санынннан алынган юллар.

Монтажчылар бригадиры Е. Харламов «Социалистическая индустрия» газетасының 12 июньдә чыккан санында үз кул астындагы коллектив, дуслары һәм иптәшләре турында сөйли. Бу бригада әле КамАЗда бер генә ел эшли, шулай да инде ул төзелештә билгеле. Кешеләр белән мөнәсәбәт, аларның йөрәгенә үтеп керү серләре турында яза бригадир. Эшне процентлар белән генә исәпләүчеләр бик зур хата эшли,— ди ул.— Мораль, холкый һәм политик тәрбиядән башка зур җиңүләргә ирешүеңне көтмә. Иҗат итү политик яктан җитлеккән, саф холыклы, рухы нык булган кешеләргә генә хас нәрсә.

ТАСС хәбәрчесе яза: Ленинград шәһәренең «Электрик» заводы өченче квартал өчен үз продукцияләрен КамАЗга озатты. Ленинградлылар автогигант төзүчеләр өчен дистәдән артык типтагы һәм конструкциядәге машиналар ясыйлар.

«Әкият булып күтәрелә КамАЗ» — «Строительный рабочий» газетасының 24 июньдә чыккан санында шундый исем астында фоторепортаж басылып чыккан. Репортажда төзелеш барышы, Ленинград шәһәре һәм өлкәсе вәкилләренең удар төзелештәге хезмәтләре сурәтләнә.

Чаллы шәһәренең генераль план схемасын карасаң, яки булачак шәһәрнең макетына күз төшерсәң, ирексездән архитекторларның фикерләү сәләте зурлыгына, шәһәр төзү структурасының төгәллегенә, шул ук вакытта гадилегенә исең китә. Болар бит проектчыларның бик зур, четерекле хезмәтләре нәтиҗәсе,— дип яза 25 июньдә «Строительная газета».

26 июньдә «Волжский комсомолец» газетасында язучы Геннадий Паушкинның комсомолның XV съезды делегаты Вазих Мавликов бригадасы турында очеркы басылып чыккан. Чаллыда Мавликов җитәкчелегендәге ташчылар бригадасын түгызынчы бишьеллыкның беренче елы чемпионы диләр. Дөрестән дә, шундый тизлеккә бары тик чемпион, чын батыр гына сәләтле,— дип төгәлли автор очеркын.

«Комсомольская правда» газетасының велосипедка утырып сәяхәткә чыгучылар удар төзелештә дә булдылар. Сәяхәт командиры Д. Горбунцев газетаның 27 июньдәге санында үзенең Кама автогиганты төзелешендә күргәннәре турында яза.

КамАЗ — автомобиль эшләп чыгара торган заводлар комплексы, яңа шәһәр генә түгел, ул башта төзүчеләрне, аннан автозаводта эшләүчеләрне азык-төлек белән тәэмин итә торган зур бер авыл хуҗалыгы предприятиеләре зонасы да. «Сельская жизнь» газетасы 29 июньдә азык-төлек индустриясе базасы төзелеше проблемалары турында яза.

Июнь ахырында Казанда РСФСР язучылары союзы идарәсе секретариаты утырышы үткәрелде. Утырышка катнашучы язучыларның бер төркеме КамАЗда кунакта булды. «Литературная Россия»нең 30 июньдә чыккан санында язучылар бишьеллыкның удар төзелеше геройлары белән очрашудан алган тәэсирләре турында сөйлиләр.

«За рубежом» журналының 38 санында «Камада гигант» дигән баш астында француз журналисты Серж Лайракның репортажы чыккан. Шул ук санда Берлинда чыга торган атналык «Хорицонт» журналыннан завод төзелешен сурәтләгән фоторәсем күчереп басылган.

Равил Биктаһиров

# «КУБИК»лар ТУРЫНДА БАЛЛАДА



Тормыштан зарлана алмыйм мин: гел җае чыгып кына торды. 1951 елны әтием Куйбышевгидстроена эшкә билгеләнде. Җәен без бөтен семьябыз белән шунда күчеп киттек. Әле дә бөтен ваклыкларына кадәр хәтерлим: Ставрополь-на-Волге шәһәреннән килгән моторлы көймә безне, каршы искән җилдән усалланган дулкыннарны яра-яра, Могут тавы янындагы буш ярга алып чыкты. Ул вакытта бу кечкенә генә бухтада иренеп кенә эшләүче җир суырткыч машина тавышы белән үзәнлектә җилләр уртасында калган иске тегермән ыңгырашканы гына ишетелә иде.

...Ә аннары башланды!

Без, гидрострой малайлары һәм кызлары, класста утырган килеш тә тәзелеш пульсын тоя идек. Жигули карьерында таш җимерткәндә кайвакытта, хәтта класс идәннәре дә селкенеп, тәрәзә пыялалары дерелди иде. Көндезге көчле җил котлованнан бирелгән «... иптәш Арта-мо-но-о-ов, рай-он-ның баш ин-же-не-ры-на» дигән радиокомандаларны да ишеттерә иде.

Олылар тәзелеш белән генә яшәделәр. Күп вакытта әти өйдән мендәр генә ала да ерактагы перемычкага китә. Бу сүз безгә, яшүсмерләргә, тылсымлы кебек тоела: чөнки ул сүзнең чын мәгънәсен белми идек. Һәм аннан соң «шуннан килгән» (эштән арып кайткан әтиләр бу исәпкә керми) һәр кеше белән очрашу безнең өчен зур вакыйга иде.

Шундый очрашучың берсе хәтердә калган. Безнең яңа мәктәптә сайлау участогы оештырылды. Сайлаулар көнне беренче булып тавыш бирергә экскаваторчы Клементьев килде. Аның экскаватор чүмече бурлак сукмагыннан беренче булып җир алганын бөтен поселок белә иде. Ул затлы костюмнан. Без, укучы-комсомоллар, урналар янында почетлы каравылда торганда, бу кыюсыз кешенең тиздән күкрәгенә Алтын Йолдыз тагасын башыбызга да китерми идек әле. Клементьевның хезмәт биографиясенең бик нык макталасын, берничә елдан аңа да багышлап «Мисырдагы дусларга» дигән шигырь язылыр дип тә уйламадык.

Ләкин шулай да без Василий Михайловичка бик нык сокланып, тылсымчыга карагандай гаҗәпләнеп карый идек.

Алар хезмәтенең нәтиҗәләрен мин студент вакытта каникулга кайткач күрдем. Могут тавы түбәсеннән минем алдымда гаҗәеп күренеш ачылды. Елганы плотина нык путадай буып куйган. Төрле ягыннан чәчәкле аллеялар уратып алган станция мәһабәт булып күренә, монда кайчандыр асты өскә китерелгән балчык өемнәре яткан дип һич тә уйламассың. Шунда мин беренче мәртәбә станция менә шулай үз кесә

эшләсен өчен өтиләрнең күпме хезмәт түккәнен тойдым. Хезмәтләре генә түгел, бөлемнәре һәм профессиональ осталыклары да таләп ителгәненә төшендем. Могут тавы түбәсендә торганда ГЭС төзегән геройлар — экскаваторчы Василий Лямин, электр белән эретеп ябыштыру остасы Алексей Улесов, водолаз Сергей Милиантларның батырлыгы бөтенләй яңача күз алдына килеп басты.

Язмыш мине егерме елдан соң Жигули дингезенең икенче чигенә — Чаллыга китерде. һәм биредә мин Клементьев, Лямин, Улесов, Милиантлар батырлыгының серен яшьләрнең көндәлек эшендә үз күзләрем белән күрәчәгемә чын күңелдән ышандым. Чөнки иске танышларымның омтылышы белән Кама янындагы удар төзелеш рухы уртак икәнлеге минем өчен ачык иде. КамАЗга нигез салучыларның һәрберсе — хәтердә калырдай кешеләр. һәм бу аңлашыла да: акча колларын буш далага күмәч күрсәтеп кенә китерә алмыйсың. Мин КамАЗ төзүчеләр белән очрашкан саен үземне дулкынландырган бер үк сорауны кабатлыйм: «Син төзелешкә нинди өлеш керттең?» һәм мин ышанам: бирәү дә минем соравыма битарафлык күрсәтмәячәк.

Узган ел КамАЗның төзелеш мәйданнарында утыз миллион кубометр җир эшләре башкарылган. Аның нигезенә 567 мең кубометр монолит бетон салынган, корпусларына 394 мең кубометр җыелма тимер-бетон монтажланган.

Бу эшләрне башкару өчен нинди генә кайнар көннәр, йокысыз төннәр кичерелмәгән! Җир казучылар, бетончылар, монтажчыларның тауларны күчерүгә тиң фидакарь эшен нинди үлчәүдә үлчәргә мөмкин соң?

Әлбәттә, бу язмаларны, Клементьев кебек, КамАЗның беренче нигез балчыгын алган кешене эзләп табу вакыйгасыннан башлыйсы килә.

Чыннан да, еллар үтүгә карамастан, КамАЗ нигез балчыгын беренче алган кешене биредә онытмаганнар, башка җир казу осталары арасында ул югалып калмаган. Беренче чүмеч балчык алган көннең ике еллык юбилеена, 1971 елның 13 декабрена, Михаил Тимофеевич Носков үзенең экипажы белән ярты миллион кубометр чамасы җир казыган иде, һәм Камгэсэнергостройның рекордчы механизатор паспорты аңа тапшырылды.

Машина экипажы командиры мондый уңышка ирешүен болай аңлата:

— Минем карашымча, безнең коллективның бәр үзенчәлеге шунда: эшләнгән эшне без сменалап түгел, бөтен бригадага исәплибез. Эш хакын да шулай бүләбез. Ә бит күп кенә бригадаларда һәр сменаның эшен аерым исәпкә алалар. «Кубик»ларны күбрәк бирү өчен алар машиналарын саклап тотмыйлар, теләсә ничек файдаланалар, яхшылап карамыйлар. Шуның өчен, социалистик ярыш шартында: «Экскаваторның ремонтсыз эшләү вакытын ике мәртәбә озынайтырга!» дип яздык. Кулларына логарифм линейкалары тотып, машинаның чыдамлылык срогын исәпләгән инженерларның билгеләмәсе бу очракта чынбарлыкка туры килми. Носковның үз арифметикасы.

Корыч организмга зыян китермичә чокырдан ничек балчык алырга, аны чүмечтән самосвалга ничек яхшырак бушатырга дигән мәсьәләләрне һәр минут чишә ул.

Чаллыда мин беренче тапкыр Жигулида булмаган профессия кешеләре — автоскреперчылар белән очраштым. Монда бит төзелеш бер карыш җирдә генә түгел, ул йөз квадрат километрга җәелгән. Туфрак монда бик уңдырышлы. Тикмәгә генә Чаллы портында революциягә кадәр үк Россиядә иң зур элеваторларның берсе төзелмәгән бит! Автоскреперлар туфракның уңдырышлы өске катламын җыеп алалар.

Автоскреперчылардан миңа иң ошаганы Харис Рафиков булды. Чибәр, таза егет ул. Мин КамАЗ художниклары урынында булсам, плакатларга гел аны гына ясар идем.

Харис Кама буенда туган. Аның туган авылы Каратай-Саклау Чаллыдан 30—40 километрда гына. Ул Кама өстендәге һавадай ачык зәңгәр күзле, үзе скрепер йөрткән даладай сап-сары чәчле.

— Минем әтинең куллары менә мондый,— дип күрсәтә Харис, ике кулын янәшә куеп. Аның үз кулларына карап, мин яшерен көнләшү белән уйлыйм: «Йонлач бал

карагы ялгыш моның белән очрашә күрмәсен! Аюыңны да сугып егар!» Ерак Көнчыгышта армия сафларында шофер булып хезмәт итү. Себердәге удар комсомол төзелешендә автокранда эшләү чыныктырган аны. Камада автозавод төзеләсен ишетү белән туган якларына кайта ул. Ни әйтсәң дә туган як үзенә тарта икән шул. Гариф абзыйның сугышта хәбәрсез югалган улыннан башкалары әтиләре янында эшлиләр. Ә Хәмит исемле абыйсы колхозның партия оешмасын җитәкли.

Без аның белән су җыйгыч һәм су чистарткыч корылмалар күтәреләчәк урында очраштык. Харисның кәефе киткән иде бугай. Ахырдан сәбәбен дә белдем. Авылына сабан туйга кайтып килүне җайлый алмаган икән. Унсигез яшендә үк бөтен республикага атаклы Зәфәр Хановны еккан егеткә сабан туйга кайта алмау нәрсә икәнен үйлап карагыз инде.

Кирәк бит шулай туры килергә, «Советская Татария» газетасы июньдә, сабан туй алдыннан гына, автоскреперчылар бригадиры Умат Наурбиевның «Бишьеллыкны — дүрт елда!» дигән хатын бастырып чыгарды. Рафиков звеносы күршеләргә чакыру ташламыйча гына аларны узып китәргә булды.

Шушы вакыйгаларның нык куерган чагына туры килдем мин. Гөнаһ шомлыгына каршы, Чаллыда ул көннәрдә түзеп тормаслык эссе иде. Эсселек күләгәдә 40° ка якынлашты. Ә кабинада тагы да эссерәк. Маңгай тире күзләрне каплый. Егетләр шулай да бирешмәделәр.

Шундый көннәрнең берсендә, вахта көндезгә ашка барганда, Наурбиев участогында машиналарның тик торганын күрделәр. Кичке якта беленде: күршеләр, кызулык бераз кими төшкәч, көндезге сәгать өчтән генә эшли башларга карар кылганнар икән. Бу яңалык бригаданың тынычлыгын югалтты. Безгә нишләргә соң? Машиналары янына җыелдылар, кайсы скрепер канатына утырды, кайсы трактор тәгәрмәченә. Шаулаштылар, бәхәсләштеләр һәм ахырдан иртәнге салкында җидедә эш башларга, кичке җидедә тәмамларга булдылар. Ә көндез чиратлашып эшләп алачаклар.

Август башларында мин Харис белән яңадан очраштым. Күршеләре белән ярышның ничек тәмамлануын беләсем килде. Минем дустымны бу гадәти булмаган «бәйгедә» җиңүе белән котларга була икән. Наурбиев бригадасы эссе көннәрне көндезен эшләмәсә дә, июльдә рекорд биргән — эшләп чыгару ике йөз сиксән процентка җиткән. Ә Харисларныкы — өч йөз утыз!

Гадәтем буенча чемпионнан сорадым: «Әйтче, дустым, күршеңне узып китү өчен син нинди дә булса техник хәйлә кулландыңмы?» — дидем. Эшченең табигый «эгоре» — бу инде галимнәр тарафыннан күптән исәпләнгән — «ат көче»нең уннан берен генә тигез бит. Нишләсәң дә шуннан артык эшли алмыйсың.

Сүзне кая таба борганымны Харис шунда ук аңлап алды, дәү кулларын бутыйбутый аңлатырга кереште:

— Беләсезме, безне гел мотор интектерә. «Җен» көче булса да, бик четерекле бит ул мотор. Әно «Жигули»ларның двигателе мең ике йөз сәгать эшләргә исәпләнгән, ә скреперның бары тик биш йөз сәгатькә. Телисеңме, юкмы, эшеңнән туктап, моторда казынырга кирәк. Ике көн буе казынырга була, бер көндә дә бетерә аласың. Уйланам: төрле тимерләрне тегеләй куеп кар йм, болай куям. Тырыша торгач, алына торган манометр, тагы кечкенә-кечкенә вак-төякләр уйлап таптым...

Әйе, хәйләсе әллә ни түгел, ә «кубик»лар күбрәк.

Хәйләсез дөнья файдасыз ди бит. Зуррак хәйлә эзләп, төзелеш җитәкчесе Е. Н. Батенчук янына киттем. Алдынгылар слеты утырышлары арасында таныштым мин аның белән. Мине дикъкать белән тыңлагач, Евгений Никанорович кыска гына итеп әйтте: «Иртәгә 8 дә. Килештекме?». Кичке яки иртәнге сигезме икәнен ачыкларга кирәк лекин. Аның эш көне иртә таңнан башлана да кайчан бетәсен үзе дә белми.

Бу гаҗәеп яхшы күңелле кеше турында берничә сүз әйтмичә китә алмыйм. «Комсомолка» узган ел җәй көне Вилюй төзелешеннән биргән репортажында аны «легендар Батенчук» дип атаган иде. Бу кенгә кадәр себерлеләр аны онытмыйлар, яхшы сүз белән искә алалар.

Ул миңа үз тормышының искитәрлек нечкәлекләрен сөйләп бирде. Менә минем блокноттан аның турында ике язма:

**Н. Тезиков, Камгэсэнергострой идарәсенең партбюро секретаре:**

Ә сез гитлерчылар концлагеренда Евгений Никаноровичның яшерен оешма белән җитәкчелек иткәнен беләсезме? Үзе ул бу хакта сугыштан соң беркемгә дә сөйләмәгән, партиядән чыгаруларын да тиешле җәза дип караган. Ул вакытта шулай иде бит: пленга төштеңме — син инде коммунист түгел.

Көтелмәгән вакыйга аны сөйләргә мәҗбүр итә. Беркөнне ул радионы куя да үз колагына үзе ышанмый: билгесез бер иптәш фашист тоткынлыгында күргән коточкыч дәһшәтләрне сөйли. Ул әсирләр арасындагы каршылык күрсәтү группасы турында, аларның листовкалар таратуы һәм бу листовкаларында конспирация өчен түшәмнән алынган санны шифр итеп куюларын әйтә. Саннардан башкалары барысы да дөрес. Ул бернинди дә шифр түгел, ә Батенчукның партия билеты номеры була. Евгений Никанорович бу хакта Мәскәүгә язып җибәрә. Тиздән дөреслек җиңә: Батенчук партиягә кайтарыла.

Сез коммунистлар — минем иң якын ярдәмчеләрем — турында сөйләргә, дисез. Батенчук — шуларның берсе. Өстәвенә, яшьләрдә патриотизм тәрбияләү эшендә ул алыштыргысыз. Хәрби тормышының эпизодларын шуңа күрә китердем дә мин. Нәрсә белән мәшгуль ул хәзер? Соңгы 9 Май көнен хәтергә төшерү дә җитә. Бу көнне Евгений Никанорович хезмәттәшләре алдында чыгыш ясый, шәһәр митингысында речь сөйли һәм идарәдәге сугыш ветераннарын җыеп, алар белән стройга басып, шефка алынган мәктәпкә барырга да өлгерә.

**Ю. Титов, тәзелешнең комсомол комитеты секретаре:**

Гадәттәгечә, смена беткәч, барлык эшчеләр дә өйләренә ашыгалар. Автобус тукталышы янында беркөнне кинәт складлар яна башлады. Тукталышта кеше күп иде, тик нигәдер берсе дә кымшанмады. Кинәт халык арасыннан олы яшьтәге бер кеше йөгереп чыкты да утны сүндерергә ташланды. Аның артыннан бүтәннәр дә иярде. Утны сүндерергә беренче ташланган кеше Евгений Никанорович Батенчук булып чыкты.

Чираттагы объектның нигезен салганда да, эшчеләр тулай торагында өй котлаганда да беренче булырга гадәтләнгән ул. Кыю инженерлык мәсьәләсен хәл иткәндә дә беренче — ул.

...Менә шундый мәсьәлә турында сөйләштек без әлеге билгеләнгән көнне. Тәзелештә хәл бик читен: ул гигант котлованнарга баткан, бетоннан коелган фундамент пирамидалары авыр гер аскандай тәзелешнең адымын тоткарлыйлар. Биналарның җир асты өлешен эшкәртү тәзүчеләргә бирелгән вакытның өчтән берен ала. Искечә ысул белән эшләгән тәкъдирдә партия һәм хөкүмәт заданиесе өзелергә мөмкин. Нигезләр турындагы фәнне җентекләп яңабаштан карап чыгарга туры килә.

Батенчук күп сөйләмәде: кыскача гына аңлаткач, мине тәҗрибә полигонына җибәрде.

Дала юллары лабиринтында «газик» озак адашып йөрде. Шофер да төгәл генә белми. Кая карама — актарылып ташланган балчык өеме. Ниһаять, ике яшел вагон янында туктадык. Беркем дә юк. Нәрсәнең нигә икәнен үзебез карый башладык. Көйгән үләннәрне таптап бораулаган кое янына килдек. Ярты метрдан киңрәк чокыр авызыннан салкынча һава бөркелде. Чокыр авызына акча ташлап карадык: тирәнлеге 10 метрдан артык булырга тиеш. Батенчук сүзләре искә төште: димәк, монда корыч каркаслар куела һәм бетон салына.

Рәттән генә әзер субайлар да күп. Алар өстенә гидравлик пресслар куелган. Пресслар белән субайларга төрле авырлыклар биреп сынау үткәрәләр. Әйе, монда гади күз белән дә күреп була: әгәр субайлар үзләренең ныклыгын расласа, бу инде нигез салуда чын-чынлап революция ясау булачак. Уйлап кына карагыз: берәр километрга сузылган котлованнар казып, аны яңадан күмәсе юк. Күпме материал, эшче көчләр, механизмнар, акча, иң әһәмиятлесе — вакыт янга калачак.

Идея бик кызыктыргыч булса да, шикләнеп караучылар да булмады түгел.

Ташландык сыман бу полигонда берничә атнадан, ягъни 1971 елның 23 июнендә, Гидроспецстройның Леонид Попов бригадасы беренче промышленный скважинаны

бораулыйсын да, нәкъ 12 айдан соң, 1972 елның 23 июнендә, Леонид Поповның шул ук бригадасы 200 мең кубометр бетон саласын да, юбилей «кубигы» салынасы субайның 2700 нче буласын да, аның өстенә автоҗыю заводы корыла башлыйсын да ул вакытта мин башыма да китермәдем.

Гидростройчыларның бенефисы Чаллыдан тыш та бик күпләрнең игътибарын үзенә тартты. Әле күптән түгел генә СССР Госстрое биредә бораулап-төеп тутырылган субайлар хакында конференция үткәрде. Озак та үтмәде, Чаллыда бригадирлар һәм мастерлар өчен бөтен Союз алдынгы тәҗрибә мәктәбе оештырылды. Эш мәйданнарында йөргәч, кунаклар үз күзләре белән күрәп, нигез салудагы яңа ысулның өстенлекләренә ышандылар. Коҗо заводының бер корпусында монтажчыларга эш мәйданы җитми икән. Әмма нигез салучылар монда 1970 елда ук килгәннәр иде бит. Ә двигательләр заводында бөтенләй икенче күренеш: нулевиклар эшкә күптән түгел генә керештеләр, шулай да түбә ябучыларны тиргә батырдылар.

Моның сере бик гади: беренче объектта нигезне искечә, котлован казып багалар утыртудан башлаганнар, ә икенчесендә субай методы кулланганнар.

Теоретик киңәшмәләрдә илебезнең индустриаль үзәкләреннән килгән кешеләр бораулап-төеп тутырылган субайлар турында тагын да тегәлрәк мәгълүматлар алдылар. СССР Госстроеның фәнни-техник советы КамАЗның өч заводында (пресс-рам, двигатель һәм җыю заводларында) анализлар үткәрде. Тикшерүләр түбәндәгеләрне күрсәтте: җир казу эшләре күләме җиде миллион кубометрга кимеде, уннарча экскаваторлар, дүрт йөздән артык үзбушаткычлар, йөз илледән бульдозер һәм башка бик күп техника эштән бушады. Нигез салу өч-дүрт мәртәбә тизләтелде. Шулай да яңалык үзенә юлны җиңел генә яра дип уйларга ярамый.

Структура һәм оештыру буенча булган бөтен сораулар ныклап тикшерелеп беткәнче шактый вакыт узды. Узган елның ахырында тезелешнең җитәкчеләре, Советлар Союзында беренче мәртәбә, бораулап-төеп тутырылган субайлар буенча махсус идарә — Фундаментэнергострой булдырды. Яшь коллектив алдына тиз хәл итүне сорый торган бетмәс-төкәнмәс проблемалар килеп басты.

Туң туфракны махсус эшләнмәгән станоклар белән ничек бораударга? Скважиналардагы арматура-каркасларны бетонлау алдыннан ничек җылытырга? Торбаларны скважиналарга бетон тутыргач ничек юарга? Шуның өстенә, субай участокларында башта армокаркаслар да, бетон да җитми иде.

Көннәрдән бер көнне безгә билгеле шул ук Леонид Попов бригадасында кызык хәлгә тап булалар. Инде барысы да әзер дип әйтерлек. Буровой станокның төп плитасы кемдер җиңелчә генә кагылудан скважинага шуып төшеп китә. Барысы да югалып калалар. Корыч «коймак»ны коедан ничек алып чыгарга? Коеның тирәнлеге 12 метр, ә киңлеге бары 60 см гына. Тар тишеккә керүен керерсең дә ди, чыга алмасаң. Тормышыңны куркыныч астына куюо кемгә кирәк? Бу каһәрләнгән скважинаны ташларга да ярамый. Проект проект инде ул.

— Егетләр, ябыштыру аппараты һәм кабель әзерләгез! — дип кычкыра бригадир, анкер гайкасын кесәсенә тыга-тыга. Бөтенесе дә әзерләнгәч, баудан үрелгән баскычтан кое төбенә төшә ул. Ике-өч минут эчендә ул эшен бетерә! Калганы, шахматчылар әйткәнчә, инде техника эше.

Субайчыларның түгәрәк сан — ике йөз меңенче субайны сукканда да мәшәкатьләре җитәрлек булды.

Шул көннәрдә, ягъни июньнең соңгы көннәрендә, бирегә бригадир булып Виктор Кузьмин килде. Үзенең КамАЗ биографиясен автозавод ТЭЦыннан Яңа шәһәргә үткәреләә торган җылылык трассасында бетончы булып башлаган ул. Шунда инде аңа, яңа гына армиядән кайткан егеткә, бригадир исеме бирелә. Аларның СМУлары мөстәкыйль махсус бүлеккә әйләнгәч, яңа бригадир нигезләр тезелеше буенча алдынгылар рәтенә чыга. Проектчылар оештырган курсларга даими йөри ул, үзе дә күп укый. Бу, билгеле, бригаданың эш күрсәткечләренә нык тәэсир итә.

Газетага Виктор хат алып килде. Стиле белән бораулап-төеп бетон тутырылган субайлар буенча бөтен Союз мәктәбенә җибәрелгән отчеттан бераз аерылып тора ул.

Эчтәлеген сөйләп тормыйча, аз гына кыскартулар белән хатның үзен китерик.

## ИНЕРЦИЯ БУЕНЧА — ДАН АЛУ, ЯКИ ПЛАН ҮТӘМӘГӘНГӘ — БЕРЕНЧЕ УРЫН АЛУ

*Узган айның башларында безнең бригадага төзелешнең иң яхшы коллективы диган исем бирелү уңае белән котлаулар кабул итәргә туры килде. Камгэсэнергостройның берләштерелгән постройкомы социалистик ярышның май ае йомгаклары буенча беренче урынны безгә бирде. Үзебез котлауларны кабул итәбез, үзебез уңайсызланабыз. Эш шунда: апрельдә дә, майда да производство планын бригада үти алмады. Дан үзе күңелле нәрсә, ә шулай да миңа үз-үземне фаш итәргә туры килде. Эшләр начар барганда бер дә макталасы килеп тормый икән. Үзегез хөкем итегез: майда без 400 субай урынына 283 не генә бетонладык. Июнь планын 50 процентка гына үтәдек.*

*Кышны искә төшерәм. Бригаданың директив нормасы — тәүлегенә 8 субай, нигезе — фантастик булып тоела иде. Ләкин без кыенлыкларны җиңәргә өйрәндек. Озак көткән көн килде: безнең бригада эш сменасы беткәндә 8 не генә түгел, ә 15 әр субай тапшыра башлады. Булган мөмкинлекләрне тикшергәч, двигательләр заводында соңгы фундаментны 1973 елда түгел, ә 1972 елның ахырына бетонларга карар кылдык...*

*Һава торышы яхшырган саен, бригадада һәм бөтен идарәдә дә эшләр начаррак бара башлады. Расланган график буенча июньнең беренче яртысында Фундаментэнергострой 11,5 мең кубометр бетон алырга тиеш иде. 6 мең генә килде. Ике ай инде трослар юклыктан көчле бораулау установкалары эшләми.*

*Бригада куләмендәге проблемалардан тыш бөтен төзелеш масштабындагылар барлыгын да аңлыйбыз.*

*Бүген ремонт-инструменталь заводын өзеклектән чыгару өчен күп көч куела, торак төзелеше һәм башкалар. Мин ихтыярсыздан уйланам: төзелеш җитәкчеләренә үз кайгыларым белән мөрәҗәгать итәргә хакым бармы минем? Шулай да кайбер фикер һәм уйлануларны әйтмичә кала алмыйм.*

*Бүгенге көндә двигательләр заводы эшләр әйбәт бара торган объект санала. Шуңа күрә аңа игътибар итүче дә юк. Ә кайчандыр ремонт-инструменталь заводы мәйданында да шулай иде бит. РИЗны бик соңга калып исләренә төшерделәр. Хәзер анда бөтен көч тупланган. Менә шундый рәвештә килеп чыккан хәлне соңга калып төзәтү шактый кыйммәткә төшә. Безгә барыбызга да моннан нәтиҗәләр чыгарырга кирәк.*

*Хәзер без чирек көчебезгә генә эшлибез. Берничә ай үтәр, ыгы-зыгы башланыр. Яңа идарәләр төзерләр, яңа кешеләр алырлар. Ә без двигательләр заводында эшне тиз генә бетереп, икенче мәйданга куча алыр идек. Моның турында хәзер үк уйларга кирәк түгелме икән?*

Эшче хәбәрче хаты буенча нинди чаралар күрелгән? Ә менә ниндиләр. Субайлар буенча еллык план октябрьдә үтәлгән. Нәтиҗәдә 1973 елда КамАЗга кирәкле 15 мең «җир якорьлары»ның төзүчеләргә ике меңләбен генә эшләргә калган.

Хәзер инде субай нигезләрнең өстенлегенә беркем дә шикләнми. Кою производствосы комплексында да кулланыла алар. Монда кичәге һәм иртәгәге аралашып бара. Нәкъ иртәгәге, ә бүгенге түгел. Ченки проектчылар да, төзүчеләр дә ачык белмиләр әле: җир асты сулары югары булган, ишелә торган балчыклы җирләрдә нишләргә? Кою заводы нәкъ шундый урынга туры килгән.

26 майда инженер Николай Кузьмич Снитко КамАЗның шушындый капризлы урынында беренче тәҗрибә ясап карады. Ә аннары китте, китте: ни утырып торырга вакыт юк, ни юньле йокы күргән юк.

Эштә мин Снитко белән берничек тә сөйләшә алмадым. Ниһаять, шулай да без аның уникенче каттагы балконында тәмле итеп чәй эчкәндә сөйләштек. Балконга шуңа чыктык — кичкенә Снитко тәмле төшләр күрә иде инде.

— ЗАГСка барырга житешә алмыйм. Бу өч айда кем генә булмады безнең кызчык: Анжелика да, Юлия да. Рита кушарбыздыр инде. Регистрациягә кертергә барырга һич вакыт тапмыйм.

Сөйләшүебез бик кызыклы булды. Николай минем блокнотка скважина схемасын ясады да аны бетонлауның серләрен бик бирелеп сөйли башлады. Шунда мин суны... су белән җиңеп булганын белдем. Яки скважина тирәли торбалар утырту белән... Яки балчык измәсе белән...

Муса Җәлил проспектындагы сары башнядан мин хәтта чыдамсыз төньяк горизонтларына каршы торырлык чаралар табыласына нык ышаныч белән киттем. Ул нәкъ шулай да. Шул ук атаклы Виктор Кузьмин, двигательләр заводында эшен данга күмеп тәмамлагач, кою заводында августта алтмыш, ә сентябрьдә өч йөзгә якын субай әзерләде.

Укучы, мөгаен, хикәяләүнең парадоксаль үзенчәлеген күргәндер: автор әле экономияләнгән «кубиклар» турында сөйли, шунда ук механизаторларның, бетончыларның төрле рекордлары турында яза. Гаҗәпләнерлек бернәрсә дә юк монда. Болар барысы да «Даешь КамАЗ 1974 елда!» дигән бер үк опера арияләре.

Монтажчылар да алардан калышмый. Бу операда аларның үз партияләре бар.

Кояшлы сентябрь көнен хәтергә төшерәм. Дизель производствосының оператив җитәкчесе, аның булачак бер цехының начальнигы — Герман Бажев белән без гигант корпусның түбәсенә менәбез. Аяк астында ташлар шыгырдый — түбәгә гравий сибелгән. Гомумән, анда үзеңне яхшы тапталган җирдә кебек хис итәсең. Аткы алырга да кузна уйнарга!

— Корпусның озынлыгы мең дә бер йөз илле ике метр, ә киңлеккә өч йөз алтмыш өч метр булачак,— ди Бажев.

Двигательләр заводында беренче колонна 1971 елның 25 сентябрендә куела. Монтаж эшләренең 95 проценты түбәгә туры килә. Бер ел эчендә тау кадәр металл һәм башка материалларны ничек итеп өрлекләргә күтәрә алганнар соң?

Юлдашым җавап урынына башын түбән таба какты. Анда бөтен корпус буйлап сузылган конвейер линиясе тора. Уртасындарак ул сынгандай була да, туксан градуска борылыш ясап, завод гөмбәзенә кереп югала. Бу заводлар заводы. Аның максаты түбә ябучылар эшен җирдәгедәй итү.

Югарыдан конвейерның бөтен звенолары күренә. Конвейер башында бер төркем кешеләр. Алар мегафон тоткан берәүне әйләндереп алып, аны дикъкать белән тыңлыйлар. Конструкцияләрне конвейерлап җыю һәм эре блоклап монтажлау буенча бөтен Союз алдынгы тәҗрибә мәктәбе бирелә.

Гади генә итеп әйтсәк, бу — КамАЗда түбәләрне гадәтләнгән тимер-бетон плиталар белән ябудан баш тарттылар һәм монтажлауны индустриаль юлга күчерделәр.

Илнең техник интеллигенциясе беренче мәртәбә бу яңалыкны 1970 елда ишетте. Ул вакытта төрле шәһәрләрдән Горькийга килгән кешеләр андагы автозаводның механик җыю цехы түбәсен конвейер методы белән ябуны күргәннәр иде. Горькийларның бу башлангычына партиянең 24 съездында А. Н. Косыгин зур бәя бирде. Төзелештә алдынгы тәҗрибәне өйрәнү һәм куллануның кирәклеген әйтеп, ул болай диде: «Аерым алганда, Горький автомобиль заводында эре цехларны конвейер ысулы белән җыю һәм төзүне кулланган СССР Минмонтажспецстрой һәм Минстройлары тәҗрибәсе игътибарга лаек». Шуннан бирле конструкторлык фикере бик нык алга китте, ул инде тәҗрибә стадиясеннән үтте. Менә хәзер 9 нчы бишьеллыкның төп төзелешендә кулланалар аны.

Нәрсә соң ул блоклар, конвейер үзе? Алдынгы тәҗрибә мәктәбенең стенограммасын карыйк. Гади блок утыз дүрт кисәктән тора.

Блокның озынлыгы — 24, киңлеге — 12 метр. Максималь авырлыгы — 56 тонна.

Бригадалар махсус технологик постларда эшлиләр. Конвейерда барысы уналты туктау урыны — металл кисәкләрен җыю өчен 8 е ачык һавада, 8 е бизәү-төзү эшләре өчен бина эчендә. Моңа кадәр әле кешелек Хеопс пирамидасын төзүче мисырлыларның осталыгына баш ия иде. КамАЗ блоклары шикелле конструкцияләр белән эш итә башласалар, бу тылсымияләренең зирәклеге дә көчсез булыр иде. Аларны җирдән ничек күтәрергә дә миллиметрларга кадәр төгәллек белән колонналарга ничек урнаштырырга?

Монтажчы каскасы кигән тылсым ияләренә Промстальконструкция институты сызымнары буенча Раменск механика заводы ясаган СКР-1500 краны ярдәмгә килде.

Ләкин КамАЗ Версавий Пан кебек рекордчылар тәрбияләмәсә, бер күтәргәндә алтмыш тонна авырлыкны егерме биш метр биеклеккә кадәр күтәрә торган баһадир кран да эре блоклап монтажлауга юл ача алмас иде.

Вуз дипломлы шәкертләр модалы куртка кигән бу эшче-профессорны зур дикъкать белән тыңладылар. Сораулар төрле яктан явып кына торды, эшче-профессор әле бер якка, әле икенче якка әйләнеп җавап бирергә чак өлгерде. Кыскача гына әйткәндә, аның сөйләгәннәре түбәндәгеләрдән гыйбарәт иде:

— Стальконструкция трестының Чаллы монтаж идарәсенә мин узган елның августында килдем. Миңа: «Конвейер төзергә барырсың, ә аннан соң сменага икешәр блок җыярсың», диделәр. Бу эш барып чыгар дип башыма да китерә алмадым. Башта безнең чыннан да бернәрсә дә барып чыкмады. Ул вакытта без егерме биш, егерме алтышар кеше эшләсәк тә, проектта күрсәтелгән норманы үти алмый идек. Хәзер сменага сигез-тугыз кеше чыксак та, планны артыгы белән үтибез.

Менә берничә кызыклы сан: узган елда гадәти монтаж вакытында безнең идарәдә кеше-көнгә ике йөз-өч йөз кг йөк туры килсә, хәзер бу күрсәткеч алты йөздән артып китте. Горькийларны без күптән узып киттек инде.

Минем егетләрнең уртача разряды 3,6. Асслар бармак белән генә санарлык. Ләкин яшь эшчеләргә төрле яктан специальләшү конвейерлап җыю серләрен тиз төшенергә ярдәм итә. Монтажчылар чылбырында без — башлап җибәрүчеләр. Шуңа күрә башкаларның уңышы да безгә бәйләнгән. Шулай булгач, блокларның алдан ук кассеталарга урнаштырылуын, ныклы график белән бирелүен тикшереп торабыз. Материаллар барысы әзер булып, башка күрше тукталышларда тоткарлык булмаса, конвейер монтажга кенәнә бишәр блок бирә ала.

Сөйләгәннәргә естәп шуны әйтәсе килә: автогигантның югары катында өч мең ярымга якын корыч ячейкаларны урнаштырасы бар, аларны җирдә ук «иң яңа модалы синтетик тунга» төрергә кирәк. Бу эш белән дүрт конвейер рәте шөгыльләнә. Кыска гына вакыт эчендә алар планлаштырылган темпны узып та киттеләр.

Нигезләр, түбәләр — КамАЗдагы фәнни-техник эзләнүләрнең глобаль башлангычы. Иҗади януның кечкенәрәк масштаблары белән монда һәр урында очрашырга була. Чаллыда килде-киттегә эшләүчеләр юк диярлек. Алар барысын да белергә, эшләп карарга тырышалар. Хәзергә әле белемең һәм тәҗрибәң азрак икән, йөрәгең эшкә җигелә.

Хәзер үк инде Камадагы бу шәһәргә туристлар маршрутлары салынган. Кызыклы кешеләрне эзләп буталмас өчен мин сиңа адресын әйтәм: Экскурсия автобусы аермачык төзелешнең «ноль меридианы»нда тукталыр. Анда кеше биеклегендә коелган «А»; «В»; «Т»; «О»; «З»; «А»; «В»; «О»; «Д» хәрефләрен күрерсең. Юлның ике ягында да баһадир корыч каркаслар. Ләкин онытма: синең фотоаппаратының объектына берьюлы сыймыйлар алар. «Д» хәрефе янынннан уңдарак сөзәк урыннан түбәнгәрәк төш тә «Б. Г. Лопатин бригадасы. СМУ-5 УС «Автозаводстрой» дигән вывесканы тап.

Әгәр син татар икәнсең — Галимовны, украинец булсаң — Дегтярьны, белорус булсаң — Картавицкийны, әрмән икәнсең—Мирзабекьянецны, чечен булсаң—Махмаевны сора. Бу егетләрнең һәрберсе үз ана телендә тимер-бетон конструкцияләр монтажлауның рекордларын сөйләр. Лопатинчылар тәүлеккә ике йөз алтмыш биш «кубик» бирделәр. Ә бу һәр кешегә 522 процент дигән сүз.

Кул көченә нигезләнгән Стаханов рекордлары заманы күптән үтте инде. Беренче бишьеллыкларның башка геройлары белән бергә камАЗлыларга язган атаклы хатка Стаханов та кул куйган. Ихтимал, синең исеңдәдер: ул хатта түбәндәгеләр әйтелгән иде: «*Без сездән көнләшәбез. Сезнең кулларда — куәтле хәзерге заман техникасы. Илебез аны бары тик хәзер — фәнни-техник революция эпохасында гына бирә алган мондый техника турында кайчандыр без хыяллана да алмый идек. Сезнең, җитмешенче еллар яшь эшчеләренең, үзләрен эштә күрсәтү мөмкинлекләре безнең утызынчы еллар белән чагыштырганда күп мәртәбә артык.*

*Хезмәт буенча безнең көрәштәшләр, безнең эшне ышанычлы дәвам иттерүчеләр өр-яңа техниканы иң рациональ файдаланып, алдынгы технология кулланып, алдынгы тәҗрибәне үзләштереп һәм җәелдереп билгеләнгән чикләргә ирешергә тиләвегез шатландыра безне*».

...Фамилиясе Лопатин булса да, керәк белән эшләми ул. СССРның 50 еллыгына багышлап, монтажчыларның ничек рекорд яулауларын белесең килсә, бригадир Борис Георгиевичны эзләп тап. Әгәр аның вакыты булса һәм сорауларың бик мәгънәсез тоелмаса, ул, мөгаен, синең белән яшел линолеум япкан өстәл янына утырыр да әңгәмәгә кушылыр. Яңа ел алды көннәрендә котырган буранда идарә начальнигы вагонын беренче мәртәбә чак-чак ничек эзләп тапканын да әйтер ул, Белояр атом станциясеннән КамАЗга командировкага килгәч, шушында калырга булган Саша Саморин белән танышуын да сөйләр.

Борис Георгиевич КамАЗга килгәнче Братскидагы алюмин заводы төзелешендә 10 ел бригадир булып эшли. Шуңа күрә ул эшне белә торган тәпле егетләрне җыярга тели. Әмма бирегә күбрәк монтаж исен иснәмәгән яшьләр килә тора. Шулай да аның шикләнүләре юкка булып чыга. Бу авыр профессиянең серләренә ул егетләр тиз төшенәләр. Бригада да эшне җиңеләйтүче җайланмалар производствога күп кертелгән. Шуның иң әһәмиятлесе — туннель панельләрен ташу өчен үзе электерепала торган ярымавтомат траверс.

Лопатин эскизлары буенча үзләре ясаган җайланма эшчеләргә тәүлеклек рекорд куярга һәм еллык планны 7 ноябрьга үтәргә мөмкинлек бирде.

* * *

...Егерме ел сизелми дә узып киткән. Күптәнме әле мин Степан Разинның кыю баркетләре исталеген саклаучы Идел ярына аяк баскан идем. Хәзер Разин кыялары тирәсендә бик күп заводлар үсеп чыкты. Шуларның иң зурысы көненә меңгә якын җиңел автомобиль бирә торган завод... Һәм хәзер Шишкин урманнары янында көненә ярты меңгә якын авыр йөк машиналары бирәчәк заводлар заводы салына.

Төзелеш чирәменә беренче аяк басканнан бирле күргәннәрнең барысын да сөйләп тә, язып та бетереп булмый. Шулай да бу урында Кузьма Камазкин исеменнән КамАЗ төзелешендәге кайбер әһәмиятле үзенчәлекләрне күрсәткән түбәндәге язманы телгә аласы килә.

### КАМАЗ — МИНЕМ АКАДЕМИЯМ

Тәзүчеләр көненә багышлана бу хикәя.

Бу көн якынлашкан саен уйланам: быел мин күпме яңа нәрсә белдем? Башка урыннарда бөтенләй очрамый торган нәрсәләрне дә күрергә ярдәм итте миңа КамАЗ.

Хәзер, бәйрәм алдыннан, кайбер вакыйгаларны хәтергә төшерәм. Менә Беренче май көннәре... Кешеләр, кешеләр, флаглар, транспарантлар, һәм кинәт сюрприз — алдына «КамАЗ» дип язылган машина. Соңыннан белдем: аңа утырып Лихачев заводы механигы Трибунских һәм аның иптәшләре трибуна яныннан узган икән. Ә моның өчен алар сәгатенә 85 километр тизлек белән Мәскәүдән Казанга килгәннәр.

Безнең булачак машинаның егерме ике үрнәге хәзер илебезнең төрле юлларында куәтләрен сынайлар. Әйтергә кирәк: «КамАЗ» үзенең нәрсәгә сәләтле икәнен күрсәтергә өлгерде инде. Хәтерегездәме, кинода күрсәткәннәр иде: ЗИЛның беренче директоры чит ил машиналары белән ком чүлендә бәйгегә чыга. Карап торуга килбәтсез генә булса да, безнең йөк машинасы ул вакытта да үзен аклаган иде. Хәзер дә шуңа охшаш сынаулар үткәрелде. Сынау автомобиле белән бергә стартка «Форд», «Мерседес», «Интернациональ» машиналары бастылар. Һәм нәрсә булган дип уйлыйсыз? Чит ил маркаларының барысын да безнең яңа авыр йөк машинасы узды.

Сер итеп кенә әйтәм: «КамАЗ»ның рулен тотып карадым мин. Машинаның кузгалып китү тизлеге 80 секундка бер километр.

Тыштан мотор һаваны кисәкләргә яргандай үкерә, ә кабина эче тып-тыныч. Утыргычы — патша тәхетедәй. Сиртмәле. Начар юлга туры килгәнсең икән — йомшарта аласың. Яки ашагач та юлга чыктың — селкенми торган ит. Комфорт.

Менә хәзер мин аңлыйм: безнең заводны тизрәк төзүгә илебез ни өчен бөтен көчен куя икән! Халык хуҗалыгына бу гаҗәеп йөк машиналарын тиз, бик тиз бирергә кирәк!

Горурланып вәгъдә бирәбез: йөзебезгә кызыллык китермәбез.

Төзүчеләр үзләренең бәйрәмнәрен каршылаган көннәрдә бетон салуның тәүлеклек күләме алты мең кубка якынлашты.

Бер кызыклы гына хәлне бөтен вагы-төяге белән китерәсем килә. Күптән түгел генә без газеталардан дөньяда иң зур Красноярск ГЭСы эшли башлаганын укыдык. Аңа КамАЗда салынырга тиешле күләмдә бетон салынган. Енисей ярларында кубикларны саный башлау 10 августта башланган. Ләкин елы... 1961.

Безнең төзелештә файдаланылган барлык техник һәм технологик яңалыклар санап бетерерлек түгел. Бораулап-төеп тутырылган субайлар үзләре генә ни тора! Чаллыда бу турыда бөтен Союз конференциясе дә уздырылды, бөтен Союз алдынгы тәҗрибә мәктәбе дә эшләде. Безгә төрле илләрдән техника килә. Безнең КамАЗ егетләре диңгез арты могҗизасына карыйлар да үзебездә моннан да яхшыны уйлап табарга иде, диләр. Һәм уйлап таптылар да: көю заводы мәйданында рәсми булмаган исемле «Иван-Като» буровой установкасы шулай барлыкка килде...

Кузьма әйткәннәргә шуны да өстәргә кирәк. Күптән түгел партиянең Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Т. Троицкий журналистлар белән очрашу вакытында көлә-көлә бер шаян җыр әйткән иде. «КамАЗ строится, время катится — кто не пишет о нем, ох, и хватится!» Моны мин мыегыма чорнадым. Һәм КамАЗдагы дусларым, укучылар алдында җавап бирәсем килде. Җырга тиң эшләр турында проза белән булса да язып, дусларыма тәкъдим итәм.

## Фәләх Насыйров

# ӘЙДӘП БАРУЧЫ



— И Разия җаным, нишләргә дә белгән юк бу яшьләр белән,— дип башлады сүзен Әтнә «Сельхозтехника» бүлекчәсе партия оешмасы секретаре Зәкия Хәсәнова.

Парткабинет мөдире Разия Хәбибуллина дустына сабыр гына күз ташлады да:

— Ә нәрсә булган хәзерге яшьләргә? — дип, сорауга каршы сорау бирде.

— Рәхәт тормышның кадерен белмиләр. Безнең кебек, ач килеш, үгез җигеп җир эшкәртергә, язгы пычракта бата-чума чәчүлек орлык ташырга туры килмәде шул аларга...

— Аның заманы шундый иде, Зәкия дустым,— диде Разия, авыр сулап.— Хәзер шул тормыш икенче инде...

— Алайса, яшьләребезнең җәмәгать эшләрендәге пассивлыгын табигый хәл дип саныйсыңмыни?

— Минем алай дип әйткәнем юк әле,— диде аны бүлеп Разия.— Ә производствода ничек эшлиләр соң алар?

— Эшләүләре зарланырлык түгел. Әмма эштән соңгы вакытларын файдалы итеп үткәрә белмиләр. «Зәңгәр елан»ны дус иткәннәре дә юк түгел...

— Син бит партоешма секретаре! Буш вакытларын күңелле, файдалы итеп уздыру чарасын күр. Әйтик, армиягә китүчеләр өчен кичәләр уздырырга буламы? Була. Әгәр анда Ватан сугышында катнашкан кешеләрне, хезмәт ветераннарын чакырсаң, аларның чыгышларын оештырсаң, соңыннан яшьләр көче белән концерт куеп җибәрсәң — буш вакытны күңелле итеп уздыруның менә сиңа бер төре. Икенче төре — яшьләрне җәлеп итәрлек кызыклы лекцияләр уку, аерым темаларга диспутлар, сорау һәм җавап кичәләре уздыру... Ярдәм кирәк булса, кил.

— Рәхмәт.

Якын дусты белән булган бу сөйләшү Разия күңелендә яшьлек хатирәләрен уятты. Зәкия чыгып киткәч, ишекле-түрле әйләнде дә өстәл тартмасыннан бер папка чыгарды. Бу аның шәхси архивы. Вакыт узу белән инде саргая төшкән газета мәкаләләрен, аерым брошюраларны алып, аларны бер-бер артлы актара башлады. Таушалып беткән бер кәгазьгә текәлеп, ул кинәт туктап калды. Аның күз алдына балалык, яшьлек еллары килеп басты. Яшьлек елларын кеше гомеренең иң бәхетле чоры дип атыйлар. Ә бу кеше гомеренең бәхетле чоры Разия тормышында булды микән?.. Тормыш ачысын-төчесен бик иртә татырга туры килде шул аңа. Язмыш, үзе туганчы ук, ятимлек ярасы әзерләп куйган иде. Ул дөньяга килүдән ике ай элек үк әтисе үлеп киткән. Унөч яшеннән үк үз тамагын туйдыру турында үзе кайгыртырга кереште. Куенына бер телем икмәк кыстырып, иптәш кызы Зәкия белән җәяүләп Казанга чыгып китте. Кесәләрендә бер тиен акчалары юк. Көч-хәл белән калага җитеп, ниндидер ишегалдының капка артында ике төн кунганнан соң: «Инде нишләргә, кая барырга?» — дип аптырап торганда, аларга җитен комбинаты эшчесе Газиз ага

Тәхфәтуллин очрады. Рәхмәт яугыры, аларны бу авыр хәлдән шул коткарды. Ачы ялангач кызларны ФЗУга илтеп, тулай торакка урнаштырды. Бик әйбәт киңәшләр бирде. Разия шунда укыганда, кичке мәктәпкә йөреп, урта белем алды, үз группасында комсомол оешмасына җитәкчелек итте, үзешчән сәнгать түгәрәкләрендә актив катнашты. Оештыручанлык сәләтен искә алып, аны Чистайдагы берьеллык партия-совет работниклары хәзерләү мәктәбенә җибәрделәр. Мәктәпне тәмамлагач, ул туп-туры үзенең туган авылы — Әтнәгә кайтып төште. Партия райкомында инструктор булып эшләде. Бөек Ватан сугышы башлангач, ВЛКСМның Әтнә райкомы беренче секретаре итеп сайланды. Менә шунда инде ныклыкка, җитлеккәнлеккә каты сынау үтте.

Фашист илбасарлары Ватаныбызга бәреп керү белән, комсомоллардан, фронтка җибәрүне сорап, бер-бер артлы гаризалар ява башлады. ВЛКСМ райкомына беренчеләрдән булып элемтәче Хәлим Нигъмәтуллин, Киров исемендәге колхоз ветфельдшеры Мәһинур Хәкимова, Кабакса авылы укытучысы Сәлим Мәгъсумовлар килде. Аларның һәм башка бик күп яшьләрнең теләкләре тиздән канәгатьләндерелде. Авыр бәрелешләрдә алар үзләрен кыю һәм батыр сугышчылар итеп таныттылар. Сәлим Мәгъсумов, мәсәлән, гади танкисттан капитан дәрәҗәсенә үсте. Тик ул үзенең туган Әтнә якларына яңадан әйләнеп кайта алмады. Канлы сугышларда батырларча һәлак булды. Җөлби авылы егете снайпер Нургали Хәсбиуллин Кызыл Армиянең 25 еллыгына бүләк итеп, 16 фашистны «теге дөньяга» озатуы турында райкомга хәбәр итте. Үртәм авылы комсомол оешмасыннан киткән Зәйтүнә Бариева шушы үк датага 76 кызылармеецны ут эченнән алып чыгып, аларның тормышларын саклап калуы турында хат язды. Әтнә комсомол оешмасыннан киткән Зәкәрия Фазылҗанова да хөкүмәтебезнең югары бүләгенә лаек булды.

Илебезнең, халкыбызның азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен фронтта арысланнардай сугышкан, комсомол антына турылыклы булган яктәшләры белән Разия чиксез горурланды һәм шатланды. Бер үк вакытта үзенең дә шулар янында буласы, үз кулы белән гитлерчыларны кырасы, аларны юк итәсе килде. Әмма, күпме генә сораса да, ул бер җавап ишетте:

— Син — партия солдаты. Тылда да син бик кирәкле кеше.

Әйе, дәһшәтле сугыш елларында тыл — икенче фронт иде. Монда да җиңел булмады. Авырлыкларны җиңәргә чыныккан, халык массасын партия карарларын үтәргә туплардай, аларга рухи азык бирердәй оештыручылар бик тә кирәк иде. Башында Разия Хәбибуллина торган Әтнә комсомол комитеты, партия оешмасы җитәкчелегендә, нәкъ әнә шундый рольне үтәде дә.

Яз җиттеме, хатын-кызларның, кечкенә чаналар тартып, чәчүлек орлыгын Арчадан җәяүләп ташуларын райкомол секретареның беркайчан да онытасы юк. Аяк асты пычрак, халык ач. Шулай булуга да карамастан, берсе дә эшкә сыкранып бармады. Бу эштә дә, беренчеләрдән булып, комсомоллар инициатива күрсәттеләр, алар баш-лап йөрделәр. Сыерларны җигәргә өйрәтүдә, алар белән җир сөрүдә булмасын, фронтка җылы киемнәр җыеп озатуда дисеңме — боларның барысын да комсомоллар күтәреп алды, алар башлап йөрде. Самолетлар эскадрильясы төзүгә Бәрәзә комсомол оешмасы секретаре Хәйретдинова бер мең сум, Киров исемендәге колхоздан Гатауллина, Галимовалар берәр мең сум акча керттеләр. Кыска гына вакыт эчендә өч миллион 150 мең сум акча тупланды. 670 пар киез итек, 500 данә телогрейка, 1100 бүрек, өч мең тире, бер тоннадан артык йон, 300 тун һәм башка бик күп җылы кием фронтка озатылды. Алар арасында, әлбәттә, Разияның үзе теккән, үзе бәйләгән киемнәре дә бар иде. Бар иде генә түгел, патриотлыкның шундый гүзәл үрнәкләрен башлап ул үзе күрсәтте, ялкынлы сүзләре белән халык йөрәгендә явыз дошманга ачы нәфрәт хисе уятты.

КПСС райкомы члены, райкомолның беренче секретаре буларак, аңа башкаларга караганда зуррак җаваплылык йөкләнде. Йөкнең авыррагын аңа тартырга туры килде.

Шулай «Йолдыз» колхозына урып-җыю чорында вәкил булып килгәч, аңа:

— Син, Разия, тазарып киткәнсең әле,— диделәр.

Әмма моның нинди «тазалык» булуын өч көннән соң гына аңладылар. Өч тәүлек буе ул көне-төне кырда, халык арасында булды. Авылдагы бөтен кечкенә игеннәрне

тукми-чәчми җыеп алуга тупланды. Кешеләр эшләгәндә читтән генә карап тора торган җитәкчеләрдән түгел иде ул. Урагын да урды, ашлык сугтыруда да катнашты. Ындыр табагында тәмам хәлдән таеп, салам өстенә барып егылгач, ниһаять, түзмәде, кешеләрдән ярты уч чи арыш алып ашады. Шул чак, килгән кеннең «Тазарып киткәнсең, Разия» дигән апа, аның янында туктап калды. Вәкилне беренче мәртәбә күргәндәй гаҗәпләнеп, аңа карап торды.

— Һай, җаным! — диде ул, кулларын җәеп.— Син бит шешенгәнсең!.. Ә мин...

Бу сүзләрдән соң, никтер, аның күңеле тулып китте. Күзенә тыгылган яшьләрен күрсәтмәскә теләп, башын читкә борды.

— Безгә килгәннән бирле ашаган ризыгың булдымы соң, Разия җаным?..— диде өлеге апа, тирән борчылу белән.

— Синдә бер чокыр сөт эчкән килеш...

— Ай, алла-а-а!.. Өч көнгә бер чокыр сөт! Ник соң миңа әйтмәдең? Берәр әйбер табып ашатыр идем...

— Үз балаларың да ач бит, апа җаным! Үзең дә кечкә йөрисең. Һәркемнең шулай: искесе — беткән, яңасы — өлгермәгән. Боларның барысын да мин күрәм, беләм бит...

Аннан ул бөтен җегәрен җыеп, аягына басты.

— Ашлык сугуны, зинһар, туктата күрмәгез. Фронтка икмәк кирәк. Анда синең дә ирең бар. Ә мин басуга, уракчылар янына киттем...

Разия, арбага утырып, атның дилбегәсен тартты. Башкасын ул хәтерләми. Юлда аңа Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе Гали ага Динмөхәммәтов белән район партия комитеты секретаре Шакиров очраган. Алар арбада ачлыктан шешенеп, аңын югалтып яткан Разияны күреп алганнар һәм аны тиз генә больницага илтеп салганнар.

Сугыштан соң Хәбибуллинага Хезмәт Кызыл Байрагы орденын тапшырганда, аның кулын кысып:

— Бу бүләккә лаек син! Бөтен авырлыкны үз өстеңә алып тарттың! — диде аңа Динмөхәммәтов.

Хәзер инде Динмөхәммәтов үзе юк. Ә аның сүзләре Разияның йөрәгенә бик тирән сеңеп калган. Күңеленә мәңге уелмаслык булып кереп урнашкан андый вакыйгалар Разия тормышында аз түгел. Аларның кайберсе, йөрәгенә ял биреп, горурлык хисе уятса, икенчеләре төзәлмәс яра булып исенә төшкәндә әле һаман да күңеле әрну-сыкрау хисе белән тула. Алар арасында иң авыры, иң газаплысы — беренче мәхәббәтен, сөеклесен фронтта югалту иде.

Ватан сугышының беренче көннәреннән алып Разия Хәбибуллина Әтнә кызларының фронтка киткән якташлары белән тыгыз элемтәдә торуларын оештырды. Кызлар җылы киемнәр һәм башка бүләкләр җибәрү белән бергә, һәр яшь йөрәккә барып җитәрдәй бик җылы хатлар яздылар. Аларның байтагы фронт газеталарында басылды. Менә «Ватан өчен сугышка» газетасының 1943 ел, 7 октябрь санында урнаштырылган «Җиңеп кайтыгыз!» дигән мәкалә:

«Күптән түгел без якташларыбыздан, Татарстанның Әтнә районы комсомолецларыннан, кайнар хат алдык. Менә алар безгә, фронтовикларга, нәрсә язалар:

— Кадерле сугышчыларыбыз, якын дусларыбыз!

Кызыл Армиянең көннән-көн алга баруы, яңадан-яңа шәһәрләрне явыз немец илбасарлардан азат итүе безнең күңелләрдә чиксез шатлык тудыра һәм безне яңадан-яңа хезмәт батырлыкларына рухландыра.

Гражданнар сугышы чорында да, тыныч төзелеш елларында да, Бөек Ватан сугышы кырларында да чиксез батырлык күрсәткән Ленин комсомолының тиздән 25 еллыгы була. Бу данлы юбилейны яңа җиңүләр белән каршы алыр өчен без бөтен көчебезне биреп тырышабыз. Ышаныгыз, без тылда сынатмабыз. Фронт өчен кирәк булган барлык нәрсәләрне бирербез. Ә сез дошманны кыйнагыз, сытыгыз һәм тизрәк җиңеп кайтыгыз!

Без сезне бик сагынабыз. Айлы төндә ашлык сукканда яисә игеннәрне эскерткә салганда сез искә төшәсез. Якты ай безгә карап үзенең нурын сибә. Ул безгә яхшырак эшләгез, бу минутта сезнең дусларыгыз, сөйгәннәрегез дошманны аяусыз кыйныйлар, дип әйтә шикелле.

Без Әтнә районы комсомоллары исеменнән бер танк сатып алдык. Ул танк юбилей көнне фронтта булыр. Без сезгә бүләкләр әзерлибез, кичләр утырып аулыклар, янчыклар чигәбез, кыш өчен җылы киемнәр әзерлибез. Өмәләр оештырып, җылы оеклар, бияләйләр бәйлибез. Шунда сезне сагынып җырлыйбыз да.

Якын дуслар! Без татар егетләренең сугыш кырларында гайрәтлелек һәм каһарманлык үрнәкләре күрсәтүләренә, немец һәм ак фин этләрен рәхимсез рәвештә кыйнауларына ышанабыз. Шуңа күрә без сезне йөрәкләребездәге иң саф мәхәббәт белән яратабыз һәм сөябез.

Комсомолларча сәлам белән, хат аша кулларыгызны кысып, районның яшьләре, комсомоллары исеменнән Әтнә райкомолы бюросы членнары: Хәбибуллина, Еникеева, Хәкимуллина, Әскәрова, Сабирова, Мөхәммәтрәхимова, Вәлиева, Гибадуллина, Сафина».

Бу хатка каршы сержант Н. Исмәгыйлов «Дусларга җавап» шигыре яза. Ул да газетаның шул ук санында басыла.

**«Сугыш тынды. Тирән траншеяда,**
**Дзотларда, блиндаж эчендә**
**Без укыйбыз сезнең хатыгызны,**
**Шатлык ташып тора күңелдә.**
**Айлы кичләр, ындыр табаклары**
**Күз алдына килеп басалар,**
**Баш өстендә талгын ак болытлар**
**Көнчыгышка таба агалар.**
**Алар сөйләр безнең батырлыкны,**
**Алар сөйләр безнең сәламне,**
**Ышаныгыз, кара тап төшерми,**
**Ал кан тамган кызыл әләмне**
**Ут һәм давыл аша без илтербез**
**Җиңү сәгатьләре җиткәнче.**
**Ашкынабыз, тынычлык юк безгә**
**Фашистларны тар-мар иткәнче.**
**Баш өстендә агыла ак болытлар,**
**Күп өсләре аксыл томанлы;**
**Рәхмәт җылы сәлам хатыгызга,**
**Без үтәрбез сезнең кушканны!»**

Фронттан килгән бу хатны укыганнан соң, Разия бер төркем иптәш кызларын җыеп ала да:

— Әйдәгез, без дә аларга шигъри хат язабыз! — дип киңәш итә. Һәм шундук алар төн утырып хат язарга керешәләр. Бу хат та шул ук газетада, редакциянең менә мондый кереш сүзе белән басыла:

«Карелия фронтында зур батырлык һәм йөрәклелек үрнәкләре күрсәтеп, немец һәм ак фин илбасарларына каршы аяусыз көрәшүче татар егетләренә Олы Әтнә кызлары язалар бу хатны. Сугышчы иптәшләр, сез бу хатны укыгыз һәм ару-талуны белмичә фронт өчен азык хәзерләүче патриоткаларның наказын тулысынча үтәгез. Кызларга җавап хаты язу өчен үзегезнең сугышчан эшләрегезне күрсәтеп, редакциягә хәбәрләр языгыз.

Һәр пуля, һәр мина, һәр снаряд һәм граната дошман йөрәген актарсын, аның оборона корылмаларын күккә очырсын. Безнең гүзәл Ватаныбыз өчен, тормышыбыз, бәхетебез һәм мәхәббәтебез өчен!»

Аннан соң Әтнә кызлары язган шигъри хат урнаштырылган:

**«Ай-һай, аккош, ай-һай, аккош,**
**Ике әйлән дә монда төш.**
**Канатыңа хатлар куйдым,**
**Дуслар кайда — шунда төш.**
**Илебезнең данлы геройлары,**
**Арысландай кыю егетләр!**

Сезгә оча безнең яшь күңелләр,
Сездә безнең бөтен өметләр.
    Сәлам яздык сезгә, әй, батырлар,
    Таңда алар барып җитсеннәр,
    Вәгъдә итеп дуслык һәм мәхәббәт,
    Таң җилләре сезне үпсеннәр.
Бәлки постта, бәлки походта сез,
Без бу хатны язган чагында,
Барасыздыр бәлки штурмга
Ямьле майның алсу таңында.
    Без үзебез монда, ә күңелләр
    Сезнең янда, дуслар, сизәмсез,
    Кайда гына, кайда йөрсәгез дә,
    Йөрәктә сез, шуны беләмсез!
Борчылмагыз басу-кырлар өчен,
Игеннәребез күкрәп үсәләр,
Бакчаларда сез кайтканны көтеп
Мул уңышлар кызарып пешәләр...
    Көмеш ак сакаллы, көмеш чәчле,
    Күз нурыдай әти-әниләр:
    «Дошман бетсен,— диләр,— улым җиңсен!»
    Һәр көн сезгә теләк телиләр...
Җиңүчеләр булып сез кайтыгыз
Туган-үскән матур якларга,
Каршыларбыз гөлчәчәкләр сибеп
Сез киләсе барлык юлларга.

Сәлам белән кулларыгызны кысып, яңа сугышчан уңышлар теләп, Олы Әтнә кызлары исеменнән Разия Хәбибуллина, Саимә Гибадуллина, Зәйнәп Әхмәтова, Тәзкирә Сәләхетдинова».

Бу хатларны меңнәрчә сугышчы укып, аларны үзләренә наказ итеп кабул итә. Алар арасында Разияның сөйгәне — Нури Сәмигуллин да булгандыр, әлбәттә. Тик алар кабат кавышу бәхетенә ирешмәделәр: каты сугышларның берсендә бу кыю танкист бик күп фашистларны кырып, батырларча һәлак була.

Үзенең олы кайгысын Разия хезмәт белән басарга теләде. Күп кырлы политик һәм оештыру эшчәнлегенә алып бару белән бергә, ул киеренке тормышта яшәүче авыл эшчәннәренең ял вакытларын күңелле итеп уздырулары турында кайгыртты. Ул Әтнә культура йорты советы члены итеп сайлангач, культура учагының эше бик нык үзгәрде. Анда агротехника, әдәбият, драма һәм хореография түгәрәкләре оештырылды. Авыл хуҗалыгы һәм политик темаларга укыла торган лекцияләр ешайды, аларның эчтәлеге яхшырды. Культура йортында яшьләрнең тематик кичәләре әледән-әле уздырыла башлады. Драмтүгәрәк эшендә дә ул актив катнашты. Бик күп спектакльләрдә төп рольләрне үзе башкарды.

«Совет Татарстаны» газетасының 1950 ел, декабрь ае санында «Җыр көчлерәк яңгырасын» дигән мәкалә басылган. «1945 елда үзешчән сәнгать түгәрәкләренең район смотры булды,— диелгән анда.— Аңа ВЛКСМ райкомы секретаре Разия иптәш Хәбибуллина җитәкчелек итте һәм башлап җырлаучы булып, үзе дә аның составына керде. Шушы вакыттан алып районда яшьләрнең җыр һәм бию ансамбле оештырылды.

Эшне башлап җибәрү җиңел булмады. Төрле авылларда яшәүче яшь талантларны эзләп табарга, җыр техникасы, музыка белеме белән әле яхшы таныш булмаган яшьләрне тупларга, аларны күмәк җырлауга өйрәтергә һәм сәхнәгә чыгарга кирәк иде...

Халык җырларына, халык моңнарына мәхәббәтләре көчле булган, ләкин моңа кадәр теге яки бу көйне аерым рәвештә генә башкарып килгән яшьләр, күп тә үтмәстән, дус һәм бердәм иҗат коллективына берләштеләр...

«Салкын чишмә» исемле әдәби-музыкаль монтажны башкарып, алар үзешчән сәнгать коллективларының 1945 елда үткәрелгән республика смотрында беренче урынны алдылар.

Коллектив членнарының осталыгы көннән-көн арта, баетыла барды. Программаның идея-политик дәрәҗәсен туктаусыз үстерүгә зур игътибар бирелде. Нәтиҗәдә, «Эш иртәсе», «Туган ил», «Бәйрәм таңы» исемле яңа әдәби-музыкаль монтажлар, «Әтнә», «Уфа-Чиләбе», «Тәймә», «Челтәр элдем читәнгә» һәм башка яңа көйләр барлыкка килде».

«...12 ел эчендә Әтнә ансамбле яхшы оешкан бердәм коллективка тупланды,— диелгән 1968 елда Казанда басылып чыккан «Авылда культура-агарту эше» исемле китапта.— Аның составы да зурайды, анда хәзер 50 кеше катнаша. Репертуары баеды, башкару осталыгы үсте».

Татарстан һәм Россия Федерациясе күләмендә уздырылган үзешчән сәнгать смотрларында катнашып, аларда беренче урыннарны яуларлык ансамбль коллективы туплау өчен күпме көч һәм тырышлык куйганын Разия үзе генә белә. Ул вакытта ансамбль баянчысы булып кечкенә генә укучы бала Хатип Галиев (хәзер Әтнәдәге авыл хуҗалыгы техникумы директоры) йөрде. Ул бик тиз арый, авырлыклар килә башлады исә:

— Разия апа, мин арыдым,— дип, аның алдына ятып йоклый иде.

Авыр булса да, алар үз алларына куйган максатка ирештеләр. 1957 елда Мәскәүдә узган татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында катнашу, башкала сәхнәләрендә чыгышлар ясау — ансамбль членнары өчен иң зур шатлык һәм бәхет булды. Шунда, ансамбль җитәкчесе Разия Хәбибуллинага хөкүмәтебезнең тагын бер зур бүләге — «Почет билгесе» ордены тапшырылды...

1949 елда ВЛКСМның XI съездында делегат булып катнашу да Разиянең күңелендә бик тирән эз калдырды. Партия һәм хөкүмәт җитәкчеләре белән очрашу — аның күңелендә иң кадерле хатирә булып саклана. Разиянең шәхси архивында «Комсомольская правда» газетасының 1950 ел, май аенда басылган «Әйдәп баручы» дигән бер мәкалә саклана. «ВЛКСМның Әтнә райкомы секретаре Разия Хәбибуллина яшьләр арасында зур авторитет казана,— дип башланган ул.— Үзенең гомуми һәм политик белемен күтәрү өстендә өзлексез эшли. Китап, газета-журналлар — аның иң якын дуслары. Яшьләр нинди генә сорау белән мөрәҗәгать итсәләр дә, ул аларга тулы һәм ачык итеп җавап бирә. Разия үзен бик гади, тыйнак тота. Үзенең белеме белән беркайчан да масаймый. Киресенчә, үзе белгәнне тизрәк яшьләргә җиткерергә ашыга. Менә шул сыйфатлары яшьләр күңелен үзенә тарта... Разия һәр вакыт яшьләр арасында. Хуҗалыкларда аны иң кадерле кунак итеп көтеп алалар. Килү белән ул халыкны дөнья хәлләре белән таныштыра, яшьләргә яңа көй өйрәнергә булыша, яңа уеннар күрсәтә, кызыклы китаплар укырга киңәш итә. Беренче булып җырын башлый, я биеп китә. Кырга чыкса, колхозчылар белән иңгә-иң басып, җиң сызганып эшли.

Барлык спорт ярышларында һәм үзешчән сәнгать смотрларында беренче урынны алуны райкомол секретареннан беркем дә таләп итми. Әмма комсомол җитәкчесе, яшьләр арасында эшләүче буларак, ул үзенең яше белән генә түгел, иң мөһиме, үзе артыннан яшьләрне ияртердәй, аларга үрнәк күрсәтердәй ташып торган энергияле, яшь күңелле булырга тиеш. Разия нәкъ әнә шундый сыйфатка ия».

Бу юллар язылганга инде чирек гасырга якын вакыт узуга карамастан, һаман да ул әлеге күркәм сыйфатларга ия. Дөрес, хәзер инде Хәбибуллина байтактан бирле партия эшендә, КПССның Арча райкомының Әтнәдәге парткабинет мөдире. Авыр елларда аның белән бергә эшләгән, комсомолга ул әзерләгән, тормышта беренче чыныгуны аның җитәкчелегендә алган бик күпләр хәзер шулай ук җаваплы постларда.

Заманында Ленин исемендәге колхозның комсомол оешмасына ун елга якын җитәкчелек иткән кырчылык бригадасы бригадиры Гатау Гыйззәтуллин байтактан партком секретаре булып эшли. «Үрнәк» колхозы комсоргы Габделфәрит Гыйләҗев тә, югары белем алып, партия хезмәткәре булып китте. Жданов исемендәге хуҗалыкның элеккеге комсомол оешмасы секретаре Габделхак Ахунҗанов — агроном. Ансамбльдә катнашып йөргән яшьләр арасыннан да кемнәр генә чыкмады һәм хә-

зер алар кайда гына эшләмиләр! Мәсәрә Миначева — Әтнә урта мәктәбендә укуукыту эшләре буенча директор урынбасары, Әдһәм Сәмигуллин — «Игенче» колхозы председателе, Фәрит Габдуллин — СМУ директоры... Бу исемлекне бик озак дәвам итәргә мөмкин булыр иде. Аларның һәркайсы белән Разия бүген дә тыгыз элемтәдә тора, аларга киңәшләр бирә, кирәк чакта ярдәм итә. Ялгышлыклары булганда халык алдында ачы итеп тәнкыйть итүдән дә тартынып тормый. Ул аларның авыр сугыш елларындагы кебек үк партия эшенә турылыклы, кешеләргә игътибарлы булуларын, җәмәгать байлыгын күз карасыдай саклап, аны арттыру өчен көчләрен кызганмый, вакытлары белән хисаплашмый, икеләтә-өчләтә энергия белән эшләүләрен тели.

Әйтергә кирәк, Хәбибуллина күп яктан аларга үзе үрнәк күрсәтә. Ул җитәкчелек иткән парткабинет партия оешмалары; агитколлектив һәм пропагандистларның чын мәгънәсендә сугышчан штабына әверелгән.

Әтнә зонасына өч совхоз һәм егерме колхоз керә. Партиянең район комитеты вәкиле буларак, Разия әледән-әле шул хуҗалыкларда була, алардагы башлангыч партия оешмаларының эше, коммунистларның үз белемнәрен күтәрүләре, политик мәктәпләрнең эшләре белән якыннан кызыксына. Пропагандист кадрларны сайлап алу, аларны үстерү, аларга методик ярдәм күрсәтү — болар барысы да парткабинет мөдире естендә.

Әгәр кайда да булса партия, комсомол яки колхозчыларның гомуми җыелышы була икән, аларга да ул катнашмыйча калмый. Һәр кешенең йөрәгенә барып житәрдәй ялкынлы чыгышларында иң актуаль мәсьәләләрне күтәрә. Болардан тыш, концерт, спектакльләрдә катнашырга да вакыт таба ул. Шул хезмәтләре өчен, КПССның Татарстан өлкә комитеты бюросы, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы, Татарстан АССР Министрлар Советы һәм профсоюзларның Татарстан өлкә советы президиумы карары белән, ул Ленин юбилеена багышланган республика Хезмәт даны китабына кертелде.

Разия Хәбибуллина һаман да сафта, ул һаман да тормышның алгы сызыгына әйдәп баручы.

Йолдыз Вәлитова

# ТЕАТРЫБЫЗНЫҢ ТАҢ ЙОЛДЫЗЫ

1905—07 елларда Казан, Уфа, Оренбург шәһәрләрендә оешкан беренче театр труппалары татар халкын рухи тәрбияләү, агарту буенча зур эш башлап җибәрделәр. Милли театрыбызның бу беренче карлыгачлары, күп төрле авырлыкларны җиңеп, бихисап мәхрүмлекләр кичереп булса да, халкыбыз күңелендә яз ясау, бәхет кояшын чыгару өчен фидакарьләрчә көрәштеләр.

Беренче сәхнә фидакарьләре арасында, атаклы Габдулла Кариевлар, Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаялар белән бергә, Зөләйха Богданова кебек, аларның сәхнә традициясен күтәреп алучы һәм уңышлы дәвам итүче яшьрәк артисткалар да бар иде.

Зөләйха Богданова 1886 елның 18 сентябрендә хәзер Арча районына керә торган Үрнәк авылында туа. Кызга өч яшь тулар-тулмас аның әтисе үлә. Шуннан соң кечкенә Зөләйха белән әнисе Казанга киләләр. Ә шәһәрдә аларны тагын да зуррак кыенлыклар көтә. Анда алар әнисе белән икәүләп иртәдән кичкә кадәр тир түгәләр. Кер юучы да, хезмәтче дә, пешекче дә булырга туры килә аларга. Ләкин бу эшләрнең берсе дә ана белән кызның хәлен җиңеләйтми.

Бераз үсә төшкәч Зөләйха Крестовниковлар заводына эшкә керә. Бу да аларның тормышына әллә ни җиңеллек китерми. Киресенчә, анда алты ел буена авыр хезмәт башкару Зөләйханың сәламәтлегенә генә зыян итә — аның күзләре начар күрә башлый. Ул уң күзенә операция ясатырга мәҗбүр була. Күзе төзәлгәч, Зөләйха яңадан заводка кайтырга уйлый, тик анда: «урынында кеше эшли инде» дип кызны кабул итмиләр. Зөләйхага яңадан әнисе белән бергә кер юу кала. Бу авыр, күңелсез эштән тәмам туйган Зөләйханы вакыты-вакыты белән күңелсез уйлар, төшенкелек билә ала, тормыш аңа тоташ караңгылык булып күренә башлый.

Ләкин ни генә дисәң дә тормыш кайчагында елмая да белә бит әле ул. Көннәрнең берендә «Сәйяр» труппасының спектаклен карау яшь Зөләйха өчен әнә шундыйрак вакыйга була. Беренче мәртәбә театр карау аның тормышына ямь кертеп җибәрә. Шуннан соң инде, кечкенә генә мөмкинлек чыгу белән бөтен эшен ташлап, ул театр карарга чаба башлый. Бераздан артистлар да театр карарга йөрүчеләр арасыннан булачак артистканы танып алалар. Начар гына киемнәрен дә килешле итеп киенгән бу кызның спектакльләр вакытында үзен-үзе онытып утыруы аларга бик ошый.



Һәм менә Зөләйха өчен онытылмаслык көн килеп җитә. 1910 ел. Көзнең бер салкын көне. Күшегеп беткән кулларына тәргәк белән кер күтәргән Зөләйха ашыга-ашыга өенә кайтып бара. Шул вакыт аның каршына һич уйламаганда артистка Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская килеп чыга. Аның Зөләйхаларга барышы икән. Нинди йомыш белән диген әле?! Зөләйханы чын артист, профессиональ артист булырга үгетләү өчен килә икән бит. Зөләйха башта моңа ышанырга да, ышанмаска да белми: ул ничек инде Сәхипҗамал туташ кебек артист була алсын! Юк, мөгаен, шаяртадыр әле бу Сәхипҗамал апасы.

Ләкин Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская һич тә шаяртырга җыенмый икән. «Сәйяр» труппасына хатын-кыз артистлар җитми, ди. Һәм әнә шундый вакытта «Сәйяр» труппасы җитәкчеләре яшь кызда ул әле үзе дә сизмәгән сәләт һәм сәхнәгә, сәнгатькә мәхәббәт барын күреп алалар, аны труппага чакырырга кирәк дигән фикергә киләләр.

Күңеле бу кадәр бәхетле һәм шул ук вакытта каршылыклы хисләр белән кайнаганы бар идеме икән әле Зөләйханың? Аның якты хыялын тормышка ашырасы, театр дөньясында яшәп карыйсы да килә, шул ук вакытта үз-үзенә ышанып җитмәү, зур адым ясар алдыннан була торган шикләнү дә юк түгел. Аның өстенә Зөләйха әнисе турында да уйлана: кызының бу юлдан китүенә ул риза булырмы соң?

Сәхипҗамал туташ белән озак кына сөйләшкәннән соң, ана кызының «Сәйяр» труппасында артистка булып эшли башлавына риза була. Шулай итеп, Зөләйха Богданованың сәхнә тормышы башланып китә. Чын артистка булу теләге белән хыялланган кызга үз максатына ирешү өчен барысына да — укый һәм яза белергә дә, матур итеп, зәвык белән киенергә дә, һәм иң әһәмиятлесе, сәхнәдә үз-үзен тоту осталыгына да өйрәнергә туры килә. Ләкин тормышның ачы-төчесен күп күргән Зөләйхада бу кыенлыкларны җиңә алырлык көч җитәрлек була. Үзенә тапшырылган һәр рольне ул тамашачының исендә калырлык һәм үзе дә канәгать булырлык итеп уйнарга тырыша.

Ә 1911 елда Нижний Новгород ярминкәсенә бару бер Зөләйха өчен генә түгел, бөтен труппа өчен дә истә калырлык зур вакыйгага әйләнә. Биредә «Сәйяр» труппасы, билгеле, бер үзе генә булмый. Ярминкәгә җыелган купец-сәүдәгәрләрнең һәм бик күп башка кешеләрнең игътибарын җәлеп итәргә тырышып йөрүче театр труппалары да, цирк артистлары да күп була биредә. Ләкин «Сәйяр»нең ярминкәдәге уңышы башкаларныкы белән чагыштыргысыз зур була. Моның сере, әлбәттә, артистларның талантында, аларның профессиональ яктан өлгергәнлегендә иде. Билгеле, уңышка ирешүнең тагын зур гына бер сәбәбе: репертуарның бөтен якларны искә алып, нык уйланып төзелгән булуында иде.

Нижний Новгород ярминкәсенә бару Зөләйха Богданова өчен беренче зур гастроль була. Аңа Галиәсгар Камал пьесаларындагы хатын-кыз рольләре тапшырыла. «Бәхетсез егет»тәге Гайни, «Беренче театр»дагы Факиһә һәм «Уйнаш»тагы Мәгълифә кебек типларны

Зөләйханың тормышта да күргәне була. Шул вакытта алган тә сирләре аңа образларны аңларга нык ярдәм итәләр.

Менә «Бәхетсез егет»тәге Гайни. Зөләйха Богданова башкаруынд бу образ яшәп килгән тормыш тәртипләрен гаепләү акты булы яңгырый. Гайни өчен бу тормышта бер изге нәрсә дә юк. Шуңа кү аңа үзенең намусын, кешелеген сату да берни түгел. Рольне башка ганда Гайнинең бөтен трагедиясен, һәлакәтле язмышын ачып сал өстенә, артистка Зөләйха Богданова аның шул тормыш үзе тудырга тип икәнлегенә дә басым ясап күрсәтә.

«Беренче театр»дагы Факиһә исә бөтенләй икенче типтагы обра Ул семьясында урта гасыр гадәтләрен урнаштырган Хәмзә байны килене, аның ярым тиле малаеның хатыны. Бары тик үзенең тапкы лыгы, акылы һәм хәйләкәрлеге аркасында гына ул бу семьяда яш ала. Зөләйха Богданова бу рольне башкарганда Факиһә характе рындагы яхшылыкны, әйбәт күңеллелекне аеруча басым ясап күр сәтә.

Шулай ук Мәгълифә карчык ролен башкару да («Уйнаш») ар тистка өчен зур сынау була. Үзенең бөтен көчен һәм сәләтен куеп барлык тормыш тәҗрибәсен эшкә җигеп, ул онытылмаслык образ — димчелекне кәсеп иткән мәкерле Мәгълифә карчыкның психологи төгәл һәм ышандырырлык образын иҗат итә.

Шулай итеп, бу гастрольдә Зөләйха Богданова төрле-төрле роль ләр башкара. Аларның һәрберсе артистканың иҗади яктан үсә, ар тистка буларак үз йөзен таба барганлыгын күрсәтә.

Озак дәвам иткән уңышлы гастрольдән соң «Сәйяр» труппасы яңадан Казанга кайта. Бу инде 1912 ел — ерак Ленадагы ату та вышларыннан бөтен Россиядәге алдынгы фикерле кешеләрнең, реак ция елларында вакытлыча тынып торган көчләрнең уяну елы була. Әлбәттә, бөтен иҗтимагый тормыштагы бу җанлану культура өлкә сендә дә сизелми калмый. 1912 елның июнь аенда Уфада икенче театр коллективы — «Нур» труппасы оеша. Труппаны Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская оештыра. Зөләйха Богданова да үзенең остазыннан калмый — ул да Уфага, яңа труппага килә.

Сәхипҗамал туташ яңа труппаны башкорт һәм татар халкын олы сәнгать белән тәрбияләү, халык күңеленә изге орлыклар салу мак сатын күздә тотып төзи. Труппага күбесенчә яшь талантлар алына. Алар арасында Л. Аитов, С. Әхмәдиева, Г. Казанский, З. Баязитский, А. Зөбәиров, Ф. Саматова, Ә. Синаева, Ф. Латипов, М. Мирвәлиева, Ш. Шамильский һәм башкалар була. Шул көчләрдән торган яңа «Нур» труппасы Уфа шәһәрендә үзенең спектакльләрен күрсәтә башлый. Шәһәр тамашачылары каршында уңыш казанганнан соң, бераздан труппа шундый ук зур дәрт белән гастрольләргә чыгып китә һәм анда да артистларга тамашачының көчле алкышлары юл даш була. 1912—15 елларда «Нур» труппасы үзенең спектакльләрен Оренбург, Чиләбе, Семипалатинск, Петропавловск, Төмән, Омск һәм башка шәһәрләрдә күрсәтә.

Шәһәрдән шәһәргә күчеп йөрүләргә, шуңа бәйләнгән күп кыен лыкларга, мәхрүмлекләргә карамастан, «Нур» труппасында иҗат ялкыны эз генә дә сүрелми. Артистлар театр репертуарын яңа әсәр ләр белән тулыландыру, тамашачылар белән араны ныгыту турында озак һәм еш уйланалар. Сәхнәдә кую өчен шул заманның, шул көн нең рухын тотып алган, тамашачыны кызыктыра алырлык әсәрләр табарга тырышалар.

Шундый олы максатлар белән янып яшәгән коллективның күре некле артисты булып киткән Зөләйха Богданованың тормышы бу ел ларда тагын да ялкынлырак һәм баерак була бара. Тынгысыз эш, гел юлда булу аңа күтелмәгән кыенлыклар китерә, ләкин бу кыен лыклар инде аның күңелен төшерә алмыйлар. Зөләйха Богданованың

хәзер дус һәм бердәм коллективтагы якты максатлы тормышы аңа күп каршылыкларны җиңәрлек көч бирә. Яраткан эше һәм дуслары артистканың якын ярдәмчеләре булалар. Хәер, коллективта Зөләйханың авырлыкка бирешеп, кара көеп йөргән чагын да күрмиләр. «Дөньяда без кичә алмаган кыенлык бармыни?! Безгә андый кыенлык очрамады әле!» — дип җавап бирә ул еш кына иптәшләренә, ярым шаярып.

Зөләйха Богданованың «Нур» труппасында эшләү еллары аның иҗатында иң югары биеклек булып тора. Бу чорда аның артистлык йөзе, индивидуальлеге бөтен байлыгына ачыла. Ул үзенең яраткан амплуасы — комедия жанрында уйнавын дәвам итеп, Галиәсгар Камал пьесаларында һәм Мольердан тәрҗемә иткән «Саран» комедиясендә онытылмаслык образлар иҗат итә. Г. Богдановның «Хуҗа һәм приказчик» драмасында кухарка ролендә күренеп кенә алып та, артистка зур гомумиләштерү югарылыгына күтәрелә. Шул ук вакытта З. Богданова башкарак характердагы рольләрдә дә үзенең көчен сынап карый. Г. Камалның «Кайниш» пьесасындагы Гөлҗамалны ул үзенең элекке рольләренә бөтенләй капма-каршы планда: басынкы холыклы, язмыш тарафыннан кыерсытылган, сабыр характерлы итеп уйный.

Зөләйха Богданова шундый ук зур осталык белән йомшак күңелле, саф йөрәкле хатын-кыз образларын да иҗат итә. Фатих Әмирханның «Тигезсезләр» пьесасындагы Сәлимә — нәкъ шундый. Ул — баеп барган коммерсант кызы. Тыйнак, тотнаклы, тырыш һәм хезмәт сөючән. Сәлимәнең күңелен тирән кичерешләр теткәли. Ул мәхәббәт утында яна. Шулай ук гимназия бетерә алмаганга да бик йөрәге әрни аның. Зөләйха Богданова башкаруында бу образ тагын бер тирән мәгънә ала. Сәлимә образы аша артистка безгә: социаль тигезсезлек яшәгәндә хәтта бай семьясында үскән кешеләр дә тулысынча бәхетле була алмыйлар, ди. Замандашларының истәлекләренә караганда, пьесаның авторы Фатих Әмирхан да Зөләйха Богданованың уенын бик яраткан. Язучы белән озак еллар дус булган Кояш Вәлитова Ф. Әмирханның: «бу роль нәкъ менә Зөләйха Богдановага атап язылган кебек» дигән сүзләрен хәтерли.

1916 елда, «Тормыш» газетасының күп санлы чакыруларыннан соң, «Нур» труппасы Уфага кайта һәм биредә кышларга кала. Труппаның бу чордагы тормышы аның күренекле татар демократ язучыларының әсәрләрен куюы белән генә түгел, ә үз репертуарына рус һәм Көнбатыш Европа классикларының әсәрләрен кертүе белән дә кызыклы. Тәрҗемә әсәрләрдән А. Н. Островскийның «Яшенле яңгыр»ында һәм Ф. Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт»ендә Зөләйха Богданова иҗат иткән образлар аеруча игътибарга лаек. Островский пьесасындагы Кабаниха ролен ул шундый зур осталык һәм тирән гомумиләштерү белән уйный, аның башкаруындагы бу образда караңгылык патшалыгының бөтен әшәке сыйфатлары гәүдәләнә. Кабаниха үзенең улы Тихонны дер калтыратып тора. Кабаниханың рәхимсезлеге Катеринаның якты ыга омтылуын, матур өметләрен, шатлыкларын сүндерә. Кабаниха тормыштагы бөтен таза, матур, көчле үсентеләрне корыта. Аның өендәге кешенең үз фикере, үз хисләре булмаска тиеш. Шушы канунннарны бозып ирекк чыгарга омтылган Катеринаның язмышы трагедия белән бетә. Кабаниха образын Зөләйха Богданова буржуаз тормышның социаль тибы итеп гәүдәләндерә.

Ф. Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт» трагедиясендә уйнау Зөләйха Богданова иҗатында үзе бер баскыч булып тора. Ике яшь йөрәкнең саф мәхәббәтенә дан җырлаган, мәхәббәтнең көче һәртөрле канунннардан өстен икәнлеген зур ышандыру көче белән ачып биргән бу спектакльдә Зөләйха Богданова ике роль башкара. Аларның

берсе — Луизаның әнисе фрау Миллер, икенчесе — бай герцогның сөяркәсе леди Мильфорд. Фрау Миллер Зөләйха Богданова башкаруында тамашачыга чикләнгән карашлы, рухи дөньясы ярлы хатын булып килеп баса. Билгеле, ул үз кызының бәхетле булуын тели. Тик ул бу бәхетне үзләренә югары даирәләрдә урын алуда гына күрә һәм шуңа ирешү өчен кызын президент малаена кияүгә бирергә тырыша.

Чын кешелек бәхетен шулай мескенәйтеп һәм байлыкка, данга гына бәйләп аңлаучы бу хатын образын башкару артисткадан әллә ни зур кыенлык сорамый. Ә менә икенче роль аның өчен бөтенләй яңа: леди Мильфорд моңарчы артистка башкарган рольләргә караганда бик катлаулы һәм каршылыклы шәхес була. Ул яшь чагыннан ук сарай тормышының күңел кайтаргыч әшәкелеге белән танышып үсә. Биредәге кешеләрнең алдау, ялагайлык, мәкерле казынулар белән тулган күңелсез һәм кызганыч тормышы инде аны туйдыра башлаган. Аның күңеле бу тормыштан качарга кирәклеген хәзер торган саен ныграк тоя. Ниһаять, Луиза белән Фердинантның фаҗигале үлеме аңа бу адымын атларга көч бирә. Леди Мильфорд герцог сараен ташлап үзенең туган иленә — Англиягә кайтып китә.

Әйе, леди Мильфорд роле чыннан да катлаулы һәм авыр була. Ләкин ничек кенә катлаулы шәхес булса да, артистка аны сәхнәдә гәүдәләндерә алырга, тамашачыга аның характерын ачып бирә алырга тиеш. Ә менә характерга ачкычны ничек табарга, ягъни ничек итеп аңа җан өрергә соң? Леди Мильфорд образына хас төп сыйфат нинди? Артистканы репетицияләр алдыннан бертуктаусыз шундый сораулар борчый. Ул аларга җавапны озак эзли, уйлана, киңәшә. Ниһаять, эзләгәне табылгандай була — леди Мильфорд тирән психологик кичерешләр кешесе булырга тиеш. Һәм, шул юлдан китеп, артистка рольне уңышлы башкарып чыга.

«Мәкер һәм мәхәббәт» спектакле Зөләйха Богданова өчен бер яктан, яңа образ тудыруы белән истәлекле булса, икенче яктан, шушы катлаулы образны уңышлы башкару аның үзенең сәләтле һәм киң диапазонлы артистка икәнен раслый иде.

Без биредә Зөләйха Богданованың иң яхшы уйнаган рольләрен, ул зур уңышка ирешкән образларны гына искә алып киттек. Ә бит аның репертуары югарыда телгә алынган рольләр белән генә чикләнми. Озак елларга сузылган сәхнә эшчәнлеге чорында ул бик күп образлар тудыра. Аның үз эшенә, сәхнәгә, театрга мәхәббәте шул кадәр көчле була: ул үзенә тәкъдим ителгән бер генә рольдән дә баш тартмый, һәр рольне нык аңларга, аның асылына төшенергә тырыша.

Зөләйха Богданова тудырган образларга реальлек һәм типиклык белән кабатланмас индивидуальлекнең табигый бердәмлеге хас. Ул теге яки бу рольне башкарганда герой психологиясенә үтеп керә, андагы иң нечкә хисләрне һәм тойгыларны тотып ала, тамашачыга бирә белә. Ә бу исә һәрбер образга тирән тормышчанлык, табигыйлек бирә.

Югарыда күренгәнчә, Зөләйха Богданова репертуарында үзәк образлар эпизодик рольләр белән аралашып бара. Эпизодик рольләрне башкарганда Зөләйха Богданова тамашачы ул геройның эшен, эчке дөньясын белеп кенә калмасын, ә аның моңа кадәр нинди юл үткәнен,ниләр кичергәнен дә белсен өчен тырыша. Шулай итеп, үзәк образлардагы кебек үк, эпизодик образларда да артистка үзенең сәләтле һәм зур тәҗрибә туплаган сәхнә остасы икәнен күрсәтә.

Зөләйха Богданованың «Нур» труппасы спектакльләрендә уйнавы хакында ул елларда Уфада чыккан «Тормыш» газетасындагы күп кенә рецензияләрдә язылган. Бу рецензияләрнең күбесе 1916 елның икенче һәм 1917 елның беренче яртысына туры килә. Аларда «Нур» труппасының тамашачы каршында зур уңыш казануы әйтелү

белән бергә, һәрберсендә диярлек, Зөләйха Богданова уенына уңай бәя бирелә. Ә артистканың уңышка ирешүе исә аның залдагыларга хөрмәт белән, аларның фикерләренә колак салып, ышанып каравыннан дип аңлатыла. Бу бәя, әлбәттә, артисткага дөрес бирелгән. Ул, чыннан да, Сәхипҗамал туташ белән бергә «Нур» труппасының «җаны» була. Коллективта аны яхшы күңелле, ярдәмчел, эчкерсез һәм ягымлы кеше буларак хөрмәт итәләр. Ул артистларга сәхнәдә генә түгел, тормышларында да һәр вакыт ярдәм кулы сузарга әзер була.

Башланып киткән гражданнар сугышы «Нур» труппасы өчен гаять авыр шартлар тудыра. Уфа шәһәре аклар кулыннан кызылларга, бераздан яңадан акларга һәм тагын кызылларга күчеп, мәхшәр кебек кайный башлый. Труппаның күп артистлары бу хәлгә түзеп тора алмыйлар — «Нур» таркала. Уфада З. Богданова, Г. Казанский һәм Ф. Латипов кына кала. Алар шәһәрдә булган һәвәскәр көчләрне җыеп, шул яңа көчләр белән спектакльләр куя башлыйлар һәм бу эшләрен революция файдасына бирү өчен үзләрен Кызыл Армиягә хезмәт күрсәтергә алуларын сорап гариза язалар. Ирекледәрдән төзелгән труппаның үтенече канәгатьләндерелә. Коллектив Көнчыгыш фронттагы 5 нче армиянең 26 нчы дивизиясе политотделы карамагына беркетелә. Труппа Кызыл Армия частьларында зур культура эше алып бара башлый. Артистлар сугышчылар өчен спектакльләр, концертлар куялар, әдәби кичәләр үткәрәләр, ә фронтта эшләр катлауланып китсә, шундук кулларына корал алып, алгы позицияләргә күчәләр, хатын-кызлар исә шәфкать туташларына әйләнәләр. Бу труппа гражданнар сугышының ахырына кадәр 5 нче армия белән бергә була. Ул көннәр истәлеге булып Зөләйха Богданова архивында 14307/3638 номерлы махсус таныклама саклана.

1920 ел. Гражданнар сугышы гарасатыннан котылган Уфа яңадан тыныч тормышка аяк баса. Шушы көннәрдә труппа Уфага кайта һәм системалы рәвештә халыкка спектакльләр күрсәтә башлый.

Ә 1922 елда Зөләйха Богданованы без яңадан Казанда күрәбез. Биредә ул Татар дәүләт театры сәхнәсендә уйнап, тамашачыларны үзе иҗат иткән яңа образлар белән сокландыра башлый.

1924 елда З. Богданова Буага килә. Биредә ул, Б. Тарханов һәм Б. Болгарский белән бергә, Габдулла Кариев исемендәге татар драма театры оештыра. Ул анда 1947 елга кадәр эшли. Театрда эшләү белән бер үк вакытта Зөләйха Богданова Буа шәһәренең культура йорты каршында оешкан үзешчәннәр түгәрәген дә җитәкли. Биредә артистканың режиссерлык һәм педагоглык сәләтләре ачылып китә. Үзенең эшен кечкенә-кечкенә әсәрләр куюдан башлаган драма түгәрәге соңга таба классик һәм совет драматургларының зур гына пьесаларын куюга кадәр күтәрелеп җитә. Ә 1935 елда Татарстанның 15 еллыгы хөрмәтенә үткәрелгән беренче олимпиадада Буа үзешчәннәре коллективы беренче урынны ала.

1950 елның 13 июнендә күренекле артистка Зөләйха Богданованың йөрәге тибүдән туктый. Татар театры үзендә якты эз калдырган йолдызын, тынгысыз характерлы артисткасын югалта.

Зөләйха Богданова — чын мәгънәсендә татар театры таңында балкыган бер йолдыз. 1920 елда «Эш» газетасының 57 санында Сәхибгәрәй Сәидгалиев нәкъ әнә шундый артистларны күздә тотып болай дип язып чыга: «Татар дөньясын беренче мәртәбә буларак театр галәме белән таныштыручы, әллә нинди авырлыкларга да карамыйча, шул милли театрның алга баруына хезмәт итүчеләр ярлы халык арасыннан килеп чыккан, шуның белән бергә әйтеп бетерә алмаслык көчле артистларыбыз булдылар».

Бу сүзләр бүген Зөләйха Богданова эшчәнлегенә дә югары бәя һәм олы хөрмәт булып яңгырыйлар.

## Гази Кашшаф

# РЕВОЛЮЦИЯ СОЛДАТЫ

Аның исеме тирәсендә төрле сүзләр йөри. Миңа, ул чактагы яшь студентка, ул сүзләр, әлбәттә, нык тәэсир итә. Аның әсәрләрен укыйм, үзен дә күрәсе килә. Ләкин аны бик зур урыннарда эшли диләр. Шуңа язучыларның җыелышларында күренми.

— Ул дивизия комиссары!

Институтта минем белән бергә укучы атаклы Гадел Кутуй Шамил Усманов белән таныш икән. Ул минә исемнәрен ишетеп, китапларын укып белгән язучылар белән таныштыра, әсәрләренә характеристика бирә, тормыш эпизодларыннан берәр вакыйга сөйләп ала. Шунысын да әйтим, Кутуй бик объектив кеше, иҗат эшенә хөрмәт белән карый, хәтта үзен тетеп салучыларга да ачу кабартып йөрми. Шамил Усмановны ул өлкән язучы итеп таный, хөрмәт итә иде.

Һади Такташ 1922 елда Казанга килгәч, Шамил Усманов аны Казан белән таныштыру өчен үзе белән ияртеп Казан урамнарында йөри. Йөри торгач, алар тимер юл станциясенә килеп чыгалар да китәргә торган товар поездын күрәләр.

— Без ачык ишекле товарный вагонга сикереп мендек,— дип сөйли Һади агай, үзенә генә хас җылы юмор белән.— Ишектән аякларны салындырып идәнгә утырдык. Шамил семечка яра, сөйләшмибез. Тимер юлчы килеп чыкты да безгә вагоннан төшәргә куша. Мин Шамилгә карыйм, ә ул бер сүз дәшми. Уң кулы белән сул як күкрәгенә төртеп күрсәтә. Ә аның күкрәгендә ТатЦИК члены значогы. Янәсе, күр, мин хөкүмәт члены... Вагоннан төшмичә, без Юдинога китеп бардык...

Такташ елмаеп сөйли, бу елмаюда мин Шамил Усмановка булган хөрмәтне сизәм. Шул ук вакытта көне буе йөреп, бик күп җирләрдән әйләнеп кайтып бернәрсә дә диярлек сөйләшми йөрүгә ул гаҗәпләнә дә һәм ирония белән:

— Шулай минем аңа көне буе тагылып йөргәнем бар! — дип үз-үзеннән көлә дә иде.

— Шамил бик кызу яза, машина кебек!

Моны миңа кем әйткәндер, хәтерләмим. Ләкин «Канлы көннәрдә» драмасын бер төн эчендә язып бетерүен искә алсак, аның җитезлеген чамаларга була. Ул әсәр яшь комиссарны олы юлга, совет әдәбияты юлына алып чыга. 1925 елда язган истәлегендә Ш. Усманов бу әсәр турында болай ди: «Бер Америка язучысының, әсәре мең мәртәбә куелгач, баеп миллионер булганын ишеткән идем. Минем «Канлы көннәрдә» дә, шөбһәсез, ул елларда меңнән артык куелгандыр. Гәрчә ул миңа бер генә тиен гонорар бирмәсә дә, рухи капиталы зур булды. Ул миңа алда язучы булырга юл ачты».

Ниһаять, мин аның үзен күрдем, бер генә тапкыр да түгел. 1927 елдан аны Казанда кайда гына күрми калып була иде икән! Ул бик хәрәкәтчән, эшлекле, бик әйбәт

оратор — армиядә комиссар булу аны бу һөнәргә яхшы өйрәткән булса кирәк. Хәер, талантың булмаса, өйрәнеп кенә буламы икән. Ул теләсә кайда, теләсә нинди аудиториядә бик иркен сөйли, язу-фәләнсез, экспромт белән. Тавышы ягымлы, хәрәкәтләре саран. Мин бөтен гәүдәсен, кулларын хәрәкәтләндереп, утлар чәчеп сөйләүче ораторларны да ул елларда күп ишеттем. Ләкин Шамил Усманов андый оратор түгел иде, ул тышкы эффектка әһәмият бирми, аның ялкыны эчтән чыга, үтемле сөйли, кирәкмәгән сүзләр кыстырмый, ык-мык итеп паузалар да ясамый. Русчасы да, татарчасы да бердәй үк ягымлы, йөрәккә ятышлы яңгырый иде.

Әйе, ул социалистик революциянең улы иде. Социалистик революция аңа атом көченә тиң көч бирде. Революциягә җаны-тәне белән бирелгән, интернационализм рухы белән сулыш алган шушы эшлекле солдат революцион колач белән эшләргә чакыра иде.

Әдәбияттан тыш аны тагын ике нәрсә мавыктыра иде, дөресрәге, ул үзе дә яшьләрчә дәртләнә һәм тыңлаучыларны да дәртләндерә, мавыктыра белә иде.

Аның берсе — радио, икенчесе — эсперанто! Радио, эсперантоның безнең тормыш өчен кирәклеген ул ярсып сөйли, революциянең бөтен дөньяда җиңүе өчен эсперанто телен үзләштерүнең бик мөһим икәненә ышанып сөйли. Соңыннан ул шушы ике нәрсәнең практик мөмкинлекләрен «Памирдан радио» исемле повестенда әдәби образлар аша да күрсәтте.

Татарстанда радионы көндәлек тормышка кертү өчен күп көч куйган беренче пионерлардан иде ул Шамил Усманов. 1922 елда ук Татарстан өлкә партия конференциясендә ул бу хакта ялкынлы чыгыш ясый. Буржуаз идеологиягә каршы көрәштә матбугат һәм радионың зур корал булуы турында, киләчәктә агитация-пропаганда эшендә радио-телефонның (ул чактагы термин) гаять зур роль уйнаячагы турында сөйли.

Еллар узды, Шамил Усмановның хыяллары тормышка ашты һәм ул үзе дә бу юлда практик эш башкарды.

Шамил агайның радио челтәрен киңәйтү өчен уздырган чаралары күп булды. Шуларның берсе, мәсәлән, артистлар катнашы белән тыңлаучылар өчен кичәләр уздыру иде. Ул чакта радиоалгычлар бик сирәк, шуңа күрә радио сөючеләргә радиоалгычны үз куллары белән ясарга кирәк иде. Кичә башланганчы Шамил Усманов радиоалгычны үзенә ничек ясарга өйрәтеп чыгыш ясый иде.

— Аңа зур нәрсә кирәкми, мин сезне шырпы тартмасы зурлыгында гына радиоалгыч ясарга өйрәтәм,— дип башлый иде ул.

Чыннан да, Шамил агай өйрәткәнчә ясалган радиоалгычтан минем файдаланганым бар. Дөресен әйткәндә, минем фатир хуҗам радио белән шаша иде һәм Шамил Усмановны тыңлап кайту белән детекторлы радиоалгыч ясарга керешә һәм ясады. Наушниклар киеп, без бик рәхәтләнеп концертлар тыңлый идек.

Минем фатир хуҗам Александр Ивановичның радиоалгычы бик мактаулы булып чыкты. Ул үзе башкаларны радиоалгыч ясарга өйрәтә башлады. Һәм аңа килеп радиоалгыч ясарга өйрәнүче беренче кеше — соңыннан СССРның халык артисты булган атаклы Максим Дормидонтович Михайлов иде! Дөрес, ул чакта Михайлов артист түгел иде әле...

Радионы пропагандалау һәм әдәбият-сәнгать вәкилләрен халыкка якынайту максаты белән Шамил Усманов 1928 елның кышында бер бригаданы Нурлат волостена алып китте. Бригада составында Шамил Усманов, радио аша халыкка бик якын булган җырчы Асия Измайлова, шагыйрь Гадел Кутуй һәм бер төркем яшьләр бар иде. Һади Такташ ниндидер сәбәп белән ул бригадада катнаша алмады. Татар мәдәнияте йорты каршында системалы рәвештә эшләп килә торган яшь язучылар түгәрәгендә катнашучы берничә язучы арасында мин дә бар идем. Без әле барыбыз да яшьләр, каләм тибрәтергә яңа өйрәнә башлаган кешеләр, халык каршына чыгып басарлык өйберләребез дә юк, шуңа күрә мин:

— Нишләрмен соң мин анда? — дидем.

Шамил агай бик гади итеп:

— Тормыш белән танышырсың, халык күрерсең. Газетага хәбәр язарсың! — диде.

Без — унлап кеше — вокзалга төшеп киттек. Минем кебек фәкыйрь студент өчен

гомуми вагонның эченче каттагы сәндәрәсе дә бик күңелгелгән урын иде. Ләкин җитәкчебез Шамил Усманов башкача карады.

— Язучылар бара! Анда безне каршы алалар! — дип, кемнең нинди дәрәҗәле кеше булуын аермыйча, йомшак вагонга билет тоттырды. Шулай итеп, без Шамил Усмановның киң колачына кереп чумдык. Билгеле, Төрләмә станциясенә чаклы без гомуми вагоннан да коелып калмаган булыр идек, ләкин, беренчедән, язучылар бригадасы әле тарихта беренче тапкыр халык эченә юнәлә, икенчедән, каршы алучылар өчен дә күңелле булачак...

Хәер, безне хәзергә олаучылар гына каршы алды, ләкин авыл башында аншлаглар тоткан мәктәп балалары һәм башка яшьләр күп иде.

Волость советы башкарма комитетының конференциясе ачылуга без дә килеп життек. Монда да безне аермадылар, барыбызга да конференциядә катнашу мөмкинлеге бирделәр.

Кич әдәбият-сәнгать кичәсе. Анда Асия Измайлова үзенең җырлары белән соклandырды. Конференциягә өлкә вәкиле булып килгән язучы Фатих Сәйфи-Казанлы, язучы-юморист Мәхмүт Бәдәйли, шагыйрь Гадел Кутуй уңыш казандылар. Шамил Усманов исә бөтен кичәнең җаны иде.

Берничә көн эчендә мин Шамил Усмановның яшьләргә бик игътибарлы булуын белдем. Ул безнең белән сөйләшкәндә үзен өстен куймый, күптәнге дусты кебек бер сафтан торып сөйләшә. Сиңа бирергә теләгән уй-фикерләрен дә акыл өйрәтү төсендә түгел, бәлки киңәшләшү төсендә алып бара.

Яшьләрне дөрес юлдан үстерү, аларга иҗади ярдәм итүне ул таләпчәнлек белән бергә алып барды. Берничә мисалда моны ачык күрергә мөмкин.

1928 елда Габдрахман Минскийнең беренче драмасы Татар дәүләт академия театрында куелды. «Мансуровлар гаилэсе» исемле бу драманың яшь авторына театрның иҗади ярдәме йомшак иде. Ул премьера көнне сизелде. Шул ук вакытта театр үзе дә хәзерләнеп бетмәстән пәрдә ачарга ашыкты. Спектакль бик озакка сузылды. Тәнәфес араларында йокы туйдырып алырга мөмкин иде.

Икенче көнне Татар мәдәнияте йортында язучыларның нәрсәгәдер багышланган җыелышы булды. Шул җыелыштан хәтердә Шамил Усманов чыгышы сакланган. Ул хәзер дә минем күз алдымда тора. Сәхнәгә ул бик җитез менде, трибунага килеп басканчы ук сүзен башлады, үзенең ораторлык осталыгын монда да күрсәтте. Кулында аның кәгазе юк, тезислары алдан әзерләнмәгән. Ул бөтен залга карап сөйли. Ниһаять, уңаен туры китереп, сүзне кичәге премьерага — «Мансуровлар гаилэсе»нә күчерде. 45 елдан соң ул болай дип әйтте дисәм, хата булыр иде. Минем көндәлекләрдә ул сакланып та калуы ихтимал. Ләкин сүзнең мәгънәсен яхшы хәтерлим, чөнки ул яшь язучыга игътибар кирәклеге турында сөйләде. Әнә шул игътибар булмау аркасында «Мансуровлар гаилэсе» өлгереп җитмәгән килеш сәхнәгә чыга, җитмәсә, театр сепктакльне төн уртасына чаклы сузып, тамашачыны ялыктыра. Ул спектакльнең сүлпәнлеген театрның яшь авторга тиешле юнәлеш бирә алмавыннан икәнен аңлатты һәм шуның өчен театрны, режиссерларны тәнкыйть итте.

Шамил Усмановның бу чыгышы үзенең кыюлыгы һәм дөреслеге белән матур иде, шуңа күрә дә ул онытылмый хәтердә сакланган.

1929 елда яшь язучы Әмирхан Еникинең беренче китабы басылып чыкты. Ул «Дус кеше» дип исемләнгән иде.

Әмирхан кебек ук мин дә ул чакта бик яшь идем һәм... Билгеле, яшь чакта буең җиткән җиргә кыюрак үреләсең һәм сүзеңне кычкырыбрак әйтергә, җитмәсә, башкалардан алдарак әйтеп калырга ашыгасың. Без Әмирхан белән дус идек, шуңа күрә аның повестен да мин бик тиз укыдым һәм повестьның йоннарын очыра торган рецензия язып чыктым.

(Җәяләр эчендә шунысын да әйтим, ул рецензия Әмирхан белән минем арадагы дуслыкны җимермәде, без дус булып калдык һәм инде дус булып картайдык. Тик икебезнең дә ул рецензияне телгә алып искә төшергәне юк!)

Шамил Усмановка минем рецензия ошамады. Ул моны шулай ук чираттагы бер җыелышта кайнар речь белән чыгыш ясаганда әйтеп китте. Шунысы кызык: Шамил агай, Минский драмасы постановкасын тәнкыйть иткәндәге кебек, турыдан-туры мине гаепләп, мине тәнкыйть итеп чыкмады. Таякның юан башы аны бастырып дөнья-

га чыгарган иптәшләргә юнәлгән иде. Янәсе, яшь кеше нәрсә язмас, аны өйрәтергә, каләменә юнәлеш бирергә кирәк. Шуннан соң ул үзенең «Дус кеше» повестен ничек аңлавы һәм ничек аңларга кирәклеге турында сөйләде.

Ул сөйли, вакыт-вакыт миңа да карап ала, ә минем битем пешә, колакларым яна һәм башымнан сөрем чыга кебек иде. Ул миңа язучының иҗатына бәя бирү кебек эшнең үен түгеллеген, гаять җаваплы булуын, беренче тәэсиргә бирелеп эш итмәскә кирәклеген төшенергә ярдәм итте. Аның чыгышыннан тагын шуны да аңладым: «Дус кеше» повесте Шамил Усмановның эчке рецензиясе буенча китап булып дөньяга чыккан икән. Димәк, ул — өлкән язучы — яшь язучы Әмирхан Еники иҗатына хәерле юл теләгән!

Соңгы тапкыр мин Шамил Усмановны 1937 елның язында очраттым.

Ниндидер эш белән Язучылар союзына килгән идем. Матбугат йортының бишенче катындагы нәни бүлмәнең түр почмагында, язу өстәленә иелгән килеш, Шамил Усманов кәлә-кәлә кемнеңдер кульязмасын укый. Мине күргәч, ул үзенә чакырып алды да, гадәтенчә, кызу-кызу сөйләп китте. Аның алдында атаклы гармунчы Фәйзулла Туишевның язмалары икән. Шамил агай, бик кызык дип, берничә урыннан укып күрсәтте.

— Күпне күргән ул гармунчы, тик яза белмәгән, литературная обработка ясасаң, менә дигән кызыклы һәм гыйбрәтле әсәр килеп чыгар иде! — диде ул.

Мин анык белмим, ләкин ни өчендер миңа Фатих Хөснине «Гармунчы» исемле повестьны язарга рухландырган кеше Шамил Усманов булгандыр кебек тоела.

Еллар бик күп детальләрне үзләре белән алып киткәннәр. Ләкин Шамил Усманов образы һаман җанлы булып, дәртле булып, эшчән, хәрәкәтчән булып күз алдында басып тора. Ул героик чорның героик улы булды һәм ул үзенең йөрәк җылысын дөньядагы барлык пролетарийларга өләшеп бирергә әзер иде. Җир шарының теләсә кайсы ноктасыннан азатлык көрәшендә ярдәм сорап кул сузучы булса, шунда атылып барырга һәм соңгы тамчы канына кадәр социаль азатлык өчен көрәшергә хәзер иде. Ул революция солдаты иде!

**Сәлам Алишев,**
**Миркасыйм Госманов,**
тарих фәннәре кандидатлары

# БӨЕК КРЕСТЬЯННАР СУГЫШЫНА 200 ЕЛ

**1917** елны,— Бөек Октябрь социалистик революциясе нәтиҗәсендә,— ниһаять, халыклар төрмәсе булган патша Россиясе җимерелде. Ниһаять, дибез, чөнки феодаль эксплуатациянең тирәнгә тамыр җибәреп ныгуы, милли-колониаль изүнең өзлексез арта баруы дәвамында барлыкка килгән, капитализм чорында халыкларны изүне тагы да катлауландырган Россия империясенең тарихы хезмәт ияләренең, җәбер-золымга дучар ителгән милләтләрнең туктаусыз көрәшләреннән: төрле формадагы баш күтәрүләрдән, бер-бер артлы кабынып торган эреле-ваклы восстаниеләрдән, революцион хәрәкәтләрдән гыйбарәт иде.

Октябрь революциясенә кадәрле булган азатлык өчен көрәш хәрәкәтләре арасында 1773—1775 елларда Емельян Иванович Пугачев җитәкчелегендә барган крестьяннар сугышы үзенең күләме һәм тарихи әһәмияте ягыннан аерым урын алып тора. Беренчедән, бу восстание феодаль империянең зур өлешен биләп алса, икенчедән, ул социаль һәм милли азатлык өчен барган көрәшләрнең органик рәвештә үрелеп үсүе белән характерлы иде. Восстаниенең күп милләтле булуы, ягъни төрле милләт хезмәт ияләренең стихияле рәвештә кулга-кул тотышып, сыйнфый интереслары бергә яклаулары азатлык хәрәкәтен киң колачлы, масштаблы итә. Кыскасы, 1773—1775 еллардагы крестьяннар сугышы, феодаль империядәге сыйнфый көрәшнең иң югары ноктасы булу белән бергә, күп милләтле Россия дәүләтендәге халыкларның көрәш тарихындагы яңа сәхифәсе дә иде. Менә шуңа күрә быел бөтен совет җәмәгатьчелеге Е. И. Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар сугышының 200 еллыгын киң күләмдә билгеләп үтә.

Без бу мәкаләдә Пугачев хәрәкәтенә татар халкының да актив катнашуына күзәтү ясау белән бергә, моңарчы киң җәмәгатьчелеккә мәгълүм булмаган татарча документлардан бер цикл тәкъдим итәбез.

XVIII йөзнең икенче яртысында Россиядә крестьяннар сыйныфының восстание күтәрүен феодализм эпохасының төп каршылыгы тудырган. Күп санлы салымнарны җыючы ришвәтче чиновникларның, басу-кырларны, болыннарны тартып алучы алпавытларның, урманнарны казнаныкы дип игълан кылучы патша хөкүмәтенең, адым саен хезмәт ияләрен эзәрлекләүче колониаль администрациянең, ниһаять, көчләп чукындыручы поплар, архирейлар, аларның кораллы ярдәмчеләренең — барысының да хокуктан мәхрүм ителгән крестьяннарга аерым-аерым да, тулаем да явыз дошман икәнлекләре күптән ачык һәм мәгълүм иде. Шуңа күрә империянең төрле милләтләрдән торган, экономик һәм политик изелүгә дучар булган крестьян массалары крепостнойлыкка, колониаль системага каршы дәвамлы көрәш алып бардылар.

Мондый көрәшләргә, башка милләт хезмәт ияләре белән берләштән, татар крестьяннары да актив катнашты. Татарларның төп өлеше дәүләт крестьяннары булып, алар алпавытлар сыйныфына гомуми феодаль бәйлектә тордылар (мәгълүм булганча, XVII—XVIII гасырларда татарларны крепостной крестьян итеп беркетү киң таралмаган иде). Шулай да аларның хәле рус крепостной крестьяннарыннан бик аз аерыла, хәтта кайбер очракларда татарлар артыграк җәберләнә иде. Мәсәлән, закон буенча, дәүләт крестьяннары җан башыннан 1 сум 70 тиен күләмендә (17 пот арыш оны бәясе) салым түләргә тиеш булсалар, чынбарлыкта татарлардан җан башы салымын 5—6 тапкыр артыграк түләткәннәр.

Милли-колониаль изү рус булмаган крестьяннарны туган-үскән җирләреннән куу, һәртөрле җыемнарның саннарын, күләмнәрен арттыру, христиан булмаган халыкларны идеологик-политик яктан (димәк, экономик яктан да) ныграк авызлыклау өчен көчләп чукындыру, иманнарын таптау, хурлау, мыскыллау кебек бик күп фактларда чагылды. Милли изү һәм чикләү сәясәте патша указлары, хөкүмәт карарлары белән законлаштырылды. Дөрес, соңрак хөкүмәт мондый талау политикасын ачыктан-ачык игълан кылудан баш тартты, мәгәр бер үк вакытта алпавытларның комсызлыгын, чиновник-түрәләрнең кансызлыкларын чикләмичә, бәлки даими рәвештә аларны яклап, милли-колониаль изүнең формаларын нечкәртү юлына басты. Нәтиҗәдә моңарчы да изелә килгән татарларның һәм социаль, һәм рухи яктан таланулары тагы да көчәя төште. Шуңа күрә дә XVIII йөздә алар, вак-төяк бунтлардан тыш, берничә зур восстание күтәрделәр. Шундыйлардан тарихта «1748 елгы татарлар хәрәкәте» дип аталган чуалышны, 1749 елдагы типтәрләр һәм мишәрләр восстаниесен, 1755 елдагы мәшһүр Батырша чыгышын, 1764—67 елларда Тирсә крестьяннарының дәвамлы көрәшен күрсәтергә мөмкин.

Ниһаять, Е. И. Пугачев җитәкчелегендәге бөек восстаниегә актив катнашу...

XVIII гасырның икенче яртысы крестьяннарның изелеп яшәвеннән һәм гаделсезлеккә каршы баш күтәрүләрдән генә гыйбарәт түгел. Никадәр изелгән булсалар да, житештерү көчләрен үстерүдә, хуҗалыкны гомум алга җибәрүдә крестьяннар барыбер төп көч булып калалар. Аларның түзем булуы аркасында иске хуҗалыклар яшәүләрен дәвам итсәләр, яңа чирәм җирләр үзләштерелеп, Башкортстан, Казагыстан сахраларына игенчелек культурасы киң колач җәюдә дә татар крестьяннарының өлеше сизелерлек булган. Татарларның массалап көнчыгыш өлкәләргә күчүләре, бер яктан, анда экономиянең үсүенә этәргеч булса, икенчедән, патша хөкүмәтенә куркыныч сала торган хәрәкәт булган.

Патша хөкүмәте куйган төрле киртәләргә карамастан, Татарстан территориясендә промышленность, мануфактура да үсә башлый. Татарлар бигрәк тә комач эшләү, сабын-шәм кайнату, күн-тире житештерү өлкәләрендә сизелерлек уңышка ирешәләр. Ләкин алар адым саен диярлек төрле чикләүләргә дучар булалар. Мәсәлән, халык хуҗалыгында төп звеноның берсе булган тимерчелек һөнәре татарлар өчен үлем куркынычы белән тыелган иде, шуңа күрә алар житештерү коралларын кирәгенчә әзерләү мөмкинлегеннән мәхрүм ителгәннәр, яисә мондый эш белән яшерен рәвештә шөгыльләнгәннәр.

Матди байлык җитештерү белән бергә, товар алмашу, сәүдә эшләре дә алга китә. Бу чорда, мәсәлән, татар сәүдәгәрләре илнең көнчыгыш өлешендә сәүдә эшләрен җәелдереп җибәрү белән бергә, империядән тыштагы Урта Азия, Көнчыгыш Төркстан, Иран, Һиндстан кебек илләргә дә чыга башлыйлар. Ләкин патша хөкүмәте, рус сәүдәгәрләре интересын күздә тотып, татарлар алдына төрле киртәләр куя (артык салымнар, эчке рыноктан сөрү, көнчыгыш өлкәләрдә күчми торган милек алуны тыю һ. б.). Хәтта Татарстанның үзендә дә татарларның сәүдә итүдәге инициативалары тоткарланган. Әйтик, 1764 елны бер Казанда гына да татарлар кулында булган 24 кибет яптырылган.

Менә шундый катлаулы шартлар — бер яктан, экономик үсү, хосусый инициативаның көчәюе, икенче яктан, хөкүмәт тарафыннан тудырылган төрле чикләүләр, тыюлар — татар халкының хәлләрен катлауларында да канәгатьсезлек уята.

Әнә шундый шартларда восстание башында торган Е. И. Пугачев һәм аның якын яраннары рус казакларының ризасызлыкларын, мәрхәмәтсез рәвештә таланган, хурланган рус крепостной крестьяннарының аһ-зарларын яхшы аңлаган хәлдә, шулай

ук кыерсытылган милләтләрнең хезмәт ияләре интересларын да, рус булмаган халыкларның гомум милли протестларын да күз алдында тотканнар. Шуңа күрә агитация максаты белән игълан итепел, рус һәм татар телләрендә халык арасына киң таратылган манифестларда «падишаһ Петр Федорович» исеме белән күрәш башлаган Е. И. Пугачев [1], бер яктан, хезмәт иясенә экономик ирекләлек — җир, урман-су, милек, шәхси азатлык, налоглар бетерүне — вәгъдә итсә, икенче яктан, рус булмаган төрле халыкларга автономик хокуклар — урыннардагы колониаль администрацияне бетерү, дин, йола, гореф-гадәт ирекге бирүгә вәгъдә кыла.

Дөрес, мондый таләпләрнең кайберләре элекке восстаниеләр җитәкчеләре тарафыннан да (мәсәлән, Батырша) куелган иде. Ләкин аларны шулай бергә җыеп бөтен күләме белән кую бары Пугачев восстаниесе чорында гына мөмкин булды. Хәтта бу сугыш вакытында манифестларда игълан ителгән программаларны тормышка ашыру буенча да кайбер чаралар күрелде (чиновникларны юк итү, алар урынына баш күтәргән крестьяннарны билгеләү, җир биләмәләрен бүлү, налог-салым түләүләрне туктату һ. б.).

Пугачев манифестларында социаль-экономик таләпләр белән янәшә милли-политик таләпләрнең куелуы рус булмаган халыкларның хәрәкәт башыннан ук восстаниегә актив катнашуын тәэмин иткән. Мәсәлән, Балтай Аббас улы Тодошев (Идоркин) һәм башкалар тикшерү вакытында биргән күрсәтмәләрендә татарлар восстаниенең башыннан ук рус казаклары белән бергә иделәр дип сөйлиләр. (Урал буендагы казаклар арасында татарлар да күп була.) Пугачев үзе дә допрос вакытында аңар беренчеләрдән булып Идыр Бахмутов (Мәхмүтов) җитәкчелек иткән татарлар группасы кушылуын күрсәтә. Шулай итеп, рус казаклары белән берраттән Оренбург якларындагы татар крестьяннары да восстаниене башлап җибәрүче көчләрдән булган.

Пугачев һәм аның көрәштәшләре халыкның төрле катлаулары өчен нәрсә кирәклеген, төрле милләт вәкилләренең интереслары нәрсәдән гыйбарәт булуын яхшы белеп, үз өндәмәләрендә шуларга тулы җавап бирергә тырышулары белән бергә, манифестларны, указларны халык арасына киң тарату буенча да актив чара күрәләр. Күп кенә указ-манифестларның ахырында, мәсәлән, «минем бу указымнан копия күчереп, урамнан урамга, авылдан авылга, шәһәрдән шәһәргә, илдән илгә... озатырсыз, һич туктатмаенча... кичектермәенчә күндерәсез, зинһар...» — дигән өндәмәләр була.

Һәм чыннан да восстаниечеләр игълан иткән өндәмәләр тиз арада тирә-юньгә таралып, хәтта ерак төбәкләргә кадәр барып җиткәннәр. Мәсәлән, сентябрь аенда Оренбург тирәсендә восстание башлану турындагы хәбәр шул ук айда Татарстан җиренә килеп җитә. Моңар, әлбәттә, Оренбург яклары белән булган тыгыз элемтә ярдәм иткән. Әйе, ул яктан кайтучы тынгысыз сәүдәгәрләр, ил гизеп бәхет эзләүче ярлы-ябагайлар «падиша Питыр Фидрауичның» исән булуы, аның ярлы халыкны яклап явыз янаралларга, майурларга каршы чыгуы, «Урымбурых» тирәсендәге «крипечләрнең» алынуы, алпавыт утарларының яндырылуы хакында хәбәрләр китерәләр. Халык гаҗәпләнә, шикләнә, өметләнә, сөенә — олы диңгез кебек дулкынлана башлый...

Рус булмаган халыкларга пугачевчыларның милли политика өлкәсенә караган лозунглары аерата нык тәэсир итә, чөнки алар бар халыкларны тигез дип танып, төрле телләрне, төрле диннәрне бердәй тигез ихтирам итәләр. Татарларга үз ана телендә мөрәҗәгать итү белән бергә, милләтләр арасындагы тигезсезлекне бетерү буенча да кайбер конкрет чаралар күрәләр (әйтик, отряд башлыкларын җирле халык вәкилләреннән билгеләү, хәрби дисциплина өлкәсендә тигезлек принцибын алга сөрү; мәсәлән, Пугачевның «баш атаманы» И. Н. Белобородов тәртип бозган «руспарны татар һәм рус командалары алдында, татарларны исә рус һәм татар командалары алдында җәзаларга» дип боерык биргән).

---

[1] Политик яктан аңсыз, патшачылык идеологиясе белән агуланган, хекем сөргән законсызлыктан «закон» турында аһ-зар итеп яшәгән халык массаларын үз ягына тарту өчен, шулай ук хәрәкәткә «законлылык» төсе бирер өчен Е. И. Пугачев үзен «падишаһ Петр (Федорович) III» дип игълан кыла. Чөнки халык арасында 1762 елны сарай перевороты нәтиҗәсендә үтерелгән Петр III «исән икән», «аны явызлар тәхеттән бәреп төшергән», «ул халык арасында качып йөри» дигән ялгыш фикер киң таралган булган.

Югарыда крестьяннар сугышын башлап җибәрүгә Оренбург ягы татарларының актив катнашуын әйткән идек. Шундыйлардан Тангаев, Булатов, Сәетборһанов һәм башкаларның фамилияләрен күрсәтергә мөмкин булыр иде. Озакламый, октябрь ае башында, Каргалы бистәсендә татарлар үзләре бер полк төзиләр; аның командиры Муса Алиев була. Соңрак барлык крестьяннардан төзелгән пехотаның командиры итеп «Казан татары Абдул» билгеләнә.

Көн саен диярлек төрле милләт вәкилләреннән оешкан эреле-ваклы отрядлар Пугачев армиясенә кушыла торалар һәм бу чуар составлы армия 4 нче октябрьдә Оренбург шәһәрен камап ала. 9 нчы октябрьдан исә восстаниегә башкортлар, марилар һәм башкалар кушыла башлый. Менә шуннан алып восстание чын мәгънәсендә күп милләтле хәрәкәткә әверелә.

Баш күтәрүчеләрнең төп көчләре Оренбург тирәсендә хәрәкәт итсә, Идел—Урал ягының башка төбәкләрендә дә властьларга буйсынудан баш тарткан аерым-аерым отрядлар хәрәкәткә килә башлыйлар. Шундый ук хәлне без Татарстан җирендә дә күрәбез. Мәсәлән, октябрь аенда ук Бөгелмә, Минзәлә төбәкләрендә, ноябрьдә исә Казан тирәсендә дә восстаниече отрядлар оешып, ирек һәм хокук дауларга керешәләр.

1773—1775 еллардагы крестьяннар сугышы тарихын, гадәттә, өч этапка бүлеп тикшерәләр. Шушы принциптан чыгып Татарстан территориясендәге сугыш хәрәкәтләрен дә өч этапка бүлеп карау дөрес булыр.

**Беренче этап** 1773 елның сентябрендә восстание турында хәбәрләр таралудан башланып, 1774 елның март айларына кадәр дәвам итә. Бу чорда стихияле рәвештә җирле отрядлар оеша, алар сыйнфый дошманнарына каршы политик оешмаган хәлдә, ничек туры килде шулай көрәш алып баралар.

**Икенче этап** 1774 елның языннан башланып, шул ук 1774 елның июль аеның уртасына кадәр вакытны эченә ала. Яз башында беренче зур җиңелүгә дучар ителгән крестьяннар сүрелә төшәләр. Ә бераз соңрак, Пугачевның төп көчләре Казанга таба юнәлгәч, хәрәкәт яңа көч белән кабынып, иң югары ноктасына җитә. Бу чор крестьян массаларының активлыгы үсү, аларның зур-зур төркемнәре восстаниегә кушылуы белән характерлы.

**Өченче этап** Пугачевның 1774 елның җәендә, Татарстаннан китүеннән башланып, 1775 елның җәендә восстание учакларының тәмам сүрелеп бетүе белән тәмамлана.

Восстаниенең барлык этапларында да татар крестьяннарының ясаклы һәм йомышлы дип аталган өлешләре хәрәкәткә бер тигез активлык белән катнашалар. Алар арасыннан крестьян отрядларының күренекле җитәкчеләре — полковниклар, старшиналар, сотниклар һәм писерләр чыккан. Мәсәлән, йомышлылардан Мәсгут Гомәров, Йосыф Енгалычев, Бәхтеяр Канкаев, Каранай Моратов, Канзафар Усаев, Ярмөхәммәт Кадерматов; ясакчылардан Уразметов, Асанов, Сәнфин; крепостнойлардан Әбҗәлил Сөләйманов, Юскәй Кудашев һәм башкалар халык арасында ихтирам казанганнар. Каргалы татарларыннан Садыйк Сәетов, татар казакларыннан Идыр Бахмутов (Мәхмүтов) Пугачевның якын кешеләреннән булып, «Югары киңәш» (Высший совет) членнары булалар.

Дөрес, йомышлы татарларның бер өлеше үзләренең чыгышы, экономик хәле белән массалардан аерылып, баш күтәргән халыкка каршы хөкүмәт ягында сугышканнар. Мәсәлән, кайбер йомышлылар Казан губернаторы фон Брандтка якыннан булышканнар, икенчеләрен без Михельсон, Фрейман командаларында күрәбез. Шуларның кайберләре М. Гомәров, Ә. Сөләймановны кулга алуда булышканнар. Пугачевка каршы сугышта актив катнашулары өчен Казандагы Яңа бистәдән 9, Иске бистәдән 10 кеше восстаниечеләр тарафыннан үтерелгән. Шундый хөкүмәт тарафдарлары татарлардан Кошар авылыннан Б. Адельшин, Шырданнан Б. Усманов, А. Ишмиев, Бәрәскәдән А. Ибраев, фабрикант И. Юсупов һәм башкалар патша исеменнән язма рәхмәтләр, бүләкләр алганнар. Пугачев Татищев крепосте янында җиңелгәч (1774 елның марты), Каргалы байлары да восстаниечеләрне Оренбург губернаторына тотып бирә башлыйлар. Мишәр старшиналарының кайберләре дә «падишаһ хәзрәтләренә» турылыклы хезмәт күрсәтәләр. Мәсәлән, Мәннан Тупеев, Аблай Исмагыйлов һәм башкалар үз отрядлары белән хөкүмәт ягында торып сугышалар, восстаниечеләрне тотып, җәзалаучылар кулына тапшыралар.

Ләкин, бу фактлардан чыгып, йомышлыларның барысы хакында да бертөрле фи-

кер йөртергә ярамый, чөнки аларның иң зур өлешен төшкил иткән ярлы катлаулары тулысы белән восстаниечеләр сафында булган.

Татар руханиларының восстаниегә мөнәсәбәтендә дә шундый ук сыйнфыйлык принцибын күрәбез. Бер яктан авыл муллаларының зур өлеше восстаниегә актив рәвештә катнашып, колларыннан килгән хәтле баш күтәргән хезмәт ияләренә ярдәм итәләр; Пугачев манифестларын һәм указларын татар теленә тәрҗемә итеп, яисә әмер-приказларны татарча язып, писерлек хезмәтен үтиләр; халык арасында агитация эше алып баралар (мәсәлән, атаклы пугачевчы Й. Енгалычевка Абдулла авылы мулласы Богдай хәзрәт йогынты ясый: «Бар, син дә Пугачев хезмәтенә бар,— ди Богдай мулла.— Ул ярлы халыкны яклап чыга, дворян-алпавытларны үтерә».) Күрәсең, татар муллаларының күп өлешенең әзме-күпме белем алган крестьяннар арасыннан чыгуы да монда зур әһәмияткә ия булгандыр. Өстәвенә, гомумән гади грамоталы кешеләрнең, мәдрәсә хәлфәләренең «мелла» дигән хөрмәтле исем йөртүләрен дә онытмаска кирәк. Кыскасы, авыл руханиларының һәм урта хәлле татар укымышлыларының бер (ихтимал, зур) өлеше восстаниегә актив катнашалар. Икенче яктан, хөкүмәт лагеренда да без татар руханиларын күп очратабыз. Мәсәлән, Каргалы бистәсе ахуннары хаинлык юлына басалар. Татар алпавыты Тәвкилев ярдәмендә Тирсә авылы ахуны дәрәҗәсенә ирешкән мулла да восстаниегә каршы агитация алып бара (баш күтәргән Тирсә халкы аны атып үтерә, атучысы мәдрәсә шәкерте була). Шундыйларның берсе Килмәт абызны (абыз — хафиз, руханилык дәрәҗәсе) халыкка каршы хәрәкәте өчен Бәхтеяр Канкаев эзәрлекли. Эре руханиларның бу сыйфатын яхшы аңлаган башкомандующий генерал А. Бибиков күренекле 10 мулланы восстаниегә каршы агитация ясау өчен халык арасына чыгарып җибәрә. Ләкин аларның барысы да диярлек төрле җирләрдә крестьяннар тарафыннан үтерелә.

Йомышлыларның байлары, руханиларның эреләре белән бергә, татарларның калдык феодаллары да (Тәвкилев, Алкин, Дәүләткилдиев һәм башкалар) хөкүмәт ягында булалар. Туып килә торган эре буржуазия вәкилләре дә алардан калышмаска тырыша. Аларның бер өлеше исә шактый вакыт әле бер якка, әле икенче якка аумакайланып, «иман таба алмыйча» аптырый. Мисал итеп, Пугачев килгәч аңар «баш салган», ул җиңелгәч Михельсонга тәлинкә тоткан бер төркем Казан сәүдәгәрләрен күрсәтергә мөмкин. (Мәсәлән, алар тарафыннан аннан-моннан чүплән Пугачев өчен дип төзелгән 17 кешелек бер отряд, Михельсон килгәч, аңар кушыла.)

Кыскасы, восстание дәвамында татарларның сыйнфыйлык принцибында капма-каршы ике лагерьга бүленүе тагы да ачыграк күренә.

Сыйнфыйлык принцибының җиңеп чыгуына өстәмә дәлилләр дә китерергә мөмкин. Мәсәлән, без Татарстан территориясендә хөкүмәт яклы булып төзелгән, актив көрәш алып барган татар отрядларын белмибез. Тәвкилев тарафыннан 1773 елның октябрендә татар-башкорт крестьяннарыннан төзелгән отряд, мәгълүм булганча, Тәвкилевнең үзен үтереп, пугачевчылар сафына баса.

Восстаниечеләр лагерена, бу лагерьнең милли составына күз салсак, без менә нәрсә күрәбез: Татарстан территориясендә үз инициативалары белән төзелеп актив рәвештә көрәшкән крестьян отрядларының безгә мәгълүмнәренең саны да 70 кә җитә! Чынбарлыкта отрядларның саны тагы да күбрәк булган булуы ихтимал.

Бу отрядларның составында күпме кеше, һәрбер төркемдә никадәре рус, татар, башкорт, мари, удмурт һәм чуваш булуын хәзергә төгәл әйтүе мөмкин түгел. Шулай да, кайбер чыганакларга таянып, Пугачев восстаниесендә ничә меңләп татар крестьяны катнашканын чамалап була. Мәсәлән, крестьяннар сугышы бастырылгач, Уфа провинциаль канцеляриясе Оренбург губерна канцеляриясенә Уфа провинциясендә рус булмаган халыкларның восстаниегә кушылуы турында авыл һәм кеше саннары күрсәтелгән ведомость төзеп җибәрә. Аннан восстаниегә Уфа провинциясендә якынча 35 мең татар катнашканын беләбез. Казан губернасында восстаниегә катнашу активлыгы исә Уфа ягыннан һич тә ким булмаган. Димәк, бу якларда татарларның саны күп булуын исәпкә алсак, баш күтәргән татарларның саны 50 мең чамасына җиткән дип уйларга мөмкин. Әгәр без ике провинциядән тыш Оренбург, Саратов, Сембер, Пенза якларында татарларның күп яшәвен онытмасак, 1773—1775 еллардагы крестьяннар сугышына 90—95 мең чамасы татар катнашкан булуы аңлашыла. Кыскасы, татарларның гына саны шул хәтле булгач, Екатерина II нең барлык восстаниечеләрнең саны 200 мең иде дип әйтүе хакыйкатьтән бик ерак икән.

Баш күтәргән татар крестьяннары арасыннан 9 полковник, 20 дән артык «войсковый» янсә, «походный» старшина, 40 лап сотник, дистәләрчә писер чыккан. Болар, әлбәттә, безгә мәгълүм булганнары гына.

Революциягә кадәр Пугачев хәрәкәтен тикшергән рус дворян-буржуаз тарихчыларының күпчелеге восстаниечеләр лагеренда милли низаглар эзләп, татар һәм башкортларның хәрәкәткә катнашуларын гел аларның милли-азатлык омтылышлары белән генә аңлатып килделәр. Ләкин төрле документларны, бигрәк тә татарча материалларны, җентекләп тикшерү мондый аңлатмаларның ялгыш һәм нигезсез икәнлекләрен исбатлый. Дөресен әйткәндә, хәрәкәтнең сыйнфый асылын аңлый алмаган дворян-буржуаз тарихчылары теләпме, теләмимме гади крестьяннарга «милли сепаратизм» гаебен тагарга тырыштылар. Әлбәттә, аерым отрядлар арасында низаглар, каршылыклар булган, ләкин алар милли нигездә түгел (чөнки ике мишәр отрядының уртак тел таба алмавы да мәгълүм), бәлки крестьяннарча чикләнгәнлек, «урынчылык» нигезендә барлыкка килгән аңлашылмаулар иде (туган җирләрен ташлап китәргә теләмәү, үз кешеләреннән генә торган вак-вак отрядлар структурасын сакларга омтылу һ. б.). Чынбарлыкта исә патша администрациясен, алпавытларны, «янарал, майурларны» дошман дип санаган рус, татар, башкорт, мари, удмурт, чуваш крестьяннары кулга-кул тотышып бер сафта көрәштеләр. Әгәр татарлар, башкортлар, марилар милләте буенча рус булган Пугачевны, дөресрәге, «мужик патшасы» «Питыр Фидраучи хәзрәтләрен» үз җитәкчеләре дип танып, шуның байрагы астында сугышка атласалар, Мәсәгут Гомәров, Бәхтеяр Канкаев, Канзафар Усаев, Әбҗәлил Сөләймановларның кул асларында да рус, татар, башкорт, мари, удмурт крестьяннары бер интересны яклап үлемгә барганнар. Димәк, милли изелүдә яшәгән татар крестьяннары, башка милләт хезмәт ияләре кебек үк, беренче планга социаль азатлык мәсьәләсен куеп, милли интересларны шуңар буйсындырган булып чыга. Боларның барысы Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар сугышы чорында империядәге төрле милләт хезмәт ияләренең сыйнфый аңнары тагы бер баскычка биегрәк күтәрелүе, милли мөнәсәбәтләрнең байый башлавы хакында сөйли.

Татарстан территориясендә сугыш хәрәкәтләренең гомум барышы турында моңарчы беркадәре язылган иде (карагыз: «Совет мәктәбе», 1966, № 10; 1967, № 2; «Казан утлары», 1967, № 1; 1968, № 1 — С. Алишев мәкаләләре). Шуңа күрә биредә крестьян восстаниесенең характерын, үзенчәлекләрен күз алдына китерер өчен Минзәлә һәм Алабуга якларында барган сугышларга махсус тукталабыз.

Минзәлә якларында да баш күтәргән крестьян отрядлары октябрь аенда ук оеша башлый. Исәнгол авылы халкы допроста «Без Кадермәт отрядына кушылдык» дип сөйли. Түбән Өрмид, Урта Өрмид, Иске Каран авылларында 150 ир, Каркино, Югары Ушад авылларында 300 ир кешелек отрядлар оешып, алар Каранай Моратов җитәкчелегендә булганнар; Асан авылы кешесе Мөхәммәтәмин Аитов кул астында 500 кешелек отряд тупланган. Башка авыл кешеләре исә Байсак Биктимиров тирәсенә җыелганнар. Шулай стихияле рәвештә оешкан отрядлар урындагы властьларны бетергәннәр, байларның малларын, алпавытларның җирләрен үзара бүлешеп, чиновникларны физик юк иткәннәр. Нәтиҗәдә Минзәлә крепосте баш күтәрүчеләр белән уратылып, камау хәлендә калган.

Ике чиркәве булып, 600—700 йорттан гыйбарәт, халкының төп өлеше отставкадагы солдатлар һәм Смоленск шляхтасы оныкларыннан торган Минзәлә крепосте, мәгълүм булганча, XVII—XVIII йөзләрдә татар-башкорт восстаниеләрен бастыруда патша хөкүмәтенең таяныч пункты сыйфатында хезмәт иткән. Халыкны эзәрлекләүче гаскәрләр аннан чыккан, кулга төшкәннәрне дә шул ук Минзәләдә җәзалаганнар. Шуңа күрә халыкта «Минзәләнең яртысын туракларга, яртысын яндырырга кирәк» дигән фикер яшәгән. Восстание башланган вакытта Минзәлә крепостенда җитәрлек корал һәм гаскәр булуга карамастан, тиздән аңа Нагайбак крепостеннан капитан Алексеев җитәкчелегендә бер рота солдат ярдәмгә килә. Ныгытманың тыш ягындагы үр-канауларга су тутырып, башнялардагы пушкаларны корып, камаучылар да сугышка әзерләнәләр.

Баш күтәрүчеләр крепостьны чынлап торып 1773 елның декабрендә камап алалар, һәм бу хәл 1774 елның мартына кадәр дәвам итә. Камаучыларның саны 2 меңнән 10 меңгә кадәр җиткән чаклар була. Алар белән «мишәрләр пулкаунигы» Каранай

Моратов һәм Наратлы Кичү авылы ясаклы крестьяны Сәнфин җитәкчелек итә. Алар кан коймыйча сугышсыз бирелергә өндәп, камалучыл арга берничә мәртәбә язу белән мөрәҗәгать итәләр. Хөкүмәт яклы көчләр өндәмәгә колак салмый. 23 декабрьдә штурм башлана (нәкъ шул көнне Чика-Зарубин җитәкчелегендәге зур отряд Уфаны штурмлый...). Бу хакта секунд-майор Петров Казан губернаторы фон Брандтка түбәндәгеләрне язган: «1773 елның 23 декабренда төнге сәгать бердә Минзәләгә көнчыгыш яктан восстаниечеләрнең 1500 кешелек отряды һөҗүм итте. Аларга Алексеев командасы каршы торды, бер казак капралы восстаниечеләр ягына качты».

25 декабрьда баш күтәрүчеләр иртәдән кичкә кадәр 14 туптан крепость өстенә ут яудырып торалар. 26 декабрьда исә 10 мең кешегә җиткән крестьяннар хәлиткеч һөҗүмгә ташланалар. Әлеге Петровның әйтүенә караганда, штурм дүрт яктан да берьюлы башланган. Иртәнге сәгать алтыда бер төркем кеше, елга аркылы чыгып, шәһәрнең паннар бистәсенә омтылып карый, әмма капитан Тихановский командасы каршылыгына очрап, нәкъ шул вакытта аңа Алексеев та ярдәмгә килеп җиткәч, кире чигенергә мәҗбүр була.

Ләкин канлы бәрелешләр, кул сугышлары кичкә кадәр дәвам итә. Нәтиҗәдә «Алексеев, 2 унтер-офицер һәм байтак башка чиндагылар яраландылар, 5 кеше үтерелде,— дип яза Петров,— Каранайның 10 кешесе әсир итеп алынды, 3 пушкасы кулга төшерелде».

Керпостьны камаучылар Дәвек һәм Мәҗен авылларында лагерь корып урнашалар, кайберләре исә үз өйләренә кайтып китә.

Моннан соң баш күтәрүчеләр турыдан-туры һөҗүмгә ташланмыйча, крепостьны камап, тышкы дөньядан изоляцияләп тоту тактикасына күчәләр, ягъни камалучыларны утынсыз, печәнсез, азык-төлексез калдыру тактикасын сайлыйлар. Ләкин камалыш барыбер бик йомшак булган. Мәсәлән, декабрь ахырында Бөгелмәдән ярдәмгә килгән капитан Евсеев командасын Сәнфин тоткарлый алмаган.

Крестьяннарга хәрби белем җитмәү өстенә саксызлык та хас булган. Әйтик, крепость янына разведка максаты белән килгән 300 кешелек отряд кетмәгәндә үзе чолганышта калып, өч дистәгә якын кешесен югалтып, чигенеп качарга мәҗбүр була. Җиңел генә җиңүдән дәртләнеп, хөкүмәт гаскәрләре аларны куа китеп, Мәҗен, Дәвек авылларындагы коралсыз, оешмаган хәлдә ваемсыз яткан татар крестьяннары отрядларын куып тараталар. Вакытлыча лагерь башлыгы булып калган Абдулла Агафеев һәлак була. Үтерелгән татар сотнигы кулындагы байрак җәзалаучылар кулына төшә. 50 дән артык крестьян әсир ителә.

Бу аяныч вакыйгадан соң да крестьяннар керәш ниятеннән кайтмыйлар, бәлки яңадан көч туплап сугышка әзерләнәләр, аларның җитәкчеләре Арча тарафында хәрәкәт итүче М. Гомәров, Әгерҗе ягы крестьяннары полковнигы Ә. Сөләймановка ярдәм сорап мөрәҗәгать кылалар. Бераз хәл җыйгач, гыйнвар, февраль һәм март айларында алар Минзәләгә тагы һөҗүм итеп карыйлар...

Алабуга тирәсендә исә хәлләр түбәндәгечә була. Кама аръягында тезелгән 600 кешелек бер отряд ноябрь башында шәһәрчек янына килеп, аның сугышсыз бирелүен таләп итә. Ләкин Алабуга ул вакытта «изге аталар»» — поплар оясы булганлыктан, восстаниечеләрнең мөрәҗәгате җавапсыз кала. Крестьяннар вәкилен алар шәһәргә дә кертмиләр. Киресенчә, шәһәрнең оборонасын ныгыту эшенә тотыналар — каравылларны көчәйтәләр, руханиларны коралландыралар. Шәһәр кешеләреннән берсе, А. Бурмистров, восстаниечеләр ягына чыга, Пугачев манифестларын алып, яңадан шәһәргә кайта һәм аларны халыкка укып, агитация эше алып бара. Руханилар аны хәйлә белән кулга төшереп, аяк-кулын бәйләп, капчыкка салалар да Казанга озаталар. Бу хәл 1773 елның 24 декабренда була. Ләкин бу вакытны бөтен тирә-юньдәге авылларны восстание ялкыны чолгап ала. Мәсәлән, Сарайлы, Качка, Чаллы авыллары һәм Танай, Өмәр, Тихогорск волостьлары буйсынудан чыккан, чиновниклар сөрелеп, крестьяннарның үз вәкилләре властьны үз кулларына алалар. Шуңа күрә А. Бурмистровны Казанга илтүче монахлар Танай авылында крестьяннар кулына төшә.

Баш күтәрүчеләрнең саны көннән-көн арта. Аларга старшина Күзмәт Ишмиев, Шәфи Тәүфигов, сотниклар Шәриф Якупов, Назар Алексеев, Василий Иванов һәм Утәгән Моратовлар җитәкчелек итәләр. Аларның барсы да башлыклары итеп «пулкаунин» Каранай Моратовны таныйлар.

Рус, татар, башкорт, удмуртлардан торган бу зур отряд Алабугага беренче штурмны 1774 елның 6 январенда ясый. Крестьяннарның туплары, мылтыклары бик аз була. Алабуга шәһәренең тарихчысы, атаклы рәссамның әтисе И. Шишкинның язуына караганда, алар таяк башларын бераз яндырып очлап, «сөңге» ясыйлар. (Яндырылган таякның очы гадәти агачка караганда бераз катырак була. Мондый ысулдан бик борынгы дәверләрдә дә файдаланганнар.) Калганнарының кулында сәнәк, чалгы, балта кебек кораллар була. Казак-татарлар, башкортлар, ди И. Шишкин, ат өстендә арлы-бирле чабып йөреп, крестьян массаларын һөҗүмгә өндәгәннәр. Ләкин начар коралланган, сугыш сәнгатен, шәһәр штурмлау тәртибен белмәгән крестьяннар тәҗрибәле офицер Перский җитәкчелегендәге солдатларны җиңеп, крепостька бәреп керә алмаганнар — яңгыр кебек яуган ядрә, пулялар астында кирә чигенгәннәр. Восстаниечеләр Танай һәм башка авыллардан 70 олау печән һәм салам китереп, шулар артына яшеренеп шәһәргә бәреп керергә ниятләгәннәр, әмма тагы чигенергә мәҗбүр булганнар.

Алабуга өчен барган сугыш гомумән крестьяннар сугышының характерын, хосусиятен күзалларга мөмкинлек бирә. Башка җирләрдә дә нәкъ шундый ук оешмаганлык, коралсызлык, хәрби тәҗрибәсезлек һәм стихиялелек хөкем сөргән. Ләкин баш күтәрүчеләр барыбер сугышканнар, әзме-күпме нәтиҗәгә дә ирешкәннәр. Мәсәлән, Алабуга янындагы крестьяннар активлыгы Казаннан Минзәләгә ярдәмгә дип җибәрелгән майор Перскийны үз отряды белән Алабугада бикләнеп калырга мәҗбүр иткән. Мондый хәлләрне без Татарстанның башка төбәкләрендә дә күрәбез. Нәтиҗәдә хөкүмәт гаскәрләренең көчләре бүлгәләнеп, Оренбург ягында сугышлар алып баручы Пугачевка иркенләбрәк хәрәкәт итәргә мөмкинлек туган.

Майор Перскийның Алабугадан язган хатына караганда, шәһәр тирәсендә 6000 кадәре восстаниече җыелган булган, алар хәлиткеч штурмга әзерләнгәннәр. Ләкин нәкъ шул вакытта Казаннан капитан Кардашевский командасындагы гусарлар килеп җитә. Старшина К. Ишмиев, сотниклар Ш. Якупов, В. Ивановлар үз отрядлары белән гусарларга каршы чыгалар, ләкин таркатылалар. Восстаниечеләрнең терәк пункты булган Танай авылында гусарлар урамда очраган һәр кешене үтереп, өйдәге хатын-балаларга хәтле тураклап йөриләр. Бик аз кеше генә качып котыла ала. Авылда калган мал-мөлек Алабугадагы христиан руханиларына бүлеп бирелә.

Шундый ук хәлгә тагы 17 татар авылы дучар ителә. Күбесендә бушап калган йортларны да яндырганнар. Мондый язмышка очраган авыллар күп еллар узгач кына башка кешеләр исәбенә яңадан үзләштерелә башлаганнар.

Полковник Ю. Бибиковның җәзалаучы отрядлары хәрәкәт иткән Зәй районында исә 22 татар авылы туздырылып ташланган, шулардан Ерыклы һәм Тоба авыллары бөтенләй көлгә әверелгән...

Крестьяннар сугышының беренче этабында халык массалары әнә шулай Пугачевтан башка чыгыш ясап, Татарстанның төрле районнарында актив хәрәкәт итәләр. Сугышның икенче этабында исә, ягъни Е. И. Пугачевның төп көчләре Идел буена килеп, июль аенда Казан өчен каты сугыш барган вакытларда, халык массаларының активлыгы тагы да көчәеп, бөтен төбәкләрне дә көрәш ялкыны чолгап ала.

1773—1775 еллардагы крестьяннар сугышы — ул XVIII гасыр гражданнар сугышы иде, чөнки чорның ике төп сыйныфы капма-каршы торып, җитештерү средстволары һәм власть өчен үзара сугыштылар. Югарыда әйтелгәннәрдән күренгәнчә, бу гражданнар сугышы безнең территориядә башка районнарга караганда ким булмаган. Башка җирләрдәге кебек үк, монда да стихияле рәвештә отрядлар оешып, хөкүмәт гаскәрләре белән сугышканнар; чиновниклар сөрелгән, алпавытлар, байлар качканнар; утарлар туздырылып, заводларга ут төртелгән; крепостьлар, шәһәрчекләр алынып, губернаның мәркәзе Казан яндырылган. Хәтта власть ияләре белән хаким сыйныф вәкилләре восстаниедән нәкъ менә шушы губернада күбрәк материаль зыян күргән. Мәсәлән, восстание бастырылгач, хөкүмәт 19 губернадан восстание вакытында акчалата күпме чыгым (гаскәр тоту, ныгытмалар төзәтү, бөлгән дворяннарга ярдәм итү өчен тотылган акча) чыгуы турында белешмә җыя. Рәсми ведомостьтан күренгәнчә, әгәр Оренбург губернасында 362.061 сум 72 тиен, Тобол губернасында 30.365 сум

05 тиен, Нижний Новгород губернасында 23.937 сум 92 тиен акча тотылган булса, Казан губернасының чыгымы 689.369 сум 1/2 тиенгә җиткән!

1773—1775 еллардагы крестьяннар сугышы Россия тарихындагы соңгы зур халык восстаниесе булды. Моннан соң крестьяннар ни өчен шундый зур восстаниеләр күтәрмәгән дигән сорауларның булуы ихтимал. Моның төрле сәбәпләре булган. Беренчедән, восстаниедән соң материаль һәм иҗтимагый шартлар үзгәргән. Мәсәлән, крестьяннар сыйныфы үз эчендә төрле катлауларга бүленә барган, ягъни крестьяннарның үзләре арасында бай катлаулар тагын да үсеп, хезмәт ияләрен авызлыклаучы естәмә көчләр туган. Аннары дворяннар реакциясе канат җәеп, аларның администрациясе, контрольләү чаралары камилләшкән. Икенчедән, җәмгыятьтә капиталистик мөнәсәбәтләр көчәеп, хуҗалыктагы буржуаз элементларның роле арткан. Боларның барысы нәтиҗәсендә мәйданга яңа көчләр чыгып, көрәш формалары һәм аның методлары да үзгәргән.

Крестьяннар сугышының җиңелү сәбәбенә килгәндә, эш югарыда күрсәтелгән төп сәбәпләргә — халык массаларының оешмаганлыгы, политик аңның чарланмаган булуы, баш күтәрүчеләр лагеренда урынчылык тенденцияләренең көчлелеге һәм башка бик күп факторларга кайтып кала. Образлы итеп әйткәндә, восстаниене крестьян стихиясе җиңгән. Әлбәттә, дворяннар сыйныфының оешканлыгын, дисциплиналы зур армиянең ролен дә онытырга ярамый. Мәсәлән, үзара оешып, берегеп җитмәгән, коралсыз, хәрби җәһәттән тәҗрибәсез, тәртипсез, бер урында дәртләнеп кабынсалар, икенче урында кечкенә генә уңышлардан соң тынычланып, сүрелеп калучы эреле-ваклы отрядларга каршы хөкүмәт 20 меңнән артык регуляр гаскәр, А. В. Суворов кебек сугышчан генералларын җибәрә. Әби патша Екатерина II нең икърар итүенә караганда, мондый армия күрше дәүләтләр өчен дә куркыныч тудырырлык көчкә ия була.

Крестьяннар сугышы җиңгән очракта ничек булыр, иҗтимагый үсеш нинди юлдан китәр иде? — дигән сорау да тарихчылар тарафыннан куела һәм төрлечә аңлатыла килә. Безнеңчә, феодаль изүнең бераз йомшаруы һәм авыл хуҗалыгында буржуаз мөнәсәбәтләрнең көчәя төшүеннән артыкка китмәс иде, чөнки хосусый милек һәм гомумән эксплуатацияне бетерүнең кирәклеген восстание җитәкчеләренең берсе дә аңламаган. Ә буржуаз мөнәсәбәтләрнең үсүенә килсәк, ул, восстание җиңелеп, дворяннар реакциясе көчәйгәч тә, үзенекен иткән: әкренләп булса да экономиканың төрле сфераларына тамыр җәя барган. Капиталистик мөнәсәбәтләрнең башка милләтләр хуҗалыгына нык тәэсир ясый башлавы да шуны күрсәтә. Мәсәлән, XIX йөзнең башында Казандагы күн-тире эшкәртү предприятиеләренең 36 проценты, җитештерүнең якынча 62 проценты татарлар кулында булып, андагы эшчеләрнең 42 проценты татарлардан гыйбарәт иде. Сабын-шәм заводларының 52 проценты, җитештерүнең якынча 61 проценты татарларда булып, эшчеләрнең 52 процентын татар хезмәт ияләре тәшкил иткән. Эшчәнлекләрен авылдан Казанга күчерүче татарлардан 100—200 мең сумга кадәр капиталлары булган фабрикант-сәүдәгәрләр чыккан.

Ләкин крестьяннар сугышының төп әһәмиятен, кайберәүләр аңлатканча, феодализм таркатылып, капитализмга юл ачылуга кайтарып калдырырга ярамый. Чөнки ул моны эшләп бетерә алмады. Әйтелгәнчә, феодализм таркалып китмәде, бәлки восстаниедән соң дворяннар реакциясе көчәйде. Әмма, мәгълүм булганча, социаль изүнең көчәюе азатлык өчен көрәш идеяләрен дә көчәйтә иде.

Чынлыкта восстаниенең прогрессив әһәмияте тирәнрәк булып, ул башка өлкәләрдә дә нык сизелде: бөтен Россиянең, андагы төрле халыкларның тарихында фикер үсешенең яңа этабына, киләчәк буыннарны рухи, иҗтимагый азатлык өчен көрәшкә турылыклы итеп тәрбияләүче олы факторларның берсенә әверелде ул. Рус Емельян Пугачев, башкорт Салават Юлаев, татар Бәхтеяр Канкаев образларының халык күңелендә яшәве, аларның җыр, риваять геройларына әверелүе моңа ачык мисал. Әгәр патша хөкүмәте «юлбасар» Пугачевның исемен телгә алуны тыеп, аның истәлеген бөтенләй юкка чыгару өчен төрле чаралар күрсә, кешеләр үзләренең яшьләрен, аерым вакыйгаларның вакытын «Пугачау явыннан» алып исәпләгәннәр.

Пугачау патшаны күрсә идең,
Алларыннан буй бөгеп узса идең,

Аргамак менеп, дан тотып,
Җаек яуларында йөрсә идең,—

дигән җырда исә халыкның «падишаһ Петр Өченче»не түгел, бәлки көрәшче Пугачевны, аның җитәкчелегендә аргамак ат менеп, ирек яулап, дан тотып йөргән чакларны — бөек көрәш елларын сагынуы ачык яңгырый.

Әйе, географик күләме һәм күп милләтлелеге белән бер Россиядә генә түгел, бәлки бөтен Европада тиңе булмаган бөек крестьяннар сугышы халкыбыз аңында тирән эз калдырган, халыкларны киләчәк көрәшләр өчен уятып калдырган вакыйгаларның берсе ул. Элгәрге сүлпән темп белән үсүче татар әдәбиятының Пугачев хәрәкәтеннән соң күзгә күренеп җанлануы, димәк, иҗтимагый фикернең дә кызурак темплар белән алга китүе моңа бик ачык дәлил.

Бу үзгәрешләр бары тик «капиталистик мөнәсәбәтләр көчәюенең» генә нәтиҗәсе булмыйча, биредә крестьяннар сугышының йогынтысы да әһәмиятле роль уйнавын түбәндәге татарча документларның рухы да бик яхшы раслый. Аларны укып, без восстаниечеләр лагерының эчке тормышын, уй-фикерләрен белү белән бергә, баш күтәрүчеләрнең тормышны үзгәртүдә (үзләренчә үзгәртүдә) нинди конкрет чаралар күрүләрен дә беркадәр абайлый алабыз. Хәрәкәтнең нигезендә тирән социаль каршылыклар ятуын, төрле милләт хезмәт ияләренең кулга-кул тотышып гамәл кылуын, демократ көчләрнең өстенлек алулары белән бергә, тормышның язма культура, әдәби тел кебек сфераларында да сизелерлек үзгәрешләр барлыкка килүен күрергә мөмкин.

Дөрес, документлар әдәби өзерлекләре, сөләтләре, хәтта грамоталыклары буенча да төрле дәрәҗәдә торучы кешеләр тарафыннан авыр шартларда ашык-пошык язылганнар. Шулай да алар бер тенденцияне бик ачык чагылдыралар: иске әдәби тел яңа шартларда — вакытлыча булса да, халык өстенлеккә чыккан мизгелдә — гадиләшү, халыкчанлашу юлына таба борылыш ясый. Моның шулай икәнлеген аңлау өчен восстаниенең беренче чорында рәсми иске татар әдәби теле нормалары белән язылган «Манифест»ны һәм соңрак восстаниечеләр тарафыннан төзелгән документларның теле белән чагыштыру да җитә. Шуңа күрә беренче документны тәрҗемәләп бирәбез. Бу документ моңарчы Газиз Гобәйдуллин һәм Мөхәммәт Гали тарафыннан ике мәртәбә бастырып чыгарылган иде. Ләкин без кайбер сүзләрне яңача укыдык.

Документлар белән якыннан танышу ерак узганны тикшерүче тарихчылар өчен генә түгел, бәлки бүгенге идеологик фронтта эшләүче киң катлам интеллигенциябез — укытучылар, лекторлар, язучы-журналистлар өчен дә әһәмиятле. Шулай ук сыйнфый көрәш, культура тарихы белән кызыксынучы укучыларга да файдалы булыр. Шуңа күрә без, гадәттәгечә, өч-дүрт үрнәк бирү белән генә канәгатьләнмичә, 26 документтан торган бер цикл тәкъдим итәбез.

Документлар Мәскәүдәге борынгы актлар саклана торган Үзәк дәүләт архивының (ЦГАДА) VI разрядындагы 416 «эшнең» II кисәгендәге материаллардан алынды. 445 кәгазьдән торган бу «эштә» турыдан-туры восстаниегә караган 220 дән артык документ берәмлеге (300 кәгазь) бар. Аларның барысын да гыйльми таләпләргә лаеклы итеп басмага әзерләү өстендә хәзер бер төркем галим эшли (бу мәкалә авторларыннан тыш Х. Госман, К. Дәүләтшин, Ә. Шәрипов, Ф. Хисамова һ. б.). Гомумән алганда, XVII—XVIII йөзләрдәге сыйнфый көрәшләргә караган татарча архив документларының хәзергә безгә мәгълүмнәренең саны мең ярымнан артык. Аларның барысын да барлап, җыеп, эшкәртеп бастырып чыгару тарихчыларыбыз, телчеләребез бурычы.

Ләкин журнал укучыларының даирәсе киңлеген, төрле даирә укучыларының лингвистик әзерлек дәрәҗәсен игътибарга алып, документларның беренчесеннән башкасын гадиләштерелгән укылышта (бигрәк тә сузык авазлар системасын транскрипцияләүдә) бирәбез, шуңа күрә мондагы укылыш фонетик яктан (ләкин лексик, синтаксик, грамматик җәһәттән түгел!) документаль төгәллеккә дәгъва итми.

Бик архаик атамаларның, гыйбарәләрнең конкрет тәрҗемәләре бит азагында бирелә. Документ даталарында иске стиль саклана (XVIII йөз өчен аерма 11 көннән гыйбарәт).

## № 1

## 3 ДЕКАБРЬ, 1773 ЕЛ. Е. И. ПУГАЧЕВНЫҢ ХӘРБИ КОЛЛЕГИЯСЕ ТАРАФЫННАН БӘХТЕЯР КАНКАЕВКА БИРЕЛГӘН МАНИФЕСТ.

### 1. Транскрипция

Сәр гаскәре мөнәввәри шаһи җиһан.

Мән ки — газәме әгъзәм җәмгы хассәи вә гавамәи мәхлукый, би-тарафәи вилайәт йортларының вә бил-истикъләл хөкемдәры, үз кулунда вә куәтендә гяһ вә гяһ мәгайән улуб тоткучы вә белгүчедәр и Руссия вә гайре, вә гайре, вә гайре һәм ничә вә ничә дәйярлары үзә всеарассискуй әгълаи галя импиратыр Питыр Фидурувич кәндү падишаһ хәзрәтләрендин сабит кыйлынол, именнуйым указдин тикшерәләп вирәлде белмәк вә инанмак өчен: тугры хәлас вә ихласонча тороп хезмәт вә чирү кыйлмакга, кәндү кулундин вә худ телемдин вирәлде бу намәи әгъляи.

Вә бәнем мөбарәк йөземи, хуб җәмалымны хәзр вә назир каршу кәлүп, раст нәзәри мөлбаләга вә гакыләнә кемсәнәләр үзә, дур күрүп вә беләп, вә игътикад вә ихласы дил, вә теле, вә кулы, вә бәгърене кәбаб әйләйүп, тәндә газиз җан илә,— әлбәттә булурмын йорлукагучы йириңезе вә суыңызы, вә байлыкыңызы, вә утуыңызны, вә кырыңызы, вә йәгачыңызы, вә пурх, вә акча, вә кургашын, вә итмәк, вә тозы, вә гайресе илән.

Кемдәр башын тарткучы вә каршылык кыйлгучы, вә байәр, вә йанарал, вә майур, вә кәпитан, вә гайресе — башы кисүле, вә малы талаулы — алыңыз, каршы торыңыз, башыны кисеңез; хәзинәсе булса, падишаһга килтерергә; вә йигеме, вә аты һәм үзгә гайре ярагъы нәрсәләр булса, падишаһга килтерергә; һәм гайре йяраг-сыз нәрсәләрене әрмийә халайыкларына таркатоп хәрәҗ кыйлыңыз. Бер вакытда сөзләрне анлар ашады вә йиде, мәнем колларымны ирексез вә ихтийарсыз итде, өкнүн үзләрене чабоңыз,— иллә мәгәр баш салмагонча. Әгәр миңа мотыйг улса, хилаф дәгелдер — тикмәйсез мәне дийән кешийә, кемдәр миңа тугры йул гизәп, чирү вә хезмәт кыйлмага. Кемдәр кинә баш тарткучы — анлар үзә асмакым вә кисмәкем анлар үзәдәр, зинһар гафил калмаясызлар.

Кәндү инанмак өчен сам Питыр Фидурувич кулом куйдом я самый Питыр трити дәйү.

Ошбу манифист бирәлде пулкувуй ыстаршина Бәхтеяр Канкай угылына, палкавуй сутник Габдәлкәрим Күскәй угылына. һәм шуның өчен Вуяннай каллигасының пичат(е) басылды.

Кәндү бу указдин күбийә һәр тарафка вә якга күндүрәсез, күйәдин күйәйә, күчәдин күчәйә, һич дә туктатмайынча йөртсәнләр дәйү гаһд кыйлынды. Кем дә байар колы вә керастийан залим дәстендә грифтәр улса, бу кен мәндин азад, яинкә зинданда вармы — хәлас ула.

Вә биоролоп, вә әмер кыйлынол ийбәрәлде маһ рамазанның 29 нчы кенендә, сәнәи 1773 нче йылда.

[Русча куелган имзалар:]
Иван Творогов
Секретарь Максим Горшков
Повытчик Иван Герасимов.

| Мөһер |
|---|

106 кгз.

## 2. УКАЗНЫҢ ХӘЗЕРГЕ ТЕЛГӘ КҮЧЕРЕЛМӘСЕ.

Җиһан шаһының нурлы гаскәр башлыгы.

Мин,— барча аксөякләр һәм гади халыкның, төрле өлкәләр һәм илләрдәге җан ияләренең ирекле хөкемдары, һәр вакытта мәгълүм хәлдә [шуларны] үз кулында һәм ихтыярында тотучы һәм белүче, Руссия һәм башка, һәм башка, һәм башка ничә-ничә илләр өстендәге бөтенрусиянең бөек, гали императоры Петр Федорович,— үземнең падишаһ хәзрәтләрем [тарафыннан] расланган, махсус указымнан тикшереп белмәк һәм инанмак өчен, тугры һәм ихлас [күңел] белән торып хезмәт [итмәк] һәм сугышмак өчен үз кулымнан һәм үз телемнән ошбу бөек язуны бирдем.

Һәм минем мөбарәк йөземне, күркәм чыраемны үзләре очратып, [ячсә] хыялдан һәм гакылдан олылаган, якыннан күреп, белеп ышанган, ихлас күңеле, теле, гамәле белән бөгырен яндырып, газиз җаны белән [тугрылыклы булган] кешеләр өчен, әлбәттә, ярлыкагучы булырмын — җиреңезне, суыгызны, байлыгыгызны, утыгызны, кырыгызны, агачыгызны, [шулай ук] дары һәм акча, һәм кургашын, һәм икмәк, һәм тоз һәм башкалары белән [бергә ярлыкармын]!

Кемнәрдер [буйсынудан] баш тартсалар, каршылык күрсәтсәләр, [һәм шулай ук] бояр, генерал, майор, капитан һәм башкалары — [барысының] башы кисүле, малы талаулы [булсын]: алыгыз, каршы торыгыз, башларын кисегез; хәзинәләре булса, падишаһка китерегез; олавы, аты һәм үзгә гайре яраклы нәрсәләре булса, падишаһка китерегез; һәм башка яраксыз әйберләрен армия халайыкларына өләшеп бирегез. Бер вакытларны алар сезне ашадылар, таладылар, минем газиз колларымны ирексез һәм ихтыярсыз иттеләр, хәзер үзләрен чабыгыз, илла-мәгәр баш салганга кадәр. Әгәр миңа буйсынсалар, хилаф түгелдер, [ягъни] мине танып, тугры юлда булып, сугышкан һәм хезмәт иткән кешеләргә тимәссез. Кем дә кем баш тартса, аларны асачакмын, кисәчәкмен. Зинһар, гафил булмагыз!

Инанмак өчен мин Петр Федорович үзем кулымны куйдым,—

Петр Өченче дигән исем белән.

Ошбу манифест бирелде полковой старшина Бәхтеяр Канкай угылына, полковой сотник Габделкәрим Күскәй угылына; һәм шуның өчен хәрби коллегиянең печате басылды.

Үзегез бу указдан копия [күчереп] һәр тарафка, [төрле] якка күндерәсез; авылдан авылга, урамнан урамга һич тә туктатмайнча йөретсеннәр дип шарт куелды; кемдер бояр кулында һәм крестиян залим кулында җәберда булса, бу көн миннән (минем тарафтан) азат [ителә], шулай ук зинданда булучы ирекке чыгарыла.

Боерып һәм әмер итеп җибәрелде рамазан аеның 29 көнендә, 1773 елда.

[Русча имзалар:]
Иван Творогов
Секретарь Максим Горшков
Бүлек мөдире Иван Герасимов.

| Мөһер |
|---|

106 кгз.

### № 2

### 8 ДЕКАБРЬ, 1773 ЕЛ. ВОССТАНИЯЧЕ ОТРЯДЛАР ОЕШТЫРУ, ТИМЕРЧЕЛӘРДӘН КОРАЛ ЯСАТУ ХАКЫНДА АТАМАН НУРАЙ ИШАЕВ БОЕРЫГЫ.

Ул олуг импиратыр агъзәм падишаһымыз Питыр Фидурувич хәзрәтләренең әмер фәрманы буйынча бойырыладыр.

Сән Алдар авылының мелла Рахманкол Гомәр угылы Усы юлында булгучы мишәрләрне бахутка чыкаргайсыз, ике идән[1] бер кешене; һәм баш салмаган халайыкларны баш салдыр(ыр)га; баш салганнары белә бергә йөреп баш салдыр(ыр)-га әмире әтрафы падишаһымыз[2] Питыр Фидурувичкә ул тирә-якдагы һәр төрле халай-

[1] Идә — өй.
[2] Әмире әтрафы падишаһымыз — биредә: бөтен тирәгә хөкемдар падишаһымыз.

ыкларны. Әгәр дә баш салмай инкяр итәсе булса, шундайларны монда тотып йибәргәйсезләр. Һәм баш салгучы купме булыр, сезләр илән бергә, шуны монда рипурт[1] илән мәгълум кыйлгайсызлар, монда кичектермәйенчә. Усы юлының мишәрләре баш салганлардыр Питыр Фидурувичкә, чиргә йөрегүчеләр рәнҗу тигермәсенләр малларына вә һәм үзләр(енә). Әгәр һәркайда җыйылгучы дошманлар булса, көчеңез йитмәсдәй булса, монда рипурт илән мәгълум итәсезләр, әгәр көчеңез йитәрдәй булса, җәһәт итәсезләр анларны харап итәргә. Шул сәбәпле һәркем монларны тыңлагайсызлар.

Падишаһымыз хәзрәтләренең каһәре, әмере газабындин куркып, монларга тиешле урынларда яр(дә)мне иткәйсезләр һәм олауны биргәйсезләр һичбер йобутмайынча[2].

Атаман Нурай Ишәй угылы тамгам салдым (...)[3],

Ыстаршина Баптай Мөслим угылы кулым куйдым;

Ыстаршина Ихсан Биард[4] угылы кулым куйдым;

Пахутнай ыстаршина Габделкәрим Максуд угылы кулым куйдым;

Молла Сөләйман Мостафа угылы кулым куйдым.

Йәнә баш салганларга биргәйсез билит ускуйның[5] куәтенчә һәм эшләгәйсезләр коралларны, тимерчеләрнең инкярларына куймайынча, биш багакны[6] бер тийенгә, бер сеңгене биш тийенгә. Әгәр инкяр итәсе булсалар тотып, рипурт илән монда йибәргәйсезләр, юкарыдагы указ куәтенчә.

Инанмак өчен атаман Нурай Ишәй угылы тамгам салдым (...);

Сәнәи 1773 йылда, дикәбернең 8 көнендә.

Указ куәтенчә бирелде ошбу билит Туктамыш камандасының Алдар авылының молла Рахманкол Гомәр угылына.

Указ бойырылды Габделмәннаф Әлмәт угылы кулына вә йәнә Муса, вә йәнә Сөбханкол вә йәнә Атнабай, вә йәнә Әлемгуҗа [кулына], Кунгур әйәзләр(енә) мәшһүр итәр өчен.

**440 кгз.**

## № 3

## 24 ДЕКАБРЬ, 1773 ЕЛ. БӘХТЕЯР КАНКАЕВНЫ ПОЛКОВОЙ СТАРШИНА ИТЕП РАСЛАУ ҺӘМ АҢАР БУРЫЧЛАР ЙӨКЛӘТҮ ХАКЫНДА И. Н. ЗАРУБИН-ЧИКА ТАРАФЫННАН БИРЕЛГӘН ӘМЕР.

Өлкән мәрхәмәтендин ул олуг импиратыр әгъзәм падишаһ хәзрәтләренең, Питыр Фидуричдин йибәрелмеш граф Иван Никифыр угылындин вә һәм пулкувник Якафановдин әмер илә, ул олуг импиратыр әгъзәм падишаһ хәзрәтләренең кайсы кем хезмәт(ен) кыйлурга теләйләр, аның өчен килде монда Туй завутына хезмәтене курсәтмәклеке буенча палкавай ыстаршина Бәхтеяр Канкай угылы.

Вә кинә[7] бойырылды ул Бәхтеяр Канкай угылына палкавай ыстаршина булып, чиру хезмәт(е) кыйлмага, вә кинә теләде үзенә юлдашлыкка яраглыкы өчен сутниклыкка Габделкәрим Кускәй угылыны,— ул олуг импиратыр әгъзәм падишаһымыз Питыр Фидуричнең хезмәтене кыйлурга, үзе берлә бергә йөреп; ушандаг тирә-яктагы башкортлар булса, вә һәм мишәрләр булса, вә һәм татарлар булса, вә һәм чирмешләр булса, вә һәм урыслар булса — ул югарыда яд иделгән һәр төрле җенесле халайыкларга ул олуг импиратыр әгъзәм падишаһымыз хәзрәтләренең указы куәтенчә әмер улынды: икешәр ивдин бер кеше алып хезмәт кыйлурга; ул олуг импиратыр әгъзәм падишаһымыз Питыр Фидурич хәзрәтләренә баш салган халайыкларны алып бергә йөреп, баш салмаган халайыкларны баш салдырырга; ул олуг импиратыр әгъзәм падишаһ хәзрәтләригә рәнҗүлек вә һәм ноксанлык китүрсәләр, кен әлгәре шундай хальләрне аң-

---

[1] Рипурт — рапорт.
[2] Йобутмайынча (юатмаенча) — туктатмаенча, тоткарламыйча.
[3] Тамга-мөһер өчен җөя эченә алынган куп нокталар куела.
[4] Исем бераз бозылган булырга охшый.
[5] Ускуйның — тиеш: войсковойның.
[6] Багак — пычак булырга тиеш.
[7] Вә кинә (кәнә) — һәм тагы.

лап вә белеп, дошманнарына каршы торырга; әгәр баш тартсалар, шундайлар илә яулашырга.

Вә кинә бойырылды: рәхимле падишаһымызның указы куәтенчә падишаһга кирәкле интириснай[1] эшләрне һәр төрле урыннардин тиргәр өчен[2] — туп тик, дары тик вә йадрә тик, вә һәм бужай тик, вә һәм туркә[3], вә һәр төрле кораллары карап алырга — инкярларына куймайынча.

Вә йәнә дәхи бойырылды туктатмәйынча моңларга олауларны биргәйсезләр, падишаһ хәзрәтләренең каһәр үлемендин куркмак өчен.

Җәди[4] йолдызының 24 көнендә, граф Иван Никифыр угылы дәйү.

1773 йылда.

175 кгз.

## № 4

## 1773 ЕЛНЫҢ ДЕКАБРЕ — 1774 ЕЛНЫҢ ЯНВАРЕ. МАМАДЫШ РУСЛАРЫНЫҢ БАШ КҮТӘРҮЛӘРЕ ХАКЫНДА СТАРШИНА КҮЗМӘТ ИШМӘНОВ ТАРАФЫННАН ШӘРИФ ЯКУПОВКА ҖИБӘРЕЛГӘН РАПОРТ.

Ул олуг трити импиратыр газиме падишаһымыз Питыр Фидурувичның указы куәтенчә пахутнай ыстаршина Күзмәт Ишмән угылына килеп баш салдылар Мамадыш саласының урыслары, тигрә-як халайыклары берлән.

Ул мәзкүр баш салган урыслар сорайлар үзләренең авылында тормакка. Пулык корулары[5] өчен үзләре һәм анлар каманда бирделәр монда. Ләкиндә үзләре сорайлар каманда башкорт халайыкларындан, бер йөз кеше.

Ишетәмез кем, сезгә мең кеше килә дип, аның өчен кем сез ыстаршина Шәриф Ягкуб угылы йөз кеше мәзкүр улынмыш[6] Мамадыш саласына йибәргәйсез.

Инанмак өчен ыстаршина Күзмәт Ишмән (угылы) кул куймак урнына тамгам салдым (...).

349 кгз.

## № 5

## 1 ЯНВАРЬ, 1774 ЕЛ. Е. И. ПУГАЧЕВ СТАРШИНАЛАРЫ БАКЫЙ АБДУЛ УГЫЛЫ, ЮСКӘЙ КУДАШОВ ҺӘМ БАШКАЛАР ТАРАФЫННАН ИЖ ЗАВОДЫ ЭШЧЕЛӘРЕНӘ БИРЕЛГӘН БИЛЕТ.

### Газәм-ел-әгъзәм

Ул олуг падишаһымыз Питыр Фидурич хәзрәтләренең указы куәтенчә бирелде билит Иш забутында эшләп торгучы Имилиан Иван угылы унбер юлдашы берлән баш салдылар рәхимле Питыр Фидурич хәзрәтләренә. Бу көндин соң армиядин — йөргүчеләр һәм гайреләр — билгесез кешеләр дип, рәнҗү-зарар тигермәгәйсезләр.

Пахутнай ыстаршина Бакый Абдул угылы кулым салдым.

Пахутнай ыстаршина Йускәй Кудашов кулым салдым.

Пахутнай ыстаршина Валит Җәгъфәр угылы кулым салдым.

Пахутнай писер Габдул Чынай угылы, ыстаршиналар әмеренчә язып, кулым куйдым.

Сәнәй 1774, гыйнвар әүвәл көнендә.

257 кгз.

---

[1] Интириснай — интересный, кызыклы.
[2] Тиргәр өчен — тикшерү өчен.
[3] Бужай, туркә — мылтык төрләре.
[4] Ай исеме, декабрь аена туры килә.
[5] Оригиналда «куркулары» кебегрәк язылган, ләкин ул мәгънәгә туры килми.
[6] Мәзкүр улынмыш — аталган, телгә алынган.

## № 6

## 10 ЯНВАРЬ, 1774 ЕЛ. СТАРШИНА БАЛТАЧ СӘЕД УГЫЛЫНА ӨФӨ ЯНЫНДАГЫ ҮЗ ОТРЯДЫНА БАРЫР ӨЧЕН БИРЕЛГӘН БИЛЕТ.

**Билит**

Ул олугы икълим[1] падишаһымыз Питыр Фидурич әгъзәм хәзрәтләренең әмер фәрманы буйынча Өфө өйәзенең Казан юлының ыстаршина Сәлим камандасының Бикмәт авылының пахутнай ыстаршина Балтач Сәед угылына биреләде билит, йәнә үзенең өч юлдашы берлән.

Бу Балтачның камандаларыны алып киткән Өфегә туп берлән бергә, каронид[2] Иван Лачович; ул Балтач үзе калган сырхау булып. Имде сырхавындин яхшы булганның соңында йибәреләде үзенең камандасы артыннан, юлыкырга[3], Өфө каласы астына.

Имде бу мәзкүр Балтачны өч юлдашы берлән Өфө астына баруында юлда — һәртөрле җенесле халайыклардин булынмыш камандирлар улсынлар — һичбер вәҗһ берлән[4] рәнҗү вә зарәр тигермәгәйсезләр.

Үзләренә бойырылды вурларга[5] катышмаска, анлар берлән бер киңәшдә булмаска дәйү,—

рәхимле падишаһымыз Питр Фидурич әгъзәм хәзрәтләренең мәрхәмәтләнмеш указының куәтенчә хезмәт итеп йөргүче Яркәй[6] юклыгында урнына торгучы Рахманкол Исай (угылы) билит биреп, инанмаклык өчен тамгам салдым (...);

1774 йылда, гинварның 10 көнендә йибәреләде.

Яңа Пәнҗәр авылындан писер Мөстәкыйм яздым, Рахманкол әмеренчә кулым куйдым.

195 кгз.

## № 7

## 13 ЯНВАРЬ, 1774 ЕЛ. КАРАНАЙ МОРАТ УГЫЛЫ ТАРАФЫНДАН НАЗАР АЛЕКСЕЕВКА БИРЕЛГӘН КҮРСӘТМӘ.

Мөнәввәр газәме әгъзәме икълим падишаһымыз Питыр Фидуричның кәнду[7] тарафындин килгән исемле[8] указының куәтенчә биреләде ошбу наставлиния[9] Казан өйәзенең Йөри юлының Чулама кәриянең[10] Илбакты...[11] шул ук йиканумическуй крәстийән Назар Әләкчай угылына.

Каюсы кем шул җәһәтдә рәхимле падишаһымыз Питыр Фидуричкә бигать[12] бирмәйенчә инкяр вә хөҗҗәтләшкүче[13] дошманларына каршы торып, аларны харап итәргә; вә каюсы кем бигать биреп, тугырылык илән бәндә улан колларына һичбер вәҗһдә[14] рәнҗү-зарар тигермәскә. Әгәр сезләрнең йөрмәклекеңез(дә) падишаһның дошманы бәрәр урында әшкярә вә заһир улса[15], шундайынларны(ң) малларыны талап, үзләренең башларыны кисәргә, әгәр падишаһ хозурына баш салмаса; әгәр баш саласы булса, тигмәйәсез.

---

[1] Олугы икълим — бөек ил, олы дәүләт.
[2] Каронид — сүз шартлы рәвештә укылды.
[3] Юлыкмак — очрашу; бирелә — кушылу.
[4] Һичбер вәҗһ берлән — һичбер нинди сәбәп (сылтау) белән.
[5] Вурлар — караклар, ягъни хөкүмәт яклылар.
[6] Яркәй — Яркәй Кадермәт угылы.
[7] Кәнду — үзе.
[8] Исемле указ — патша тарафыннан адресатның исемен атап биргән махсус указ (именной указ).
[9] Наставление — бирелә: күрсәтмә.
[10] Кәрия — «кария» (авыл).
[11] «Илбакты»дан соң бер сүз төшкән булырга тиеш.
[12] Бигать — буйсыну, буйсыну турында ант.
[13] Хөҗҗәтләшү — бәхәсләшү, дәлил сорап бәхәсләшү.
[14] Вәҗһ — сәбәп, сылтау; бирелә: һичбер яктан да.
[15] Әшкярә вә заһир — бирелә: ачык һәм мәгълүм.

Мәгълүм улына сән Назар Әләкчәй угылына: йөрмәклекендә яхшы кагыйдә илә йөрегәйсән — курыккайсән падишаһның каһәрле указыдин тәйү, шуның өчен,—
Ыстаршина Каранай Мөрат угылы кулым куйдым.
Сәнәи 1774 йылда, гинварның 13 көнендә.

266 кгз.



## № 8

## ЯНВАРЬ, 1774 ЕЛ. ТЕГЕРМӘННЕ ЭЛЕККЕЧӘ КАРАП ТОРУ ХАКЫНДА КАНЗАФАР УСАЕВ ТАРАФЫННАН БИРЕЛГӘН ӘМЕР.

Ул олуг импиратыр әгъзәм падишаһ хәзрәтләре Питыр Фидуричның әмер фәрманы буенча бирелде билит Суксун завытының ыстарыстасы Фидур Иван угылына шуның хакында:

Кайсы Александр Григурий угылы Димидауның бар иркәндер ясаткан тегермәне, Күнгүр өйәзе Пинтурин авылында ясаткан тегермәне, бойырылды ул тегермәнне борынгы кагыйдәчә карарга засыпка[1] Фрул Вуревьевка, вә һәм тарттырырга; тарттыргандин кәзин[2] җыйылган онындин засыпкасы җәмәгате илән ашасын, ашагандин артканын вә һәм җыйылган акчасын рәхимле падишаһымыз Питыр Фидуричның хәзинәсенә тугырылык илән язарга дәйү; бездин гайре кәмандирлар вә гайре халайыклар рәнҗү-зарар тигермәгәйләр, курыкмакда улып падишаһның каһәрле хөкемләрендән дәйү,—

Ыстаршиналык [эшен] әда [кылгучы][3] мелла Канзафәр Усай угылы кулым куйдым.

Сәнәи 1774 йылда, гинварның көнендә...

420 кгз.

## № 9

## 23 МАРТ, 1774 ЕЛ. ДОШМАННАРГА КАРШЫ СУГЫШЫР ӨЧЕН ОТРЯДЛАР ОЕШТЫРУ ХАКЫНДА СОТНИК ИЛЕТБАЙ ИЛЕМБАЙ УЛЫНА САЛАВАТ ЮЛАЕВ ӘМЕРЕ.

Ул олуг импиратыр падишаһымыз Питыр Фидурич хәзрәтләренең указы куәтенчә тәхкыйк бойырыладыр бән пулкауник Салават ыстаршина Юлай угылындан кайсы кем ул сутник Илетбай Илембай угылыга:

Рәхимле падишаһ хәзрәтләренә каршылык кыйлгучы вурларга каршы торып, үз кул астындагы камандалары илән җан-тән илән сугыш итәргә дәйү; һәр кадән хезмәткә ярагудайларны — атларны[4], йәйәүләрне калдырмайынча, иңкярларына куймайынча падишаһ хезмәтенә чыгарырга дип; әгәрчә хезмәткә иңкяр итәсе булсалар, андай кемсәнәләрне тотып, рипуртың илән безләргә йибәрергә дәйү; вә һәм сез түбәндә язылгучы каманда халайыклары сутник Илетбай Илембай угылы хөкемен тыңламакда улып хезмәт иткәйсезләр, падишаһымыз әгъзәм хәзрәтләренең вә һәм хөкемендән курыкмак өчен дәйү,—

Пулкауник Салават, ыстаршина Юлай угылы, кулым куйдым вә һәм инанмаклык хакында пичәт бастым.

Сәнәи 1774 йылында, мартның 23 көнендә.

208 кгз.

---

[1] Засыпка — тегермәнче.
[2] Кәзин — соңра.
[3] Әда кылгучы — башкаручы.
[4] Атларны — кирәк: атлыларны.

## № 10

### МАРТ-АПРЕЛЬ, 1774 ЕЛ. АТАМАН ГАДЕЛ БИГӘШЕВ ТАРАФЫННАН БӘХТЕЯР КАНКАЕВКА ЯЗЫЛГАН РАПОРТ.

**Сез ки гыйззәтле вә хөрмәтле, бүләнд һиммәтле**[1] пулкауник Бәхтеяр Канкай **угылына һәм ыстаршина** Яркәй Кадермәт угылына күбдин-күп догалардин соңра мәгълүм ула.

Кайсы кем үзеңездән килгән рипурт берлә ике кеше сәг вә сәламәт йитделәр. **һәм мәгълүм ула:** үземез Танып буйында Карабай авылында торамыз һәм каманда йыйыйлгандин[2] соң Әңсак завуты тигрәсенә[3] каравыллар куйып тәмам иткәч, үземез сезгә хәзерләнеп барырмыз, инша аллаһе тәгалә дәйү,—

Мелла Гадел Бигәш угылы кулым куйдым.

Писер Мөхәммәд Муса угылы язып кулым куйдым.

Сәнәи 1774, дүшәмбе көнне.

Ошбу рипурт берлә баргучы ике казакъка һич бер сәгать йобатмайынча авыл-авылдан берәр олауны биргәйсез, пырагунсыз[4].

50 кгз.

## № 11

### 27 АПРЕЛЬ, 1774 ЕЛ. БАШ АТАМАН ИВАН БЕЛОБОРОДОВ ТАРАФЫННАН БӘХТЕЯР КАНКАЕВКА БИРЕЛГӘН ОРДЕР.

Ошбу урдир йиберелде.

**Главнай атаман** Иван Наумич Билабурудуфка сән пулкавуй ыстаршина Бәхтеяр Канкай угылы рипуртларың илән мәгълүм кыйлдың; ни кем сезләр хәуефләнеп торасызлар ул якдагы Күңгүр дошманларындин; халайыкларны җыйдырып йәнә дә карауыллап ядасыз[5], бик гаять дә сак булып.

һәм сез андагы ыстаршиналарга әмердер: ул якдагы урыс казакъларны вә һәм татарларны һич дә бер ниндәй инкярларына карамайынча монда йибәрәсезләр һәм кару иткәнләрен бәйләп, һәм качсалар эзләп, табып үлтергәйсезләр вә һәм аскайсызлар.

Сән Бәхтеяр мәгълүм кыйлдың әч ат, анлар бик әрыклар дип; имде анлар симергәнчә торсыннар, андин соң падишаһлыкка алыныр.

Йәнә мәгълүм кыйлдың, ыстаршина Илчегол тәннә исереп килеп сезнең авылыңызга, халайыкларны куркытып, бәгъзыларын сукдырып, күп рәнҗүләр итде дип, һәм сәнең кулың астыңа теләп кергән кешеләрне үз кулы астына күчләп хөкем идәр дип; ул Илчегол мондин соң андай эшләрне эшләмәсен, һәм кемләрдер хезмәткә чыккан вакытда ниндәй ыстаршиналарны теләйләр пулкавуйлардан, аның кулы астында йөресеннәр, һәм кемләр күчләүче булмасыннар.

Йәнә мәгълүм кыйлдың анда кимәләр бар баярларның дип, ни кем анларның эчендә бар ирмеш сумала һәм сусләре (?)[6], аны командаларга тикшереп, өләшеп биргәйсезләр дип,—

урусча кул куйылды Иван Билабурудуф,
Априлның 27 көнендә, 1774 йылда.

Иван Белобородовъ[7].

177 б, 177 кгзләр.

---

[1] Бүләнд һиммәтле — югары дәрәҗәле.
[2] Йыйылу — җыелу.
[3] Тигрәсенә — тирәсенә.
[4] Пырагун — прогон (транспорт хакы).
[5] Ядасыз — ятасыз.
[6] Бу сүзләр якынча укылды.
[7] Имза русча куелган.

## № 12

## АПРЕЛЬ, 1774 ЕЛ. Е. И. ПУГАЧЕВ АРМИЯСЕНЕҢ КӨЧЕ, ЗУРЛЫГЫ ХАКЫНДА ПРОПАГАНДА МАКСАТЫ БЕЛӘН БӘХТЕЯР КАНКАЕВ ТАРАФЫННАН ЯЗЫЛГАН МӨРӘҖӘГАТЬ.



Сән главнай ыстаршина Кәнкәй Йәшбакты угылына вә һәм Очуб[1] ыстаршина ата(ма)нга, сән палкавай сутник Ишмәт Мәмәткол угылына, вә һәм липутат[2] мелла Бакыйга, вә һәм палкавай сутник Иман Аладин угылына палкавай ыстаршина Бәхтеяр Канкай угылындин.

Сез ки ыстаршиналарга вә һәм сутникларга сүз будыр, урдир[3] илә мәгълүм булынган хәбәрләр сезләргә мәгълүмләнә:

Падишаһымызның кайда иркәнлеге мәгълүм булынды Ибан Билабуруданың урдиры илән[4], Уклы кальгасендә дәйү.

Вә һәм рәхимле падишаһымызга ун мең кырыгыз[5] казакы килеп, баш салып гаскәр булганлардыр; бихисаб йылкысын вә һәм сыгырын, вә һәм куйын алып килгәнләрдер, армиягә таркатып бирер өчен.

Вә йәнә артындин йегерме мең гаскәр киләдер дәйү хәбәр булгандыр. Вә һәм Урынбурхны алгандыр; вә һәм сикез йөз гусарски пулыкны баш салдыргандыр, коралларыны алып, ант иттереп, үзенең армиясенә кушып, Урынбурхка керетеп, Кинҗә мелланы[6] баш итеп куйгандыр.

Вә һәм Урынбурхда бик [каты] сугыш булгандыр, шул кадәр кем, кан атның тубыгындин булганчы. Рәхимле падишаһымыз именуаннай Урлувны[7] алгандыр, борынындин зәнҗырлап[8], тимер тарак берлә тарап аркасын, газап берлә үлтергәндер.

Вә йәнә Бирдә кальгадә кырык мең гаскәр куйгандыр, үзе гаскәрендин; вә һәм Өфе кальгагә ун биш мең кеше килеп камагандыр. Вә йәнә әби[9] яклы булган халыкны каралдыларын үртәп[10] һәляк иткәнләрдер. Вә һәм ул Солтанморатның артындин Каранай пулкауник килә, мең кеше илә, камап һәляк итәр өчен. Вә йәнә Иләк кальгасендә йегерме мең кеч куйгандыр. Вә йәнә Җайык кальгесендә ун биш мең кеч куйгандыр, рәхимле падишаһымызның үз янындин биш мең армия илә килеп кергәндер, Уклы кальгасенә.

Вә йәнә Билайбурудуфка рәхимле падишаһымыздин урдир килгәндер, Саткыга кире кайтсын дәйү, анда ятырга; ул Чиләбе(не) алгандыр, тупларын, дарыларын — көллесен алгандыр; анда кергән армияне кырып һәляк иткәнләрдер. Күнгүрдин чыккан вурлар анда һәляк булганлардыр. Башкортлар алдап, бераз монча күренеп, күбесе күренмәй торганлардыр[11]. Рәхимле падишаһымыз ул якдагы крипечләрне алып бетергәндер.

Ул Мәскәү ягындин тәрек килеп, Мәскәүне камагандыр, кыстап киләдер дәйү,— урдир килгәндер Билайбурудуфка.

Вә йәнә рәхимле падишаһымызга ун йите мең губирна баш салгандыр. Тудасы[12] килеп, күп мең кечләр илә, ул Мәскәү ягындин, анлар бер булып, кыстап киләдер. Вә йәнә ике дутасы[13] падишаһымызга кеч биргәндер, Питыр Әләкчеичнең кызларыдыр.

---

[1] Ачуб — Осип?
[2] Липутат — депутат.
[3] Урдир — ордер.
[4] Сүз Пугачевның Татищев кальгасе янында җиңелгәннән соң яңадан кеч туплый башлавы хакында бара. Иван Наумович Белобородов — восстаниенең бу чорында иң күренекле җитәкчеләрнең берсе.
[5] Кыргыз — бирегә: казакъ.
[6] Кинҗә Арсланов — башкортлар арасында иң күренекле восстание җитәкчеләренең берсе, полковник.
[7] Ике сүз бик кыенлык белән укыла. Беренчесе русча «именованный» (аталган) сүзеннән бозылган булырга охшый, икенчесе — Орлов, фамилия булырга тиеш.
[8] Зәнҗырлап — чылбырлап.
[9] Әби — патша Екатерина II.
[10] Каралдыларын үртәп — каралтыларын яндырып.
[11] Сүз кайбер башкорт старшиналарының патша хекүмәте ягына чыгулары хакында бара.
[12], [13] Тутасы, ягъни Петр III нең кыз кардәшләре.

Именуаннай[1] бу хәлләрне падишаһымыз урдир илә Билабурудуфка мәгълүм иткәндер, шуның өчен шатланып торгайсызлар. Моны ишетеп шадланып торыңыз, падишаһымызның иминлекен теләп.

Бу язу илә баргучы кешегә андагы хәбәрләрне язу илә язып йибәргәйсезләр. Бу язуны йөретсенләр бу хәлләрне аңлатсыннар. Именуаннай[2] падишаһымыз Саткыга килергә урдир йибәргәндер; шуның өчен падишаһга каршы килердәй булган[3] урыс казакъларын, кайда булса да, сөреп йибәрсенләр дәйү.—

Палкавай ыстаршина Бәхтеяр Канкай угылы кулым куйдым.

Бу баргучы Исәнбулат Намаз угылыны, юлдашы Габбас Биккенә угылы илә, олаулар берлә йөретсенләр һич дә туктаусыз йөресенләр, бер писер илә, кайдин булса да туктаусыз кушып йөретсенләр. Әгәр дә, кайда булса [да], урыс казакъларын тотса, инкяр иткәнләрене тотып йибәрергә патмук[4] итсенләр, һич инкярларына карамайынча, авылдин авылга сутниклар бу эшләрне тыңласыннар.

Вуйскы писер мелла Хәби Шәриф угылы кулум куйдым.

199, 198 б, 198 кгзләр.

## № 13
## 4 МАЙ, 1774 ЕЛ. СОТНИК И. МӘМӘТКОЛОВ ТАРАФЫННАН Б. КАНКАЕВКА БИРЕЛГӘН РАПОРТ.

Без сутник Ишмәт Мәмәтколый угылындан сән гуспудин пулкавай пулкуник Бәхтеяр Канкай угылының — бүләнд вә һиммәтле, шәфкать итгүчечәнең гали дәргяһларына[5] гарзе хәлләремезне түбәндә язу илә мәгълүм кыйламын.

Бәндәчелек илән рипурт.

Сән пулкуник Бәхтеяр Канкай угылының хозурындан йибәрелгән — Исәнбулат Намаз угылы берлән йибәреп, фаш булыр өчен[6], урдир куәтенчә [язган] указы әмер-намәңне юлыкдым; укытып, фәһем идеп, аңлап сәвендем, бик гайәтдә шад булдым. булган халайыкларым берлән күп йиллар саг улсын дәйү.

Имде түбәндә мәгълүм улынадыр ки, Күңгүр армиясе тарафындан — Күңгүрнең үзе эчендә ун алты туп берлән гаскәрләре хазердер ки дәйү ишетәмез. Йәнә мәгълүм улынадыр ки, Алтин[6] авылычың Иван Бахывның угылын Күңгүрдән кырык кеше килеп алып китебдер, тотып; йәнә шул ук Күңгүр тарафындан хезмәт иткүче гуспудин атаман Иван Наумич избасын Күңгүр кальгасенә бер бүрәнәсен куймайынча кучерделәр дәйү ишетәмез.

Йәнә сәнең хозурыңдан килгән Исәнбулат Намаз угылы Бикр[7] авылында торгучы урысны алып китәргә теләде. Имде бән Ишмәт аны бирергә кабул итмәдем. Аның өчен үземнең камандам эченә дизек[8] язылгандыр; камандамның нә кадәрлесен рипурт берлән мәгълүм иткәнмен пулкавай камандирларга; шуның өчен соңгы кәне сорау булса, камандам кәм булыр. Вә һәм бу мондагы йорты берлән торган гадел урысдыр. Әлгәре үзеңдән килгән иде шуларны кысыбрак йибәрәсез (дип)[9]; сән бойырып бик күп язулар йибәрәсен, бәнең хәлем йитмәйдер. Әгәр урыс язу йибәрсәңез, инша-алла, хода ярдәме берлә, ул мәзкүр татар уртыр[10] берлән хәлемез йитмәйдер; укыр сәбәбдән казакълар һәм гайре урысларга булышуны хәл идүне, әлбәттә, үзеңдән йибәрелгән кешеләрне үгет-нәсихәт берлән йибәрәсен.

Кәнә дәхи сән гуспудин пулкувник Бәхтеярга мәгълүм идәмен: әүвәлдә Күңгүр халайыклары, бәнең каманда булганлары һәм гайреләре йортларында торалар, ивләре һәм маллары сәбәпле. Имде анлар мәгълүм идеп, язу язып йибәрерләр, качан каманда килсә, безләр хазербезләр дәйү. Бәгъзы дошманларның сүзе берлән кән әлгәре рәнҗү-зарар итмәйсән.

---

[1, 2] Именуаннай — аталган (именованный).

[3] Ике сүз бик кыенлык белән укыла.

[4] Русча «подмога» (ярдәм) сүзеннән бозылган булырга тиеш.

[5] Шәфкать иткүченең гали дәргяһларына — шәфкать итүченең олы бусагасына (хәнәләренә).

[6] «Мәгълүм булыр өчен» дигән мәгънәдә.

[7] Русчадан бозылган авыл исемнәрен тегәл аңлап булмады.

[8] Дизек — тезем (исемлек).

[9] Соңгы ике сүз шартлы рәвештә укылды.

[10] Уртыр — русча «ордер» сүзеннән үзгәргән.

һәм Асылбай Мәмәт угылы һәм Мостай Сулай угылы һәрвакытда Күңгур тарафыннан хальләрен белеп, безнең хозурымызга килеп мәгълүм идәләр.

Бән сутник Ишмәт Мәмәтколый угылы инанмак өчен кул куймак урынына гадәдләнмеш[1] тамгам (...) салдым.

Әмер иткүче сутник Ишмәт бойыруы берлән язып, мән Әлмехәммәт Мостай угылы кулым куйдым.

Сәнәи 1774 йылда, майның 4 кенендә.

[Адрес:]

Ошбу рипурт тәслим улына[2] гуспудин пулкуяник Бәхтеяр Канкай угылының дәргяһларына[3].

166 б, 166 кгзләр.

## № 14

## 14 ИЮНЬ, 1774 ЕЛ. НӘДЕР ШӘРИФ УГЫЛЫНЫҢ МИЛКЕН КОНФИСКАЦИЯЛӘҮ ХАКЫНДА СӘЕТ ҖӘГЪФӘР ЗАЙСАН УГЫЛЫНЫҢ БӘХТЕЯР КАНКАЕВКА, ГАДЕЛ БИГӘШЕВКӘ РАПОРТЫ.

Рипурт пулкунник Бәхтеяр Кәнкәй угылына, атамән Гадел Бигәш угылына.

Ул олуг падишаһымыз Питыр Фидрувич хәзрәтләренең указы куәтенчә, Биш Мачы авылының изменшик[4] Нәдер Шәриф угылының малларыны алырга йибәрелмеш без ки сутник Сәйед Җәгъфәр Йайсан угылы, үземнең юлдашларым ун кеше илән, гадел гуаһлар[5] алдында хисаблап язып алынды. Йортында падишаһымыз хәзинәсенә ярагудай нәрсә һич дә табылмады. Әүвәл чыкды үзенең кия торган бер ак тире тун(ы), ике бүрек — бере төлке колакчын, бере илтер бүрек, пилес тышлы; бер кайыш камыт, бер бакыр комган, бер алатыр бадыяны, бер чәйнек, алты агач дустыган, өч кургаш ыстубка[6], бер алетыр куштабак, бер бизмән, бер «Йосыф китабы», бер чыбылдык; вә йәнә йөз туксан тиен бакыр акча.

Сарык малы,— олысы, кечесе илән,— ун өч баш; ат-йылкысы,— олысы, кечесе илән,— унбер баш.

Биш баш сыгыр, өч бозавы, бер башмак тана, бер башмак үгез.

Ошбуңа гуаһ Тимушка авылының Васка Муса угылы Мулла авылының Гомәр Мостай угылы, Мәлкәй Сәйендек угылы.

Шул рипуртка мән сутник Сәйед Җәгъфәр Йайсан угылы кул куймак урнына тамгам салдым (...);

Сәнәи 1774, маһи рәбигыль-ахирның 4 кенендә.

Ошбу вәрәкадә[7] күргәзелгән ун өч баш сарыкдан биш сарык алынды — олысы, кечесе илән, сигез башы йәтим нарасидларга[8] калдырылды. Ун бер баш йылкыдан бер карала бийә ялчысы Кунакбай Габбас угылының иркә(н)[9] — аңар бирелде. Бер колынлы кәрән бийә хатыны Айсолтан Габбас кызының мәһәрегә бирелгән икән,— аңар бирелде. Йәнә бер бәләкәй ак сыгыр, бозавы берлән, хатыны Айсолтанга мәһәргә биргән икән,— аңар бирелде. Йәнә бер кара тана килене Шәһәрбануга таянычка бирелгән иркән,— аңар бирелде. Йәнә ике тай нарасидларга бирелде — бере кола, бере соры. Вә йәнә ике бозау калынды.

162 б, 162 кгзләр.

---

[1] Гадәдләнмеш — гадәтләнгән, күнегелгән.
[2] Тәслим улына — тапшырыла.
[3] Дәргяһ — сарай, хәнә: бусага; бирәдә: штаб.
[4] Изменшик — изменник, хаин.
[5] Гуаһ — таныкк, шаһид.
[6] Ыстубка — стопка (кечкенә стакан).
[7] Вәрәка — бит, кәгазь.
[8] Нарасид — үсмәгән, нарасый.
[9] Иркән — икән.

№ 15

## 6 ИЮНЬ, 1774 ЕЛ. САЛАВАТ ЮЛАЕВ ТАРАФЫННАН СТАРШИНАЛАРГА БИРЕЛГӘН ӘМЕР.

Сез ки рәхимле күңеле берлән хезмәт иткүче ыстаршина Буләк Ягкуб угылыңдан, йәнә атаман Аладин Фәлан угылыннан, йәнә ыстаршина Арслан Рангул угылыннан йибәрелгән рипуртны бән главнай пулкуник Салават Юлай угылы юлыкдым [1], Габделкәрим Гайд угылы аркылы.

Имде мондин түбән мондагы хальләрне бәян идәм.

Рәхимле падишаһымыз Питыр Фидурувич хәзрәтләре безнең Әй буйына килде, тукыз мең кеше илән; һәм мәзкүр гусарлар пулкыны юлыгып, ике мәртәбә сугыш итдек, бик [күп] кешеләрне үлтереп, бер аз кешеләре качып котылды.

Имде анда йибәрелмеш камандирларның әмерен дыңлап, гаять дә мәхкәмлек [2] илә каманда жыйып, килгән дошманлар илә каршы торыр җәһәтене кыйлгайсыз, күңелеңезне һич бер якка авышты(р)майынча дәйү, әмер идүче,—

Главнай пулкуник Салават Юлай угылы.

1774 йылда саратанның 6 көненең [3].

Мондин анда барырга булмады, Күңгүргә китдек, һәм сезләр бер анча камандалар илә килеп, безләргә юлыккайсызлар.

Ошбу язу берлән баргучы Габделкәрим Гайд угылына ылауны биргәйсез, юлдашы берлән, туктаусыз һәм бырагунсыз [4].

197 кгз.

№ 16

## 13 ИЮНЬ, 1774 ЕЛ. «ОЛУГ АРМИЯ» ТӨЗҮ ТУРЫНДАГЫ ФИКЕРНЕ КУӘТЛӘП, Б. КАНКАЕВКА Е. И. ПУГАЧЕВ ТАРАФЫННАН БИРЕЛГӘН УКАЗ.

Ул олуг падишаһ импиратыр бил-истиклал [5], көлле Руссиянең хөкемдары, бәзем өгъзәм хәзрәтләремезнең указы мишәр пулкувникы Бәхтеяр Канкай угылына, пухуднуй ыстаршина Ярмехәммәт Кадермәт угылына.

Сезнең рипуртыңыз ошбу саратанның 13 йәүмендә [6] васыйль улынды [7]. Үтенепсез бойорык указыны җәмыг идәр өчен башкорт һәм урыс гаскәрене. Шуңа бинаән [8] безнең иминнуй указымыз илә әмер иделәдер: ул чирүне — урыс һәм башкорт җәмәгатене җыярга, бик җәһәд вә сәгый [9] кыйлурга, олуг армия җәмыг итмәклек хакында; дошманлар каршысына торып, безнең хәзрәтемезгә каршылыклы кешеләрнең тамырыны кисәргә, сән пулкувник Канкай угылына һәм Кадермәт угылына хәрәкәт идәргә, ошбу безнең указымызның тәкърибенчә [10] барчасы хакында тәгайерсез [11] йирена келтүрергә.

Инанмак өчен кәнде әле [12] һәм нәкышбәнд мөһере [13] басылмак илә бирелде саратанның 13 көне, 1774 сәнәи руссиясендә, әле басылмышдыр

Питыр дәйү.

85 кгз.

---

[1] Юлыгу — очрату, алу, күрү.
[2] Мәхкәмлек — ныклык.
[3] «Көненде» булырга тиеш.
[4] Бырагун — прогон (транспорт хакы).
[5] Бил-истикълал — мөстәкыйль, биредә: «самодержец».
[6] Йәүмендә — көнендә.
[7] Васыйль улу — очрау, җиту, ирешү.
[8] Шуңа бинаән — шуңа нигезләп, шуның нигезендә.
[9] Сәгый — тырышлык.
[10] Тәкърибенчә — биредә: күрсәтүенчә, әйтүенчә.
[11] Тәгайерсез — үзгәртмичә.
[12] Кәнде әле — үз кулы.
[13] Нәкышбәнд мөһере — биредә: сурәтле мөһер.

## № 17
## 24 ИЮНЬ, 1774 ЕЛ. МАРИЛАР СТАРШИНАСЫ АХМӘР АГЫЙ УЛЫНЫҢ Б. КАНКАЕВКА РАПОРТЫ.

Мән чирмешләр ыстаршинасы Ахмәр Агый угылы мәгълүм кыйламын.

Бөре калагасе[1] астында яткучы ике йөздән артык тошманлар[2] берекделәр Калинлектә яткучы тошманлар белән һәм Усак авыл урысларыга килеп әйткән дәйү, керәстийән урыслар хәбәр бирделәр. Усы юлына чыгарга теләйләр дәйү. Шул сәбәпле иләмез харабалыкка киләдер. Сез ки гаскәр әһелләренең башлыклары бөйек мәртәбәле Бахтеяр Кәнкәй угылына мәгълүм уладыр, бәрча башлыклар һиммәт үзеңез кыйлсаңыз ирде дәйү теләймез. Ул тошманлар Бөре калага тауның өстенә бикит[3] торгыздылар. Шул сәбәпле мәгълүм кыйлып,—

Ыстаршина Ахмәр Агый угылы кул тамгам салдым (...).

1774 йылда, рәбигыль-ахирның 14 көнендә.

Ошбу язу белән йибәрелгән Мырза Уразбакты угылына авылдан авылга ике лауны[4] инкярсыз биргәйсезләр, пырагунсыз, ибдәше илән.

Юкарыда язылган тошманларның килгәнлеге хакында армидан килгән ыстаршина Күзмә Митри угылының камандасы Садыш Бурай угылы монда Сукыйаз каравылга туктады, түрт ибдәшләре илән; монда тошманлар күбәйәдер, туктаганлары хакында сезки гаскәр әһелләренең башлыкларына мәгълүм уладыр.

157 б, 157 кгэләр.

## № 18
## 15 ИЮНЬ, 1774 ЕЛ. БӘХТЕЯР КАНКАЕВ ҺӘМ БАШКАЛАР ТАРАФЫННАН БАЙКЕ ТУЙКЕ УЛЫНА БИРЕЛГӘН ӘМЕР.

Бөре тарафына йибәрелмеш гаскәр әһеленең башлыклары пулкунник Бәхтеяр Канкай угылындан, йәнә главнай атаман мелла Гадел Бигәш угылындан бәрчә юлдашларымыз илә приказ сән ыстаршина Байке Туйке угылына.

Кайсы сән Әңсак завудында улдыкың заманда алып китепсез Әңсак завудындан ун йите баш пулун[5] атларны, шул атларны ошбу приказ сәңа йиткән заман һичбер сәгать йованмайынча алып килгәйсән, монда безнең кашымыздагы армигә. Әүвәлдә монда Әңсак тарафына йибәрелгән вакытдагы кулыңа табшырылмыш чирмешләрдән камандаларың илә, һич берсән куймайынча. Никем ул атлар кирәкле буладыр монда армидәге казакъларга атланып сугышлар кылырга. Һәм бу тарафда дошманлар бик күпдер, шуны аңлагайсән, әүвәлге кебек гафил булмагайсән.

Сәнәи 1774, саратанның 15 көнендә.

Пулкун[ник] Бәхтеяр Канкай угылы кулым куйдым.

Главнай атаман мелла Гадел Бигәш угылы кулым куйдым.

Атаман Алладин Биктуган угылы кулым куйдым.

Аилар кашында писер мән Әбүбәкер Теләч угылы язып кулым куйдым.

161 кгэ.

## № 19
## 13 ИЮЛЬ, 1774 ЕЛ. КИЛМӘТ АБЫЗНЫ БӨТЕН ГАИЛӘСЕ, МАЛ-МӨЛКЕ БЕЛӘН КУЛГА АЛУ ХАКЫНДА Б. КАНКАЕВ ӘМЕРЕ.

Рәхимле падишаһымыз Питыр Фидурувич хәзрәтләренең фәрманы һомаюны[6] илә Казан тарафына йибәрелмеш главнай пулкувник Бәхтеяр Канкай угылындан приказ.

---

[1] Калагасе — кальгасе, крепосте.
[2] Тошманлар — дошманнар.
[3] Бикит — пикет, күзәт.
[4] Лау — олау.
[5] Пулун — әсир (борынгы төрки сүз).
[6] Фәрманы һомаюны — дәүләт әмере.

Кайсы Йазсу авылының татары Килмәт абызны үзенең хатыны һәм кызы Шәмесне бергә алып килергә бойырылды, һичбер төрле инкярларына карамайынча һәм хальләрендә бәр әсбаплары илә. Хосусән, Җиһанкояшы[1] Шәмесне кагыйдәчә килтерергә дәйү.

Сәнәи 1774, ийүлнең 13 көне.

Инангулык өчен пулкувник Бәхтеяр Канкай угылы кулым куйдым.

Пулкувник Рахманколый Дусай угылы кулым куйдым.

Пудпулкувник Сөбханколый Әҗекә угылы кулым куйдым.

Вуйскы писер Әбүбәкер Телач угылы язып кулым куйдым.

Ошбу хальләрне әда кылыр[2] өчен йибәрелде йурамалы (?) вуйскы казакълары.

89 кгз.

## № 20
## 14 ИЮЛЬ, 1774 ЕЛ. ПУГАЧЕВНЫҢ ХӘРБИ КОЛЛЕГИЯСЕНӘ БӘХТЕЯР КАНКАЕВ РАПОРТЫ

Рәхимле падишаһымыз Питыр Фидрувич хәзрәтләренең Вуяннай куллигәсенә пулкувник Бәхтеяр Канкай угылыннан бәндәчелек илә рипурт.

Кайсы ошбу сәфәремездә тапдык ошбу Казан өйәзенең һәр җенесле[3] халайыкларыны, барчасын,— җан вә тән илә рәхимле падишаһымыз Питыр Фидрувич хәзрәтләренең хезмәтенә рад[4] һәм барча олуг вә кечекләре бәрәр чакырым кадәре безләрә[5] хальләрендә бар нигъмәтләре берлә каршы киләләр һәм безнең кашымызда[6] күз йәшләрен түгеп, «рәхимле падишаһымыз һәм шәфкатьле атамыз Питыр Фидрувич хәзрәтләре күп-күп йылларә вә озын гомерләре саг вә сәламәт улсын», [дип] теләк итәләр.

Һәм бу заманда кашымызда йөрегүче гаскәремез алты йөздән зиядәдер[7] һәм һәр көнне килеп үзләре мәгълүм булалар, ихтиярән пухудка кәлдек дәйү. Бер үк анларның эчендә кийемсез һәм атсызлар вә коралсызлар бардыр, шунлар хакында бойырылса иде фәрман-нәмә[8] без гарибләрә — каю урыннардан атлар вә кораллар алыныр; һәм юлымыз өстендә йакын торучы баярларның үзләрендән калган мал вә хайванларын аламыз, хәзинәгә тапшырмак хакында.

Һәм йәнә изминщикларның башлыклары Солтан Морад Йәнеш угылының кашында йөрегүче гаскәр өһелләрендән биш кешеләрене безнең разйезга[9] йөрегүче кешеләремез тотып келтерделәр безгә, анлар һәнүз безнең кулымыздадыр. Никем анлар чыкканлар икән вурлыклар[10] итәр өчен; һәм ул вурлар, бу заманда беленде шул кешеләрдән, Арча юлының Курса авылында кунганлыгы.

Йәнә шундаг ук һәр тарафларга пикит каравылларына камандалар йибәрәмез, дошманлар хәбәрен белер өчен дип.

Һәм йәнә мондан әүвәл ике мәртәбә рипуртымыз илә йибәрелгән Вуяннай каллигәгә кашымызда йөрегүче казакълардан кешеләр, һәнүз анлар безгә килеп мәгълүм булганлары юк.

Һәм йәнә иделләрдәге[11] барча гыйраәузларны иллешәр кешеләр йибәреп каратамыз, вурлар партиның[12] хәбәрләре бәр өчен. Йованиуымыз сәбәбе шул хальләр өчендер дәйү,

Сәнәи 1774, ийүлнең 14 көне.

105 б, 105 кгзләр.

---

[1] Җиһанкояш — Килмәт абызның хатыны исеме булса кирәк.
[2] Әда кылу — башкару, урынына җиткерү.
[3] Җенес — төр; биредә: ыру, халык, милләт.
[4] Рад — шат.
[5] Безләрә — безләргә (безгә).
[6] Кашымызда — каршыбызда, яныбызда.
[7] Зиядә — артык.
[8] Фәрман-нәмә — боерык кәгазе.
[9] Разйез — разъезд.
[10] Вурлык — караклык, биредә талау.
[11] Иделләр — елгалар (гомумән). Сүз Кама белән Нократ (Вятка) елгалары турында бара.
[12] Вурлар парти — караклар партиясе (төркеме).

## № 21

### 22 ИЮЛЬ, 1774 ЕЛ. БӘХТЕЯР КАНКАЕВ ТАРАФЫННАН ТӨРЛЕ ОТРЯД БАШЛЫКЛАРЫНА, ШУЛАЙ УК КАЛМЫКЛАРНЫҢ, КАЗАКЪЛАРНЫҢ ҖИТӘКЧЕЛӘРЕНӘ ҖИБӘРЕЛГӘН МӘРӘҖӘГАТЬ (АХЫРЫ ЮК).



Ул олуг падишаһымыз импиратыр әгъзәм Питыр Фидурувич хәзрәтләренең фәрманы һомаюны[1] илә һиммәт вә шәукәт һәм куәт вә носрат[2] иясе, җыйылмыш гаскәрләрнең башлыгы главнай атаман Әлибай Морзагол угылына, йәнә Каранай Морад угылына, йәнә Качкын Самар угылына, йәнә калмыклар түрәләренә, йәнә шундаг ук кыргыз[3] ханларына вә һәм төрле халайыкларның олуг башлыкларына гарзе халемездер[4].

Кайсы сезләрнең һиммәтләнешеп гаскәрләр җыйганлыгыңызны ишетдек, ийүлнең 22 көне, шул ук сәгатьдә, рәхимле падишаһымыз хәзретенә пучта аркылы рипурт йибәрдек, шул сезнең дөрест игътикадларыңыз[5] буйынча агыр гаскәрләр җыймаклыгыңызны бәян идеп.

Һәм сезләрә бәшарәт улсын: рәхимле падишаһымыз Күңгүр тарафындан башлап җөмлә кальгаләрне хараб идеп, һәм завудларны ут илә үртәп, монда Казан кальгасен һәм алып хараб әйләде; җөмлә рәгыйәтләрен[6] вә кальгасен ут илә яндырды һәм йәнә шул тигрәдәге үзгә кальгаләрне(ң) җөмләсен шөйлә әйләде[7].

Имде сезләргә үтенечдер: һәрберeңез кашыңыздагы агыр хәрб гаскәреңез илә бергә йованмайынча монда Казан тарафына килсәңез иде дәйү. Безләр бу хальләрдә Казан кальгасенең якынындагы дошманларга җавап биреп, һәр пыравузларны[8] каравыллап торамыз; кашымыздагы өч меңдән зиядә[9] гаскәремез һәм йәнә тупларымыз илә. Йәнә дәхи бу Казан өйәзенең һичбер төрле халайыкларын каршылык кылгучы тапмадык, барчалары җан вә күңел илә рәхимле падишаһымызга муйын сонып, көлле хезмәтләренә радлардыр...

91 б, 91 кгзләр.

## № 22

### 22 ИЮЛЬ, 1774 ЕЛ. САБА ТАТАРЛАРЫНА БӘХТЕЯР КАНКАЕВ ТАРАФЫННАН БИРЕЛГӘН БИЛЕТ.

**Ул олуг импиратыр әгъзәм падишаһымыз Питыр Фидурувич хәзрәтләренең указы куәтенчә пулкувник Бәхтеяр** Канкай угылындан бирелде ошбу билит Казан өйәзенең, Арча юлының, Әдһәм сутнасы[10], Байлар Сабасы берлә Тинке Сабасының татарлары Тәрҗемә Нуркә угылына, Габделваһаб Мөхсин угылына шул сәбәпле:

Кайсы анларның олуг армиядә рәхимле падишаһымыз кашында бар икән хезмәт итмеш кешеләре, шул кешеләре хакында яңадан монларны пухудка дәйү кыстамагайсыз, бездән йибәрелмешләр һәм үзгә армийә камандирлары һәм атландырмагайсыз[11] дәйү.

Санәи 1774, ийүлнең 22 көне.

Инангулык өчен пулкувник Бәхтеяр Канкай угылы кулым куйдым.

Вуйскы писер Әбүбәкер Теләч угылы язып кулым куйдым.

83 кгз.

---

[1] Фәрманы һомаюны — патшалык әмере.
[2] Носрат — ярдәм.
[3] Шундаг ук кыргыз — шулай ук казакъ.
[4] Гарзе халь — хәлдән хәбәр.
[5] Дөрест игътикад — туры юл; ихлас күңел; ышанычлылык.
[6] Җөмлә рәгыйәтләрен — биредә: барлык шәһәр халкын.
[7] Шөйлә әйләү — шулай эшләү.
[8] Пыравуз — провоз, кичү, үткел.
[9] Зиядә — артык.
[10] Сутна — сотня (йөз).
[11] Атландыру — биредә: поход сәфәренә чыгару (яуга каршы атландыру).

№ 23

## 23 ИЮЛЬ, 1774 ЕЛ. Б. КАНКАЕВ ТАРАФЫННАН ЯРАЛЫ СУГЫШЧЫГА ӨЕНӘ КАЙТЫР ӨЧЕН БИРЕЛГӘН БИЛЕТ.

Ул олуг импиратыр әгъзәм падишаһымыз Питыр Фидурувич хәзрәтләренең указы куәтенчә, пулкувник Бәхтеяр Канкай угылындан биреддә ошбу билит Казан өйәзенең Йери юлының сутник Мостафа Мәмәтай угылының камандасы, Савыш авылының татары Элмәкәй Бимәкәй угылына, үзенең ивенә кайтыр өчен, никем Казан кальгасендә олуг арми кашында сугышлар кыйлып яралы булганы сәбәпле.

Һичкем бу Элмәкәйгә шул яралы булганы сәбәпле сүз-өн итмәгәйсезләр дәйү, Сәнәи 1774, йиул 23 көне.

Пулкувник Бәхтеяр Канкай угылы кулым куйдым.

Вуйскы писер Әбүбәкер Теләч угылы язып кулым куйдым.

102 кгз.

№ 24

## ИЮЛЬ, 1774 ЕЛ. КИЧҮНЕ САКЛАУ ХАКЫНДА КЕРӘШЕННӘРГӘ Б. КАНКАЕВ ТАРАФЫННАН БИРЕЛГӘН БОЕРЫК.

Пулкувник Бәхтеяр Канкай угылындан биреддә приказ сән Гирачем Сабай угылына.

Чистай кичүенә йәнә һәм кичү илә үзләренә — әүвәл Көчек авылына, йәнә Тәрберде Чаллысына, йәнә Бүкәш авылына, йәнә Чураш авылына, йәнә Казаклар авылына, йәнә Сатлыган авылына, йәнә Мукшы авылына, йәнә Чаллы Башына — һәрвакытда даимчелек[1] илән унбиш кеше тормак үзеренә кичүдә[2].

Ошбу эш тапшырылды Көчек авылының Мәнди Туктамыш угылына, һәр вакытда яхшыдин һәм ямандин хәбәр булса, юкарыда язылган Гирачемгә рипуртавайт[3] итмәгә.

Бу мәзкүр юкарыдагы язылган сәкез авыл җәмәгатьләрене пухут сорап һич кем рәнҗетмәгәй, ошбу мәзкүр кичү хакында бойырдык, атла(нга)нлары булса[4] һәм кайтарырга, һәм көн элгәре анларны кеше сорап рәнҗетмәскә.

* * *

Пулкуник Бәхтеяр Канкай угылындан биреддә приказ сән керәшен Гирачем Сабай угылына.

Бойырдык ике авыл керәшенләренә — бере Арнаш Башы, йәнә бере Түбән Арнаш — һәр ике авыл җәмәгатьләре мәзкүр Гирачем Сабай угылына һәр каю кичүләр[5] хакында ярдәм биреп, хезмәт итмәк өчен. Шул сәбәпле бу мәзкүр Арнаш Башы йәнә Түбән Арнашдин һәр икесендән пухут сорап һичкем рәнҗетмәс өчен һәм борын атланганлары булса һәм кайтармага әмер итдем.

172 кгз.

№ 25

## 11 АВГУСТ, 1774 ЕЛ. БАШ КҮТӘРҮЧЕЛӘР АРАСЫНДА ХАИННАР БАРЛЫГЫ ХАКЫНДА К. УСАЕВКА СЫРТЛАНОВ ХАТЫ.

Һуаллаһе-л-гани әл-бари[6]

Сезки гыйззәтле вә хөрмәтле, бик мәртәбәлә гаспудин балкадир[7], падишаһның сәвеклесе, дустымыз мелла Канзафар Усай угылына бихәд, бинииһайә[8] догаи сәламләр

[1] Даимчелек — даимилек.
[2] Тормак үзеренә кичүдә — биредә: кичүдә торсын өчен.
[3] Рипуртавайт — рапортовать.
[4] Атланганлары булса — биредә: юлга, походка чыкканнары булса.
[5] «Кичүләр»дән соң артык «гә» язылган.
[6] Хат башына куела торган шаблон формула, мәгънәсе: «Ул алла байдыр, ярату́чыдыр».
[7] Балкадир — бригадир (хәрби чин).
[8] Бихәд, бинииһайә — иксез-чиксез.

васыйль улындыкдан кәзин[1] күп йылларә вә бихисаб айларә саг вә сәлим улгайсән вә барча әһле әтбагларың[2] илә.

Вә бәгъдә мәгълум улынадыр, безгә йибәргән язуың мелла Рахманкол аркылы тапшырылды һәм бойырылган урынларга йибәрдем. Вә йәнә ул кемсәнәләрдән һичбер халь белмәймән.

Вә кәнә[3] сәнең хозурыңа күрешә барырга нийәт итеп торамын ирде, мелла Рахманкол берлә ыстаршина Максудтан язу килде, сәне кире юлланды дәйү; мелла Сәләүсендән «монда кире кайт» дәйү язу килгәч, шунда кайтды(м), шул сәбәпле бән сәңа юлыга алмадым.

Имде хәзрәтеңә бондан түбән мәгълүм итәмен бондагы хальләрне. Инде монда падишаһымыз хәзрәтенә һәм сәңа бераз дошманлар бардыр һәм ихласларындан дүнеп[4] торалар, мишәрләрдән һәм башкортлардан булсын. Берүк ул дүнгүчеләр бик аздыр һәм гайре тигез халайыклар падишаһ хәзрәтенә дөрес ихласлары берлә торалар, мишәрдән һәм башкортдан булсын, һәм ыстаршиналардан курыкмаклыкларындан баралар пахут(ка). Вә йәнә бондан түбән падишаһымыз хәзрәтенә ихласлары берлә торган ыстаршиналарны мәгълүм кыйламын; һәм һич кальгага рипурт язмайынча торалар. Ибраһим Мирас угылы, аны ирексез итеп чиргүгә баш итеп язганлар; һәм мишәрләр ыстаршинасында Габделислам Мәмдәле угылы, татарлар ыстаршинасында Максуд Мирзакәй угылы һәм Ибраш Уразбакты угылы. һәм ул яд кыйлган ыстаршиналарны изгелекләреңдән ташламагайсән. һәм аларда(н) гайре ыстаршиналарга инанып аз каманда берлә йөремәгәйсән, антларын бозып, ихласларындан дүнгәнләрдер. һәм үзләре язу берлә кеше йибәреп сезләрне чакыры(р)лар, көч берлә килсенләр дәйү, үзләре кальгага рипурт йибәрерләр «бурлар киләдер» дип, «безгә көч биреңез» дәйү, һәм түрәләр анларга көч бирмәйләр. Ничек мәлгунь, гакәбә[5] шуның әрәвешле кешеләр бардыр, әлбәттә, саклангайсән. Мән[6] ни җәфалар күрмәдем, алла хәзрәте саклады. һәм дүнгән ыстаршиналарның исемнәрен үзем качан үзеңә юлыксам, шунда бәян итәрмен.

Өфе кальгасе тарафындан үземә карендәш тиешле кеше килде, андан сорадым Өфе кальгасендәге түрәләр ни халь берлә торала(р) дип. һичбер тирә якдагы халайыкларга зарар юк ирмеш. Вә йәнә изгелек теләгән урынларга язу язасың, без дустыңа да язгайсән, изгелек мәрхәмәтеңездән ташламагайсән. һәм бу язуны йибәрдем үземнең дустым Бикмәмәт Мөслим угылы аркылы, бик яхшы тугыры кешедер, үземә ышанычлыдыр, һәркаю урынга йөртсәң ярар кешедер. Бу язу тәкабеленә[7] һәр ни халь булса да язгайсән.

Вә йәнә ишетеп [белдем], пулкувник Туктамыш Кызыл Яр кальгасенә килгән дип. Вә йәнә янарал кенәз Галичин талап алган, малын үртәп китепдер, мәгайн; һәм үзен Нократ иделен[8] чыгармайынча камап торалар дип әйтәләр. һәм шул фигыле [начар] ыстаршиналарның арада йөргән язулары кулыма төште, һәм сәңа йибәрдем. Гаскәрең булса таралмагайсән, җәһәт иткәйсән. Бу язуны үзең дуст күргән кешеләреңә аңлаткайсән, күп кешегә мәгълүм итмәгәйсән — арада шым күбдер.

һәрдаим изгелек теләгүче пулкунник дустыңыз Моратшаһ Сыртлан угылы дәйү беләсән.

Сәнәи 1774 йылда, маһ җөмадиел-ахирның 3 көнендә бетелдә[9].

[Адрес:]

Ошбу вәрәкаи һомаюын[10] табшырыладыр балкадир Канзафар Усай угылына билхәйри[11].

29, 28 б, 28, 29 б кгзләр.

---

[1] Васыйль улындыкдан кәзин — ирешкәннән соң.
[2] Әһле әтбагларың — кул астындагы кешеләрең.
[3] Кәнә (кинә) — янә, тагы.
[4] Дүнү — йөз чөерү, баш тарту.
[5] Гакәбә — ышанычсыз, явыз.
[6] Кульязмада ялгыш: «сән».
[7] Тәкабеленә — каршысына.
[8] Идел — биредә: гомумән елга.
[9] Бетелү — язылу.
[10] Вәрәкаи һомаюн — биредә: «дәүләт язуы».
[11] Билхәйри — хәерле.

## № 26

### 4 СЕНТЯБРЬ, 1774 ЕЛ. Б. КАНКАЕВКА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ ТУРЫНДА ГАБДУЛЛА МОСТАЕВ РАПОРТЫ.

Главнай пулкунник Бәхтеяр Канкай угылының йүчә[1] хәзрәтләренә рипурт.

Сәнең хәзрәтеңдин йибәрелмеш рипуртың мәңа мәгълум булды, армияң берл тиз заман кайтып йиткәйсән дийеп бойырыпсән, җыйылган кадәренчә йибәрдем туксан кеше, дәхи алла бойырса, тизлек берлә йибәрермән йөз ун кеше. Үземә тиз кайтырга мөмкин дәгел, бу төшдәге халайыкларның күңеле мөшәввәшләнгән ирмеш. Әлбәттә, безләр килеп арми җыя башлагач хуш күрделәр, без йөргән йирдә гайре төшне алла белер. Андагы булмыш хальләрне тиз заман рипурт берлә мәгълум кыйлгайсән. Мондин соңра ходай ни кадәр халайык[3] бойырыр, үземез алып кайтырмыз.

Вә йәнә йүчә хәзрәтеңезә мәгълүм ула. Вә йәнә Әдһәм сутникка бойырыпсән кәмандаңдин кеше атландырып килгәйсән дәйү. Әлбәттә, аның кәмандасын тикшерег карадык, рәхимле падишаһымыз берлән атланган икән, күп җәмәгать; ул җәмәгатьләр(дин) бик аз кеше кайткан җәрәхәтләнеп, бәгъзысы пулун[4] төшеп һәм авырып сырхап кайткан; шул сырхау хале берлә безгә ярдәм итеп йөридер.

Вә дәхи мулла Халиткә бойырган икәнсән арми җыярга,— бездин башка мөмкин булмаган. Үзе һәм сырхау икән; сырхау хале берлә безнең берлә һиммәт идеп йөридер. Әмма икесендин башка безгә йөрергә мөмкин дәгел.

Сәнәи 1774 йылда, маһ җөмадиел-ахир айының 27 кичендә,
пулкунник Габдулла Мостай угылы кулым куйдым инанмак өчен.

[Адрес:]

Ошбу рипурт йибәрелде гуспудин пулкунник Бәхтеяр Канкай угылының мөбарәк дәстенә била тәэхәйр[5].

178, 178 б. кгзләр.

---

[1] Йүчә — бөек, югары дәрәҗәле.
[2] Мөшәввәш — шик-шөбһә, төшвиш.
[3] Бу сүз (халайык) шартлы рәвештә укылды.
[4] Пулун — әсир (борынгы төрки).
[5] Мәгънәсе: хәере белән мөбарәк кулына...

Фарваз Миңнуллин

# ПРОЗАНЫҢ ГРАЖДАНЛЫК ЙӨЗЕ

1972 елгы татар прозасына күзәтү

Прозаикларыбыз иҗат елын әйбәт төгәлләделәр. Татар совет әдәбияты кызыклы гына роман-повестьлар, яңа хикәя җыентыклары белән баеды. Байтак еллар аяк өсте сырхаулап йөргәннән соң, прозабыз, ниһаять, яңадан элекке хәленә кайтып килә шикелле.

Прозаның элекке хәле дигәндә, мин алтмышынчы елларның беренче яртысын күздә тотам. И. Газиның «Онытылмас еллар»ы (икенче кисәк), Ф. Хөснинең «Утызынчы ел», А. Расихның «Ике буйдак» романнары басылган елларны... Г. Бәширов һәм Г. Әпсәләмов, И. Салахов һәм С. Рафиков, Г. Ахунов һәм Н. Фәттахларның яңа романнары, Ә. Еники, С. Баттал, М. Шабай, Р. Төхфәтуллин кебек язучыларның берсеннән-берсе кызыклырак хикәя-повестьлары чыккан заманнарны... Тагын да конкретрак итеп әйткәндә, прозаиклар әдәби хәрәкәтнең алгы сафында йөргән һәм бөтен әдәбиятка юнәлеш, тон биреп барган вакытларны. Бар иде шундый вакытлар!..

Менә шул кызыклы һәм көчле прозабыз бер заман түбәнгә тәгәри башлады. Әзәлап кына, сиздерми генә ул үзенең иң көчле сыйфатларын югалта барды. Без, акрынлап, карашлар киңлеген, масштабларны югалттык, без олы характерларыбызны югалттык. Елдан-ел прозаның иҗтимагый яңгырашы кими барды. Аның каравы, урта кул конфликтлар, урта кул геройлар активлашты. Әдәбиятта урта кул әсәрләр полосасы башланды. Прозаиклар тавышсыз-тынсыз гына әдәби хәрәкәтнең артынарак чигенделәр. Беренче рәткә шагыйрьләр күтәрелеп чыкты...

Нәрсә булды? Ни өчен проза шундый хәлгә калды? Ул чагында без моны ачыкларга ашыкмадык, әлеге сорауларга җавап эзләп, артык баш ватмадык. Киресенчә, проза өлкәсендә барган үзгәрешләрне күрмәмешкә салынып йөрдек.

Бүген исә, күпме генә тырышсак та, без ул сәбәпләрнең һәммәсен ачыклап бетерә алмабыз. Хәер, моның инде әллә ни кирәге дә калмады. (Прозаикларыбыз, безнең ярдәмнән башка гына, үткәндәге кимчелекләрдән арынып киләләр. Татар проза әдәбияты элекке үрләренә күтәрелеп бара.) Шулай да үз вакытында прозаның хәлен шактый авырайткан бер сәбәпкә тукталмый үтеп булмый. Мин буыннар алмашынуны күздә тотам.

Билгеле булганча, соңгы 6—7 ел эчендә әдәби эстафета акрынлап урта буын прозаиклар кулына күчте. Проза йөген, тәртәнең төбәнә җигелеп, алар тарта башлады. Элегрәк, картлар белән аралашып яшәгәндә, бик сизелмәгән иде. Үзләре мөстәкыйль тормыш юлына аяк басуга күрдек: урта буын без көткәннән сыеграк, без уйлаганнан йомшаграк булып чыкты. Үзбаш яши башлауга, әти-әниләре уңган семьяларда үскән балалар кебек, алар бер мәл-

гә аптырап, каушап калгандай булдылар. Гомуми шаукымга ияребрәк йөрделәр, бер өлкәдән икенче өлкәгә, бер темадан икенче темага ташланып аптыраттылар. Баксаң, күбесенең умыртка сөяге дә ныгып өлгермәгән, кайберләренең хәтта иҗади иманнары, әдәби кыйблалары да анык түгел икән...

Билгеле, моннан чыгып, урта буын прозаиклар арасында бер генә рәтле кеше дә булмаган икән дип уйларга ярамый. Бар иде алар (алдарак кайберләренең исеме дә телгә алынды). Ләкин аз иделәр. Прозаның гомуми хәлен алар гына үзгәртә алмады.

Бер акланырга тотынгач, шул кадәресен дә әйтеп узыйм: йомшак диеп, сыек диеп яман аты чыккан әлеге буын әдәбиятка начарлык кына төяп килмәде. Алар иҗатында мактауга лаек яклар да бар иде. Аларның күбесен, мәсәлән, берничек тә активлык җитмәүдә, иҗади пассивлыкта гаепләп булмый иде. Бу яктан бүген дә тел-теш тидерерлек түгел.

Соңгы елларда безнең проза йөз белән заман темасына борылды. Бүгенге көннең уңай героен, замандаш образын иҗат итү юнәлешендә кызыклы тәҗрибәләр ясалды. Тормышның мөһим, актуаль мәсьәләләренә багышланган роман-повестьлар күбәйде. Монда урта буынның роле зур булды.

Прозабызда авыл темасы өстенлек итә иде. Хәзер эшче темасы алга чыкты. Бусы да алар катнашыннан башка гына эшләнмәде. Әмма ни генә булмасын, уңышларга караганда кимчелекләр, ачышларга караганда югалтулар күбрәк иде.

Бәхеткә каршы дип әйтергә кирәктер инде, прозабызның авыру хәле әллә ни озакка сузылмады. Еллар уза торды. Еллар узу белән урта буын үз иҗатындагы кимчелекләрдән аз-азлап арына барды. Алар сафына яңадан-яңа авторлар кушыла торды. Әлеге буын елдан-ел ишәя, көчәя килде. Һәм менә 1972 елда ул безне күп кенә кызыклы әсәрләр белән куандырды.

Шулай итеп, прозада яңа буын үсеп җитте. Әдәбиятның киләчәге шул буын кулында. Татар прозасының яңа сәхифәләрен шулар язачак. Ничек язарлар? Ул кадәресе күп кенә дәрәҗәдә үзебезгә бәйле. Әдәби җәмәгатьчелекнең һәм тәнкыйтьнең бүгенге көндә никадәр таләпчән һәм принципиаль булуына, язучыларыбыз иҗатына карата нихәтле игътибарлы булуына бәйле.

Яңа буын прозаиклар үз иҗатларында иң җаваплы чорга — иҗади җитлегү чорына аяк бастылар. Булырдайларының үз стиле, үз йөзе калыплашып килә. Ничек калыплаша? Дөрес юнәлештәме, без теләгәнчәме? Ныклап уйлашырга кирәк...

Яшьләр прозасы торган саен күп төрлерәк, кызыклырак була бара. Бүгенге прозада төрле юнәлешләр һәм тенденцияләр төсмерләнеп килә. Шуларның кайсына ориентация тотарга? Кемнәргә күбрәк өмет багларга? Бергәләп уйлашырга һәм ачыкларга тиешле тагын бер мәсьәлә менә шушы. Аны дөрес хәл итү безнең нихәтле сизгер булуыбызга һәм алдан күрә белүебезгә бәйләнгән.

Сүз дә юк, татар совет прозасы алга таба да иң дөрес юлдан — партия, халык күрсәткән юлдан барачак. Сүз дә юк, прозаикларыбыз киләчәктә дә партияле, халыкчан әсәрләр иҗат итәчәкләр. Бу кадәресенә шикләнмәскә мөмкин. Әмма безне әле аларның иманнарының көче, зурлыгы да кызыксындыра. Максатлары зурмы аларның? Идеаллары биекме? Көчләре күпкә җитәрлекме?.. Кыскасы, борчый, уйландыра торган мәсьәләләр күп. Бәлки барысына да җавап табып бетерә алмабыз. Шулай да хәл кадәренчә тырышып карыйк. Алда безне кызыклы авторлар, кызыклы яңа әсәрләр көтә!..

«Казан утлары» журналының узган елгы саннарында ике роман, унбер повесть басылган. Шул унөч әсәр арасыннан аеруча зур популярлык казанганы Фәнис Яруллинның «Җилкәнне җилләр еккач» исемле повесте булды дисәм, әллә ни ялгышмам кебек. Укучылар арасында иң нык кызыксыну уятканы шушы повесть булды. Редакциягә килгән хатларның күпчелеге шул әсәр уңае белән язылган иде.

Баштарак мондый популярлыкның серен мин үземчәрәк аңлап йөргән идем. Билгеле булганча, повесть авторның үз тормышына, аның үз башыннан узган хәлләргә нигезләнеп язылган. Фәниснең тормышын беләсез: бәхетсезлеккә очрап, яшьли гарип калу. Больницадан больницага күчеп, озак еллар буе рәхимсез язмыш белән көрәшү. Больницада яткан килеш урта мәктәп тәмамлау. Аннары университетта уку. Шуларның һәммәсе өстенә иҗат газаплары, бу тынгысыз дөньяның бик күп башка газаплары... Мондый материалга нигезләнгән әсәр, ничек язылса да, мавыгып укылырга тиеш дип уйлый идем мин. Янәсе, материалның характеры шундый. Әсәр белән ныклап танышкач, ялгышканымны аңладым. Популярлыкның төп, хәлиткеч сәбәбе по-

вестьның сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәсендә икән.

Фикеремне дәлилләү өчен, мин әсәрдән бик күп мисаллар китерә алыр идем. Гаҗәеп көчле язылган аерым өзекләр дисезме, берсеннән-берсе кызыклырак әдәби детальләр, матур-матур чагыштырулар дисезме. Әмма хикмәт аларда гына түгел. Хикмәт язучының художник буларак өлгергәнлек дәрәҗәсендә, аның әдәби-эстетик карашлары җитлеккән булуда. Шул хакта сөйли торган берничә мисал китерим.

Алда Фәнис Яруллин сайлаган материалның характеры турында, аның әдәби әсәр язу өчен отышлы булуы турында әйткән идем. Отышлы булу өстенә, автор сайлаган материал шактый куркыныч та әле. Аз гына чама хисен югалттыңмы, сине монда сентиментальлек һәм мелодраматизм, төче пафос һәм күз яшьләре сагалый, ясалма әдәбиятка хас башка куркынычлар көтә. Фәнис Яруллин шул куркынычлардан исән котылган. Авторның җитлеккәнлеге хакында сөйли торган мисалларның берсе менә шул.

Әсәрне укыган кешеләр хәтерлидер, Фәниярне очраклы бәхетсезлек харап итә. Турникта күнегүләр ясаганда, ялгыш егылып төшә, шуннан гомерлек гарип кала. Баштарак бу момент та күңелдә ризасызлык уяткан иде. Бигрәк юкка харап була инде, янәсе. Берәр зур эш башкарганда, бөегрәк максатлар өчен көрәшкәндә булса икән... Уйлый торгач, бу мәсьәләдә дә автор белән килешергә туры килде. Нишлисең бит, кешеләр төрле-төрле булган кебек, бу дөньяда алар эшләгән батырлык та күп төрле икән. Берәүләрне тормыш гомергә бер генә сыный. Шул чагында югалып калмаганны батыр дилә. Газинур кебек, Матросов, Зоялар кебек. Башкалар алдына тормыш бөтенләй икенче төрле сынаулар китереп куя. Аларны ул көн саен, сәгать саен сыный, гомер буе сыный. Сынаулар гомер буена сузылганда, кешедән инде башка төрлерәк батырлык сорала. Андый чакта синнән һәр көн, һәр сәгать, һәр минут йөрәгеңне учың белән кысып, сыкранмыйча, зарланмыйча яшәү сорала. Фәниярнеке әнә шундый батырлык. Фәнис Яруллин гомер буена сузылган, гомер буена сынала торган батырлык турында язарга теләгән. Шуңа күрә аның герое турниктан гына «егыла»...

«Җилкәнне җилләр еккач» — нигездә бер герой язмышына багышланган повесть. Әсәрнең башыннан ахырына кадәр Фәнияр турында, аның фаҗигале язмышы, рәхимсез тормыш белән өзлексез көрәше турында сөйләнә. Фәнияр язмышы — күп кенә дәрәҗәдә Фәнис язмышы да. Телиме-юкмы, автор үз тормышы, үз хисләре, үз кичерешләре турында язарга мәҗбүр. Менә шунда ул тагын бер егетлек күрсәткән. Фәнис Яруллин үз героеннан, хәтта үз-үзеннән югарырак күтәрелә алган. Автор үз героен идеаллаштырмый, Фәниярнең кимчелекләрен, йомшак якларын яшереп калдырмый. Моңа карап образның дәрәҗәсе дә төшми, мөлаемлыгы да кимеми. Киресенчә, аның тормышчанлык көче генә арта. Фәниярнең батырлыгы безне сокландыра, тырышлыгы, үҗәтлеге бездә ихтирам хисләре уята. Аны ярата башлыйсың, аңа ышана башлыйсың. Әйе, ышана башлыйсың. Фәнияр образы ышандыру көченең зурлыгы белән дә аерылып тора. Мин аның барлык эшләренә, кылган барлык гамәлләренә ышанам. Иң кыен вакытларда иманын югалтмавына да, больницада яткан килеш урта мәктәп бетерүенә дә, аңа гына канәгать булмыйча, университетка керүенә дә, әйбәт шагыйрь булып китүенә дә, ниһаять, Илсөя исемле бик чибәр кызның Фәниярга кияүгә чыгуына да ышанам. Чөнки автор ышандырырлык итеп яза белә, геройларының эш-хәрәкәтләрен, үз-үзләрен тотышларын дәлилли, мотивлаштыра белә.

Билгеле, никадәр генә тырыш, үзсүзле егет булмасын, Фәнияр бу кадәр кыенлыкларны үзе генә җиңеп чыга алмас иде. Тормыш юлында аңа әйбәт кешеләр очрап тора. Шулар иң кыен чакларда аның рухын күтәрәләр, кеше булырга, күтәрелергә булышалар. Әсәр безне тагын әнә шул әйбәт кешеләре белән үзенә җәлеп итә. Гәлсөйдә түти белән Фәниярнең туганнары турында сөйләп тә тормыйк ди. Алардан калганнарын алыгыз. «Берүк мишәйтләп йөрмәгез, егетебез укый...» дип, Фәниярнең тынычлыгын саклап торучы швейцар карчыктан башлап, күпме алар: Илдус Гаделшиннар һәм Илсөяләр, Фәниярнең сәламәтлеге өчен көчләрен дә, вакытларын да кызганмаган медицина хезмәткәрләре, җәмәгать башлангычы тәртибендә авыру егеткә белем биреп йөргән укытучылар коллективы (бөтен бер коллектив!), җитен комбинаты кызлары, укучылар, пионерлар... Шулай да минем үземә авыручы ошаганы хәтерсез Нәсимә булды. Барыннан да ныграк шул образ куандырды.

Әсәрдәге әнә шул кешеләрне күргәч,

күңелдә горурлык хисләре кузгала. Әнә нинди безнең кешеләр, дисең. Шунда ук тагын бер хис уяна. Ышану хисе. Нинди генә хәлдә калсам да, ташламаячаклар икән дигән хис. Укучы күңелендә мондый хис уята алган язучы — өлгергән язучы инде ул!

Дөрес, повестьның барлык өлешләре дә бер дәрәҗәдә язылмаган. Көчле, тыгыз язылган бүлекләр белән бергә, йомшаграклары да очрый. Минем үземдә, мәсәлән, әсәрнең баштагы бүлекләре, бигрәк тә чигенү рәвешендә язылган бүлекләр, шундыйрак тәэсир калдырды. Андый урыннар повестьның уртасында да очраштыргалый. Монда авторның гомуми тенденциясе дә комачаулаган шикелле. Сентиментальлек китә күрмәсен, кырыс булсын, җитди булсын дип тырыша торгач, язучы урыны-урыны белән күңелсез, коры кешегә әйләнеп киткәли.

Әмма ни генә булмасын, Фәнис Яруллин матур һәм файдалы повесть язган. Зур таләпләр куеп сөйләшерлек сәнгать әсәре, чын мәгънәсендә җитди әсәр язган. Олы максатларга омтылып яшәүче актив геройлары булган әсәр иҗат иткән. Бик кирәк безгә мондый әсәрләр, бик кирәк безгә мондый геройлар!

...Алда урта буын хакында байтак язылды. Ул сүзләрнең күбесе Шамил Бикчуринга да кагыла. Урта буын прозаикларның күбесе кебек үк, Ш. Бикчурин да байтак еллар бер урында таптанды. Аның күптәнге бер тальян гармуны бар иде. Тегеләй дә тартты ул шул гармунны, болай да сузды. Соңгы вакытларда без инде аннан өмет үк өзә башлаган идек. Без өмет өзәргә җыенып йөргәндә, ул яңа роман тәгәлләп яткан икән. Шактый кызыклы, игелекле булып чыкты аның яңа романы. Ул авторга югала башлаган репутациясен кире кайтарды, язучының моңарчы без белмәгән яңа якларын ачып салды.

«Каты токым» — нефтьчеләр турындагы, дөресрәге, нефтьче-разведчиклар турындагы роман. Әсәрдә нигездә бер бригада кешеләре, аларның эше, тормышы турында сөйләнә. Роман үзенең җыйнаклыгы, композицион төзеклеге белән аерылып тора.

Зөбәеров бригадасы бораучылары яңа мәйданга күчәргә җыеналар. Күнегелгән, ияләнелгән җирләр кала. Танышып, дуслашып беткән кешеләр кала. Никтер китәсе килми, бик тә ямансу. Роман әнә шул вакыйгаларны сурәтләү белән башлана. Күпмедер вакыттан соң бригада кешеләре Язтургай мәйданындагы яңа скважинаны да бораулап бетерәләр. Тагын күченергә кирәк... Әсәр аларның тагын бер яңа урынга күченүләрен сурәтләү белән тәмамлана.

Ике күчену арасында күп булса 4—5 ай вакыт. Автор безне разведчикларның шул вакыт эчендәге авыр һәм мәшәкатьле тормышы, тынгысыз һәм борчулы хезмәте белән таныштыра. Бригада кешеләре, аларның гадәт-холыклары белән таныштыра. Төрле холыклы, төрле язмышлы кешеләрдән, төрле милләт вәкилләреннән торган бригаданың бердәм коллектив булып туплануын күрсәтә. Авторның төп игътибары соңгы икесенә — образлар иҗат итүгә һәм коллективның ныгуын күрсәтүгә юнәлтелгән. Иң мөһиме — шушы мәсьәләләр. Бер тигез югарылыкта ук булмаса да, автор аларның һәр икесен нигездә уңышлы башкарып чыккан.

Авторның көче, барыннан да бигрәк, образлар иҗат итүдә ачык күренә. Романның иң зур уңышы — кызыклы образлары. Зөбәеров бригадасында күпме кеше бар, язучы шуларның һәр кайсын индивидуаль бер шәхес итеп бирергә тырышкан. Бригаданың һәр кешесе уйламаган бер моментта балкып-ачылып китә, ниндидер бер ягы белән хәтердә кала. Бер алар гынамыни! Авыл халкын, Язтургай кешеләрен алыгыз: Фәридәләрне, Камилләрне, тәксе Галләмнәрне, калтыравык Сабирҗаннарны...

Шул уннарча кызыклы образлар арасыннан аеруча нык хәтердә калганы Мотгәрәй, әлбәттә. Нәрсәсе белән шулай хәтердә кала, кай ягы белән үзенә тарта бу образ? Югыйсә, әллә ни искитәрлек җире дә юк бит инде. Тәбәнәк гәүдәле, кыска аяклы, балан бәлеше кебек җәенке битле гап-гади бер авыл егете. Ә ифрат сөйкемле үзе. Әллә, сабый баладай, беркатлы, самими булуы ошый инде?.. Әллә җиргә, игенче хезмәтенә булган мөнәсәбәте шулай якын итә инде?.. Әллә мәхәббәт мәсьәләләрендә бик саф, чиста күңелле булуы сокландыра инде?..

Фәридәсе дә Мотгәрәйдән ким түгел. Дөрес, баштарак язучы аның тышкы матурлыгы белән күбрәк мавыга. Ул, мин сиңа әйтим, йомры тез башлары, калку күкрәкләр, дисеңме. Ул юан ботларын янякка ташлабрак атлап китүләре. Гел көлеп, елмаеп кына торган күзләр. «Егет булсаң— үп шуны!» дип, бүлтәеп торган дымсу иреннәр. Җитмәсә, тол хатын үзе. Тот та тизрәк Мотгәрәй белән бер түшәккә сал. Безнең кайбер яшь авторлар булса, шулай

эшләрләр иде дә. Шамил Бикчурин түшәккә салырга ашыкмый. Җае чыгып, вакыты җиткәч, Фәридә кинәт икеләнеп, куркыпкаушап кала. Шул моменттан башлап, укучы каршында Фәридәнең дә, Мотгәрәйнең дә абруе, дәрәҗәсе тагын да күтәрелеп китә. Әгәр «Казан утлары» журналының быелгы икенче санында Фатих Хөснинең «Без китмәскә дип килдек!» дип исемләнгән мәкаләсе басылып чыкмаган булса, әгәр ул мәкаләдә «Каты токым» романы турында сүз бармаса, мин әсәрдәге бу ике образ хакында озаграк та яза алыр идем. Фатих Хөснидән соң сузып тору кирәкмәс шикелле.

Хәтердә калырлык образлардан тагын Фәрхетдин бар. Бусы да бик колоритлы һәм кызыклы шәхес. Берниндн шартларда да югалып калмый торган үткен егет, шома егет. Эләктергән җирдән тешли, тешләгән җирдән өзә торган егет. Мәзәк сөйләргә бик оста кеше, бригададагы бөтен кешене көлдереп, бөтен кешенең күңелен күтәреп йөри торган җор егет. Романның баштагы бүлекләрендә ул әнә шундый мәзәк сөйләүче, кеше көлдерүче бер егет булып кына йөри дә. Шул хәлендә калса, ихтимал, минем аңа артык исем дә китмәс иде. Хикмәт тә шунда, ул шул хәлендә генә калмый.

Шулай бер вакыт мактаулы егетебез хурлыкка кала бит. Әле нинди мәсьәләдә диегез. Бөтен кешене авызына каратып торган егет сәхнәгә чыгып ике куплет шигырь сөйли алмый. Менә шунда Фәрхетдинебез ачыла да китә. Ш. Бикчурин үз геройларын еш кына әнә шундый хәлләргә куярга ярата. Образның асылы ачылырлык ситуацияләр, вакыйгалар таба белә. Малае армиягә китеп, ялгыз калу куркынычы тумаса, Галләм безнең алда, ихтимал, кеше белән рәтләп сөйләшә дә белми торган, төксе һәм пырдымсыз председатель булып калыр иде әле. Нишлисең, малаен армиягә алалар. Галләм япа-ялгызы кала. Менә шунда ул, ниһаять, тәвәккәлләп, тол хатын Фәридә тәрәзәсен кагарга була. Килсә, анда инде Мотгәрәй утыра. Бу соңга калган... Бик тә кызганыч булып китә шул чак председатель Галләм.

«Социалистик Татарстан» газетасының быелгы 14 январь санында М. Зариповның «Каты токым» романына багышланган рецензиясе басылды. Уйландыра торган, кызыклы рецензия. Бер урында рецензент Зәбәеровны халык байлыгын әрәм-шәрәм итүдә гаепли. Сүз Фазыл Зәбәеровның калтыравык Сабирҗан ишегал төзелешләрдә бер мичкә керосины һәм ℓлар юк та юк утын турында бара. Бәлки ‹нең фоны, сулыдыр. Әмма минем үзем урында газета бу жесты бик ошады. Н‹енчә белгәннәколач һәм көч күрдем ℓбер өсти алшушы эпизод булмаса, по сәләтле язукиенеп, кызлар торагына кер‹амалов кебулмаса, Фазыл образына нидерәнә дә иде. Без аның бригада хәтле бригад җитәкчелек итә алуына да, Рәйсә кебек кызны үзенә карата алуына да ышанып бетмәс идек. Ә бит Ибраһим-Задә кебек мастер булырга, таудан биек, кыядан каты, диңгездән колачлырак җитәкче булырга хыялланып йөргән Фазылыбыз роман өчен бик тә кирәк образ.

Алда бер тапкыр әйтелгәнчә, Ш. Бикчурин үз өстенә алган икенче мәсьәләне дә нигездә уңышлы башкарып чыккан. Сүз менә таралам, менә таралам дип торган бригаданың таза бер коллектив булып оешуы турында бара.

Язтургайдагы берничә ай вакыт эчендә Зәбәеров бригадасы, чыннан да, шактый ныгый. Кешеләр күзгә күренеп үзгәрә, алар арасындагы мөнәсәбәтләр тагын да яхшыра төшә. Кырыс разведка тормышы хәтта Мотгәрәй. Сапарбай кебекләрне дә акрынлап тәртипкә сала. Бригада кешеләре үзара дуслашып, тагын да якынаеп китәләр. Бүген китәм, иртәгә китәм дип, күпме генә үзләрен алдап йөрмәсеннәр, аларның берсе дә бригададан китмәячәк, китә алмаячак. Язучыдан әнә шул идеяне раслау сорала иде шикелле. Без бу карарына ышанабыз.

Әмма автор ышанмаслар дип курка. Безне маңгайга сугып, көчләп ышандырырга тотына. Шул эш белән артык мавыгып китеп, чама тойгысын онытып җибәрә. Әсәрдәге байтак кимчелекләр, ышандырмый торган нәрсәләр шуннан килеп чыга.

Фатих Хөсни дөрес әйтә, баш-аягы белән авылга береккән, беткәнче авыл кешесе булган, җитмәсә, яңа гына Фәридәгә өйләнгән Мотгәрәйдән нефть патриоты ясауның, аны бригадага тагып җибәрүнең һич тә кирәге юк, билгеле. Әнә шул мавыгу, чама хисен белмәү харап итә.

Роман күчену белән башлана, күчену белән бетә, дидек. Ике күчену арасындагы аерманы күрсәтез иде. Беренче күченгәндә бригада кешеләренең һәркайсының башында караңгы, төшенке уйлар гына. Соңгы күченүне карагыз: Тин-Тиныч Валясын тапкан, Мотгәрәй өйләнгән. Фәрхетдин

күңелдә горурлниса, Сапарбайныкында — нинди безнең белән Миргазиянның, Катагын бер хис өбәеровның да дөньялары генә хәлдә кал, кадәр шомартырга? Яздигән хис. Укучда искитәрлек, дөньяның уята алган язумәшәкатьләрен оныттырырул! булмады бит. Бригада тагын

Дөрес, ныгый төште. Бары шул гына. дә бер арны шул ук нефтьче-разведчик язы ышы: авыр һәм мәшәкатьле эш кетә...

Романда тагын мастер Зөбәеровның бик тә уңган хатыны бар. Рәйсә исемле. Болай аның ни өчен әсәргә килеп керүе дә, нинди вазифа башкарырга тиешлеге дә бик ачык. Бер заман авторыбыз шул хатын белән мавыгып китә бит. Нинди генә геройлыклар эшләми ул! Сөйләп тә, язып та бетерерлек түгел. Рәйсә килеп коткармаса, бетәселәр икән бу Язтургай кешеләре. Бигрәк каралар, бигрәк артта калганнар инде... Бусы да чама хисен онытып җибәрү бәласе.

Чыннан да, бу романда арттальк, искелек исе бик көчле. 50 еллардагы нефтьчеләр, 50 еллардагы авыл. Мин моның өчен авторны гаепләргә җыенмыйм. Ул шул чордагы нефтьчеләр турында яза, шул чордагы фонны сакларга тырышкан. Шулай да романның фонын азрак яңартырга, бүгенге көнгә якынайтырга кирәк булмадымы икән?! Бу — бәхәсле мәсьәлә, билгеле. Һәрхәлдә, уйлашып карарга ярый. «Каты токым» документаль әсәр дә, тарихи роман да түгел бит.

Үзенең югарыда телгә алган кызыклы рецензиясендә М. Зарипов роман авторын производство мәсьәләләренә җиңелрәк караган, аларга киңрәк тукталмаган өчен шелтәли. Чыннан да, әсәрдә хезмәт процессларын сурәтләүгә урын азрак бирелгән. Язучы производство мәсьәләләрен мөмкин хәтле читләтеп узарга тырыша. Хәтта читләтеп узарга ярамаган чакларда да... Нигә алай, нәрсә бу? Производство мәсьәләләренә керергә курку, нефтьчеләр хезмәтен йомшак белү бәласеме?.. Минемчә, түгел. Сәбәп башка нәрсәдә. Автор әсәремне укымаслар дип курка. Шуңа күрә производство мәсьәләләрен мөмкин хәтле читләтеп узарга тырыша. Инде һич тә мөмкин түгел икән, бик чамалап, җәен белеп кенә туктала. Аларны ул я буровойдагы яңа кеше Камил күзлегеннән карап сурәтли, я булмаса башка берәр җаен таба. Хикмәт һич тә нефтьне белмәүдә түгел, юк. Нефть, буровой тормышы аның үз җырына, үз моңына әйләнгән.

Әнә шуңа күрә дә эшче темасына, производство мәсьәләләренә багышланган бу роман мавыгып, яратып укыла. Авыл темасына караган, мәхәббәт мәсьәләләренә багышланган әсәрләр кебек укыла. Бик күңелле, бик куанычлы хәл бу. Мәсьәләгә шул яктан килеп караганда, «Каты токым» романының әһәмияте бер Ш. Бикчурин иҗаты белән генә чикләнми төсле. Билгеле булганча, бүгенге совет әдәбияты барлык милләт язучыларының уртак тырышлыгы белән үстерелә. Һәр әдәбият уртак хәзинәгә үзеннән билгеле бер өлеш кертә. Берәүләрдә — бер як, икенчеләрдә икенче як көчле. Рус совет әдәбиятында, әйтик, авыл темасы көчлерәк эшләнгән, Урта Азия һәм Балтик буе әдәбиятларында тарихи-революцион роман нык активлашып бара. Безгә насыйбы эшче темасыдыр, бәлки?! Татар прозасы, татар әдәбияты шушы өлкәдә үз сүзен әйтергә тиештер, бәлки?! Татарстан бүген иң эре промышленность үзәгенә, иң зур төзелешләр республикасына әйләнде. Безнең әдипләр дә алынмаса, бу темага тагын кем тотыныр икән?! Безнең проза йөз белән заман темасына борылып кына калмады, ул аны хәл итүдә дә шактый югары дәрәҗәгә ирешеп килә хәзер. Ш. Бикчурин романы тагын әнә шул хакта да сөйли.

Ә Мөсәгыйть Хәбибуллин повесте? Барлас Камаловның «Урамнар киңәя» повесте? Бүгенге прозаның дәрәҗәсе бу әсәрләр белән дә билгеләнмимени?! Минемчә, билгеләнми. Безнең прозаның гомуми дәрәҗәсе бу әсәрләрдән шактый югары. С. Рафиковның «Тын елга буенда» һәм Ә. Баяновның «Ут һәм Су» романнарын искә төшерегез. Нихәтле сүз булды, күпме тиргәдек без аларны. Хәзер менә уйлап карыйм: Б. Камалов, М. Хәбибуллин повестьлары белән чагыштырганда, алар бер баш югары булганнар икән. Ә. Баянов романында бүгенге төзелешкә бәйле кызыклы мәсьәләләр күтәрелә, ахырга кадәр эшләнеп бетмәсәләр дә, оригиналь образлар бар иде. С. Рафиков үзе яза торган өлкәне, төзелеш кешеләренең тормышын нык белә, шул ягы белән ихтирам уята иде...

Соңгы елларда безне Б. Камалов кебек куандырган прозаиклар ничә генә булды икән?! 1970 елда «Казан утлары» журналында язучының «Күршеләр» исемле повесте басылды. Барлык өлкән язучыларыбыз аның бу әсәренә әйбәт бәя бирделәр. 1971 елда авторның «Күңел кыңгы-

раулары» исемле яңа җыентыгы чыкты. Башка хикәя-повестьлары белән бергә, анда «Җан кардәшләр» дигән матур бер повесть та бар иде. Шул ук 1971 елда «Казан утлары» журналында язучының «Ялыкмаслар» исемле тагын бер повестен укыдык. Тәнкыйть бу әсәрдәге Хафиз Кадергулов образын әдәбиятыбызның бер казанышы дип бәяләде. Шуларның һәммәсеннән соң, әлеге яңа повесть: «Урамнар киңәя».

Дөрес, аның бу повестенда да матурматур эшләнгән аерым бүлекләр, кызыклы гына образлар бар. Зөһрәбану карчыкны алыгыз — коеп куйган образ! Морзахан абзыйга да сүз әйтеп булмый. Халык мәкальләрен дә чама беләнрәк кулланса, ярыйсы гына карт буласы. Тик КамАЗга багышланган әсәрнең уңышын Зөһрәбану карчык белән Морзахан картка карап билгеләү дөрес булырмы икән?!.

Ниндидер бер җыелышта Б. Камалов: «КамАЗ төзелә башлагач, әлеге төзелешкә читтән бик күп татарлар кайтты. Шулар турында яңа әсәр яздым»,— дип сөйләгән иде. Ул, мәгаен, шушы повестен күздә тоткандыр. Бу повестьта кайтучылар чыннан да бар. Алар берничә кеше. Вәдүт белән Рәйхан моңарчы Төмән якларында яшәп ятканнар икән. Берсе — укытучы, икенчесе — төзүче. Берсе — яңа армиядән кайткан яшь егет. Икенчесе — ире үлгән тол хатын. Бер-берсен табышалар, яратышалар, гаилә корырга булалар. Шунда кайту мәсьәләсе дә хәл ителә.

— Сүзем шул: мин риза,— ди Рәйхан өйләнешик дип килгән егеткә.— Алай да бер шартым бар. Уку елын тәмамламый торып өйләнешмибез, ямә?

Эш шарт куюдан киткәч, Вәдүт тә югалып калмый:

— Туй иткәч, Чаллыга кайтабыз. Бөтенләйгә. Автомобиль заводы төзергә. Яңа шәһәр салырга,— дип, үз шартын куя.

Кайтучыларның өченчесе — Яфиз исемле үсмер егет. Уналты яшь тә тулмаган килеш, Сәргачтагы мәктәп-интернаттан качып килгән. Өчесе дә Чаллыга, Морзахан абзыйның шыгырдап торган йортына кайтып төшәләр. Кайту-китү мәсьәләләре асылда шушы йорт эчендә хәл ителә, нигездә Зөһрәбану карчык хәл итә. Дөрес, ул бик каршы торгач, Яфиз мәсьәләсе бераз катлаулана. Бу эшкә Самородкинны да тарталар. Әмма кайтучылар мәсьәләсе шуннан да ары китми...

Бу повестьта чын мәгънәсендә төзелеш белән бәйләнгән, бары зур төзелешләрдә генә очрый торган характерлар юк та юк инде. Ичмасам, чын төзелешнең фоны, сулышы булсын иде. КамАЗ турында газета материаллары, очерклар буенча белгәннәребезгә Б. Камалов яңа әйбер өсти алмаган. Бик кызганыч. Ул бит сәләтле язучы. Менә шуңа күрә Барлас Камалов кебек прозаикның нинди генә әсәренә дә без битараф карый алмыйбыз.

Чаллыга килү мәсьәләсен М. Хәбибуллин да әле генә тикшереп узган «Урамнар киңәя» әсәрендәгечә хәл итә. Җәйге ялга кайткач, Зөлфәт үз авылларындагы бер матур кыз белән танышып ала. Яратышып китәләр. Егет кызны ничек тә үзенеке итәргә була. Миңа кияүгә чык, Казанга алып китәм, ди. Кыз, нәкъ Б. Камалов повестендагыча, егет алдына бер шарт куя:

— Әйдә Чаллыга... Анда зур төзелешләр башлана... Кайт шунда,— ди.

Матур кызның бер сүзе җитә. Казандагы менә дигән эшен, көйләнгән тормышын ташлап, Зөлфәт Чаллыга чабып кайта. Көч-хәл белән начар гына эшкә урнаша, торыр урын юнәтә. Инде сөйгән кызы Мәсновияне дә алып килим дип авылга кайтса, тегесе кияүгә чыккан... Тормышта болай булмый, билгеле. Яраткан егетенә кыз кеше ниндидер шартлар куеп тормый. Егетләр дә, алдын-артын уйламый гына, мондый зур эшкә тәвәккәлләмиләр.

Ярар, ни булса ул, егетебез Чаллыда яшәп кала шулай. Баксаң, моның кулыннан Мәсновияне тартып алган кара мыеклы егет тә шушында ук икән. Җитмәсә, Зөлфәт белән бер ук автохуҗалыкта эшли икән. Сүз дә юк, болар башта ук бер-берсен яратышмыйлар... Алар арасындагы дошманлык повестьның урталарына кадәр тартылып-сузылып килә дә, бер вакыт туктап, сүрелеп кала. Зөлфәт белән Ислам арткы планга чигенәләр, алга Сәгъди Низамов килеп чыга. Әсәрнең Низамов турындагы өлеше башлана.

Менә шофер егетләр арасындагы конфликтның ярты юлда сүрелеп калуы да, повесть үзәгенә һич уйламаганда Сәгъдинең килеп керүе дә артык гаҗәпләндермәде. Әсәрдәге образларның чын йөзе ачык түгел. Ниндирәк кеше икәнлекләрен чамалап булмый. Иң нык аптыратканы әнә шул булды. Повестьның баштагы өлешләре буенча, Ислам безнең алга шактый начар бер кеше булып килеп баса. Зөлфәт аңа каршы көрәшә башлагач, шатланып ук куясың. Менә ул аны фаш итәр, менә ул

аның чын йөзен ачар, дип котәсең. Баксаң, үзенең дә Исламнан артык җире юк икән. Ислам кебек үк, ул да тыелган юл белән Бәкыйдан моторын көйләтеп ала. Ислам кебек үк, дан, акча артыннан куа башлый. Хатын-кыз мәсьәләсендә исә Исламнан да уздырып җибәрә. Әле кайчан гына Мәснәвия дип елап йөргән иде. Карыйсың, квартира хуҗасы белән дә эшләре көйләнеп килә, балалар бакчасында эшләүче Хәят исемле чибәр кыз белән шаярып алырга да каршы түгел... Нәрсә бу? Нинди кешеләр болар? Һич аңларлык түгел.

Шулай да ныграк уйлана торгач, бу мәсьәлә дә бераз ачыла төшә сыман. Соңгы елларда без язучыларга адым саен бер фикерне тукып килдек. Геройларыгыз бер генә калыптан сугылган булмасын! Коеп куйган уңай герой да, коеп куйган кире герой да кирәкми безгә. Күп яклы, күп планлы, тулы канлы образлар бирегез! Геройларыгыз тере булсын, тормышчагы жанлы булсын, янәсе... Күп кабатлый торгач, арттырыбрак җибәргәнбез булса кирәк. Әнә, күрәсез, вульгар социологизм заманнарындагы «ак-кара» урынына яңа бер шаблон, яңа бер схема туып килә икән. Уңай да, кире дә түгел, хәтта кем икәнлеге, нинди кеше икәнлеге бөтенләй анык булмаган геройлар модага әйләнеп бара икән. М. Хәбибуллин шул модага ияргән диясе килә.

Повестьтагы Сәгъди Низамов образы болай кызыклы гына уйланган. Урыны-урыны белән ул матур гына ачылып та китә. Ләкин аңа да аныклык, конкретлык җитми. Унберенче бүлектә Сәгъдинең биографиясенә бәйләнешле тетрәтерлек вакыйгалар сөйләнә. Әмма ул вакыйгалар Сәгъдинең характерын ачарга булышмыйлар. Киресенчә, мәсьәләне шактый бутый, чуалта гына төшәләр. Автор бик кызыклы, үз урынында белеп кулланылганда ифрат отышлы материалын бу әсәргә кертеп әрәм генә иткән.

М. Хәбибуллин «Унсигезенче яз» исемле кызыклы повесть белән әдәбиятка килде. Шул әсәре белән аны Язучылар союзына алдылар, шул әсәре белән ул язучы булып танылды. Шуннан соң бер урында таптана башлады. 1971 елда гына «Икмәк кадере» исемле повесте өчен тәнкыйтьләнгән иде. Менә тагын бер ахыргача эшләнеп бетмәгән әсәр бастырды. Кызыклы гына образлары, матур гына эпизодлары булуга карамастан, повесть безне канәгатьләндерә алмый.

Шушы тештә, берочтан, «Адашканга юл кая?» һәм «Милиция лейтенанты» повестьларына да тукталып узарга кирәктер, мәгаен. Икесенең дә авторлары — хатын-кызлар. Һәр ике әсәр детектив әдәбият төренә карый.

Журналда «Милиция лейтенанты» басылып чыккач, бер төркем язучылар шактый вакыт дулап йөргәннәр иде. Баштарак аларның бу кадәр дулаулары аңлашылып та җитмәгән иде. Чыннан да, нигә бу кадәр исләре китә икән?.. Гадәти, урта кул повесть инде. Һәр детектив әсәр кебек, җиңел укыла торган повесть. Башка халыкларда мондый әсәрләр языла тора, басыла тора. Аннан соң Р. Ишморатова үз әсәрен яхшы ният белән язган бит әле. Автор безне милиция хезмәткәрләренең тынгысыз һәм авыр эше белән таныштыра. Укучыларда аларга карата ихтирам һәм мәхәббәт хисләре тәрбияләргә тели. Шуның өчен тырыша.

Повесть белән ныклабрак танышкач, шулай да шиккә каласың. Нияте бик изге, ә нәтиҗәсе ничегрәк? Нәрсә бирде, нәрсә белән баетты ул безне? Минем үземә, мәсәлән, әллә ни бирмәде. Үзе дә милициядә эшләгән, бу эшнең нечкәлекләрен, рәтен белгән автор ни өчен безгә берни дә бирә, безне баета алмады? Ни өчен повесть безне битараф калдырды? Сәбәбе бик гади. Автор детектив әдәбиятка хас мәгълүм шаблоннардан котыла алмаган. Зәлфәтнең, Шерлок Холмс кебек, гел генә җинаятьчеләр артыннан чабуы да, мәхәббәт белән хезмәте арасындагы конфликтлар да, милиция хезмәткәрләренең куна-төнә эш урыннарында ятулары да — һәммәсе иске, һәммәсе күп тапкырлар кабатланган, шаблонга әйләнгән нәрсәләр. Иң аяныч шул, кызыклы вакыйгалар, маҗаралы хәлләр артыннан куып, автор геройларының җанын, характерларын ачарга оныткан. Образларның эш-хәрәкәтләре, кылган гамәлләре мотивлаштырылмаган. Шуңа күрә геройларның язмышы безне битараф калдыра. Шуңа күрә әсәр дулкынландырмый, шуңа күрә әсәр безне баетмый.

Мәдинә Маликова повестенда мактап телгә алырлык яклар шактый гына. М. Маликова гади, табигый итеп яза ала. Ул шәһәр тормышын, шәһәр кешеләрен, аларның көнкүрешен әйбәт белә. Повестьта бигрәк тә шәһәр мещаннары — Люси, Нателла, Рифлар дөньясы оста тасвирланган. Әсәрнең сюжет-композиция ягы да ярыйсы кебек.

Шул ук вакытта әсәрдә кимчелекләр дә шактый әле. Зөлфә белән Атлас арасындагы мөнәсәбәтләргә ачыклык җитми. Нияз болай шактый кызыклы уйланган образ. Урыны-урыны белән ул матур гына ачылып та китә. Зөлфәне, машинага утыртып, кырга алып чыгып киткән урыннарны искә төшерегез! Әмма ни генә булмасын, бу егетнең, тикшерүче роленә кереп, детектив булып китүе, җинаять ачучы изге шымчы булып йөрүе, ничектер, акланып җитми. Турысын гына әйткәндә, бу яңа повесть белән М. Маликова безне әллә ни шатландыра да, куандыра да алмады.

М. Мәһдиевнең «Фронтовиклар» романын киң катлау укучылар массасы да, әдәби җәмәгатьчелек тә җылы каршылады. Ул һәммәбезнең игътибар үзәгендә булды. Бу роман буенча күп урыннарда конференцияләр, фикер алышулар уздырылды. Матбугат битләрендә, үзебездә булсын, башка тугандаш халыкларда булсын, күп кенә мәкалә-рецензияләр басылды. Мин үзем Ф. Хөсни һәм Ф. Урманчиев белән Т. Галиуллин мәкаләләрен аеруча кызыксынып укыдым. Романның төп пафосын, яңалыгын һәм үзенчәлеген әүвәл алар ачты. Мин алар башлаган сүзне дәвам иттерүче генә.

«Фронтовиклар» — укыр өчен кызыклы, әмма тикшерү, фикер әйтү өчен шактый кыен роман. Кыенлыгы шунда, ул моңарчы без укып, тикшереп гадәтләнгән әсәрләрнең күбесенә охшамаган. «Фронтовиклар» — ифрат үзенчәлекле әсәр. Үзенчәлек романның теленнән, язучының хикәяләү стиленнән үк башлана. «Без кырык беренче ел балалары» дигән повесте басылып чыккач ук күрдек: аның прозасы акылга һәм иронияга бай иде. М. Мәһдиев әсәрендә лиризм һәм юмор табигый рәвештә бергә үрелеп бара иде. «Фронтовиклар» романында язучы стиленең әлеге сыйфатлары тагын да үсә, тагын да камилләшә төшкән. Монда инде лиризм белән юмор гына түгел. Бусында инде гади хикәяләү стиле, лиризм, юмор, сатира һәммәсе бергә үрелеп бара. Язучы бер төрле хистән икенче төрле хискә, бер настроениедән икенче настроениегә гаять җиңел, гаять табигый күчә. Кырыс реализм юмор белән, җылы лиризм сатира белән чиратлаша. Шуларның һәммәсе бик табигый, бик тормышчан чыга. Стильдәге менә шул күп төслелек, күп тавышлылык романга үзгә бер ямь, үзенчәлекле яңгыраш бирә.

Татар прозасының күп еллар буена туплана-ныгый килгән үзенә хас сыйфатлары бар. Безнең күпчелек роман-повестьларыбызга салмак агымлы, тәфсилле стиль хас. Алардан аермалы буларак, «Фронтовиклар», соң чиккәчә кысылган пружина кебек, тыгыз язылган әсәр. М. Мәһдиев бер битлек-бит ярымлык мәйданга зур бер хикәялек материал сыйдыра ала.

Роман үзенең формасы, архитектоникасы ягыннан да шактый үзенчәлекле. Тыштан карaганда, әсәрдә буйдан-буйга сузылып килгән үзәк конфликт та, андагы бөтен вакыйгаларны, эреле-ваклы үсеш сызыкларын үз тирәсенә җыйнап торырлык ситуация дә юк кебек. Ә эчке бөтенлек, эчке киеренкелек бар. Күзгә күренми торган ниндидер җепләр романны таратмый тотып тора, андагы вакыйгаларны бер төенгә бәйли. Ниндидер бер эчке көч безне гел киеренкелектә тота. Әлеге киеренкелек һаман үсә, көчәя, киңәя бара. Һәм җиңү бәйрәменә багышланган мәҗлестә ул үзенең иң югары ноктасына күтәрелә. 9 Май бәйрәме — бөтен романның иң биек ноктасы, 9 нчы дулкыны.

Билгеле булганча, роман Рушад белән башлана. Автор безне геройның тормышы, яшьлеге белән таныштыра. Бүлектән бүлеккә ул ачыла, тулылана бара. Менә ул Акбалык мәктәбенә килә, балалар укыта башлый. Үзе белән бергә, акрынлап, безне дә мәктәп тормышына алып керә. Без Акбалык мәктәбенең укытучылары, укучылары белән таныша барабыз. Безнең алда мәктәп тормышы, андагы кешеләр ачыла, аларның шатлык-кайгылары, борчу-мәшәкатьләре, җаннары ачыла. Роман торган саен киңәя, тармаклана бара. Мәктәп тормышыннан авыл, колхоз хәлләренә күчебез. Бераздан романга район, республика күләмендәге вакыйгалар, ахырга таба бөтен ил күләмендәге вакыйгалар килеп керә. Вакыйгаларның кысалары киңәйгән саен, кешеләр арта, язмышлар зурая, хәл итәргә тиешле мәсьәләләр күбәя. Әсәрнең колачы, сулышы киңәя бара.

Шулай да нәрсә турында соң бу әсәр? Аның үзәге, умыртка сөяге бармы? Төп мәсьәләләре бармы?.. Минемчә, андый мәсьәләләр бар. Телгә алып сөйләрлеге, зуры ике бугай. Дөрес, аларның берсе икенчесенә бәйләнгән. Шулай да нигездә ике мәсьәлә.

Роман «Фронтовиклар» дип атала. Әлеге ике мәсьәләнең берсе әсәрнең исеменнән үк килеп чыга: фронтовиклар... Бөек Ватан сугышында без коточкыч әшәке дош-

манны җиңеп чыктык. Ләкин узган сугыштагы җиңүнең әһәмияте моның белән генә чикләнми. Бөек Ватан сугышында катнашу Рушадларның, Гаталарның бөтен тормышына тирән бер эз сала, сугыштан алар үсеп-зураеп, чыныгып кайталар. Фронт чынбарлыгы аларны тормышның көндәлек вак-төякләреннән өстен булырга, намуслы булырга өйрәтә. Тыныч тормышта да алар фронтовиклар булып калалар. Иң кыен чакларда чит җирләрдә үлеп калган фронтташ дусларын искә төшерәләр, күңелләреннән алар белән киңәшәләр. Кырыс сугыш чынбарлыгы аларны үз язмышларын ил язмышы белән бәйләп карарга өйрәтә. М. Мәһдиев данлы Совет Армиясен, совет солдатының тиңдәшсез батырлыгын мактый, аларның батырлыгын онытмыйк, ди.

Мәсьәләләрнең икенчесе укыту-тәрбия эшләре, мәктәп тормышы белән бәйләнгән. Автор үзе озак еллар укытучы булып эшләгән кеше, хәзер дә шул эшен дәвам итгерә. Сүз дә юк, ул бу өлкәне шәп белә. Аның тәрбия, уку-укыту мәсьәләләренә карата үз фикере, әйтер сүзе бар. Ул, мәсьәлән, укыту-тәрбия эшендә укытучының шәхси үрнәге хәлиткеч роль уйный, дип уйлый. Әллә нинди дәреслекләр, бик шәп кулланмалар чыгарырга мөмкин. Әмма ахыр чиктә мәсьәләне укытучы, аның нинди кеше булуы хәл итәчәк, ди. Хәзер безнең мәктәпләрдә ир укытучылар азаеп бара икән. Моның инде күңелсез нәтиҗәләре дә күренә башлаган. Малайларда ирлек сыйфатлары кимеп бара, ди. «Фронтовиклар» романындагы Гаталар, Рушадлар бәлки педагогика фәненең нечкәлекләрен белеп тә җиткермиләрдер. Кызып китеп, педагогика кануннарына сыеп бетми торган тәрбия ысуллары да кулланалардыр. Әмма алар күпне күргән фронтовиклар. Алар балаларны шәхси үрнәкләре белән үк тәрбияләләр. Дөрес карашмы бу? Килешәсезме? Анысы сезнең эш. Роман авторы шулайрак уйлый һәм шул фикерен безгә дә җиткерергә тырыша.

Әгәр романдагы һәр образны, һәр эпизодны әлеге ике мәсьәлә белән генә бәйләп карый башласак, билгеле, без шактый уңайсыз хәлдә калыр идек. Роман роман инде ул. Күпмедер дәрәҗәдә халык тормышының энциклопедиясе. Әсәргә авторның гомер буе җыйган күзәтүләре, аз-азлап туплаган ачышлары кереп киткән. Монда аның тормыш, кеше гомеренең мәгънәсе турындагы уйланулары, идеаллары, теләк-омтылышлары. Монда авторның дөньяны аңлавы, тормышка, кешеләргә мөнәсәбәте. Монда ул үзе. Билгеле, аларның һәммәсе әлеге ике мәсьәләгә генә сыеп бетмидер. Әмма шулар булмаса, әсәр күп мәртәбә саегыр, тоныкланыр, тәссезләнер иде. Әгәр шулар булмаса, романның матурлыгы, шигърияте нык кимер иде, андагы чор сулышы, заман рухы бу кадәр үк булмас иде.

М. Мәһдиев истә калырлык образларның бөтен бер галереясен тудырган. «Иптәшләр, бу — минем гаеп» дип, укыту-тәрбия эшендәге бөтен җитешсезлекләрне үз өстенә алып килә торган акыллы һәм хәйләкәр мәктәп директоры Сабир Ишмуратовичны алыгыз, аның хатыны — матур итеп авырый белә торган, егылганда да «грандиозно» итеп егыла белә торган, тавышы дөньядагы бернинди гармунга туры килмәсә дә, җырчы данын күтәреп йөргән Гөлчирәне алыгыз! Ике сүзнең берендә «бәлки, мин ялгышамдыр...» дип кабатларга ярата торган надан Хушият, мут күзле Мәсрүрә, акыллы һәм әдәпле Бәлкыйс, нәзакәтле Нәркис... Алар бик күп. Ф. Хөсни дә, Т. Галиуллин белән Ф. Урманчиев та язучының образлар иҗат итүдәге осталыгына шактый киң тукталалар. Аларны кабатлап тормыйм. Минем бары Гата образы турында гына берничә сүз әйтәсем килә.

Бу образ турында шулай ук күп язылды. Аның кайнар канлы, бунтарь йөрәкле булуы да искәртелде. Гатаның көтелмәгән хәлләр, сюрпризлар кешесе икәнлеге дә әйтелде. Гата Сәләхиев образының әсәр ахырына таба тоныклана төшүе дә билгеләп үтелде. Мин боларның һәммәсе белән килешәм. Тик Гата образының социаль әһәмиятенә генә ныграк басым ясый төшәсем килә.

Әйе, Гата — көтелмәгән хәлләр, сюрпризлар кешесе. Төрле сюрпризлар эшләргә ярата торган Гата, чиратка тезеп, авыл агайларын аракы белән сыйлый. Кайнар йөрәкле, бунтарь Гата гармун күтәреп университетка килеп керә. Бусының да үзенә күрә логикасы бар. Гата бик шәп белә: Октябрь революциясе булмаса, аны университетның коридорына да аяк бастырмаслар иде. Ә хәзер ул әнә рәхәтләнеп йөри ала!.. Дөрес, совет власте биргән хокуклардан ул үзенчәрәк, малайларчарак файдалана. Нишлисең, шулай булмаса, ул Гата да булмас иде.

Ләкин без әле икенче бер Гатаны да беләбез. Яшьли ятим калып, көтү көтеп

ускән Гатаны. Әнә шул көтүче малай тырыша-тырыша педучилище бетерә, университетка барып керә. Шул көтүче малай, яшьли сугышка эләгеп, кыю разведчик булып китә. Зур батырлык эшли. Орденнар белән бүләкләнә. Гади көтүче малае өлкән лейтенант дәрәҗәсенә күтәрелә, Берлинны алуда катнаша, Җиңү парадын күрә... Без әле тагын олы максатлар, зур идеаллар белән янып яши торган, зур мәсьәләләр турында кайгыртып яши торган Гатаны, район башкарма комитетының председателе булып эшләгән Гатаны беләбез. Ил язмышын үз язмышы иткән Гатаны, дәүләт кешесе дәрәҗәсенә күтәрелгән Гатаны беләбез. Көтүче малай дәүләт кешесе дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә! Совет власте менә нинди кешеләр тәрбияләп үстерде! Гата образының төп әһәмияте әнә шунда, минемчә.

Ифрат колоритлы, тормышчан һәм җанлы булулары өстенә, М. Мәһдиевнең образлары тормыш шартларына карап үзгәрә дә торалар әле. Билгеле, автор ярдәме белән, автор кушуы белән. Бусы — аеруча зур осталык сорый торган әйбер. Бусы — сирәк кеше кулыннан килә торган эш. Фикеремне бер генә мисал белән дәлилләп китим. Кышкы ял көннәренең берсендә Рушад белән Гата Казанга китәләр. Сорочи базарына барып икесенә дә пальто сатып алалар. Шуннан аерылалар. Килгән-килгән, Рушад университетка сугылып чыгарга була. Шул тирәдә йөргәндә Акбалык мәктәбендә үзе белән бергә эшләүче чибәр Нәркисне очрата. Сөйләшеп китәләр. Нәркис белән зур мәсьәләләр турында гәп корып барганда, Рушадны бер исерек туктата. Күтәрелеп караса, каршында Мөби — Рушадның яшьлек дусты, заманында бер телем икмәкне бүлешкән якын иптәше басып тора. Үзегез беләсез: Рушад бик итагатьле, әдәпле, кече күңелле егет. Җитмәсә, педагог, романның уңай герое. Сүз дә юк, ул, килеп, Мөбине кочаклап алырга, хәлен сорашырга тиеш иде кебек, ләкин Рушад икеләнеп кала. «Дәшәргәме? Бер читтә Нәркис карап көтеп тора. Әле генә бик тәмле, тыныч әңгәмә иде. Әле генә янда күңелне кытыкларлык помада исе бөркеп торган принцесса бәхет турында сөйли иде. Әле генә бик рәхәт иде. Нигә бу дөньяда һәр вакыт шулай — ак янында кара, ут янында су...» Дәшми калу хәерлерәк булыр дип уйлый, Рушад танымаганга салыша. Мөби китеп бара. Ләкин Рушадның күңеленә борчу, газап салып китеп бара. Аңа вөҗдан газабын салып китеп бара. «Гафу ит, Мөбәрәк! Мин сине барыбер эзләп табармын. Барыбер табармын, тик бүгенгесе өчен гафу ит! Тик зинһар үпкәләмә!..»

Әнә шулай, тормыш шартларына карап, вакытына, җаена карап, роман геройлары гел үзгәрә торалар, укучы алдында әле бер яклары, әле икенче яклары белән ачылалар. Автор үз геройларын үсештә, үзгәрештә бирә белә.

Романдагы кайбер кимчелекләргә, житешсез якларга күз салыйк. Йорт салынып беткәч, аның әйләнә-тирәсен чистарту, җыештыру эшләре башлана. Бөтен артык әйбер җыеп алына. Эшләгәндә йөрерго уңайлы булсын дип салынган басмалар сүтелә. Йорт тирәсендәге чүп-чар җыеп түгелә. Йорт тирәли юллар салына, чәчәкләр утыртыла. Бары шуннан соң гына ул файдалануга тапшырыла. Безнең күп кенә прозаикларга шул нәрсә җитми. Алар яңа әсәрләрен тарап, чистартып чыгарга иренәләр. Шул ук нәрсә «Фронтовиклар» романында да сизелә. Әсәрдә очы-очка ялганып җитмәгән аерым урыннар, бер-берсенә каршы килә торган распаулар, романның төп рухына ятышмый торган әйберләр калган. Бер сүз белән әйткәндә, басмалар сүтеп алынмаган, йорт тирәсе чистартылмаган. Алар ямьле әсәрнең ямен җибәреп, аны котсызландырып торалар. М. Мәһдиев романын җиңел генә, гади генә итеп башлап киткән иде. Эш йомгаклауга барып җиткәч, тәмамлый алмый интегә. Артык суза торгач, роман сүлпәнәя, геройлар тоныклана төшә. Баштагы тәэсир шактый кими. Дөрес, Мәһдиев һаман да Мәһдиев булып кала. Юк-юк дигәндә дә, берәр шәп күзәтүе булыр. Инде тәмам сыекланды дигәндә дә, берәр кызыклы образ бирел ташлар. Шулай да бик көчле башланган романның сүрелә төшеп тәмамлануы кызганыч, әлбәттә.

Узган ел А. Гыйләҗевнең «Кызлар хатлары» исемле повестьлар җыентыгы чыкты. Яңа җыентыкка авторның өч повесте кергән. Аларның «Дүртәү» исемлесе безгә электән таныш иде. «Урталыкта» һәм «Кызлар хатлары» дип исемләнгәннәре соңгы елларда иҗат ителгән повестьлар.

Яңа повестьларның һәр икесе кызыксыну белән укыла. Ул әсәрләрдә без әдәбиятыбызны кызыклы гына сәхнә әсәрләре, әйбәт хикәяләр, повестьлар белән баеткан элекке танышыбыз белән, безнең әдәбиятка шигъри күңелле, зәңгәр күккә, йолдызларга сокланучы романтик табигатьле ге-

ройлар алып килгән язучы белән, бүгенге кешеләрнең уй-хисләрен, замандашларыбызның характерын, психологиясен өйрәнү юлында, бүгенге көн геройларының образларын иҗат итү юлында өзлексез эзләнүләр алып барган автор белән, безнең әдәбиятта үз урыны, үз йөзе, үз почеркы булган А. Гыйләҗев белән очрашабыз. Ул һаман бүгенге дөнья мәсьәләләре, бүгенге кешеләр, аларның тормышы белән кызыксынып яши икән.

«Кызлар хатлары» — бүгенге яшьләр турындагы әсәр. Повестьны укыганда, без бүгенге яшь буынның тормышы һәм дөньяга карашы белән, аларның уй-теләкләре, идеаллары, омтылышлары белән танышабыз. «Кызлар хатлары» — 17—18 яшьлек кызлар турындагы әсәр. Хатларда кызларның иң саф, иң яшерен серләре: бәренче мәхәббәтләре, шатлык-сөенечләре, кайгы-хәсрәтләре. 17 яшьлек кызларның рухи халәтен, иң саф хисләрен, хатларыннан тыш, тагын каян белер идек? Хатлар повестьның кысаларын киңәйтергә, әсәргә заман сулышы бирергә булыша. Яшьләребез бай күңелле икән, бер-берсенең язмышы өчен борчыла, кайгыра беләләр, битараф түгелләр икән. «Кызлар хатлары» белән танышкач, без өнә шуңа ышанабыз. Тик шунысы гына бераз эчне пошыра. Әсәрдә бер төрлерәк хатлар, бер төрлерәк кызлар күп. Хатлар санын да, кызлар санын да киметә төшәсе килә. Повесть Лена белән булган фаҗигале хәлне хәбәр итүдән башлана. Әнә шул шомлы, ямьсез хәбәр безне әсәр буена изеп, басып тора. Хатларны табигый хәлдә укырга комачаулый. Көләсе килгәндә көлеп, шатланасы килгәндә шатланып булмый. Тегә шомлы хәбәр тыеп тора, ничектер уңайсыз кебек...

Җыентыктагы әсәрләрнең иң җитдие — «Урталыкта» повесте. Бу әсәр авторның бүгенге дөнья, бүгенге тормыш турында җитди уйлanулары хакында сөйли. «Урталыкта» рухи торгынлыкка, күңел тынычлыгына каршы юнәлдерелгән әсәр. Авторның игътибар үзәгендә бер кеше язмышы. Әсәрдәге көрәш, конфликт бер кеше күңелендә бара. Көрәш, давыл — идеалларын, тынгысызлыгын, иҗат дәртен югалтып, дача кешесенә әйләнеп барган Сәгыйть күңелендә.

Фани дөнья рәхәтләренә иялешеп, йөрәген май баса башлаган Сәгыйтькә шомлы хәбәр җиткерәләр. Сәгыйтьнең остазы, аның бик күп кайгы-шатлыкларын бүлешкән сердәше, иҗат газапларын, иҗат шатлыкларын уртаклашкан якын дусты — Баязит карт үлем түшәгендә ята икән. Бу шомлы хәбәр аны сискәндереп, уятып җибәрә. Уянып, тирә-ягына, үз тормышына күз салса, аптырап һәм гаҗәпләнеп кала егет. Аптырар, борчылыр нәрсәләр күп икән, һай, күп икән шул. Әле кайчан гына ул зур идеаллар, зур максатлар өчен янып йөргән тынгысыз иҗат кешесе булган. Ашкынып, дәртләнеп яшәгән, бетмәс-төкәнмәс иҗат планнары белән рухланып йөргән. Рузалия Сәгыйть абыйсына әнә шул көннәрдә гашыйк булган...

Тыштан караганда, аның хәле әле дә артык начар түгел кебек. Планын үтәп, премиясен алып бара. Мактыйлар, сәләтле инженер, диләр. Элекке дан бетеп җитмәгән, аңа әле һаман ышаналар. Ләкин Сәгыйть үзе сизә: ул инде элекке инженер түгел. Элекке дәрт, элекке ялкын калмаган. Иҗат кешесе буларак, сүнеп килә. Хәер, Сәгыйтьнең хәлен Баязит абыйсы да күреп ята, Рузалия дә сизенә башлаган бугай. Сәгыйтьнең үзен дә, Баязит картны да әнә шул нәрсә пошаманга сала. Нигә мондый хәлгә төште ул?.. Нигә иҗат ялкыны сүнде?.. Шундый уйлар газаплый егетне. Уйлаган саен уй арта, уйлаган саен уй зурая. Сәгыйть үз тормышы, үз язмышы турында уйлана. Үзе турындагы уйларга үз буыны турындагы, Баязит абзыйлар буыны, Рузалияләр буыны турындагы уйлар килеп ялгана. Әсәр герое буыннар арасындагы мөнәсәбәтләр турында, бүгенге дөнья, аның иминлеге турында уйлана. Сәгыйть белән бергә, автор да уйлана. Монда без авторның үз уйлары, үз фикерләре, үз күзәтүләре белән дә очрашабыз. Повестьта без А. Гыйләҗевнең шәхси кичерешләре, шәхси борчулары белән дә танышабыз...

Безнең алда, акрынлап, Сәгыйть кичергән газапларның мәгънәсе ачыла, Сәгыйть үзе ачыла. Дөрес, Сәгыйтьнең бу хәлгә төшүен төрле кеше төрлечәрәк аңлата. Сәгыйть үзе бер төрле, Рузалия икенче төрле, Баязит карт өченче төрле аңлата. Кайсысы дөрес? Өзеп кенә әйтүе кыен. Әмма бер нәрсә бәхәссез: Сәгыйть инде элекке инженер түгел. Аның иҗат дәрте, иманы сүнеп бара, ул гади көнлекчегә әйләнеп килә. Бусы — бәхәссез нәрсә.

Шушы урында тукталып калса, минем бу әсәргә артык исем китмәс иде. Автор тукталып калмый. Ул Сәгыйть күңелендә кабат иҗат ялкыны кабынып килүен дә күрсәтә. Дөрес, башка прозаикларыбыз кебек үк, бу мәсьәләдә А. Гыйләҗев тә артыг-

рак тырышып, артыграк шомартып ташлый. Әмма ни генә булмасын, без Сәгыйт күңелендә борылыш тууга, аның зур эшкә алынуына һәм җиңеп чыгачагына ышанабыз. Буыннар арасындагы бәйләнеш өзелми, тормыш дәвам итәчәк. Иң әһәмиятлесе әнә шул. Мин әсәрне шулай аңладым, ул миндә шундыйрак фикерләр уятты. Ә менә Фатих Хәсни «Урталыкта» повесте турында башкачарак уйлый икән. «Казан утлары» журналының февраль санында басылган мәкаләсендә ул болай яза:

«...Ләкин бер хакыйкатьне онытмаска кирәк: без кешенең эчке күлмәкләрендә казыну чорында яшәмибез, без гомум халыкның уртак шигаре булган бердәм хәрәкәт, юктан бар итү, гомуми иҗат энтузиазмы, кешеләр һәм халыклар белән кулга-кул тотынып, яңа дөнья төзү юнәлешендә яшибез. А. Гыйләҗевнең исенә төшерергә һәм вакытында иптәшләрчә кисәтергә кирәк: әгәр ул чорның кире кагып булмастай бу хакыйкатен тиешенчә төшенергә теләмичә, гел аерым шәхесләр җанында казыну юлы белән китсә, аның иҗатының чор иҗатыннан аерылу куркынычы бар» (179 бит).

Күрәсез, А. Гыйләҗев өстенә гаепнең зурысы, бик олысы ташланган. Ләкин дөресме ул? Минемчә, юк, дөрес түгел. Фатих Хәснине әдәбият белеменең элементар кагыйдәләрен белмидер, дип уйламыйм. Әдәбиятның төп объекты — кеше тормышы, кеше үзе икәнлеген дә белә булыр. Художникның төп эше — кеше тормышын өйрәнү, кеше җанында казыну, дип әйткәннәрен дә ишеткәнә бардыр. Лев Николаевич Толстой бер вакыт әйткән бит: язучылар кеше күңеленең яшерен серләрен өйрәнергә тиешләр, дигән. Аннан соң Фатих абый күтәргән лозунгның әллә ни яңа булмавын да искә төшереп узасы килә. Әле 30 елларда ук кайбер иптәшләр: безнең чорда төп герой — масса, шулай булгач, безгә аерым... типлар тудыру мәсьәләсе белән чуалмаска кирәк, массаны бирсәң — шул җитә, дип чыктылар. Совет әдәбиятының үсеш тарихы аларның бу карашын кире какты.

Бәлки А. Гыйләҗевнең бу әсәре артык озын гомерле булмас. Бәлки ул әдәбиятыбызның алтын фондына ук кермәс. Әсәрнең төп образы Сәгыйт тоныграк, таркаурак чыккан. Ихтимал, шуңадыр, безгә Сәгыйтнең үзеннән бигрәк аның уйлары якын. Әмма, ни генә булмасын, бу повесть безнең бүгенге көнебез өчен кирәк. Ул безне бүгенге тормыш атмосферасына алып керә, замандашларыбызның уй-фикерләре, борчулары белән таныштыра. Нигә яшереп маташырга: Сәгыйтне борчыган мәсьәләләр күбебезне борчый ич. Күпмедер дәрәҗәдә Сәгыйт уйлары безнең уйларыбыз да ич. Шуңа күрә, Фатих Хәснидән аермалы буларак, «Урталыкта» повестен мин файдалы әсәр дип саныйм, безнең һәммәбезгә гражданин булырга булыша торган әсәр дип бәялим. Ф. Хәсни, билгеле булганча, бик таләпчән, туры сүзле, усал телле тәнкыйтьче. А. Гыйләҗев иҗатына да ул зур таләпләр биеклегеннән торып якын килгән. Бу кадәресе аңлашыла. Әмма таләпчәнлек игътибарлы караш белән дә чиратлашса файдалырак булыр иде.

Шундый ук таләпчән бәягә һәм игътибарлы мөнәсәбәткә мохтаҗ авторларның тагын берсе Азат Ганиев булса кирәк. Матбугатта чыккан беренче хикәясе белән ук ул укучылар арасында төрле бәхәсләр, капма-каршы фикерләр уяткан иде. Аннан бирле яшь автор яңа повесть бастырды, бөтен бер җыентык чыгарды. Бәхәсләрнең исә тынар исәбе күренми. Бу аңлашыла да, А. Ганиевнең шундый чагы, иҗатта киеренке эзләнүләр алып барган чагы. Ул заманча геройлар, заманга хас стиль эзли. Шул ук вакытта үз шәхесен расларга, бәрәүгә дә ияреп китмәскә, беркемне дә кабатламаска тырыша. А. Ганиев иҗаты билгеле бер эзгә төшү, формалашу процессында.

Әйткәнемчә, автор заманча, заманга хас стильдә язарга ярата. Ул фикерен чәйнәп бирми, укучының көченә, эрудициясенә ышана. Кайбер нәрсәләрне юри мотивлаштырмый, аңлатып тормый. Шул ук вакытта аның әсәрләрендә шаблонга әйләнгән алымнар, артык традицион стильдә язылган эпизодлар очрый. А. Ганиев куе, романтик буяулар ярата. Шунда ук кырыс реализм ярылып ята. Язучы үз геройларын калку итеп, идеаллаштырып бирергә ярата. Аның геройлары шактый чудаграк, сәеррәк кешеләр итеп бирелəләр. Ләкин ул сәер кешеләр вакыты белән артык аек акыллыга әйләнәләр, бик конкрет, бик реаль эшләр белән шөгыльләнәләр. Хәзергә аның иҗатында төрле алымнар, төрле стильләр бергә аралашып яши. Шул нәрсә аның әсәрләренә шактый чуар бер төс бирә. Шулай да А. Ганиев әсәрләрендә шаблоннан бигрәк оригинальлек, искелектән бигрәк яңалык көчле, башкаларга ия-

рудән бигрәк үзенеке күп. Бу нәрсә авторның «Сүзсез җыр» исемле яңа повестенда да шактый ачык сизелә.

А. Ганиевнең бу әсәре күп яклары белән игътибарны җәлеп итә. Минем үземә повесть иң элек тыгызлыгы, җыйнаклыгы белән ошады. Композицион яктан ул шактый төзек, пөхтә эшләнгән. Безнең матбугатта бу әсәрдәге Габделхак образы турында төрле фикер булды. Аны эгоистлыкта, мактанчыклыкта гаепләүчеләр булды. Аның күңеле, җаны чиста түгел, диючеләр булды. Ләкин бер нәрсә бәхәссез: ул — кызыклы эшләнгән, тере, җанлы образ. Габделхак тормышта гади бер винтик булып калырга теләми. Ул үз урынын эзли, үз шәхесен расларга тырыша. Асылда ул тормыштагы кимчелекләр белән килешеп яши алмый торган тынгысыз кеше. Бу сыйфатлары өчен аны хөрмәт итми дә мөмкин түгел. Укучылар арасында иң нык ризасызлык уяткан нәрсә Габделхак белән Хәят арасындагы интим мөнәсәбәтләр булды. «Социалистик Татарстан» газетасында Ф. Мусинның әлеге повестька багышланган зур гына рецензиясе басылды. Ул анда Габделхак белән Хәят арасындагы интим хисләр мәсьәләсенә дә ачыклык кертә. Нигездә мин аның фикерләре белән килешәм.

1972 ел безнең прозага яңа бер автор алып килде. «Казан утлары»ның 12 санында Гөлшәһидәнең «Минем кала алуым» дигән повесте басылды. Яшермим, гаҗәпләнеп һәм сагаебрак, сәерсенеп һәм шикләнебрәк укый башлаган идем. Дөнья бу, төрлесен күрдек, күреп торабыз... Укыгач, сөенеп, җиңел сулап куйдым. Яшь авторның беренче әсәре матур чыккан. Алай да берьюлы ышанып җитмәдем әле. Тагын бер кат укып чыктым. Журналның шул ук санында басылган башка проза әсәрләре белән чагыштырып бактым, Ф. Хөсни, Б. Камалов кебек прозаикларның повестьлары янына куеп карадым. Юк икән, ялгышмаганмын икән.

Бик мактагач, сез инде дөньяда шушыннан да камил сәнгать әсәре юк икән дип уйлый күрмәгез. Сүз мәсьәләне принципта хәл итү турында бара. Сәнгать әсәреме ул? Әллә булмаса салкын, коры акыл җимеше генәме? Автор укучыга әйтер яңа сүзе булганга күрә каләмгә тотынганмы? Әллә, тукта, мин дә бер язып карыйм әле, дип кенә тотынганмы? Сүз әнә шул мәсьәләләрне ачыклау турында бара. Әй болай повестьта тәҗрибәсезлек тә җитәрлек, ышандырмаган урыннар, һәр яшь язучының беренче әсәрендә була торган башка төрле җитешсезлекләр дә шактый. Урыны-урыны белән Наҗия артык акыллы, тәҗрибәле кешегә әйләнеп китә. Аптырап ук куясың: бу соң әле кичә генә 8 классны бетергән сала кызымы?.. Вакыт-вакыт автор белән Наҗия икесе бер кешегә әйләнеп китәләр, аларны бер-берсеннән аерып булмый башлый. Наҗия авызыннан сибелгән афоризмнар, йомры-йомры сүзләр шуның галәмәте булса кирәк. Күңелдә тагын бу сала кызы бик җиңел алмыймы каланы дигән шик тә туа. Башка язучылар кебек, Гөлшәһидә дә бөтен нокталарны куеп бетерергә, барлык мәсьәләләрне ахыргача хәл итеп бетерергә ашыга. Нигә ашыгырга? Наҗия яшь кыз бит. Аңа әле яшисе дә яшисе. Калалар да берьюлы алынмый. Калалар бик авыр алына, гомер буе алына... Минем үземне профессор гаиләсенең бер авыл кызы өчен бу кадәр үлеп торуы да ышандырып җиткермәде. Тормышта андый кешеләр булмый дияргә җыенмыйм. Профессор гаиләсен начар итеп күрсәтергә дә кирәкми, калсын шул көе. Тик дәлилли, мотивлаштыра төшәргә иде. Бик тырышып эзләгән кеше әсәрдән башка төрле җитешсезлекләр дә табар. Хикмәт анда түгел. Кимчелекләреннән бигрәк, көчле, матур яклары белән игътибарны җәлеп итә повесть.

Иң элек повесть (бәлки повесть ук та түгелдер, хикәядер) ягымлы җылылыгы, самимилеге белән үзенә тарта. Әсәрнең үзәгендә — Наҗия язмышы. Ул Наҗия белән башлана, Наҗия белән бетә. Таралмый, чәчелми. Ул миңа җыйнаклыгы, пөхтәлеге белән ошады. Һәм барысыннан да бигрәк Наҗия үзе ошады. Аның, сарыклар төягән машинага утырып, беренче тапкыр авылдан чыгып китүләре матур сурәтләнгән. Аның шәһәр балалары янында югалып калмавы, тырышлыгы ошады. Ул булгач-булгач, барысы да шәһәрчә булсын инде дип, толымнарын кистереп атулары, гусар итекләре киеп алулары белән үзенә тартты. Язучы яшь кыз күңелендә мәхәббәт хисләре бөреләнеп килүен матур ачкан. Наҗия балаларча беркатлы булуы, самимилеге, эчкерсезлеге белән үзенә тарта. Наҗия оста язылган портреты белән хәтергә сеңеп кала. «Мин сирәк очрый торган экземпляр! Табигать миңа кап-кара чәч биргән дә аны ике толым итеп ак бантик белән үреп куйган. Маңгай астына ук зәпзәңгәр ике күз төрткән. Алай да аз тоелган табигатькә: минем битемә учлап кара

сипкел сипкән. Шуннан соң минем биттәге күз явыңны алырдай төсләрдән үзе үк курыкып калган, күз тияр бит моңар дип уйлаган һәм... бармак очы белән минем борыныма китереп баскан. Чөенке борынлы, сипкелле, күк әчү ташы кебек зәңгәр күзле, шомырт кара чәчле кыз бу озын чәчле ирнең ушын алды, ул миннән күзләрен алмый карый...» Шәп бит!

Нәҗия художник булырга хыяллана. Ул алырга тиешле иң зур кала — әнә шул. Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, әсәрдә рәсем сәнгате турында күп сөйләнә. Миңа калса, язучы рәсем сәнгатенә хас нечкәлекләрне, бу эшнең хасиятләрен әйбәт белә. Ул бу өлкәне ярыйсы ук нык өйрәнгән. Әйе, нәкъ менә өйрәнгән. Язучы үзе әйбәт белгән өлкә турында язса гына әсәр әйбәт чыга. Бу — бәхәссез хакыйкать. Әмма һәр язучы бары үзе белгәнне генә язып ятса, безнең әдәбиятның тематикасы нык тараер иде. Шуңа күрә алар үзләре белмәгәнне дә өйрәнергә тиеш булалар. Минемчә, бу әсәр тормышны махсус өйрәнеп язылган. Аның ышандыру көче әнә шуннан килә. Әсәрдә Нәҗия язган өч картина телгә алына. Авылын, анда калган әти-әниләрен сагынып, юксынып йөргән көннәрдә Нәҗия «Каен кызы» дигән картина тәмамлый. Икенчесе — Рөстәмгә ачу итеп кенә, аннан үч алу өчен генә ясалган «Автопортрет». Өченчесе — профессор Нурмөхәммәт абзыйсы. Без өч рәсемнең дә уңышлы чыкканлыгына шикләнмибез. Чөнки автор Нәҗия язган рәсемнәрне тасвирлау белән генә чикләнми. Ул Нәҗиянең әлеге картиналарны язган чактагы рухи халәтен дә бирә алган. А. Гыйләҗевнең Сәгыйте, гомумән, иҗат кешесе. Сәгыйть инженер булырга мөмкин, шул ук вакытта Сәгыйть язучы, артист яки композитор булырга да мөмкин. Гөлшәһидәнең Нәҗиясе бары рәссам, бары художник кына була ала.

Ниһаять, соңгы мәсьәлә. Әсәрнең ышандыру көче, эмоциональ тәэсир көче ахыр чиктә әсәрдәге автор образына, әсәрнең пафосына бәйләнгән. Без автор образы, авторның кайнарлыгы дигән нәрсәне онытабыз. Шуның аркасында бәяләребез бер яклырак булып чыга. Узган ел басылган роман-повестьларыбызга күз салыйк. Иң яхшыларын, эмоциональ тәэсир көче аеруча зур булганнарын аерып карыйк. Ул әсәрләрнең көче әлеге кайнарлыкка, пафоска да бәйле бит. Авторның карашлары, фикерләре нинди? Өлгергән карашлар, кызыклы фикерләрме алар? Автор үзе нинди кеше? Мөстәкыйль фикерле, өлгергән кешеме? Ахыр чиктә сәнгать әсәренең язмышын әнә шулар хәл итә. Гөлшәһидә повестенең уңышы да соңгы чиктә шуңа бәйле. Әсәрдә акыллы фикерле автор образы бар, аның тормышка мөнәсәбәте бар. Шулар булмаса, бер җылылык, самимилек белән генә әллә ни ерак китә алмас иде.

Бездә җылы, матур язылган әсәрләр күп очрый. «Казан утлары» журналының 5 санында Ф. Мансуровның «Яктытауда бүз тургайлар» исемле повесте басылды. Болай бик тә җылы, матур язылган әсәр. Кызыклы образлары бар, лирик җылылык белән сугарылган матур эпизодлар бар, укучыны тетрәтерлек аерым күренешләр бар. Шулай да, тулаем алганда, әсәр мине канәгатьләндереп җиткермәде. Әсәрдә авторның үзе сурәтләгән хәлләргә мөстәкыйль карашы сизелми. Бездә мондый характердагы әсәрләр байтак булды. Ф. Мансуров шулардан уздыра, аларга яңалык өсти алмаган. Һәрхәлдә, В. Нуруллинның «Шинельсез солдатлары»ннан соң Ф. Мансуровныкын яңа, оригиналь әсәр итеп кабул итүе кыен.

Өлкән буын прозаиклар иҗаты турында берничә сүз. Ифрат тырыш һәм эшчән, ифрат игелекле һәм озын гомерле булып чыкты безнең ул буыныбыз. Ярты гасыр буена диярлек алар татар совет прозасын үз кулларында тотып килделәр. Алар әдәбиятыбызны дистәләрчә романнар, йөзләрчә хикәя-повестьлар белән баеттылар. Ул әсәрләрнең байтагы әдәбиятыбызның алтын фондына керде. Халыкка күрсәткән зур хезмәтләре өчен, без алар алдында күп тапкырлар ихтирам белән башыбызны идек. Алар әле һаман да тынгысыз иҗат тормышы белән яшиләр.

1972 елда да өлкән буыныбыз күп һәм нәтиҗәле эшләде. Аларның яңа җыентыклары чыкты, газета-журналларда бик күп яңа әсәрләре басылды. Бер «Казан утлары» журналында гына да өлкән әдипләребезнең өч яңа повесте белән таныштык. Тормышчан һәм табигый булулары, ышандыру көченең зурлыгы ягыннан ул повестьлар безнең күп яшьләргә үрнәк булырлык.

Сүзне Мирсәй Әмирнең «Балыкчы ялганнары» исемле повестеннан башлыйсы килә. Мирсәй аганың бу повестен укучылар да, тәнкыйтьчеләр дә нигездә җылы каршылады. Аның нинди дә булса җитди кимчелекләрен күрсәтеп мәкалә язган кешене хәтерләмим. Андыйлар булмады шикелле. Киресенчә, җәмәгатьчелек тарафыннан ул кы-

зыклы һәм үзенчәлекле әсәр дип бәяләнде. Бу кадәресе бераүгә дә сер түгел.

Тик менә повестьның үзенчәлеге, әһәмияте һәм яңалыгы нәрсәдә? Аңа кайсы яктан якын килергә? Аңа ничек бәя бирергә? Мәсьәләнең кыен ягы шунда булды. Һәм бу мәсьәләдә инде һәркем үзенчәрәк фикер йөртте. Повестьның иҗтимагый әһәмиятен төрле кеше төрлечәрәк аңлатты. Берәүләр әсәрдәге җитди моментларны алгы планга чыгарырга, аңа шул яктан килеп бәя бирергә тырыштылар. Бу әсәрдә табигатьне саклау, табигатькә карата мәхәббәт тәрбияләү кебек мөһим мәсьәләләр күтәрелә, диделәр алар. Повестька гомуми бәя биргәндә, шул мәсьәләләрне игътибар үзәгенә куйдылар. Билгеле, күпмедер дәрәҗәдә алар да хаклы иде...

Минем өчен исә «Балыкчы ялганнары», барыннан да бигрәк, шаян повесть булуы белән игътибарга лаек әсәр булды. Аның төп кыйммәте, әһәмияте һәм үзенчәлеге өнә шунда иде. Шул ноктадан карап бәя биргәндә, «Балыкчы ялганнары» — әдәбиятыбызны баета, аның жанр чикләрен киңәйтә торган әсәр дип каралырга тиеш.

Бездә шаян әсәрләргә ихтыяҗ элек-электән зур иде. Бүген ул тагын да арта төште. Эш шунда ки, татар әдәбияты үскәннән-үсә бара. Язучылар саны күбәя, алар иҗат иткән әсәрләр саны елдан-ел арта бара. Кыскасы, без хәзер әдәби әсәрләргә зур байлык, муллык чорында яшибез. Һәммәбезгә мәгълүм: мул яшәгән, тамагы тук булган саен, адәм баласы ризык төрләндерергә ярата. Бу яктан якын килеп караганда, «Балыкчы ялганнары» күптән көтелгән тансык аш, нәкъ кирәк чагында, үз вакытында туган әсәр булды дияce килә.

Башта ук шул кадәресен дә әйтеп куярга кирәк, Мирсәй Әмир, тулаем алганда, яратып һәм мавыгып, рәхәтләнеп укырлык әсәр язган. Повестьта кызыклы ситуацияләр, көлкеле хәлләр күп. Бу яктан әсәрнең баштагы өлешләре аеруча отышлы чыккан. Повестьта бер тын алуда йотыла торган, бөтен дөньяны онытгыра торган бүлекчәләр бар. «Такыр башлы кеше», «Мөхәммәтша», «Иртәгә балыкка чыгасы көннең киче», «Иртәгә балыкка чыгасы кичнең төне», «Чистай сәгате һәм Тула самавары», «Хәтер төзәтү тарихы», «Сәгатьле чуртан» кебек бүлекчәләрне искә төшерик. Нихәтле шаянлык, күпме мәгънә аларда!

Әсәрдә көлә һәм көлдерә белә торган мәзәкчел кешеләр бар. Үтә заманча киенеп йөрергә ярата торган Латыйп карт үзе генә ни тора! Повестьның иң матур, иң шаян урыннары шушы карт белән бәйләнгән. Дөрес, урыны-урыны белән образның дәрәҗәсе шактый кими төшә. Әйтик, бер урында Латыйп карт тормыштагы вактөяк кимчелекләрдән зарланырга тотына («Нәрсә эчне пошыра?» дигән бүлекчә). Шул төшләрдә газета стиле көчәеп китә. «Балыкчы ялганнары»на мондый алым ятышмый, Латыйп картка бигрәк тә. Бу мәзәкчел картның бүгенге тормышта очрый торган кимчелекләргә реакциясе үзенчәрәк, Латыйпчарак булырга тиеш иде кебек.

Икенче бер урында: «Ул үзенең... хәтта берникадәр вакыт райком секретаре булып торуы турыларында да әйтте», дигән җөмлә бар. Латыйп картны элекке райком секретаре итәргә кирәкмәс иде кебек.

Беренчедән, бу — ышандырып җиткермн, Латыйп картның характерына, биографиясенә ятышмый. Икенчедән, бу нәрсәнең укучыларда кирәксез һәм урынсыз фикерләр уятуы мөмкин. Әмма ни генә булмасын, Латыйп образы — авторның зур уңышы. Әлеге образы белән М. Әмир татар совет әдәбиятындагы әдәби геройлар галереясен тагын да баета һәм төрләндерә төшкән.

Хәтердә калырлык, кызыклы образларның тагы берсе — «пошляк» Мөхәммәтша. Латыйп карт кебек ук, ул да ифрат сочный һәм колоритлы шәхес. Билгеле, әсәрдәге кызыклы образлар болар белән генә чикләнми. Оптимист Мәхмүтне алыгыз. Аның янына ата балыкчы Таҗины китереп куегыз. Андрюшиннарны, башка образларны искә төшерегез. Язучы аларның һәркайсын индивидуаль бер шәхес итеп бирергә тырышкан. Повестьтагы һәр образ диярлек уйламаган бер моментта ачылып китә, ниндидер бер ягы белән хәтердә кала. Шулай да Мөхәммәтша белән Латыйп картка җиткәне юк. Әсәрнең уңышын нигездә шул ике образ билгели.

Кайбер кешеләргә әлеге повестька кайчандыр басылган иске хикәянең килеп керүе ошамаган. Сүз М. Әмирнең «Склероз» исемле мәгълүм хикәясе турында бара. Мин аны яратып, бер дә сәерсенми укыдым. Беренчедән, әлеге хикәя үзе бик шәп, ничә кат укысаң да туйдыра торган түгел. Аннан соң ул әсәрнең гомуми тукымасыннан артып, бүселеп тормый. Аның повестьта сөйләнгән вакыйгаларга, андагы геройларга турыдан-туры катнашы бар. Автор аны әсәрдәге вакыйгаларга

бәйле белгән, повестька китереп кертүнең җаен, әмәлен тапкан.

Алда бер тапкыр әйткәнчә, «Балыкчы ялганнары» — ифрат кызыклы һәм үзенчәлекле әсәр, безнең әдәбиятны баета торган әсәр. Шулай да ул минем шаян әсәрләргә булган сусавымны, сусынымны канәгатьләндереп бетермәде. «Балыкчы ялганнары» бик матур башланып китә, чын шаян әсәр булып башлана. Аны мавыгып һәм яратып укырга тотынасың. Рәхәтләнеп көләсең, шатланасың. Әмма тора-бара әсәр сүрелә, сүлпәнәя төшә. Алай да өмет өзмисең әле. Һаман нидер көтәсең. Болай гына булмас, моның белән генә калмас, дисең. Көткән әйбер һаман килеп чыкмый, ул арада повесть бетеп тә китә.

Сәбәбе нәрсәдә? Матур башланган әсәр нигә сүрелә? Шаян повестьта нигә шаянлык бетә? Билгеле, моның сәбәпләре байтактыр. Һәммәсен дә ачыклап бетереп булмас. Шулай да әсәрнең сәнгатьчә бөтенлегенә зыян китергән бер сәбәпкә тукталмый үтеп булмый. Миңа калса, автор көлүнең көченә ышанып җитми. Югыйсә, аның шушы шаян әсәргә көчле-көчле җитди төс бирергә, җитди мәсьәләләр китереп кертергә тырышуын башкача ничек аңлатасың?! Иң элек ул үз тирәсеннән юморга бай кешеләрне куып бетерә. Алар урынына Азат, Фәнил кебек күңелсез кешеләр җыелып кала. Бер килеп кергәч, автор аларны ахырга кадәр сөйрәп барырга тиеш була. Әлеге күңелсез геройлар шаян повестька күңелсез вакыйгалар алып керәләр. Шул рәвешчә, повестьның көлечлеге, төп яңгырашы сүрелә төшә, әсәрнең тәэсир көче шактый кими. Кем ничек уйлыйдыр, мин «Балыкчы ялганнары»ның авторы көлүнең җитди нәрсә булуына ышанып җитми, ахырга кадәр матур итеп «ялганлый» белми, әсәрнең тәэсир көчен шул нәрсә киметкән дип саныйм.

Ф. Хөснинең ел саен яңа повесть бирми калганы юк дияргә була. Кайбер елларны хәтта бер белән генә чикләнеп калмый. Шуңа күрә «Без яшь идек» дигән яңа повесте дә гадәти бер күренеш буларак каршы алынды. Берни язмый, бер повесть та чыгармый калса, гаҗәпләнер идек.

Бу повесть әйтелми калган мәхәббәт турында. Әйе, мәхәббәт хисләре әйтелми калган... Бер-берсеннән оялганга гына түгел, әлбәттә. Моның зуррак, тирәнрәк сәбәпләре булган. Авыр сугыш еллары. Яңа гына 10 ны бетергән кызны ерак бер авылга эшкә җибәрәләр. Укытучы итеп. Бара, урнаша, эшли башлый кыз. Шунда моңа 10 класста укый торган бер егет гашыйк була. Фоат исемле. Кыз да егеткә битараф түгел. Тик ярамый. Берсе укытучы, берсе укучы. Бер елдан мәсьәлә җиңеләя төшә. Егет, унны бетереп, колхозда эшли башлый. Ул арада Миңлегөлнең хәлләре катлауланып китә. Кызыбыз авырып китә. Миңлегөл тазарып кайтуга Фоатның хәлләре катлауланып китә. Чираттагы бер тилелеге өчен егетне комсомолдан чыгаралар. Шул чагында кыз авызына су кабып утыра, яклап чыкмый. Шуңа ачу итеп, Фоат читкә китеп бара. Мәхәббәт әйтелмәгән килеш кала. Әсәрнең кыскача эчтәлеге әнә шундый.

Ф. Хөснинең һәр әсәре кебек үк, бу повесть та җиңел һәм мавыгып укыла. «Без яшь идек» повесте матур язылган бик күп урыннары белән истә кала. 10 класс малайлары белән Миңлегөл арасында булган маҗаралар аеруча колоритлы, аеруча шәп чыккан. Образлардан Фоат ныграк истә кала. Үзенчәлекле характеры, кылган гамәлләре, кызыклы эшләре белән истә кала. Туры сүзле, принципиаль егет булуы белән үзенә тарта. Тик шунысы бераз эчне пошыра. Ул Ф. Хөсни өчен бик үк яңа образ түгел инде. Фоатның шәҗәрәсе Айдарларга, Сафәргалиләргә барып тоташа. Тилелеге дә, дуамаллыгы да, чуар йөрәкле булуы да шулардан үк килә.

Болай Миңлегөл дә ярыйсы гына образ. Әсәрнең баштагы бүлекләре буенча, ул бик мөлаем, бик сөйкемле бер кыз булып күз алдына килә. Ахырга таба Миңлегөлнең әнә шул мөлаемлыгы, самимилеге югала төшә. Аннан соң әсәрнең Миңлегөл белән бәйләнешле бүлекләрендә дәлилләнеп җитмәгән, ышандырып бетерми торган урыннары бар.

Менә ул мәктәпкә килә. Аңа ничек тә укучыларны үз кулына алырга кирәк. Ничек итеп кулга ала, диярсез. Ифрат җиңел итеп: чыга каршыларына, сугыш турында, сугыш китергән авырлыклар турында сөйли һәм сорый:

— Сүз бирәсезме тырышып укырга? Юкса, кайтып китәм,— ди.

Балалар бер авыздан:

— Укыйбыз, тырышабыз, китмә, апа!— дип кычкыралар.

Шуңа ышанып, кыз укытучы булып кала. Соң бу вәгъдәләрен алар икенче дәрестә үк онытачаклар бит... Минем үземне эт тешләү белән бәйләнгән маҗаралар да ышандырып бетермәде. Бер башлагач,

шул шигемне дә әйтим: Фоат Айдарлардан килсә, Миңлегөл сызыгы Фатих абыйның соңгы елларда язган әсәрләреннән, «Язмыш шуклыгы» кебек әсәрләреннән башлана сыман. Начармы бу, әллә мактылырга, хупланырга тиешле сыйфатмы? Билгеле, бер типтагы образлар кулланган, бер характердагырак мәсьәләләр күтәргән өчен генә язучыны гаепләп булмый. Язучы иҗатындагы кабатланган мәсьәлә һәм образларның тенденциясе нинди? Әсәрдән-әсәргә үсә, көчәя, тирәнәя баралармы алар? Әллә, кимүгә, сүрелүгә йөз тотып, кирегә тәгәриләрме? Бөтен хикмәт әнә шунда. Үсә, тирәнәя барганда, моның өчен язучыны мактарга кирәк. Түбәнгә, кирегә киткәндә — тәнкыйтьләргә. Кызганычка каршы, Ф. Хөсни повесте соңгы төргә керә.

Әлбәттә, «Без яшь идек» повесте беренче башлап язучы прозаик тарафыннан язылган булса, мин аңа бу кадәр каты бәрелмәс идем, хәтта мактар идем. Теләсә кайсы башлап язучы мондый әсәр белән мактана, горурлана алыр иде. Әмма Фатих Хөсни өчен «Без яшь идек» мактанырлык та, горурланырлык та әсәр түгел.

«Казан утлары» журналының 9 санында Ә. Еникинең «Без дә солдатлар идек» дип исемләнгән яңа әсәре басылды. Жанры анык түгел. Бары «Фронт дәфтәреннән» дип кенә куелган. Әсәр белән танышкач, шул нәрсә ачыклана: ул гадәти истәлек кенә түгел, очерк та түгел. Ул — чын әдәби әсәр, чын сәнгать әсәре, билгеле. Стиле, язылу рәвеше ягыннан — истәлекләргә тартым повесть. Бәлки повесть-истәлек дип куярга кирәк булгандыр.

Каравыл хезмәтендәге солдатлар турында бу әсәр. Шуңа күрә повестьның геройлары да сугышның алгы сызыгында, ут эчендә сугышучы солдатлар түгел. Алар барысы да нестроевойлар, алгы сызыкта сугышырга ярамый торган солдатлар. Алар арасында күпме фронтта йөреп бер мәртәбә мылтык атып карамаган кешеләр бар. Алар арасында, шулай ук алгы сызыкта булып, сугыш эченнән шактый өтеләп чыккан кешеләр дә бар. Боларны каты яраланып, госпитальләрдә ятканнан соң, нестроевой булып, кирә фронтка кайткан солдатлар. Хәзер әнә гади генә, шапырынмый гына үз эшләрен башкарып, солдат хезмәтен үтәп яталар. Язучы безне шул солдатларның тормышы белән, алар башыннан узган вакыйгалар, кызыклы эпизодлар белән таныштыра. Вакыйгаларның төрлесе: кечкенәләре, зурлары бар. Күләмнәре нинди булуга карамастан, аларның һәркайсы мәгънәле, һәркайсы гыйбрәтле. Вакыйгалар безне әсәрдәге образлар белән таныштыра, вакыйгалар барышында аларның характерлары, гадәт-холыклары ачыла. Вакыйгалар да, ул вакыйгаларда катнашучы кешеләр дә Ә. Еникигә хас пөхтәлек һәм төгәллек белән эшләнгән. Язучы төрле милләт кешеләренең истә калырлык образларын тудыра алган. Бу яктан авторга тел-теш тидерерлек түгел. Шул ук вакытта без аның «Саз чәчәге», «Рәшә», «Әйтелмәгән васыять», «Вөҗдан» кебек әсәрләр белән янәшә торырлык булмавын да әйтми кала алмыйбыз.

Менә без өч өлкән әдибебезнең өч әсәрен карап уздык. Өчесе өч төрле, өчесе өч характердагы әсәр. Ләкин аларга кайбер уртак сыйфатлар да хас шикелле. Бу әсәрләрнең берсендә дә бүгенге тормышның беренче чираттагы мәсьәләләре күтәрелә дип булмый. Моның өчен мин аларны гаепләргә җыенмыйм. Шулай да дереслекне әйтеп китәргә кирәк. Бу повестьларның өчесе дә әлеге әдипләребезнең алдагы әсәрләреннән кайтыш, йомшаграк. Боларның күләгәсе «Агыйдел» һәм «Саф күңел»ләргә, «Йөзек кашы» һәм «Җәяүле кеше сукмагы»на, «Саз чәчәге» һәм «Әйтелмәгән васыять»ләргә төшмәсме икән? Бу әсәрләрнең күләгәсе әлеге язучыларыбызның данына, популярлыгына зыян китермәсме икән? Мине мәсьәләнең әнә шул яклары борчый. Аннан соң, өлкән әдипләребез һаман элекке запаска ышанып яталар шикелле. Тәэсоратларны, материалны яңарта төшсәләр дә начар булмас иде. Мөмкинлекләре, вакытлары җитәрлек. Талантлары чәчрәп тора, тәҗрибәләре хәттин ашкан. Аларга әле иҗади киеренкелекне киметергә, тынычланып калырга иртәрәк дип уйлыйм...

Узган әдәби ел безгә кызыклы романнар, кызыклы повестьлар алып килде. 1972 ел безнең прозага кызыклы яңа авторлар алып килде. Әдәбиятта яңа буын үсеп житте. Алда бер тапкыр әйтелгәнчә, алар безнең прозаны йөз белән заман темасына бордылар. Бу — безнең прозаның иң көчле ягы. Алар әдәбиятка күп кенә яңа темалар, яңа мәсьәләләр алып килделәр. Прозаның горизонтлары тагын да киңәя төште. Әдәби сурәтләү чараларыбыз да байый, төрләнә төште. Алар безнең прозаны күп кенә кызыклы образлар белән баеттылар. Замандаш образын, бүгенге көн

героен иҗат итү юлында телгә алып сөйләрлек уңышларыбыз бар.

Булган кадәр уңышларыбызны, эшләгән эшләребезне бездән беркем дә тартып ала алмас. Игътибарны алда торган бурычларга, хәл ителмәгән мәсьәләләргә юнәлтик. Без әле зур сәфәргә чыктык кына. Алда — без узасы юллар, без күтәреләсе үрләр, без яуларга тиеш биеклекләр күп. Ярты юлда тукталып калмас өчен, күп кенә мәсьәләләрне бүген үк сөйләшеп, бүген үк хәл итеп китәргә кирәк. Мин, 1972 ел безнең прозага күп кенә кызыклы образлар алып килде, дидем. Чыннан да, узган ел чыккан проза әсәрләрендә зур идеаллар, зур максатлар белән яши торган байтак образлар бар. Әмма олы характер дәрәҗәсенә күтәрелгәннәре, тарихка кереп калырлыклары күп түгел.

Сәнгать өлкәсендә гел шулай, бер кимчелек икенчесенә бәйләнгән, бер җитешсезлек икенче җитешсезлекне китереп чыгара. Олы характерларның аз булуы, үз чиратында, олы, зур конфликтларның азлыгына бәйләнгән. Заманнар узу белән безнең әдәбияттагы конфликтлар да, ул конфликтларның характеры да үзгәрә барды. 30 еллар әдәбиятының нигезендә сыйнфый көрәш ята иде, ул чордагы конфликтларның характерын сыйнфый көрәш билгеләде. Бөек Ватан сугышы темасы безнең прозаны бик күп әсәрләр белән баетты. Ул әсәрләр конфликтларының зурлыгы, көче белән аерылып торалар. 50 еллар ахырында, 60 еллар башында күп кенә кызыклы әсәрләр язылды. Бүгенге проза өчен, йөз белән заман темасына борылган проза өчен, ул конфликтларның күбесе искерде. Новатор эшче белән консерватор завод директоры, бюрократ җитәкче белән масса арасындагы конфликтлар да йөри-йөри шомарып, шаблонга әйләнеп бетте.

Бүген роман-повестьларыбыздагы конфликтлар тагын вагаеп, сыегаеп бара. Бер гаилә эчендәге конфликтлар, аерым шәхес күңелендә барган конфликтлар күбәеп китте. Чорга хас конфликтлар табу, бүгенге кендәге үсешебезне тоткарлый торган кимчелекләрне ачу, бүгенге заманга хас каршылыкларны күрсәтү — прозаиклар алдында шундый бурыч тора.

Архитектоника мәсьәләләре, сюжет-композиция төзү мәсьәләләре безнә һаман борчып килә. Без яңадан бәхетле тәмамланыш полосасына әйләнеп кайттык. Нокталарны үз урынына куеп, бөтен мәсьәләләрне ахырга кадәр тәмам хәл итеп бетерү гомуми күренешкә әйләнеп бара.

Жанрлар өлкәсендә аныклык җитми. Романны повестьтан, повестьны хикәядән аерып булмый башлады. Бу бигрәк тә повестьларга карый. Повесть жанры сыегайды, вакланды. Күтәргән мәсьәләләрнең күләме һәм җитдилеге, образларының эшләнеше ягыннан якын килеп караганда, узган ел басылган әсәрләрнең байтагы чын повесть булып җитмәгән. Жанрның шуннан да түбән төшүенә, арзанаюына юл куярга ярамый.

Кыскасы, безнең алга хәзер бөтен зурлыгы, бөтен җитдилеге белән әдәби осталык мәсьәләләре килеп баса. Халкыбыз бик нык үсте, бик нык күтәрелде. Әдәбиятны нечкәләп, тирәнтен аңлый белә торган укучы үсеп җитте. Әнә шул үскән, күтәрелгән укучыга, бөек эшләр башкаручы халкыбызга лаеклы әсәрләр тудырыйк! Бүгенге көннең төп лозунгысы менә шундый булырга тиеш.

Инде совет әдәбиятының бөтен дөнья күләмендәге зур миссиясен дә истә тотып фикер йөртсәк, әдәби осталык мәсьәләләренә тагын да җитдирәк игътибар бирелергә тиешлеген күрербез. Бүгенге буржуаз сәнгать, буржуаз әдәбият турында без әле һаман да искечәрәк фикер йөртәбез. Имеш, аларда модернизм көчле, имеш, аларда абстракционизм сәнгате генә. Модернизм да, абстракционизм да буржуаз сәнгатенең үткән этабына әйләнеп бара. Бу юл белән массаларга тиешле йогынты ясый алмаячакларына алар, ниһаять, төшенеп киләләр. Бүгенге буржуаз сәнгать башка нәрсәләргә йөз тота: секска, парнографиягә, төчелеккә, мелодраматизмга, арзанлы күз яшьләренә. Бүгенге буржуаз дөнья хезмәт ияләренең игътибарын чорның, заманның актуаль мәсьәләләреннән читкә алып китә торган сәнгатькә, массовый әдәбиятка, массовый сәнгатькә йөз тота. Аларның бу тенденциясенә җавап төсендә, без үз әдәбиятыбызның сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәсен тагын да үстерә, әдәбиятның иҗтимагый ролен тагын да күтәрә барырга тиешбез. Сыйнфый дошманнарыбыз совет әдәбиятының, социалистик реализм методының мөмкинлекләрен шик астына куярга азапланалар. Язучыларның төп бурычы — дөнья аренасына чыгарлык сәнгать әсәрләре иҗат итү. Сыйнфый дошманнарыбызның яла сүзенә иң көчле җавап әнә шул булыр!

# ШИГЪРИЯТ ҮРЛӘРЕ

Мәскәүнең «Советская Россия» нәшрияты Максим Горький исемендәге премия лауреатлары сериясендә С. Хәкимнең соңгы елларда язылган шигырьләре җыентыгын басып чыгарды [1]. Китап рус телендә чыкса да, бу юлы тәрҗемәләрнең сыйфатына тукталып тормаска булдым — анысы үзенә башка бер тема. Җыентыкның эчтәлеге бераз чикләнгән, алда әйтелгәнчә, аңа нигездә авторның соңгы елларда иҗат иткән әсәрләре тупланган. Шуңа күрә шагыйрьнең иҗат үзенчәлекләре турында сүз йөрткәндә, аның бу җыентыгына кермәгән әсәрләренә игътибар итү дә зыянлы булмастыр. С. Хәкимнең иҗат йөзен тулырак чагылдыру максаты куелган очракта җыентыкта, әйтик, «Дуга» поэмасы һичшиксез булырга тиеш иде. Сүзне нәкъ шушы «Дуга» поэмасыннан башлыйсы килә дә.

С. Хәким — үзенең поэтик үрен тапкан, шул үргә менеп-күтәрелеп җиткән шагыйрь; бүгенге көнне ил мәйданында хикмәтле сүзнең тулы көченә ат уйнатучы шагыйрь. Аның иҗатта зур ачышлар ясар чагы, бер татар поэзиясен генә түгел, ә бәлки совет поэзиясен яңадан-яңа казанышлар белән баетачак вакыты. «Дуга» поэмасында шагыйрь чирек гасыр элек үз взводы белән ут сызыгында торган бер үргә килә. Бу — аның айлар буе җир казып, ныгытмалар корган, разведкага йөргән үре. Шагыйрь бүген аннан, тирән дулкынлану белән, кайчандыр үзе утка кергән җирләргә — Ерик суы буендагы колхоз басуларына, аның эскертләренә, кибәннәренә карый. Биредәге карт имәннәр аңар үз взводының сирәгәеп калган солдатлары кебек тоелып куя...

Ләкин поэмада бу үр аерым бер хәрби частьның уңайлы сугышчан позициясе булып кына калмый, шагыйрь аны бөек тарихи бәрелешнең чын-чыннан югары бер биеклегенә әверелдереп җибәрә, бу үрдән лирик геройның күзе бик еракларга кадәр ачылып китә, шагыйрь югары, зур шигъри гомумиләштерүләргә ирешә.

Бу үрдә шагыйрь (лирик герой) элегрәк үзе катнашкан Ржев сугышларын күңеленнән кичерә (тимер чыбыкка шинель ташлап, атакага барулары, кардан носилка сөйрәүче Сарбайлар...). Менә лирик герой элекке сугышчан дуслары Низамнар, Киекбай, Степан Бурмаклар белән кабат Курск дугасының дәһшәтле көннәренә күчә, шушы ук үрдән аңар утлы Дуганың атаклы Прохоровкасы, Белгород яклары күренә... Дуслар яңадан ут эчендә (Бурмак үзе шушы як кешесе: «Туып үскән нигезе, йорты монда. Тик утлары янмый йортының...» Үзе ул, әнә ике иптәше белән дошман тылыннан «тел» алып чыга: «Без кетәбез шомлы имәнлектә, без көтәбез тын да алмыйча, кыр яңгырый, кырда кинәт шартлау: мендә берсе мина естенә... Аяк тавышы... Якынлаша тавыш: «Бире китер, бире естерә...» «Ракеталар яктысында алар Төнлә кырда кулдан ычкынган Арысланнар сыман күренделәр...»). Дугадагы бөек бәрелешкә Сталинград батырлары килеп кушыла... Яу бәрелеш күренешләре дә поэмада шушы ук үрдән торып сурәтләнә.

Шушы ук үрдән шагыйрь күзенә илнең, халыкның ерак чорлардагы узганнары, халык язмышының кырыс борылышлары да ачылып китә... Аксак Тимер көлгә әйләндергән Болгар, озын толымлы болгар кызы шагыйрьнең күз алдына килә. Шагыйрь күрү белән генә чикләнә алмый, үткәндәге фаҗигаләрне дә бар йөрәге белән кичерә (Болгарның «яңа уты яна күкрәгемдә...») һәм үзенең лирик герое белән, сугышчан дуслары белән бергә «Болгар өчен,

[1] Сибгат Хаким. Стихи последних лет. Рус телендә. «Советская Россия» нәшрияты. 1973 ел.

Казан, Орел өчен» утка керә. Яу кырына Болгар чоры шагыйре «мәһабат, горур сынлы» Кол Гали үзе килеп чыга («Безнең тарих — сезнең кулда,— ди...»)... Менә шушындый югары үрләре бар шагыйрьнең. Ватан ул — халкыңның, илеңнең үткәннәре, бүгенгесе, киләчәге дә, халкыңның иң кадерле рухи байлыклары: аның революцион традицияләре һәм синең үзеңнең шушы Ватаның өчен, аның якты киләчәге өчен көрәшең, хезмәтең, иҗатың да икән... Барсы бер икән. Минемчә, Сибгат Хәкимнең барлык иҗатын менә шушы югары шигърияте, тирән хикмәтле олы бер инану берләштерә дә.

Шуңа күрәдер, шагыйрь ни турында язмасын — камыл кыштырдавымы, үз чытырманындагы чыпчык турындамы, Тукай турындамы, Европага «Дуслык» юлы сузучы Халидәләр турындамы, Бах музыкасы, Җәлил шәһәре, бүгенге Казан, бүгенге республикабыз турындамы — барсы да дулкынландыргыч һәм актуаль яңгырый, барсы да туган җир, Ватан һәм ватандашлар хакында, илләр, халыклар, киләчәк хакында, барсы да олы кайнар бер күңел белән җылытылган булып чыга.

«Васыятьләр»дә түшәктәге ана янына Казан артының атаклы әкиятчесе мәрхүм Әхмәтҗанның шәүләсе килә — базар халкын, болын халкын авызына каратып торар бер ярлы («Туган тел — аның бар байлыгы...»). Колакчын бүректән, шинельдән коммунист Шәйдулла шәүләсе килеп чыга — беренче колхоз оештыручылардан, сугышта ятып калган ир. Онытын җитәкләп, бүгенгә колхозның тракторларын, атларын саный килә, күп Шәйдуллаларның берсе...

Хозыр Ильястай Әхмәтҗаннары булган туган тел дә, халыкның Шәйдуллалары җитәкләгән бөек эшләре дә, ана кешенең изге теләкләре белән бергә, безгә васыять итеп тапшырылган. Бу васыятьләр егерме икенче елларда, Ленинга тәүлегенә унар гына минут эшләргә рөхсәт бирелгән декабрь көннәрендә, юлбашчының илгә васыять итеп язылган соңгы хезмәтләреннән аерылгысыз:

Калыкты ул васыять халыкның
Үзеннән, йөрәге түреннән.
Васыятьтә ил, дәүләт, киләчәк.
Васыятькә барлыгы — ун минут.
Уйлыйм да кабынам, шигъремә
Менә бит кайлардан үрли ут.
Көненә ун минут... Ун минут
Дөньяны ул ничек киңәйткән:
Калыкты алыплар шикелле
Түбәннән — хөр, азат милләтләр.
Васыятьтә язмышы...

Шул изге васыять хакына гомереңне кызганма, кыл барын,— ди шагыйрь. «Васыятьләр» поэмасы — үзе бер югары поэтик үр.

С. Хәкимнең Ленин темасына язганнары, тукта әле, бу темада да каләм сынап карыйм әле, дигән кебек, очраклы рәвештә генә язылган әсәрләр түгел. Киресенчә, аның иҗатында Ленин — татар халкының язмышын, башка милләтләр язмышын, бөек ил язмышын, дөнья язмышын революцион яңартып җибәрүче югары поэтик образ. Ленин темасы аның иҗатына нәкъ халык язмышы турында уйланулардан килеп кергән дә. Иң олы, иң кадерле, иң югары тема булып килеп кергән. С. Хәким иҗатында Ленин темасы — ул үрләр үре. Бу үрләр булмаса, аның бүтән шигъри үрләре дә бу кадәр үк биек һәм мәгънәле булып җитә алмаслар иде кебек. Шагыйрь нәкъ менә шуңа күрә Бәһави, Хисами солдатлар көрәшенең олы мәгънәсен, Җәлилләр, Фучиклар, Вапцаровлар батырлыгының чорга лаек бөеклеген, бүгенге эшләребезнең олылыгын шулай үткен күрә, шулай дулкынландыргыч ачык итеп сурәтли ала. Нәкъ шушы үрләр үреннән торып фикер йөрткәнгә күрә аның ерак үткәннәргә карашы тарихи һәм поэтик дөрес концепциягә ятыша да.

Ялган пафосның мәңгелек дошманы булган С. Хәким Ленин темасы өчен үзенә башка интонация, аерым бер тантаналылык, күтәренкелек, үзенчә бер төрле пафос уйлап чыгаруны кирәксенми. Шул ук тыенкы, тирән һәм нечкә хис, шул ук әкрен, ләкин эчкерсез әйтелә торган сүз. С. Хәкимнең безгә гомер буе таныш үз интонациясе, тирән уйлы, хак сүзле, гади, ышандыргыч шигыре. Шул ук тормышчан, гади сурәтләр, Сибгат Хәким нәкъ үзе.

Бирәдә дә ул тормыш чынлыгына таяна, чын тормышта булганны ил язмышы белән, бөек революцион көрәш белән бәрлектә алып, югары поэзия дәрәҗәсенә күтәрә. «Бәһави моңы»нда автор моны алдан ук әйтеп куя: «Бу җырны мин уйлап чыгармадым, шул көенчә алдым тарихтан»,— ди. Хисами да чын Казан арты татары: Арыс дигән авылы бар, урман буе комлыкта үскән вак арышлары бар... Ибраһим Йосфи дисәң, ул — легендага күчкән татар улы... Һәр әсәренең нигезе тормышның үзендә, тарихта. Хикмәт тик бер генә: шагыйрь яза бу әсәрләрне, ил йөзенә күрсәтерлек итеп яза. Нык уйланып, барсын да күңеленнән нык кичереп яза.

С. Хәким иҗат иткән Ленин образының кабатланмас бер үзенчәлеге бар — ул чын татар шагыйре иҗат иткән образ. Ильич күңелендә гомере буе бала чагы яши: Кокушкиносы, «ачык йөзле» Апакае, түбәтәйле, чыбыркылы, ялан аяк Бәһавилары белән... Себердә, Шушенскоеда Ленин янына татарча тыйнаклыгы белән «әкрен генә, кыяр-кыймыйча» Бәһавиның моңы килеп керә. («Сары, сары, сап-сары...») Тәрмәләрдән тәрмәләргә, илдән илгә күчә-күчә, авыр көрәш алып барганда, Ленин күңелендә Марсельезалар белән бергә, татар моңы да яңгырый. Ил мәйданында барган бөек революцион көрәштә Арсен Амирян, Степан Шаумяннар, Азизбеков, Гинцбурглар арасында татарның Ибраһим Йосфилары, Мулланурлары, Бәһавилары, Хисами солдатлары да була... Ленин татар хезмәт ияләрен дә революциягә күтәргән, хөрриятькә, яктылыкка чыгарган, ул Казанлы, Тукайлы республиканың да киләчәген кайгырткан. Шуның өстәвенә яшь Ульяновның хезмәт халкы турында уйланган беренче тавы — безнең Казанда; Ленинның Кокушкинодагы музей-йортында татар кызы эшли... Ленинның мондый образын чыннан да тик татар шагыйре иҗат итә алыр иде.

Кызык, нәкъ Ибраһим Йосфилар, Хисамиларның Ленин фәрманы белән Совет власте өчен утка ташланганын сурәтләгәндә генә шагыйрь иҗатында моңарчы булмаган бер героик интонация яңгырап туа. Ат өстендә атакага барганда кылыч чабып бару ритмы ишетелә... Уйлап карасаң, бу бит — «Сак-Сок бәете» үлчәве ләбаса! Менә шигырьнең чын рухы үлчәүләрне нишләтә...

С. Хәким иҗатының интернациональ рухы да аның шушы үзәк темасыннан килә. Мари карты Филипп белән татарның Хәйрулласы бергә сал куган, бергә баткан, берберсен үлемнән коткарган; фашист явына каршы татарның Низамие рус Степан Бурмаклар, кыргыз Киекбайлар белән бергә сугыша; Бах музыкасының ике Германия чикләрен таратуын шагыйрь үткен сизә, Бахның зур рухына гашыйк икенлеген яшерми, Веймарда, Гете йортында, үзебезнең Тукайны онытмый... Шагыйрьнең бүгенге киеренке дөнья турында уйлангандагы борчылуы татарлар хакында гына түгел...

Сибгат Хәкимнең поэтик стиле турында иркенләп, җәелеп бер сөйләшергә булыр иде. Тел чаралары, тасвирлау, сурәтләү үзенчәлекләре турында. Бирдә шуны гына әйтеп узасы килә: шагыйрьнең барлык иҗаты — рухы белән дә, стиле белән дә — чын халыкчан, тормышчан. Киң, ачык карашлы партияле иҗат.

Экстрамодный шигырьчеләрнең мең газап белән уйлап чыгарып, тартып китергән ярым-йорты охшатырулары, ятышыр-ятышмас чагыштырулары С. Хәкимдә юк, исе-әсәре дә юк. Мода куучыларга тормыш чынлыгы, тормышчан идеяләр кадерле түгел—җилбәзәк бер-ике күңелне бер тапкыр шаккатырса, аларга гомер буе мактанырга шул җиткән! Сибгат Хәкимгә тормыш үзе кадерле. Бар көенчә, чын көенчә. Изге көрәшләре, олы эшләре белән. Аның образлары, сурәтләре, буяулары менә шуннан килә. Тормышның үзеннән алар, колакны ертмыйча, күзгә төртелмичә генә киләләр.

Шагыйрь җиде бабасы якларына искелек дип кул селти торганнардан түгел. Ул — крестьян баласы. Нәсел очы — межачы Мәмкә. Мәмкә елгасы да бар — җир бүлгәндә — чылбыр өстенә ятып елаган җире. Шагыйрьнең җыры да — шул буынбуыннардан сузыла килгән авыр чылбыр... Туган туфрак кадерле. Бераү, аты үлгәч, кыр өстенә ятып елаган да, аты белән бергә, йөгәне, камыты белән бергә, йөрәген дә күмгән... Мин шул йөрәктән өзелеп төшкәнмен, ди шагыйрь («Крестьян йөрәге».) Аның сугыштан тол калган Миңлебикәсе сабан туйларында арттан килгән атка нәзер әйтеп сөлге бәйли. Үзенең Назиры соңлап булса да кайтсынга юрап... («Нәзер аты».)

Үткәзеп әйтү — халыкчанлык сыйфаты. Моның мисаллары С. Хәкимдә — әсәр саен. Мондый образларга ышанмый мөмкин түгел, болай язылган әсәрләрне күңелгә алмый мөмкин түгел.

Бармы соң С. Хәким әсәрләренең кимчелекле яклары? Минемчә, бар. Әйтик, миңа аның кайбер юлларындагы сүз әйләнмәләре авыр кебек тоела. Җөмләдә аерым сүзләрнең урынын алмаштырып куюы укуны, аңлауны авырайта шикелле. Ләкин бу — зәвыкка караган ваклык, мисаллары да бик сирәк.

С. Хәким әсәрләренең ил мәйданына чыгуы татар поэзиясе йөзенә кызыллык китерәсе түгел. Шагыйрьнең, никадәр күбрәк иҗат итсә, поэзиябезне шул кадәр баетасы, күтәрәсе дәвере.

**Мәҗит РӘФЫЙКОВ.**

# РЕВОЛЮЦИЯ ТАРИХЫНА ЯҢА СӘХИФӘ

Бөек Октябрь революциясенә багышланган һәрбер яңа китапны без зур кызыксыну белән каршы алабыз. Соңгы елларда Казан тарихчыларыннан М. Мөхәррәмов, Р, Нәфиков, И. Ионенко, А. Борһанов, И. Таһировларның Октябрь турындагы фәнни хезмәтләрен укыган идек. Әле күптән түгел Казан дәүләт университеты нәшрияты «Урта Идел буенда революцион хәрәкәт» дигән тагын бер китап бастырып чыгарды.

Тарих фәннәре кандидаты Рәмзи Вәлиевнең бу хезмәте 1917 елның июль һәм октябрь айларында Урта Идел буендагы революцион хәрәкәтне өйрәнүгә, бу хәрәкәтнең моңарчы галимнәр күзе төшмәгән кайбер урыннарын ачыклауга багышланган.

Китап кереш сүздән һәм зур булмаган 3 бүлектән тора. Укучыларга берникадәр мәгълүмат бирү өчен, кыскача гына ул бүлекләр белән танышып чыгыйк.

Менә китапның беренче бүлеге. Ул «Большевикларның халык массаларын социалистик революциягә мобилизацияләү буенча эшчәнлеге» дип исемләнгән. Автор әлеге мәсьәләне берничә өлешкә бүлеп карый. Башта ул партиянең VI съезды яктылыгында Урта Идел буендагы хәлне, анда Советларны большевиклаштыру өчен барган көрәшне яктырта. Р. Вәлиев үзенең игътибарын нигездә Урта Идел буендагы зуррак шәһәрләргә — Казан, Самара, Саратов, Сызраньга һәм алардагы большевиклар оешмаларының эшчәнлегенә юнәлтә. Авторның күрсәтүе буенча, бу вакытка большевикларның Казан оешмасында 650 кеше була һәм алар, Вакытлы хөкүмәтнең кулга алуларына, төрле провокацияләренә дә карамастан, массалар арасында зур эш алып баралар. Автор үз хезмәтендә «Рабочий», «Кызыл байрак» газеталарында ул елларда басылган мәкаләләрдән дә өзекләр китерә.

Бу бүлектә большевикларның Казан оешмасында яшьләр арасындагы эшнең дә нык җанланганлыгы әйтелә. 11 августта, мәсәлән, Казанда эшче яшьләрнең социалистик союзы төзелә һәм ул массаларны оештыру буенча зур эшчәнлек җәелдерә.

Беренче бүлектә тикшерелә торган икенче бер әһәмиятле мәсьәлә — ул фабрика-завод комитетлары, профсоюз оешмалары һәм заводларда урнаштырылган эшчеләр контроле турындагы мәсьәлә.

Р. Вәлиевнең раславынча, Урта Идел буенда эшчеләрнең югарыда саналган оешмалары Петроград һәм Мәскәү эшчеләре үрнәгендә 1917 елның язында ук барлыкка килгән. Шәһит Әхмәдиев тарафыннан төзелгән «Приказчиклар союзы» Казандагы әнә шундый оешмаларның берсе була. Бу оешма Мөселман социалистлар комитеты йогынтысында эшчеләрнең экономик һәм политик таләпләрен үтәү өчен көрәш алып бара. «Приказчиклар союзы»ның 27 майда булган утырышында, мәсәлән, бай сәүдәгәрләрдән С. Бәхтиев, С. Мусин, С. Садыйков, В. Насыйров һәм Г. Бәхтиевләр эше карала. Ә үзенең икенче бер утырышында союз сәүдә хезмәткәрләренә эш хакын 50—100 процентка күтәрү турында карар кабул итә. Бу карарга буйсынмаган байлардан Хөсәен Таһиров эше югары органнарга тапшырыла. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, башта мөселман эшчеләренең генә оешмасы булган «Приказчиклар союзы» Октябрь революциясе алдыннан интернациональ оешмага әйләнә. Әнә шундый фактлар китереп, автор бу бүлектә Казан шәһәрендә генә түгел, ә бөтен Урта Идел буендагы фабрика-завод комитетлары эшчәнлеген шактый тулы күз алдына китереп бастыра.

Билгеле булганча, Бөек Октябрь социалистик революциясе үсешенә илебезнең төрле урыннарындагы революцион вакыйгаларның нинди йогынты ясавы безнең фәндә әле ныклап ачыкланып, өйрәнелеп бетмәгән. Әнә шуңа күрә «Вакытлы хөкүмәтнең җирле органнары кризисы» дип аталган II бүлектә авторның, совет тарихчыларыннан беренчеләрдән булып, Вакытлы хөкүмәтнең җирле органнарының «искечә идарә итә алмауларын» тикшерергә алынуы бездә зур кызыксыну уята. Автор хезмәтенең бу бүлегенә дә бай фактик материал туплаган. Ә бу материаллар үз чиратында авторга алган темасы тирән һәм тулы итеп яктыртырга мөмкинлек биргәннәр. Бүлектә китерелгән һәрбер факт Вакытлы хөкүмәт тарафыннан урыннарда төзелгән органнарның үз вазифаларын

үтәргә бөтенләй сәләтсез, көчсез булуын күрсәтеп тора. Мәсәлән, бу чорда өязләрдә, кечкенә шәһәрләрдә Вакытлы хөкүмәт комиссарларының бик еш алышынулары гадәти хәлгә әверелгән. Казан губернасының Чабаксар шәһәрендә дүрт ай эчендә генә дә дүрт комиссар алышынган. Ә Лаеш өязендә өч ай буе урын өчен көрәш барган һәм Октябрь революциясенә кадәр биредә ныклы власть булмаган. Күп урыннарда исә халык үзенә ошамаган, үз интересларын үтәүдән баш тарткан идарә органнарын я бөтенләй тараткан, яки аңа буйсынмаган. Шундый хәлләрнең берсе Казан өязенең Кукмара волостенда була. Анда волость крестьяннары азык-төлек һәм җир комитетларын бетерергә карар чыгаралар, сходкаларыннан өяз комиссарын һәм секретарен куып җибәрәләр. Моңа охшаш хәлләр солдатлар арасында да була. Мәсәлән, Казан хәрби округының штаб начальнигы Караулов һәм шәһәр коменданты Григорьев «искечә идарә итә алмауларын» үзләре үк танырга мәҗбүр булганнар.

Күп милләтле Урта Идел буенда халыкларның социаль көрәше милли азатлык хәрәкәте белән бергә һәм бер-берсеннән аерылгысыз булып барды. Китапның соңгы өченче бүлеге әнә шушы проблеманы өйрәнүгә багышланган. Биредә укучы Урта Идел буендагы милли-азатлык хәрәкәте һәм аның кайбер үзенчәлекләре турында кызыклы фактлар, фикерләр таба ала. Татарларның милли-азатлык хәрәкәте мәсьәләләренә кагылып, автор аны өч агымга — милли буржуазия хәрәкәтенә, революцион-демократлар хәрәкәтенә һәм пролетариат хәрәкәтенә бүлеп карый. Бүлектә Мөселман социалистлар комитетының эшчәнлеге киң яктыртыла. Аның җитәкчеләреннән М. Вахитов, Г. Сәйфетдинов, Ш. Әхмәдиев, Ә. Мөхетдиноваларның бу чордагы революцион хәрәкәттә зур роль уйнаганлыклары күрсәтелә.

Әнә шундый кызыклы фактларга бай китап зур игътибар белән укыла. Аның белән танышкач, безгә 1917 елның июль— октябрь айларында Урта Идел буендагы революцион күтәрелешнең нинди шартларда барганы ачык аңлашыла.

Ләкин шушы файдалы һәм кирәкле хезмәтнең кайбер кимчелекләрен дә күрсәтеп үтми булмый. Милли хәрби частьлар турында сөйләгәндә, автор аларны кораллы восстаниегә кадәр «революцион оборончылык» һәм милләтчелек позициясендә тордылар дип күрсәтә (128 бит). Бу тезиска, әлбәттә, ачыклык кертү кирәк. Шулай ук икенче урында да (135 бит) автор «II Бөтенроссия мөселман съездының сул фракциясе кечле оешма тәэседе» дип кенә күрсәтеп үтә. Аннан соң хезмәттә телгә алынган кайбер фамилияләрдә дә төгәлсезлекләр очрый. Китапның аз тираж белән чыгуы шулай ук күңелдә канәгатьсезлек хисе калдыра.

Әмма ни генә булмасын, Р. Вәлиевнең бу китабы Бөек Октябрь социалистик революциясе турындагы хезмәтләр арасында үзенең тиешле урынын алыр дип ышанабыз.

**М. МӨЛЕКОВ,**
тарих фәннәре кандидаты.

# МИШӘРЛӘР ТУРЫНДА ЯҢА ХЕЗМӘТ

Мәскәүнең «Наука» нәшриятында мишәрләр турында яңа тарихи-этнографик хезмәт басылып чыкты. Ул «Татарлар-мишәрләр» дип атала. Авторы — Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының өлкән гыйльми эшчесе Рәмзия Мөхәммәдова.

Мәгълүм булганча, мишәрләр — Идел буе татарларының зур бер этник группасы. Аларның гомуми саны бер миллионга якын. Мишәрләрнең күп өлеше Мордва АССРда, Горький, Рязань, Пенза, Тамбов, Ульяновск, Куйбышев, Саратов өлкәләрендә, Татарстанның Буа, Чүпрәле, Чистай, Аксубай районнарында яши. Аларны шулай ук Чувашстанда һәм Башкортстанның кайбер районнарында очратырга мөмкин.

Р. Мөхәммәдова хезмәтендә сүз башлыча Идел буе мишәрләре, тагын да төгәлрәк итеп әйткәндә, Урта Иделнең уң ягында яшәгән мишәрләр турында гына бара. Хезмәт XIX йөзнең икенче яртысында һәм XX йөзнең башларында әлеге төбәктә яшәгән мишәрләрнең материаль һәм рухи

культураларын өйрәнүгә багышланган. Авторның төп игътибары мишәрләрнең Казан татарлары белән булган культура һәм этник бәйләнешләрен өйрәнүгә юнәлтелгән.

Рухи культураларындагы һәм тормыш-көнкүрешләрендәге аерымлыкларыннан чыгып, галим мишәрләрне 8 төркемгә бүлә (Сергач, Карсун, Ләмбер, Инсар, Темников, Керенск, Кузнецк һәм Буа мишәрләре). Алга таба һәр төркемнең гореф-гадәтләренә һәм йолаларына, йорт-җирләренә, кием-салымнарына һәм аш-суларына туктала, мишәрләрнең материаль һәм рухи культураларына хас күп кенә үзенчәлекле якларны аңлата. Китап җыйнак кына керештән, төрлесе төрле зурлыктагы дүрт бүлектән тора.

Керештә мишәрләр хакындагы хезмәтләргә тәпле күзәтү ясала. Автор моңарчы язылган хезмәтләрнең көчле һәм көчсез якларын билгеләп үтә, аларда очраган тенденциоз карашларны фаш итә. Шунда ук ул мишәрләрнең этногенезына бәйле мәсьәләләргә туктала. Билгеле булганча, фәндә мишәрләрнең килеп чыгышы хакында капма-каршы карашлар яшәп килә. Берәүләр мишәрләрнең килеп чыгышын фин халыкларына китереп бәйли, икенче бер галимнәр мадьярларга, өченчеләре буртасларга бәйләп аңлата. Соңгы елларда тупланган тел материалларына, антропология, этнография, археология материалларына таянып, Р. Мөхәммәдова әлеге карашларның нигезсез булуын дәлилли.

«Соңгы елларда,— дип яза ул,— галимнәр тарафыннан мишәрләрнең теле, антропологиясе буенча шактый материал тупланды, шулай ук яңа археологик материаллар табылды, болар һәммәсе аларның этногенезы турындагы мәсьәләне яңача куярга мөмкинлек бирә. Әлеге тикшеренүләр мишәрләрнең телләре, антропологик типлары буенча да, шулай ук материаль һәм рухи культуралары буенча да барыннан да бигрәк Казан татарларына якын торганлыкларын күрсәтәләр» (13—14 битләр). Ләкин мәсьәләнең икенче ягын да онытмаска кирәк, ди автор. Мишәрләр элек-электән Урта Иделдәге башка халыклар белән дә якыннан аралашып яшәгәннәр. Бу нәрсә аларның тормыш-көнкүрешенә, гореф-гадәтләренә булсын, үз эзен салмый калмаган, билгеле.

Хезмәтнең беренче бүлегендә без XIX йөзнең беренче яртысында һәм XX йөзнең башларында мишәрләрдәге игенчелек эше белән танышабыз. Ләкин чынлыкта бүлекнең хронологик чикләре XIX йөзнең икенче яртысы, XX йөзнең башлары белән генә чикләнми. Мишәрләрдәге крестьян хуҗалыклары турында сөйләгәндә, автор әле ерак үткәннәргә экскурс ясый, әле бүгенге көннәргә күз сала. Шундый ук киңлек китапның калган бүлекләре өчен дә хас.

Алга таба мишәрләрнең материаль культуралары тикшерелә. Мишәр авыллары һәм аларның йорт-җирләре, мишәрләрнең кием-салымнары һәм бизәнү әйберләре, аш-сулары һәм йорт-җир җиһазлары — хезмәттә аларның һәркайсына тулы һәм төпле характеристика бирелә. Автор, мишәрләрнең материаль культуралары хакында язганда, Казан татарларының материаль культураларына да туктала, мишәрләр һәм Казан татарлары, мишәрләр һәм руслар белән мордвалар арасындагы уртак якларны, шулай ук аерымлыкларны күрсәтеп бара. Хезмәтнең мишәрләрдәге гаилә тормышына, алардагы туй йолаларына багышланган бүлеге дә кызыксынып һәм мавыгып укыла.

Дүртенче бүлек мишәрләрнең рухи культурасын тикшерүгә багышланган. Сүз анда мишәрләрнең гореф-гадәтләре һәм йолалары, халык иҗаты һәм аның төрләре турында бара. Хезмәт күргәзмә материалларга гаять бай булуы белән аерылып тора. Һәр бүлектә диярлек карталар, диаграммалар, төрле схемалар, рәсемнәр һәм таблицалар бирелгән. Иң ахырдан, кушымта тесендә, мишәр авылларының зур исемлеге тәкъдим ителә. Күргәзмә материалларның күплеген хезмәтнең тагын бер уңай ягы дип билгеләп үтәсе килә.

**Әхмәт БУЛАТОВ.**

# КАМАЛ I



Атаклы татар совет артисты һәм режиссеры Камал I Россиядәге революцион күтәрелеш елларында сәхнәгә килгән һәм үзенең күп кырлы талантын туган халкына биргән кеше.

Габдулла Камал I 1893 елның сентябрендә Казан шәһәрендә мех эшләүче кустарь семьясында туа. Аның хезмәт юлына басуы бик яшьли — 1905 елгы революция елларында була.

Ә 1912 ел яшь егетне сәхнәгә алып килә. Бу елны аны Габдулла Кариев тәкъдиме һәм агасы Галиәсқәр Камал булышлыгы белән «Сәйяр» труппасына эшкә алалар. «Сәйяр» труппасында эшләү Камал I иҗатында якты бер чор булып тора. Анда ул үзенең беренче рольләрен башкарып, татар сәхнәсенә кызыклы һәм үзенчәлекле яңа артист килгәнлеген күрсәтә. Габдулла Камал I тарафыннан иҗат ителгән Йосыф (Фатих Әмирханның «Яшьләр»е), Вәли (Галиәсгар Камалның «Беренче театр»ы), президент (Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт»е), Дикой (А. Н. Островскийның «Яшенле яңгыр»ы) һәм башка күп кенә образлар тамашачы күңеленә онытылмаслык булып кереп урнашалар.

Үз юлын сәнгатьтә, театрда тапкан Камал I Бөек Октябрь социалистик революциясе һәм гражданнар сугышы елларында да яңа, бәхетле тормыш өчен көрәшүче халык белән бергә була. Ул елларда Камал I фронтлардагы театр бригадаларында эшли, һәм күчеп йөри-йөри Астраханьга барып чыга. Анда Камал I үзенең күптәнге танышы, большевик Касыйм Туйбахтин белән очраша. Касыйм Туйбахтин аны Гадәттән тыш комиссиядә эшләүгә күндерә. Ләкин Камал I гә бу эштә озак эшләргә туры килми — дошман пулясыннан яраланып, госпитальгә керә.

Аннан соңгы елларда Камал I не без Бохара, Хива, Фәргәнә кебек Урта Азия шәһәрләрендә күрәбез. Биредә ул труппа белән спектакльләр, концертлар куя. Ләкин гражданнар сугышында һәм Астрахань шәһәрендә алган яралар Камал I гә күчмә тормышта йөрү мөмкинлеген калдырмый — ул тору өчен Ташкентка килә. Биредә ул Казан, Уфа, Оренбург шәһәрләреннән килгән бик күп артистлар белән бер труппага берләшә һәм алар Ташкент сәхнәсендә М. Фәйзи, К. Тинчурин һ. б.ларның әсәрләрен куя башлыйлар. Соңыннан Габдулла Камал I Төркстан ЦИКы каршындагы хәрби гарнизонның драма түгәрәгө җитәкчесе итеп билгеләнә. Төрле милләт артистларыннан торган бу түгәрәк соңга таба Ташкентның Зур театры булып үсеп җитә, ә аның баш режиссеры итеп Камал I куела. Үзбәк театрына нигез салучыларның берсе Хәмзә Хәкимзадә ул елларда Камал I нең сәхнедәш дусты була.

Камал I Оренбург һәм Ашхабад театрларында да эшли.

1932 елда Камал I Казанга кайта. Ләкин туган шәһәрендә ул озак эшли алмый — 1933 елның 25 апрелендә авыру аны тормыштан алып китә.

Камал I киң диапазонлы артист, режиссер һәм педагог иде. Үзенең зур таланты, көчле оештыру сәләте белән ул татар, башкорт, үзбәк, төркмән һәм әзербәйҗан халыкларының милли театрларын булдыруга һәм үстерүгә зур өлеш кертте. Бүген, милли театрларыбыз һәм сәнгатебез чәчәк аткан чорда, без артист һәм режиссер Камал I нең исемен зур горурлык белән искә алабыз.

## Җәүдәт Дәрзаманов

### Яңа чана яңа шул

Яңа чана
Яңа шул,
Җилдәй җитез
Чаба шул.
Шуа, буран
Туздыра,
Башкалардан
Уздыра.
Шатлыгыма
Чама юк —
Моның кебек
Чана юк!
Очтым бер көн
Үзәннән,
Утлар чыкты
Күземнән.
Яңа чана
Яңа шул,
Салса, «җайлы»
Сала шул...

### Камыр аяк

Киеп алдым
Тимераяк.
Тик дерелди
Минем аяк.
Бозга чыгып
Басу белән
Барып төштем
Башым белән.
Бер килсә, гел
Килеп тора.
Бер кыз үртәп
Көлеп тора:
— Тыңламый шул
Тимераяк,
Булсаң әгәр
Камыраяк!

## Аюым

Йом күзеңне,
Аюым,
Кетмә кояш
Баюын.
Әлли-бәү,
Бәлли-бәү,
Йом күзеңне,
Аюым.

Һаман ачык
Күзләрең,
Ник йоммыйсың
Үзләрен?
Әлли-бәү,
Бәлли-бәү,
Һаман ачык
Күзләрең.

Тыңламыйсың
Сүзләрем,
Күзлисең
Күк йөзләрен.
Җырлый-җырлый
Әлли-бәү,
Йомылган үз
Күзләрем.

## Балык тотты

Кармакларны алабыз да
Салабыз яңабаштан.
Кызык булмас, колак каксаң
Килеп капкан балыктан...

Тарта бугай! Калкавычым
Вак дулкыннар тарата.
Алмый торам — балык халкы
Алдашырга ярата.

Инде тартам — алып булмый,
Балык зу-уур, мин кечкенә.
Ярга селтәп атар идем,
Җитеп бетми көч кенә.

Вәт балык бу! Шундый тартты,
Куйдым да бер чайкалып,
Аяк таеп, дөмберт суга —
Үземне тотты балык.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ДУСЛЫГЫБЫЗ НЫГЫЙ

Казан дәүләт консерваториясенең актлар залында милли әдәбият һәм сәнгатьләрнең үзара йогынтысы һәм бер-берсен баетуы проблемаларына багышланган фәнни теоретик конференция уздырылды.

Конференциягә СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият, тарих институты галимнәре һәм Татарстанның иҗат оешмаларыннан күп санлы вәкилләр катнашты.

Конференциядә барысы илледән артык доклад тыңланды. 23 докладчы күрше автономияле республикадан килде.

Конференциягә Мәскәү, Ленинград, Горький, Таллин галимнәре катнашты.

Әдәбият галиме С. Сафуанов (Уфа) СССРның төрки халыклары әдәбиятларының үзара бәйләнеше, театр белгече Л. Атанова (Уфа) совет музыка культурасының башкорт композиторлары иҗатына йогынтысы, филология фәннәре кандидаты Ф. Ермаков (Ижевск) удмурт әдәбиятының Идел буе төрки халыклары белән бәйләнеше; М. Георгина (Йошкар-Ола) бүгенге мари театрында традицияләр һәм новаторлык, Е. Владимиров (Чабаксар) Идел буе халыклары әдәбиятлары үсешендәге кайбер уртак сыйфатлар, К. Ванюшкин (Чабаксар) Чуваш театрының Идел буе халыклары сәхнә сәнгате белән иҗади бәйләнешләре турында сөйләде.

Ленинградтан Л. Скафтымовның «Музыкада миллилек һәм интернациональлек» дигән темага доклады аеруча кызыклы булды.

Казаннан философ һәм тарихчылар М. Булатов, Я. Абдуллин, К. Гыйззәтов, М. Сәйдәшева, әдәбият галимнәре М. Гайнуллин, И. Нигъмәтуллина, тәнкыйтьче Р. Мостафин, музыка белгечләре М. Нигъмәтҗанов, Ч. Бахтиярова, З. Сәйдәшева, театр тәнкыйтьчеләре И. Илялова, Х. Гобәйдуллин, татар архитектурасын өйрәнүче галим С. Айдаров, сынлы сәнгать белгечләре А. Файнберг, М. Саттарова һәм башкалар актуаль темаларга чыгышлар ясадылар.

Конференция Идел һәм Урал буе автономияле республикалары галимнәре һәм иҗат әшлекләләре арасындагы багланышларны тагын да ныгытты.

## ИГЪТИБАР ҮЗӘГЕНДӘ — КамАЗ

* * *

Хор өчен язылган патриотик җырлар һәм тынлы музыка әсәрләренә үткәрелгән бөтен Союз конкурсында КамАЗга багышланган «Яшьлек каласы» исемле җыр өчен ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Тукай премиясе лауреаты композитор Ә. Бакиров һәм шагыйрә С. Сөләйманова өченче премиягә лаек булдылар.

* * *

Июль аенда музыка белгечләре КамАЗ темасына иҗат ителгән яңа җырлар тыңладылар. Композиторлар Ф. Әхмәтовның «Чаллыдан хат» (М. Газар сүзләре), М. Латыйповның «КамАЗ — туган йортыбыз» (М. Хөсәен сүзләре), Ф. Әхмәтовның пионерлар өчен язылган җырлары, А. Монасыйповның «Адымнар» балладасы аеруча уңышлы дип табылды.

* * *

Казан телевидениесе әдәби-драматик тапшырулар редакциясе тарафыннан оештырылып килгән «Эшче даны» дигән рубрикадан чираттагы тапшыруны күрсәтте. Бу тапшыруда язучы Б. Камаловның «Урамнар киңәя» повесте һәм журналист Җ. Кәлимуллин белән бергәләп язылган «Дуслык таулар кичерә» исемле очерклар җыентыгы игътибар үзәгендә булды. Тапшыруга Б. Камалов үзе дә катнашты һәм очеркларның геройлары КамАЗда яшәүләрен, эшләүләрен әйтте. Тамашачыларга КамАЗ төзелешеннән кинокадрлар, Б. Камалов һәм телевидениенең өлкән редакторы Э. Гаделев арасында барган кызыклы әңгәмә күрсәтелде.

* * *

Актерлар йортында Казан театрлары артистларының автозавод төзүчеләр белән очрашуы булды. Килгән көнне Чаллы төзүчеләре Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында «Чит кеше» (И. Дворецкий) исемле спектакль карадылар. Аннары спектакльдә катнашкан артистлар белән очрашу үткәрелде.

Икенче көнне иртән кунакларны В. Качалов исемендәге рус драма театры артистлары кабул итте. Төзүчеләр В. Качаловның музей-бүлмәсе белән таныштылар һәм артистлар белән бүгенге театр сәнгате турында фикер алыштылар.

Шул ук көнне Актерлар йортында Чаллы төзүчеләренең Татарстан сәнгать осталары белән очрашуы булды. М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры директоры М. Боголюбов, Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры баш режиссеры М. Сәлимҗанов, В. Качалов исе-

мендәге рус драма театры артисты Б. Петров камАЗчыларга үз коллективларының иҗат планнары турында сөйләделәр. Автозавод төзүчеләр ялкынланып яңа кала салулары, гигант завод торгызулары, төзелештә яңа кеше тәрбияләнүе хакындагы фикерләре белән уртаклаштылар.

Очрашуны бөтен Россия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге председателе Р. Жиһаншина алып барды.

Соңыннан кунаклар хөрмәтенә Казан театрлары артистлары көче белән концерт бирелде. Сәнгать осталары һәм кунаклар истәлек-бүләкләр алыштылар.

## «ЗА РОДИНУ»ГА 50 ЯШЬ

Идел буе хәрби округы газетасы «За Родину» чыга башлауга 50 ел тулды. Шушы олы бәйрәм уңае белән Куйбышев шәһәрендә тантаналы җыелыш үткәрелде. Җыелышка Идел буе республикалары һәм өлкәләренең төрле иҗат оешмаларыннан күп санлы вәкилләр килгән иде.

Татарстан язучылары исеменнән «За Родину» газетасы хезмәткәрләрен һәм авторларын Татарстан язучылар союзының җаваплы секретаре, шагыйрь Р. Харис котлады, редакциягә язучылар бүләк итеп җибәргән китапларны тапшырды.

## ПУШКИН БӘЙРӘМЕ

Июнь аенда илебезнең төрле урыннарында Пушкин истәлегенә багышланган шигырь бәйрәмнәре булып узды. Бөтен Союз тантанасы быел Болдинога да килде. Бөек шагыйрьнең анда бернинә мәртәбә булуы, дөнья әдәбияты җәүһәрләренә керган даһи әсәрләр иҗат итүе һәркемгә мәгълүм.

Болдино районы культура сараенда үткәрелгән әдәби кичәдә Мәскәү шагыйрьләреннән М. Алигер, Н. Старшинов, профессор В. Урнов, Чувашстаннан С. Шавлы, Мари АССРдан М. Майн һәм Горький өлкәсе шагыйрьләре чыгыш ясадылар.

Пушкин бәйрәменә Татарстаннан шагыйрь Ә. Маликов катнашты. Кичәдә ул «Татар әдәбияты, Тукай һәм Пушкин» дигән темага чыгыш ясады. Пушкин шигыренең татарча тәрҗемәсен һәм рус телендә үз шигырьләрен укыды.

* * *

Михайловскийга Пушкин бәйрәменә Татарстаннан шагыйрь һәм прозаик Ә. Баянов барды. Аның бу олы, традицион бәйрәмдә укылган шигырьләре халыклар һәм әдәбиятлар дуслыгына багышланган иде.

## КУЛЬТУРА ИНСТИТУТЫНДА

Казан культура институтының беренче чыгарылышы булды. Яшь кадрлар төрле культура сарайларына, авыл клубларына таралдылар. Алар житекчелегендә һәм алар катнашында дистәләгән спектакльләр куелды да инде.

Чыгарылыш курсының сәнгать эшләре житәкчесе, сәнгать фәннәре кандидаты Х. Кумысников иде.

* * *

Өченче курс татар группасы (сәнгать эшләре житәкчесе — режиссер, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Тукай премиясе лауреаты Ш. Сарымсаков, режиссер-педагог — Р. Батуллин) диплом эше итеп Ш. Хөсәеновның «Зөбәйдә — адәм баласы» исемле спектаклен күрсәтте. Спектакль Саба районында һәм Казан культура сарайларында зур уңыш белән барды.

* * *

Режиссура бүлегенең II курс студентлары актерлык осталыгы һәм режиссура буенча имтихан тапшырдылар.

Тамашачыларга Италия драматургы К. Гоццининың «Зөбәйдә» дигән әкият-пьесасыннан өзек, Т. Гыйззәтнең «Шомлы көннәр» драмасыннан бер фрагмент, А. Чеховның «Тәкъдим» дигән бер пәрдәлек пьесасы нигезендә эшләнгән спектакле күрсәтелде.

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Р. Тумашев, режиссер-педагог Р. Батуллин житәкчелегендәге бу группа студентларының бишесе югары бәя, дүртесе яхшы бәя алды.

## ФАЙДАЛЫ ХЕЗМӘТ

Мәскәүдә, СССР Фәннәр академиясенең СССР тарихы институтында «Казанның барлыкка килү вакыты» дигән темага фәнни доклад белән СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты гыйльми сотрудникгы, тарих фәннәре кандидаты Р. Фәхретдинов чыгыш ясады. Докладта күтәрелгән мәсьәләләрдән Казанның тарихи датасы, аның материаль культурасының болгар культурасына нигезләнүе, Казан шәһәренең туу чорын Иске Казаннан исәпләргә кирәклек турындагы фикерләр галимнәр тарафыннан дөрес дип табылды. Фикер алышуларда чыгыш ясаган тарихчылар докладта тәкъдим ителгән Казан датасын билгеләүнең кирәклеген һәм әһәмиятен билгеләп үттеләр. Илебезнең зур экономик, фән һәм культура үзәге булган Казанның борынгы тарихын тикшерүнең, бигрәк тә киң планда археологик эзләнүләр алып баруның зарурлыгына басым ясадылар. Казан һәм Татарстан тарихы буенча чыганаклар базасын баету файдасына эшлекле киңәшләр бирделәр.

## ЙӨЗ КОНЦЕРТ

Татарстанның халык артисткасы Әлфия Афзалова житәкчелегендә эстрада бригадасы Казагыстан, Төркмәнстан, Кыргызстан, Үзбәкстан, Таҗикстан һәм башка республикаларда йөздән артык концерт бирде.

Татарстан артистларын һәркайда ачык

йөз, якты чырай белән каршы алдылар. Бу концертларда Ә. Афзалова яңа җырлары белән чыкты.

## УФА СӘХНӘСЕНДӘ

Уфа тамашачылары Х. Вахитның Салават дәүләт башкорт драма театры тарафыннан әзерләнеп сәхнәгә куелган «Мәхәббәтең чын булса» дигән драмасын карадылар.

РСФСРның атказанган артисты В. Галимов әлеге спектакльне чын сәнгать югарылыгында эшләгән.

## ЯШЬ ШАГЫЙРЬЛӘР ФЕСТИВАЛЕ

Горькийда һәм Горький өлкәсенең Кстово шәһәрендә Идел буе республикаларының яшь шагыйрьләре фестивале булды. Шагыйрьләр заводларда, төзелешләрдә эшчеләр һәм төзүчеләр белән очраштылар. Аларның чыгышлары Горький телевидениесе аша күрсәтелде.

Татарстаннан фестивальдә шагыйрь Зөлфәт катнашты.

## ӘДӘБИ АТНАЛЫКЛАР, ОЧРАШУЛАР

Традицион әдәбият бәйрәмнәре июнь аенда Чирмешән һәм Буа районнарында үткәрелде.

Чирмешән районында язучылар һәм артистлар ике группага бүленеп йөрделәр. Беренче группада шагыйрьләр З. Нури, Г. Афзал, прозаик Х. Сарьян, Ш. Бикчурин, М. Маликова, Татарстанның атказанган артисткасы Җ. Сәлахова, баянчы Р. Лотфуллин, ә икенче группада шагыйрьләр Г. Рәхим, Роберт Әхмәтҗанов, Х. Халиков, шагыйрь һәм прозаик Ә. Баянов, Татарстанның атказанган артисты Ф. Юсупов бар иде.

Язучылар һәм артистлар колхоз клубларында, культура йортларында, җәйләүләрдә, мәктәпләрдә чыгышлар ясадылар. Район халкын бүгенге татар әдәбиятындагы һәм сәнгатендәге яңалыклар белән таныштырдылар.

* * *

Буа районында уздырылган әдәби атналыклар чуваш язучылары белән бергәләп оештырылган иде. Анда Чувашстаннан Н. Дедушкин, А. Калган, А. Воробьев, А. Галкин, В. Ухли, Ф. Агивер, Татарстаннан Г. Минский, Г. Ахунов, Н. Дәүли, Р. Харис, Т. Камалиев, филология фәннәре кандидаты, журналист һәм язучы К. Петров, җырчы Җ. Сәлахова, композитор М. Макаров катнашты.

* * *

Минзәлә районында җирле Советларга сайлаулар уңае белән уздырылган әдәби-музыкаль кичәләрдә драматург С. Шәкүров, язучы К. Тимбикова, Татарстанның атказанган артисты С. Йосыпов, артист М. Шиһапов, яшь җырчы Р. Гайнуллина катнаштылар.

* * *

Г. Тукай премиясе лауреаты шагыйрь Ш. Галиев, драматурглар һәм прозаиклар А. Гыйләҗев, Т. Миңнуллин, Татарстанның атказанган артисты С. Йосыпов, яшь җырчылар Р. Гайнуллина, К. Хәйретдинова, баянчы И. Җаббаров Зәй районында иҗади очрашуларда катнаштылар. «Ямьле Зәй буйларында» дип аталган программа белән алар районның күп кенә колхозларында булдылар, клубларда, культура йортларында игенчеләр, терлекчеләр, авыл интеллигенциясе белән очраштылар, һәркайда язучыларның китапларын сату оештырылды.

* * *

Язучылар М. Мәһдиев белән В. Нуруллин берничә көн Пермь шәһәрендә булып, эшчеләр алдында чыгышлар ясап кайттылар.

«Тугандаш әдәбиятлар дуслыгы» дигән девиз белән уза торган мондый очрашулар шәһәрдә инде күптән традициягә кергән. Пермь шагыйрьләре-тәрҗемәчеләре В. Радкевич, А. Домнин, Н. Домовитов һәм башкалар шигырь сөючеләрне әледән-әле татар шагыйрьләре иҗаты белән таныштырып торалар.

Үз чиратларында Пермь язучылары да Татарстанга еш килә. Әле күптән түгел генә шагыйрь А. Домнин Казан хезмәт ияләре белән очрашты.

## ШАГЫЙРЬЛӘР СЕКЦИЯСЕ УТЫРЫШЫ

Чираттагы утырышта яшь шагыйрь Әхмәт Рәшитов иҗади тикшерелде.

Шигырь сөючеләргә Ә. Рәшитов «Шәҗәрә», «Авылдашлар» поэмалары, күп санлы патетик һәм лирик шигырьләре, «Беренче мәхәббәт», «Зәңгәр күлмәк» кебек популяр җыр текстлары белән яхшы таныш.

Утырышта Ә. Рәшитов иҗаты хакында доклад белән өлкән шагыйрь Ә. Исхак чыкты. Ул, яшь шагыйрьнең иҗаты инде җитлеккән, ләкин Ә. Рәшитов һаман эзләнә, яңадан-яңа шигъри образлар, сурәтләр таба, гомумән, поэзиягә чын шагыйрьләрчә җитди карый, дигән фикер әйтте.

Ә. Рәшитов иҗаты һәм аның «Хатирә» дигән соңгы җыентыгы турында Х. Туфан, Ә. Баянов, Роберт Әхмәтҗанов, Р. Гатауллин, Т. Камалиев, З. Насыйбуллин һәм башкалар сөйләде.

Ә. Рәшитовның шигырьләре нигездә бүгенге поэзия таләпләренә җавап бирерлек дип табылды, һәм утырыш яшь шагыйрьне СССР Язучылар союзына тәкъдим итү турында карар чыгарды.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

* * *

Әлмәт бүлеге язучылары җыелышында Лениногорск әдәби берләшмәсе җитәкчесе А. Хәсәнов, Әлмәт һәм Баулы әдәбият-иҗат түгәрәкләре җитәкчеләре С. Сөләйманова,

А. Малов иптәшләр отчет докладлары белән чыктылар.

Чыгыш ясаучылар Ә. Маликов, М. Хәсәнов, Р. Төхфәтуллин, Г. Афзал, Ю. Әминов яшьләр белән эшләү буенча сизелерлек уңышлар барлыгын әйттеләр һәм әдәби түгәрәкләрнең эшчәнлеген тагын да көчәйтергә кирәклеге турында сөйләделәр.

* * *

Әлмәт район культура йорты каршындагы агитбригада репертуарына нефть якларында яшәүче шагыйрьләрнең күп кенә шигырьләре, җырлары кертелгән.

Драматург С. Кальметов агитбригада составында «Зәй» колхозы клубында чыгыш ясады. Колхозчыларны ул татар язучыларының яңа әсәрләре белән таныштырды, үзенең кечкенә юморескаларын укыды.

* * *

Әлмәт шәһәрендә журналистлар университеты яшәп килә. Аның эшендә Әлмәт язучылары да актив катнашалар. Журналистлар университетының чираттагы занятиесендә шагыйрә С. Сөләйманова чыгыш ясады.

* * *

Әлмәттәге әдәбият-иҗат түгәрәгенең чираттагы утырышында X класс укучысы К. Кәримованың «Наил» исемле поэмасы тикшерелде. Чыгыш сөйләүчеләрдән түгәрәк җитәкчесе С. Сөләйманова, яшь шагыйрь И. Әхсәнов һәм түгәрәк членнары әсәрне яңабаштан эшләү, камилләштерү турында файдалы киңәшләр әйттеләр.

* * *

Азнакайда үткәрелгән чираттагы утырыш язучы М. Хәсәновның «Саф җилләр» романының икенче китабын тикшерде.

Утырышта романның уңышлы һәм кимчелекле яклары әйтелде, авторга файдалы киңәшләр бирелде.

## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАРЫБЫЗ!

Татарстан язучыларының яңа әсәрләре белән иң башлап танышырга уйласагыз, «Казан утлары» журналына язылыгыз.

Тугызынчы бишьеллыкның гигант төзелешләре, республикабызның хезмәт батырлары турында күбрәк белергә теләсәгез, «Казан утлары» журналын алдырыгыз.

Республикабыз галимнәре, композиторлары, артистлар, художниклар тормышын һәм аларның иҗат юлларын да сез «Казан утлары»ннан укып белерсез.

Халкыбызның тарихи сәхифәләре белән кызыксынган укучылар да журналдан канәгать калырлар.

«Казан утлары» — күләме белән зур, эчтәлеге белән бай журнал.

Аңа Советлар Союзының барлык почта бүлекләрендә языларга мөмкин. Язылган вакытта журналның индексын искә төшерергә онытмагыз. Аның индексы — 73210. Ул сезнең эшегезне җиңеләйтер.

1974 ел өчен «Казан утлары» журналына язылып калырга ашыгыгыз. Язылу бәясе бер елга 6 сум.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210